ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

3.2006





Фатих Әмирхан
1886—1926

# Казан утлары
# Qazan utları

2006

3

(1001)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөсния́р**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Әхмәт Рәшит, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(8432) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

Рухи галәмдә яшәргә. Президент Минтимер ШӘЙМИЕВ белән шагыйрь Равил ФӘЙЗУЛЛИН әңгәмәсе ..... 5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Мөхәммәт МИРЗА. Робагыйлар ..... 21
Марат ӘМИРХАНОВ. И, кылган догам минем. *Повесть* ..... 26
Клара БУЛАТОВА. Яңа шигырьләр ..... 51
Заһид МӘХМҮДИ. Һәркемнең үз юлы. *Роман* ..... 55
Рәдиф ГАТАШ. Гомер сәхифәләре. *Шигырьләр* ..... 90
Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Төрмәче. *Хикәя* ..... 95
Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА. Яраланган бер кош сыман. *Шигырьләр* ..... 99

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Эльмира ҖӘЛИЛОВА. Түгелер дә йөрәк... *Шигырьләр* ..... 102
Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Ә очасы килә... *Шигырьләр* ..... 104

**ХӘТЕР**

Рәйсә ЮСУПОВА. Ак сагыш иясе. *Очерк-хатирә* ..... 106
Розалина НУРУЛЛИНА. "Бер-берегезгә гыйззәт кыйлыңыз" ..... 177

**ОСТАХАНӘ**

Рашат НИЗАМИ. Каләм алдым кулыма... *Эссе* ..... 124

**КЛАРА БУЛАТОВАГА 70 ЯШЬ**

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Шигърият һәм туган тел хадимәсе ..... 141

**ӘХМӘТ РӘШИТОВКА 70 ЯШЬ**

Зиннур МАНСУРОВ. "Мөмкин" белән "түгел" арасы ..... 151

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге ..... 166
"Татар энциклопедиясе" битләреннән ..... 175

**ШӘХЕСЛӘР**

Александр ФИЛИППОВ. Гөргөри ..... 160
Нурулла ГАРИФ. Таныш тавышлы милләттәш ..... 171

**АК ҖИЛКӘН**

Илшат СӘЙФУЛЛИН. Үсмерләр өчен шаян хикәяләр ..... 184
Котлыйбыз! ..... 187
"Казан утлары" архивыннан ..... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

Интервью народного поэта Равиля ФАЙЗУЛЛИНА с Президентом РТ Минтимером ШАЙМИЕВЫМ.
"Проза и поэзия": роман З. МАХМУДИ "У каждого своя дорога", повесть М. АМИРХАНОВА "Моя молитва" (продолжение), рассказ Р. ГИЗЗАТУЛЛИНА "Тюремщик"; стихи М. МИРЗЫ, К. БУЛАТОВОЙ, Р. ГАТАША, Ш. ЗИГАНГИРОВОЙ.
"Творчество молодых": стихи Э. ДЖАЛИЛОВОЙ, Л. ГИБАДУЛЛИНОЙ.
"Память": очерк Р. ЮСУПОВОЙ "Светлая память", статья Н. ГАРИФА о соотечественнике А. ИБРАГИМОВЕ. Эссе Р. НИЗАМИ о творческой лаборатории писателя (окончание).
"Наши юбиляры": статья Х. МИННЕГУЛОВА к 70 летию К. БУЛАТОВОЙ и статья З. МАНСУРОВА к 70 летию А. РАШИТА; статья А. ФИЛИППОВА о Г. РАХИМЕ.
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН "Словарь нации": "Страницы из татарской энциклопедии".
"Юмор-сатира": юмористические рассказы И. САФИУЛЛИНА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: народный поэт Равиль ФАЙЗУЛЛИН с Президентом РТ Минтимером ШАЙМИЕВЫМ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

Interview of National poet Ravil FAIZULLIN with the President of Tatarstan Republic Mintimer SHAIMIEV.
«Prose and poetry»: novel by Z. MAHMUDI «Everyone has his way», story by M. AMIRHANOV «My pray» (continuation), story by R. GIZZATULLIN «Jailer»; verses by M. MIRZA, K. BULATOVA, R. GATASH, SH. ZIGANGIROVA.
«Creativity of youth»: verses by E. DJALILOVA, L. GIBADULLINA.
«Memory»: sketch by R. YUSUPOVA «Light memory», article by N. GARIF about compatriot A. IBRAGIMOV. Essay by R. NIZAMI about creative laboratory of writer (ending).
«Our jubilee celebrators»: article by H. MINNEGULOV to 70th anniversary of K. BULATOVA and article by Z. MANSUROV to 70th anniversary of A. RASHIT; article by A. PHILIPPOV about G. RAHIM.
«Science»: A. TIMERGALIN «Dictionary of nation»: «Pages from Tatar encyclopedia».
«Humour-satire»: comic stories by I. SAFIULLIN.
Dairy of social-cultural life.
On our covers: national poet Ravil FAIZULLIN with the President of Tatarstan Republic Mintimer SHAIMIEV.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 20.03.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3–162. Тираж 7011.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2006 ел.

# РУХИ ГАЛӘМДӘ ЯШӘРГӘ

ПРЕЗИДЕНТ МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ БЕЛӘН
ШАГЫЙРЬ РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН ӘҢГӘМӘСЕ

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: "Быел фәлән жанвар елы, быел фәләннеке" дип йөртүләр борынгыдан гадәткә кергән. Соңгы дәвердә, иҗтимагый төсмер биреп, Аналар елы, Сәламәтлек елы, Балалар елы кебек әйтүләр дә булды. Галәми фикер йөртсәң, еллар алай "тамгаланып" кына бер-берсеннән әллә ни аерылмыйлар. Фасыллар табигый рәвештә яңарып, алышынып тора. Кеше туа, үсә, картая... Яңа буыннар килә... Вакыт дигәннәре, бер нәрсәгә исе китми, ага да ага... Шулай да, 2006 елның Татарстанда Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителүе мине ихлас сөендерде. Димәк, быел әдәбият һәм сәнгатькә, гомумән, иҗатчыларга аерым бер игътибарлы караш булачак! Күпләребез шулай уйлый, уңай үзгәрешләргә өметләнә. Бу фәрман-указны ни өчен нәкъ менә шушы елга атап чыгарырга булдыгыз?**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Һәр яшәлгән ел—рух, иҗат һәм хезмәт елы, гомумкешелек хәзинәсенә өлеш кертү елы булырга тиештер ул. Цивилизацияне кеше акылы, кеше таланты казанышлары тәшкил итә ләбаса. Үткән тарихны без борынгылар калдырган гаҗәеп корылма-биналар, илаһи көйләр, бөек китаплар аша беләбез. "Кеше китә, жыры кала", диләр. "Гомерем минем моңлы бер жыр иде, үлемем дә яңгырар жыр булып",—дип язган Жәлил дә. Әнә шул Жыр дигән могжизага яшәү мәгънәсе сыйгандыр мөгаен.

Еллар бер-береннән әллә ни аерылмыйлар диюгез белән килешеп бетмим. Гомумән, һәркайсыбыз һәр киләсе елны үзенчә кабул итеп ала, һәр ел ниндидер вакыйгасы белән хәтергә уелып кала. Мәсәлән, 2000 елны үзенчәлекле ел түгел дип һич кенә дә әйтә алмыйбыз. Гасырларны гына түгел, меңьеллыкларны ялгаучы ел! Ата-бабаларыбыз, ата-аналарыбыз, күпмедер өлешендә без дә яшәгән бөтен бер гасырны тәмамлап, балаларыбыз, оныкларыбыз, аларның оныклары яшәячәк яңа гасырга һәм өченче меңьеллыкка аяк басу нәкъ менә безгә насыйп булды бит. Бу, әлбәттә, киләчәк хакында, кыласы гамәлләребез турында, тарихның шушы мизгелендә безгә зур җаваплылык салынуы турында уй-фикерләргә этәрә. Уйлы-гамьле кеше шуның белән яши дә инде. Менә 2005 елны алыйк: Казаныбызның 1000 еллык юбилей елын берничек тә гадәти ел дип булмый. 2005 елда без күпме язмышларга кагылган дәһшәтле Бөек Ватан сугышында миллионлаган кеше гомере бәрабәренә яуланган Жиңүнең 60 еллыгын да билгеләп үттек.

2006 елны Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итүнең дә үз хикмәте бар. Беренчедән, чыннан да, быел республика тормышында зур юбилейлар күп: Габдулла Тукайның тууына—120 ел, Муса Жәлилнең тууына—100 ел, Татар театрына нигез салынуга—100 ел... Натан Рахлин, Сара Садыйкова, Александр Ключарёвларның 100 еллыклары. Фатыйх Әмирхан, Нәҗип Жиһанов, Рөстәм Яхин, Габдулла Кариев, Хәлил Әбҗәлилов, Николай Фешин, Гали Ильясов кебек күренекле шәхесләребезнең юбилейлары. Нинель Юлтыева, Софья Гобәйдуллина өчен истәлекле ел бу. Сез мөхәррирлек иткән "Казан утлары" журналының 1000 нче саны чыгу... Әле болардан башка да истәлекле даталарыбыз күп. Әйтик, бу елны һичсүзсез Тукай елы дип атап булыр иде. Андый тәкъдимнәр дә булды. Әмма безнең Жәлилебез дә бар! Мондый бөек шәхесләребез булу — бәхетебез, алар рухи-мәдәни тормышыбызның алтын баганалары. Шуңа күрә мин 2006 елны Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан

итик дидем. Һәм барыбыз да җиңел сулап куйдык — бөтен теләкләрне вакыйгаларыбызны берләштерә торган вариант табылды.

Икенче сәбәбе шул: инде әйткәнемчә, узган ел без башкалабыз Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иттек. Без үзебезне дөньяга дус, тату, иҗтиһат итүче халык итеп күрсәтә алдык. Беләсез, бәйрәмгә дәрәҗәле кунаклар: хәзерге бәйсез дәүләтләр, элеккеге союздаш республикалар башлыклары, илебез төбәкләре җитәкчеләре, чит ил вәкилләре килде. Алар Казанны күреп хәйран калып киттеләр. Алай гынамы, эшләнгән эшләребезгә без үзебез дә шаккаттык. Булдырабыз икән бит!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: "Булдырабыз!" дип әйтү милли идеянең бер чагылышы инде ул.**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Әйе, рух ныклыгын күрсәтә ул. Без үз көчебезгә ышандык, бәйрәм көннәрендә барыбыз да горурлык хисе кичердек. Мин, әлбәттә, бервакытта да гел милли фикер генә юллап йөргән кеше түгел. Әмма Камал театрында куелган "Баскетболист" спектакле минем һич башымнан чыкмый. Хәтерлисездер, аның герое Сократ авыл җирендә, безгә "Уникс" командасын җыярга кирәк дип, авыл малайларын 167 сантиметрлы тактага салып үлчәп йөри, тәки җыя бит команда! Мондый команда белән җиңеп булмаслыгын аңлагач та, күңелен төшерми, безгә опера йолдызлары булырга кирәк дип, авылдашларыннан хор оештыра. Безнең халыкның, мөмкинлеге чикле булганда да, хыялы бар, рухы бар. Ә тарихта, мәгълүм булганча, омтылышлы, рухлы халыклар гына эз калдыра. Казанның 1000 еллыгын уздырганда без рухи күтәрелешкә ирештек һәм, менә шушы күтәрелешне саклап калган тәкъдирдә, безгә әдәбиятыбыз, сәнгатебез алдында торган мәсьәләләрне хәл итү җиңелрәк булыр кебек тоелды миңа. Сүз дә юк, икътисад үсәргә, төзелешләр дәвам итәргә, тормыш дәрәҗәсе күтәрелергә тиеш—болар безнең көндәлек эшебез. Дөресен генә әйткәндә, тормышта игътибарны рухи дөньядан читкә юнәлдерүче факторлар җитәрлек. Ә Казанның 1000 еллыгы исә безнең барыбызны да уртак рухи галәмгә җыйды. Һәм без алга таба да, үзебез дә сизмәстән, шушы галәмдә, иҗат атмосферасында яшәргә тиешбез. Моның өчен, әлеге унай мизгелне кулдан ычкындырмыйча, кешеләрне рухи хәзинәләргә күбрәк җәлеп итәргә, моның яңадан-яңа формаларын уйлап табарга кирәк. Шөкер, безнең халыкта әдәбиятка, сәнгатькә омтылыш зур, аны үстерергә ярдәм итү — дәүләт җитәкчеләренең дә, мәдәният әһелләренең дә бурычы. Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итүдә әнә шулар да күздә тотылды.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Мәгълүм хакыйкать: теге яки бу халыкны, иң әүвәл аның бөек шәхесләре—үзегез әйткәнчә, "Җыр" калдыра алган илбашлары, галимнәре, әдәбият-сәнгать даһилары аша беләләр. Мисалны ерактан эзлисе юк, соңгы дистә елларда Сезнең исем аша Татарстан дөньякүләм дәрәҗәдә шактый ук танылa алды... Шулай ук, бу җәһәттән Тукай, Җәлил, Сәйдәш, Урманче исемнәре дә тонықланды дип уйламыйм. Сез, әдәбият-сәнгать дөньясын, аның нечкәлекләрен белеп-тоеп яшәгән җитәкче буларак (сәяси-икътисад өлкәсендә генә түгел, сәнгать дөньясында да дөньякүләм дәрәҗәле исемнәр тикмәгә генә бирелмәгән!), яхшы беләсез: талант—табигать бүләге, һәм ул һәрчак аңлауга һәм яклауга мохтаҗ. Халык яклавына да, дәүләт яклавына да. Җәмгыять байларга һәм ярлыларга аерымланган бу заманда әдәбият-сәнгать әһелләренә яшәү җиңел түгел. Мәскәү күзенә карап торган милли республика шартларында бигрәк тә. Иҗатыңа җәмгыятьтә ихтыяҗ булмау, кылганың бәһаләнмәү—иҗат кешесе өчен иң кыены шул. Әгәр чын талант бәһаләнми икән, димәк, җәмгыять үзе бигүк төзек (бозык ук дип әйтсәм килми) түгел булып чыга түгелме соң?**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Иң элек шуны әйтеп китим: иҗат кешеләре, чыннан да, Аллаһ кешеләре. Аллаһ Тәгалә безне яхшы якка үзгәртер өчен, игелеклерәк, камилрәк итәр өчен аларны җибәрә. Бу дөньяда аларның үзләренә дә җиңел түгел һәм бүтәннәргә дә гел уңайлыклар гына тудырып тормыйлар. Төптәнрәк уйлап карасаң, халыкның вөҗданы инде алар. Ә вөҗданлыларга, бигрәк тә нечкә күңеллеләргә, беркайчан да җиңел булмаган. Тормышлары фаҗига белән тулы язмышлылар күпме! Шәрык тарихыннан да, гарәп тарихыннан да мисаллар җитәрлек. Ерак китәсе юк, Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр да каберстан сакчысы вазифасында иҗат иткән түгелме соң? Үткән гасыр әдәбиятыбыз классиклары—шул ук Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәримнәрне искә төшерик: хәтта 40 яшькә дә җитә алмаганнар. Кайсына—27, кайсына—30... "Үлемнәре белән үлемсезлек яулаган" талант ияләре. Гомумән, минемчә, һәрбер зур талантның язмышында үз фаҗигасе бар. Шул ук Хәсән Туфан, Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакыйларны алыйк... Ахыр килеп, иҗат итү өчен бар шартлар тудырылган сурәттә дә иҗат – ул үзе үк газап, авыр хезмәт түгелмени?

Инде талантның бәһаләнү-бәһаләнмәү мәсьәләсенә килсәк, шунда ук сорау туа: ә кем бәһаләргә тиеш соң? Минемчә, бу үзе бер аерым тема. Әлбәттә, төп бәһаләүче—халык үзе. Әдәбият һәм сәнгать әсәрләре халык өчен иҗат ителә, халыкны кызыксындыра. Халыкка киң таныла алу бәһаләнүгә керәме? Әгәр керсә, бездә үзенең һәм рәсми, һәм гаммәви бәһасен алган иҗат кешеләре байтак. Әдәбияттан һәм сәнгатьнең һәр өлкәсеннән исемнәр китерә алам. Алыйк, әдәбиятны. Халык язучысы, халык шагыйре исеме алган әдипләр бәһаләнмиләр яки бәһаләнмәделәр дип әйтмәс идем. Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Ренат Харис... Сезнең үзегезне дә шул исемлеккә кертер идем. Алыйк театр дөньясын: Туфан Миңнуллин, Марсель Сәлимҗанов, Шәүкәт Биктимеров, Ренат Таҗетдинов... Рәссамнардан: Бакый Урманче, Харис Якупов, Әхсән Фәтхетдинов... Җыр өлкәсендә Илһам Шакиров, Фәридә Кудашева, Әлфия Афзаловаларны әйткән дә юк, ә Азат Аббасов, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Идрис Газиевлар халык мәхәббәтен яуламадылармы? Алардан соң килгән Салават, Хәния Фәрхиләр дә бар.

Ә танылу өчен ни кирәк? Иң элек – талант, сүз дә юк, бу – хәлиткеч фактор. Аннан соң—иҗатыңның халыкка барып җитүе. Бу турыда ныклап уйлану зарур. Моның заманча гамәли ысуллары да табылырга тиеш. Хәер, Татарстанда танылу өчен мөмкинлекләр бар дип саныйм мин. "Йолдызлык" ("Созвездие"), Илһам Шакиров исемендәге җыр конкурсы, "Җиде йолдыз", "Яңа татар пьесасы" бәйгеләре телемә килә. Заманасы кызык бит аның. Алыйк, мәсәлән, җырчыларны. Әлбәттә элеккеге классик җырчыларыбызга һәм хәзерге эстрада җырчыларына карашыбыз төрлечә. Ләкин бүгенге эстрадала барысы да начар җырлый, тормышлары җиңел дип гадиләштерәсем килми. Иганәчеләр дә табылып тора, кызыклы гына башкаручылар да бар. "Казан егетләре" ансамблен карагыз, элеккеге җырларны яңача көйләп халыкка җиткерәләр бит. Хәзер бит ничек кенә теләсәң дә, яшьләрне клубка җыеп, "Галиябану" көенә биетә алмыйсың. Тырышалар җырчылар, үзләрен танытталар, үз юлларын табалар. Алар тизрәк табалар, чөнки жанры шундый. Башка жанрларда танылу юлы озынрак булуы мөмкин. Әйтик, театр сәнгате. Яшь талантлар театр училищесын яки мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлыйлар, республикабыз театры сәхнәләреннән халык каршына килеп чыгалар. Күз алдыбызда таныла баралар. Мәсәлән, Камал театрында һәрвакытта да дәвамчылык яшәп килә. Буыннар алышына, яшь артистлар, Камал театрының югары таләпләренә туры килгән хәлдә, үз урыннарын табалар. Минемчә, таланты бар кеше конкуренцияне җиңә ала. Менә безнең опера җырчысы Михаил Казаков. Ул Дмитровград шәһәреннән килеп консерваториядә укый башлаган иде. Глинка фестивалендә җиңеп, хәзер зур иҗат юлына чыкты,

илебезнең Зур театрында эшли. Шул ук Чулпан Хаматованы алып карагыз. Нинди кискен конкуренция шартларында дөньякүләм дәрәҗәдәге актриса булып бара. Талант!

Аңлыйм, Сез хәзер бу бит дөнья, ил күләмендә, ә безнең татар язучыларына авыррак дип әйтәчәксез. Милли язучыларга, ничек кенә талантлы булмасыннар, элек тә җиңел булмады, хәзерге заман да яңа киртәләр барлыкка китерде. Милли әдәбият өчен нинди шартлар тудырырга? Бу аерым проблема һәм без аның турында сөйләшергә тиешбез. Мин болай фикер йөртәм: безнең яхшы шигырьләребез, проза әсәрләре халыкка ни рәвешле барып җитәләр соң? Әйе, китапларның тиражлары кими. Бу, әлбәттә, дөньяви процесс, глобаль проблема. Мин ел саен китапларның, газета-журналларның тиражларын карап барам. Тиражлар кимү мәгълүмат артуга бәйле дип саныйм, ул гына да түгел, мәгълүматның башка, заманча чаралары барлыкка килде. Бу бер милләткә генә кагыла дип әйтмәс идем. Төп чара—чын әсәрне, эстетик кыйммәте һәм тәрбияви әһәмияте булган талантлы әсәрне (әдәбиятта гына түгел, сәнгатьнең бүтән өлкәләрендәге әсәрләрне дә күздә тотам) халыкка җиткерүнең отышлы, үтемле ысулларын табу. Беләм, әйтергә генә җиңел, эшләве авыр. Бу минем хәзер генә туган фикерем түгел, газета-журнал мөхәррирләре, радио-телевидение җитәкчеләре белән сөйләшкәндә гел әйтә киләм: табыгыз талантлы авторлар, җыегыз редколлегия һәм уйлашыгыз дим. Мәсәлән, шигърият. Мин үзем шигырьләр яратам. Хәзерге заманда әдәби әсәрләр шулкадәр күп ки, барысын да укып бару мөмкин түгел. Ә шигырьгә кыска формада тирән фикер салына, ул үзенә җәлеп итеп тора. Миңа күп язучылар үз китапларын бүләк итәләр, күренеп тора: кызыклы китап, укыйсы килә. Әмма, ни үкенеч, вакыт җитми. Кеше гомере шулкадәр кыска! Йөрәгем сыкрана, шундый яхшы әсәрләр бар, ә рәхәтләнеп укырга вакыт юк. Сүз уңаеннан, мин министр булып эшләгәндә, Югары Советта бер җаваплы хезмәттәшебез бар иде. Китаплар дефицит чакта ул бик күп китаплар җыйды. "Хәзер вакыт юк, пенсиягә чыккач укыйм мин аларны",—ди иде. Без дә аның аша китаплар алгалый идек. Шул рәвешчә бик күп классикларның том-том әсәрләрен тупладык. Ул пенсиягә чыккач, сорыйм: "Хәзер теге китапларны рәхәтләнеп укыйсыңдыр инде?" Ә ул: "Укып булмый шул, хәзер вакыт бар, әмма күз күрми",—ди. Заманында укып калмасаң, кире әйләнеп кайту кыен ул. Хәзер исә глобальләшү процессы бара, көн саен, сәгать саен мәгълүмат киңлегенә яңа әсәрләр килеп керә.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Кызык! Нечкә күңелле булуыгыз мәгълүм, ә шигырьләрне яратып укуыгыз турында бик үк белми идем. Капылт икеюллык искә килде. "Каргалар шигырь укыса, күгәрчен булыр иде!". "Карга" дигән сүзгә ниндидер астыртын мәгънә салынган дип аңлашылмасын. Шулай туган ул икеюллык. Гомумән, шигырь укыган, шигырь яраткан кеше кадерле миңа. Шигырь кешене бәхетлерәк итә дип раслый алмыйм, әмма шигырь кеше күңелен нечкәртә, чистарта, табигый асылына кайтара... Әгәр шагыйрьнең шигырь язгандагы халәте укучының шигырьне укыгандагы күңел дулкынына тәңгәл килсә, шигырь сиңа фикердәш тә, җандаш та була ала...**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Әйе, сүзем шигырь турында иде бит әле... Мин әйтәм, әйдәгез телевидениедә, радио аша матур итеп, кеше күңеленә барып җитәрлек итеп шигырь укуны оештырыйк, дим. Автор үзе укысын, йә булмаса артистларыбыз укысын дим. Омтылып карыйбыз, башлыйбыз, тагын сүнеп китә бу эш. Без бит үзебез бар мөмкинлекләрдән дә файдалана, оештыра белмибез. Минем уйлавым буенча, татар шигырьләрен халыкка татарча гына түгел, русча да җиткерергә кирәк. Татарча ничек яңгырый ул, русча ничек? Акыллы кешенең башына керә ул. Мин үрнәк итеп "Культура" телеканалын китерә алам. Мин үзем, мәсәлән, дөньядан бераз онытылып торасым килсә, шушы каналны карыйм. Чүл уртасындагы оазис кебек ул һәм бу фикергә

күпләр кушыла. Тормышта һәркем үз өлкәсендә эшли, үз эшенә мавыгып яши. Аны әнә шул халәттән чыгарырга, игътибарын җәлеп итәргә кирәк. Хәтта мине—Президентны да үз эшеннән тартып чыгара торган булсын ул! Андый шигырьләр, тапшырулар, спектакльләр бар ул, димәк, моны эшләп була. Мәсәлән, 8 март көнне "Яңа гасыр" телеканалыннан Туфан Миңнуллин әсәре буенча "Эзләдем, бәгърем, сине" спектаклен күрсәттеләр. Анда төп рольләрне Илсөяр һәм Рамил Төхвәтуллиннар башкарды. Өйгә, һәрвакыттагыча, эш кәгазьләре алып кайткан идем, аларны бер кырыйга этеп куеп, шуны карадым. Көпә-көндез, бөтен гаиләбез белән күз яшьләрен сөртә-сөртә карадык... Талантның халыкка тәэсире—зур көч! Мондый байлык бар ич бездә. "Мәскәү күзенә карап торабыз" дисез, биредә Мәскәү берничек тә комачаулый алмый. Бу мәсьәләдә тезгенне тарткан кеше юк. Чап та чап алга! Тик үзебез чаба алмыйбыз. Күп нәрсә үзебездән тора. Сезне гаепләү булып яңгырамасын, мин үзем дә бик борчылам бу хакта. Проза әсәрләрен житкерүнең дә формаларын эзлисе бар.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Әйе, гел искечә генә язып булмый хәзер.**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Бүген бөтен дөньяда шулай: күләм – кыскалыкка, ә мәгънә тирәнлеккә омтыла. Мин Пауло Коэльо әсәрләрен укыйм. Алар бит зур түгел, әмма гаять үтемле, күңелеңне актарып чыгара. Әмирхан ага Еникины алыйк. Мәсәлән, "Кем җырлады?" хикәясе—искиткеч көчле хиссиятле әсәр. Эх, фильм төшерсәң иде, дим. Безнең андый әсәрләребез житәрлек. Гадел Кутуйның "Тапшырылмаган хатлар"ы дисенме... Әйтик, Зөлфәт Хәкимнең "Телсез күке" әсәре. Мин аны укып та чыктым, спектаклен дә карадым. Ул бик тирән әсәр, аннан менә дигән фильм чыгар иде. Бүгенге көндә Татарстанның мондый формаларның матди ягын тәэмин итү мөмкинлеге бар. Теләк, омтылыш җитми безгә. Үзебезне күрсәтәсебез килә икән, без аны әнә шундый талантлы сәнгать әсәрләре аша эшли алабыз. Килешәм, бездән ярдәм кирәк, без андый чыгымнарга бара да алабыз. Ләкин аның киләчәккә эшли торган сизелерлек нәтиҗәсе дә булырга тиеш.

Сез дөрес әйтәсез, талант яклауга һәм саклауга мохтаҗ. Без озак еллар социализм идеологиясе кысаларында яшәдек. Әмма мин ул чорга мәдәниятне, халыклар дуслыгын саклап калу ягыннан кире бәя бирмәс идем. Әлбәттә, башкача фикер йөртү, үзең тойганча иҗат итү ирек юк иде. Кем әйтмешли, "үтерми дә, яшәтми дә" кебек булса да, иҗат кешеләре өчен, нигездә, ниндидер тотрыклылык бар иде дип саныйм. Ә менә үзгәртеп кору чоры, башка тормыш рәвешенә күчү чоры иҗат әһелләре өчен, чыннан да, бик авыр булды. Ул әле икътисад өлкәсе кешеләре өчен дә искиткеч кыен иде, чөнки без андыйга яраклашмаган. Чөнки барысы турында да хөкүмәт уйлаганга күнеккән. Аннан соң, үзгәртеп кору чорында, гомумән, иҗат әһелләре арткы планда кала. Кичә китап укый, спектакль карый, җыр тыңлый торган кеше бүген, шул үзгәрешләр аркасында, башка мәсьәләләрне кайгыртырга мәҗбүр. Икътисадның бөлгенлеккә төшүе, базар мөнәсәбәтләренә күчү иҗат кешеләренә бигрәк нык кагылды. Нәкъ менә шул чорда мин Бөгелмә шәһәрендә рәссамнар белән очраштым. Ачыктан-ачык сөйләштек. Алар әйттеләр: "Менә без, рәссамнар, үз икмәгебезне төрлебез төрлечә эшләп ала идек. Берәү үз картиналарын сата, берәү үзе өчен иҗат итә, ә кемдер иҗатына өстәп партия плакатлары эшләп тамак туйдыра иде... Хәзер ул система җимерелде, ә безгә ничек яшәргә?" Әлбәттә, аларның талант дәрәҗәсе төрлечә булгандыр. Әмма һәрбер очрак – кеше язмышы. Илнең астын өскә китергән үзгәрешләр килеп чыгуда аларның гаебе юк. Шунда минем башыма бер фикер килде: боларга ничек тә булышу ягын карарга кирәк, дим. Татарстан Президенты каршындагы Мәдәният үсешенә ярдәм итү фонды әнә шулай барлыкка килде. Минем Президент буларак оештырган беренче һәм бердәнбер фондым шушы. Без иҗат кешеләренә дә,

ижади берлекләргә дә күпмедер күләмдә ярдәм итәбез. Бу чат саен сөйләп йөри торган гамәл түгел, әмма күпләргә булышып киләбез. Талантларның ижатын бәяләүдә безнең тарафтан эш бармый дип әйтмәс идем. Бөтенесен дә санап тормастан, кайберләрен генә искә төшерик. Тукай премиясенең дәрәҗәсен күтәрдек. Җәлил премиясенең дә статусы зурайды. Республиканың иң югары бүләге—"Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен" дигән орден ияләре арасында да иҗат әһелләре әз түгел. Сүз дә юк: зур ижатлары булган чын талант ияләренә, төрле юлларын табып, булышырга кирәк һәм шуны эшлибез дә. Бу уңайдан гонорарлар түләүне арттыруны күздә тотабыз, шулай ук, сәләтле яшьләргә грантлар да булдырыла.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Әйе, үткән ел Казанның меңьеллыгын бөтендөнья күзе алдында зурлап үткәрү соңгы чор татар тарихында бөек вакыйга булды. Юкны күрсәтү мөмкин түгел, димәк, борынгы зур мирасыбыз бар. Шулай да, эйфориягә дә бирелеп китәргә ярамыйдыр безгә. Югарыга менгән саен җилләр катырак булучан. Меңьеллык нигезен дип әйтикме, биеклеген диикме, ныгытасы да ныгытасы әле! Монда мин меңнең беренче бишйөз өлешен ныгытуны, ягъни шул чордагы рухи һәм матди мирасны өйрәнүне, дөньяга киңрәк танытуны күз алдымда тотып әйтәм. Башкалабыз юбилее уңае белән бик кирәкле уникаль басмалар чыкты: "Алтын Урда хәзинәләре", "Тартарика", "Сказание о Казани" һәм башка китап-альбомнар... Күптән түгел Республикада "Мәдәни мирасны саклау буенча комплекслы программа" кабул ителде. Бәлки, әлеге программада тарихыбызның борынгырак өлешен киңрәк колачларга кирәк булгандыр... Меңьеллыклар турында сүз йөрткәндә, мәдәнилегебезне иң әүвәл язма әсәрләр, әдәби ядкарьләр дәлилли... Кыскасы, "ташларны җыяр чаклар" җитте. Бу очракта, туры мәгънәдә—халыкча әйтсәк, хан заманындагы борынгы кабер ташларын да. Аларның байтагы Сезнең резенденциянең тәрәз төбендә бит...**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Узган ел ачылган "Хәзинә" милли сәнгать галереясы да, Татарстан Фәннәр академиясенең тарих институты да минем резиденциядән ерак түгелләр. Аларның Сез әйткән милли язмалар, ядкарьләр, шул исәптән борынгы кабер ташлары белән шөгыльләнү өчен мөмкинлекләре бар дип беләм. Тарихыбызны барларга, мирасыбызны тупларга безгә беркем дә комачауламый. Эшлик! Җиң сызганып эшләргә җай вакыт килде. Ни дисәң дә, демократия ныгып барган җәмгыятьтә яшибез. Без үзебезне цивилизацияле дөньяга тиндәш икәнлегебезне күрсәтә барабыз, хөр фикер йөртә башладык. Динебезне кайтардык. Димәк, тарихи бер үсеш этабын үттек. Әле кайчан гына шәһәр урамнарында татарча тартынып кына сөйләшәләр иде, сөйләшсәләр, шелтәкисәтү ясаучылар да табыла иде... Хәзер андый хәл бетте бит.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Мәскәүдә, гадәттә, "милли" дигән сүзне рус милләтенә бәйләнештә генә кулланырга тырышалар. Гәрчә, федераль дәүләттә милләтләр байтак булса да. Кызганыч, Россиядә тотрыклы милли сәясәт әлегә юк. Милли мәсьәләләр буенча махсус министрлык булмау да шул хакта сөйли. Хәзер милли проектлар турында күп сөйлиләр. Әлеге проектлар, башлыча, авыл хуҗалыгына, сәламәтлек, мәгариф һәм торак төзелеше тармагына карый. Болары бик әйбәт. Әмма мәдәният турындагысы әлегә күренми. Татарстан кайбер юнәлешләрдә федераль башлангычлардан алданрак йөрүчән. Әдәбият һәм сәнгать елы дип Сез игълан иткән Указны безнең шартларда мәдәният өлкәсендәге өстенлекле проект дип санарга буламы?**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Һичшиксез. Мәдәният өлкәсендә без бервакытта да илкүләм фәрманнар көтеп тормадык, кулдан килгәнчә кайгырта килдек. Гомумән, игътибар итсәгез, игълан ителгән милли проектларның һәркайсы буенча республиканың эш тәҗрибәсе бар.

Инде милли сәясәт мәсьәләсенә килгәндә, шуны әйтәсем килә: без дәверләр дәвамында күпмилләтле илдә яшәдек һәм яшибез. Шуна күрә, Россиядә һәр халыкның икътисади, тарихи, мәдәни ихтыяҗларын кайгырта торган милли сәясәт һәм аны тормышка ашыра торган тулы хокуклы структуралар булырга тиеш. Мин бу хакта байтак еллар буе әйтеп киләм. Сүзләремнең дөреслеген тормыш үзе раслап тора. Франциядә милли җирлектә кабынган гаугалар тынып та җитмәде, дөньяда Мөхәммәт пәйгамбәргә каршы ясалган карикатураларга бәйле ыгы-зыгы купты. Безнең илдә дә кешеләргә милләтенә карап һөҗүм итү очраклары булып тора. Шул сәбәпле, Россиядә милли сәясәт министрлыгы булдыру турында ешрак сөйли башладылар. Күптән түгел генә Россия Федерация Советы "Милли һәм конфессиональ сәясәт буенча берләшкән комиссия" төзү инициативасы белән чыкты. Бу мәсьәләләрне хәл итү сәгате сукты дип уйлыйм. Күрәсез, илнең иминлеге икътисад үсешеннән генә тормый. Европаның алга киткән илләрендә дә бу яктан барысы да ал да гөл түгел. Милләтләрне хөрмәт итүгә корылган илдә генә бәрәкәт була ала.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Әдәбият һәм сәнгатьне үстерергә телибез икән, табигый ки, телне сакларга, үстерергә кирәк. Сәнгатьнең күп төрләре сүз сәнгате белән бәйле: әдәбияты да, театры да, музыка-эстрадасы да... Ахыр чиктә, тел— халыкның, милләтнең җаны. Халык язучысы Нурихан Фәттах болай дип язып калдырды: "Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә, нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?.. Икенең берсе: йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә..."**

**Туган телебез язмышы өчен, әлеге язучыбыз кебек, без дә кирәк каләр яна-көрәшәбез микән? Шул исәптән республика җитәкчеләре дә?**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Яну-көрәшүгә килгәндә, без үзгәртеп кору елларында татар телен аякка бастыру, саклап калу өчен аз эшләмәдек. Совет чорында Казанда бары тик бер генә татар мәктәбе калганын да онытмаска кирәк. Телләр турында закон кабул ителде, татар теле дәүләт телләренең берсе дип игълан ителде, мәктәпләрдә, балалар бакчаларында татар теле укыту, татар мәктәпләре ачу мәсьәләсендә хөкүмәт тарафыннан ни кирәк – барысы да эшләнде.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Әйе, уңай үзгәрешләр күп. Аларны танымау сукырлык булыр иде. Чыннан да, 90 нчы елларда телебез күзгә күренеп терәкләнә-үсә башлады. Кухнядан чыгып, урам-мәйданнарда, трамвай-поездларда, гомумән, җәмәгать урыннарында кыюрак яңгыраш алды. Парламент утырышларында татарча сөйли башладылар. Моннан кырык еллар элек "Минем телем" дигән шигырь язган идем. Анда: "минем телем... конгресслар, парламентлар ачып йөрми" дигән юллар бар. Хәзер аңлыйм, ялгышканмын. Минем телемдә дә, шөкер, парламент, конгресс утырышлары да ачыла хәзер. Сирәк хәл: бу ялгышлыгым миңа борчу китермәде, әйткәнемнең киресе килеп чыгуы сөендерде генә. Шулай да, реалист булыйк, соңгы елларда бу өлкәдә артка таба чигенеш башланды кебек. Сүземнең очы, табигый, мәктәпкә, мәгариф системасына барып тоташа. Сан ягыннан карасаң, татар мәктәпләре, гимназияләре дә, аларда укучылар да күп кебек. Ләкин соңгы вакытта аларда татарлык кимеп, шактые асылда рус мәктәбенә әйләнеп бара шикелле. Шәһәрләрдә, бигрәк тә Казанда, "ата-аналар теләге белән" дигән теге заманнар формулировкасы янә эшкә җигелә башлады. Татарча укытуга астыртын саботаж ясаучы мәгариф әһелләре дә юк түгел дип беләм. Күпме көч һәм вакыт сарыф итеп, җан тырмашып, бөртекләп ачылган татар мәктәпләрен җуя башладык. Милли мәгариф бетсә, татар әдәбияты, татар сәнгатенең ни хәлдә каласы мәгълүм...**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Сез артка чигенеш дисез, ә мин бу хәлне башкача бәялим. Юк, артка китмибез, соңгы вакытта без, авыр йөк тарткан ат кебек, алга барудан кинәт кенә туктап калдык. Чөнки ирешкәннәрне ныгытып, алга бару кыенрак булып чыкты. Махсус сыйныфлар оештырдык, тәрбиячеләргә, укытучыларга өстәмә хезмәт хакы билгеләдек, мәктәпләр ачтык, махсус укыту программалары эшләдек — болар берсе дә юкка чыкмады ләбаса. Укыту процессында татар телен саклап калуга аяк чала торган мәсьәләләр бар икән, әйтегез, тәкъдим кертегез, боларын да хәл итәрбез. Тел язмышы турында сез дә, без дә дөрес борчылабыз. Әмма ул борчылу гаепләне эзләүгә кайтып калмасын иде. Әйе, Мәскәүгә, Татарстан хөкүмәтенә сылтарга була. Бу турыда сүз чыкканда мин Финляндиядә яшәүче татарларны искә төшерәм. Саклаганнар бит телне! Алынма сүзләр кыстырмыйча, чип-чиста итеп татарча сөйләшәләр. Чит җир, милли мохит юк дәрәҗәсендә, сан ягыннан әллә ни күп түгелләр, дәүләти мәктәпләре юк, туган тел белән карьера ясап булмый... Ә тел исән! Гыйбрәт алыйк без шуннан. Без һаман кемнедер гаеплибез, тик үзебезне түгел. Әйләнә-тирәбезне барлап, күрше-күләнне, хезмәттәшләрне, дус-ишләрне, туган-тумачаларны искә төшерик тә, уйлап карыйк: кемнәрнеңдер балалары туган телләрен белми икән, моңа бүтәннәрне гаепләргәме? Һәрбер татар үзеннән башласын иде, үзе эшләгән, яшәгән урынында үз телен саклап калу өчен нәрсә эшли ала? Бу—халыкның үзаңы дәрәҗәсен күрсәтә торган фактор. Һичьюгы үз гаиләсендә татарча сөйләшәме? Бу сорауларга хәзергә беркемнең дә төгәл җавабы юк, шул исәптән минем дә. Димәк, бергә-бергә эзләргә кала.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Сез, шәхсән үзегез, туган телне олылауга зур өлеш керттегез. Чыгышларыгызны тыңлап, көнләшеп тә куям: телнең бөтен нечкәлекләрен, тылсымын, мәгънәви көчен һәм моңын белеп сөйлисез. Шулай булырга тиеш тә. Үз телен камил белмәгән кеше Илбашы була ала димени! Сезгә карап, республикадагы эреле-ваклы байтак җитәкчеләр туган телгә мөнәсәбәтләрен үзгәрттеләр, хәтта кайберләре ана телендә ярыйсы гына сөйләшә дә башлады. Ләкин андыйлар күп түгел. Дәүләт Советы утырышларында да (рәсми очрашулар, хуҗалык киңәшмәләрен инде әйткән дә юк!) күбесе дәүләт теле саналган ана телендә чыгыш ясамый. Ә бит аларның байтагы чыкылдап торган татар авылы малайлары... Соңгы вакытта исә төрле дәрәҗәдәге җитәкчелеккә туган Тел һәм Моң төшенчәсен аңламаган яшьләр килә... Әйткәнегезчә, татар теле—дөньяның абруйлы телләре исәбенә керә. Россия Президенты Путин да татарча сөйләп күрсәтте бит инде югыйсә! Ярый әле парламентта әлеге дә баягы әдәбият һәм сәнгать вәкилләре—язучылар бар, юкса анда кайбер милли мәсьәләләр бөтенләй күтәрелмәгән дә булыр иде... Бу җәһәттән Сез туган телнең киләчәген ничек күзаллыйсыз? Әйтик, 40-50 елдан?**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Минемчә, бүгенге кыенлыкларга карамастан, телне саклап калу һәм үстерү өчен социаль шартлар өлгереп килә. Бу, гомумән, дөньякүләм процесс бит. Татар теленә генә түгел, күпмедер дәрәҗәдә рус теленә дә һәм башка телләргә дә куркыныч яный. Без озак вакыт аерым бер идеологиягә буйсындырылган җәмгыятьтә яшәдек, дөресен әйтик, рухи кыйммәтләр турында уйларга җаебыз юк иде безнең. Ә хәзер барыбыз да сизәбез: рухи кыйммәтләр алгы планга чыга башлады. Моны кешеләрнең дингә омтылышы көчәю дә ачык күрсәтә. Шөкер, без иманыбызга кайту юлында. Әлбәттә, тел мәсьәләсе авыррак. Моның чишелеше рухи кыйммәтләр яссылыгында ята. Ана телен белү горурлыкка, үз-үзенне бәяләүнең, шәхес булуыңның бер билгесенә әйләнергә тиеш. Ана телен саклап калу балаларым, нәселем, милләтем алдындагы бурычым дип санаган кешегә бернинди чит тәэсирләр дә куркыныч түгел. Аның милли үзаң дәрәҗәсе югары дигән сүз. Кызганыч, бүген бу турыда уйлаучы аз. Мин татарлар үз телен белергә теләми

дигән фикер белән килешмәс идем. Мәсәлән, кайсы республикага гына барма, татар кешеләре очрап тора. Хәтта чит илләрнең сәяси даирәләрендә дә бар алар. Күбесе үз шөгыленда шактый уңышларга ирешкән. Алар минем янга махсус килеп күрешәләр, татарча сөйләшә алмауларыннан уңайсызланалар. Димәк, җаннарында татарлык сүнмәгән. Казанның 1000 еллыгын үткәреп без күпме милләттәшебездә йокымсырап яткан горурлык хисләрен уяттык. Бу— безнең зур казанышыбыз. Мин моны Шәймиев Президент булган чорга туры килгән өчен генә әйтмим. Аллага шөкер, дөньябыз шулайга китте. Безгә шушы тарихи моментны тотып алып, һич сузмыйча, кешенең аңына сеңдереп калырга кирәк. Татарларның үз туган җиренә, үз тамырларына бәйләнеше — каннарында, димәк, ул күпмедер дәрәҗәдә балаларына да күчә. Әлеге моментны ычкындырсак, туган телнең киләчәге шикле булырга мөмкин. Әйдәгез, уйлашыйк, моны ничек эшләргә? Бу бик нечкә мәсьәлә, бирелә зирәк, талантлы иҗатчыларыбыз сүзе кирәк, шунсыз булмый. Кешенең күңел кылларына кагыла белү тылсымы сезгә бирелгән дип уйлыйм.

Татар теле—төрки телләр семьялыгыннан, бу телләрдә күп кенә илнең халыклары сөйләшә, алар күп милләтләрнең туган телләре. Шуңа күрә бу мәсьәләдә безгә барлык төрки дөнья белән бергә эш итү дә кирәк дип саныйм. Гасырлар буена һәр тел күпмедер дәрәҗәдә үзгәрә, ә менә телләр төркемен саклап калу— глобальләшү чорында безнең уртак бурычыбыз.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Ил тормышында күңелне борчый торган нәрсәләр шактый. Шулар арасыннан безгә, язучыларга, турыдан-туры кагылганнарының берсе—әдәбиятны укучылар, гомумән, укучылар саны кимүе, матбугатыбызның таралу сферасы кысылуы, милли зыялылар катлавының югары баруы борчый мине. Һәр иҗатчы, табигый, йөрәгеннән чыкканның күбрәк кешеләргә ирешүен тели. Әсәр, чыннан да, эстетик һәм тәрбияви әһәмияткә ия икән, ул җәмгыятьтә үзенең лаеклы урынын алырга тиеш. Фикеремне җөпләр өчен үзем эшләгән "Казан утлары" мисалын гына китерәм. Әле генә аның 1000 нче саны чыкты. Зур сан, зур вакыйга. Горурланып әйтәм: Россиядә мондый санга ирешкән бүтән әдәби журнал юк. Редакциягә җибәргән котлавыгызда үзегез дә шуны танып, журнал эшчәнлегенә югары бәя бирдегез. Рәхмәт. Менә шул журнал, күпләр әйткәнчә, бик тә кирәкле басма, халыкта тиешенчә таралмый. Аны бөтенләй алдырмаган мәктәпләр, уку йортлары, мәдәният учреждениеләре, китапханәләр бар. Төрле ведомстволар турында әйткән дә юк инде. Сүз безнең журнал турында гына бармый; мәсәлән, заманында 500 меңләп данәдә чыккан "Азат хатын" (хәзерге "Сөембикә") хәзер 13 мең чамасы, элек 300 меңгә якын укучысы булган "Ватаным Татарстан"ның—20 меңләп әбунәчесе бар. Сез, бәлки, әйтерсез, заманы шундый, бүтән халыкларда да шул хәл, диярсез. Алай дисәң, үзебезнең Татарстанда бер төбәктә бер төрле нәтиҗә, икенче җирдә бөтенләй бүтәнчә (бу хәл халык саны һәм милли составы бер чама районнарда). Кайбер районнарда китап кибетләре эшләп килә, кайберләрендә бөтенләй юк. Хикмәт, күрәсең, җирле хакимиятләрнең эшчәнлегенә, аңлавына, аерым кешеләрнең интеллектына, җаваплылыгына да бик нык бәйледер... Бәлки, җирле җитәкчеләрдән икътисадый сан-процентлардан тыш, рух дөньясына караган күрсәткечләрне дә таләп итәргәдер? Булдырырдай нәрсәләр күп бит. Мәсәлән районнарда ел саен төрле слетлар, уңыш бәйрәмнәре уздырыла. Анда алдынгыларга бүләкләр бирәләр: аракылар салынган пакеттан башлап машиналарга кадәр. Бу форсаттан хезмәтчәннәргә затлы китаплар, еллык подпискалар да кушып бүләкләргә була бит. Мәгънәсе, савабы булыр иде. Безнең түрәләр кушканны үтәргә күнеккән. Алар бит, иң ким дигәндә, берничә дистә ел Сезнең күзегезгә карап тордылар...**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Татар телендәге газета-журналларны таратуның яңа юлларын уйлап табу—уртак эшебез. Хәзерге заманда кешене теге яки бу журналга көчләп яздырып булмый. Һичшиксез, балалар матбугаты аерым

игътибар үзәгендә булачак. Сез "Казан утлары"н мисалга китердегез. Чыннан да, ул журнал белән таныш булмаган укытучы бүгенге татар әдәбиятын ничек итеп сыйфатлы итеп укыта алсын икән? Әдәбият укытучыларына һөнәри дәрәҗә биргәндә болар һәммәсе дә искә алынырга, таләп ителергә тиештер бәлки? Шул ук вакытта, әсәрләр үзләре дә заман таләпләренә җавап бирерлек, әйткәнемчә, мәгълүмат ташкынында үзенә җәлеп итәрлек булсын иде. Көнүзәк проблемаларны күтәргән заманча әсәрләребез күп дип мактана алмыйбыз әлегә. Әйдәгез, тәкъдимнәр кертегез, әйтегез, нинди ярдәм кирәк? Мәсәлән, бүгенге көндә иҗат интеллегенциясеннән бу турыда нинди дер фикер ишеткәнем юк әле минем. Татарча журналларны методик әдәбият белән бергә тәкъдимнәр татарча укытучыларга, мәдәният хезмәткәрләренә таратырга кирәк икән—бусы безнең кулдан килерлек эш. Мәктәп китапханәләренә, гомумән, республиканың барлык китапханәләренә яздыру да хәл итәлә алмый торган мәсьәлә түгел. Газета-журналларны тарату мәсьәләсенең хәзерге заманда зур игътибарга лаек башка ягы бар. Без республика мәктәпләрен 100% компьютерлаштырдык. Хәзер Интернетка күчеп барабыз. Бүгенге көндә һәрбер матбага үзенең сайтын булдыра. Мәсәлән, "Казан утлары" сайтын дөньяның теләсә кайсы почмагында ачып, анда басылган әсәрләрне уку мөмкинлеген тудыру өчен күп акча кирәкми. Әлеге дә баягы тел саклау мәсьәләсенә дә кагыла бу. Әгәр безнең тел Интернетта булмый икән, без дөнья мәгълүматы кинлегеннән төшеп калабыз. Күп очракта искечә фикер йөртү комачаулый безгә, без замана чараларыннан файдалана белмибез. Безнең матбугат татарлар яшәгән илләргә, мәсәлән, Үзбәкстанга, Казакъстанга барып җитми дибез. Хәзер төргәк-төргәк газета-журналны поезд яки самолет белән ташу заманы узып бара. Интернетны тулысынча эшкә җигәргә кирәк. Белгечләр белән бергә җыелып сөйләшергә кирәк бу хакта. Ачыйк бер әдәби сайт, куйыйк шунда язучыларыбыз әсәрләрен, җырларны, шигырьләрне, тарихи язмаларны... Матди ягын үзебез карарбыз. Бу юнәлештә хәрәкәтләнергә кирәк дип уйлыйм мин. Хәрәкәттә—бәрәкәт.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Әдәбият һәм сәнгать турында әңгәмәләшкәндә, телевидение һәм радио һич кенә дә читтә кала алмый. Рухи хәзинәбез үрнәкләрен халыкка җиткерүдә аларның роле бәяләп бетергесез зур. Әмма әлеге гаммәви мәгълүмат чаралары бик үзгәрде хәзер, өстәвенә хуҗалары да күбәйде. Аларда, минемчә, дәүләти программа буенча эшләү җитенкерәми. Һәр иртәдә үз тапшыруларын республикабыз гимны белән башлый торган бердәнбер "Татарстан" радиосының да бүгенге көндә элегрәк халык көтеп ала торган, сәгатьләр буена рәхәтләнеп тыңлаган радиопостановкалар, спектакльләр яңгырату мөмкинлеге юк... Ә дистәләрчә (!) коммерция радиоларында бик күп эфир вакыты югары сәнгатьтән бик ерак җыр-көйгә (һәм шуңа иш җыр башкаручыларга), ике алып баручының тузга язмаганны сөйләп, телефоннан юк-бар сорауларга җавап биреп утыруына, дөресрәге, халтурага сарыф ителә... Масса культурасы цунами шикелле ишелеп килә! Телевидениебезнең "Татарстан" каналында исә дәүләт теле саналган татар телендә көндәлек хәбәрләр, яңалыклар да ишетә алган юк...**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Радио мәсьәләсенә килсәк, аның заманнар үзгәрү белән әһәмияте кимемәде, аның киләчәге зур. Чөнки кешенең нидер укырга, карарга вакыты җитми, ә радионы ул машинада барганда да, өй тирәсендә йөргәндә дә, ашау пешергәндә дә тыңлый ала. Әйе, соңгы вакытта радиостудияләр артты. Әлбәттә, бу өлкәдә конкуренция зур. Шуңа күрә, үз тыңлаучына барып җитүнең үтемлерәк чараларын уйлап табу зарур, элеккечә эшләп булмый – бусы көн кебек ачык. Нинди генә радио булмасын, дәүләтнекеме ул, үз хуҗасы бармы аның – татар радиоларында тапшыруларның сыйфаты турында уйларга кирәк, Сез дөрес әйтәсез. Эфир вакытын милләт мәнфәгатьләрендә, булдыра алганча отышлы итеп файдалану ягын карарга

кирәк. Әйтик, татарча сөйләүче коммерциячел радиоларнын да хуҗалары татар балалары ләбаса. Татарлар үзара сөйләшеп уртак фикергә килә алмаслар микәнни? Әйе, Сезнен белән килешәм, кайчак машинада барганда тынлыйм, кабатлаулар, мәгънәсез сүзләр шактый. Алар бит моны үзләре дә яхшы белә: әдәби, сәнгати мәгълүмат житми. Тәүлек буенча эшләүче радиолар бар. Барысы белән дә санлашып, бергә жыелып гәпләшсәгез, аларга матур итеп мәгънәле, зәвыклы, кызыклы тәкъдимнәр кертсәгез, минемчә, алар моны рәхәтләнеп кабул итәчәкләр. Гонорар да түләячәкләр әле үзегезгә. Әлбәттә, без бу мәсьәләдән читләшергә жыенмыйбыз, уртак эшебез булыр. Грантлар, гонорарлар—хәл итеп була торган мәсьәләләр.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Безнең буын—китап укып үскән буын, "Китап—белем чишмәсе" шигарендә тәрбияләнгән буын. Яшәвем белән үткән гасыр кешесе буларак, һаман да, китаптан алган белем тирәнрәк була дигән фикер белән яшим. Шулай ук, радио-телевидение дә безгә чит түгел.**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Чит кенә түгел, якын да булырга тиеш. Заманга каршы барып булмый. Бу яктан "Яна гасыр" спутник телевидениесе булдыруыбыз дөрес адым булды. Без моны үз вакытында, чыгымнарнын зур булуына кармастан, тып-тын гына эшләп куйдык. Кычкырып йөрүнен кирәге дә юк, юкса, комачаулыклар килеп чыгар иде, бәлки. "Яна гасыр" телевидениесе булмаса без бүгенге көндә ничек яшәр идек? Күз алдына да китереп булмый. Беләсез, Россия төбәкләре үз тапшырулары белән тәүлеккә нибары сәгать ярым гына эфирга чыга алалар. Яналыклар да, мәдәни, икътисади тапшырулар да шул сәгать ярым вакытка сыярга тиешләр. Ә без көне буе татарча спектакль карап утырабыз. "Татарстан" телерадиокомпаниясенен мөмкинлекләре чикле икән, "Яна гасыр" компаниясен күбрәк эшкә жигәргә кирәк. Чөнки максатлары уртак. "Яна гасыр" телеканалы дөньянын бөтен татарын экран каршына жыя ала бит. Узган ел бөек жырчыбыз Илһам Шакировнын юбилей кичәсен бөтен дөньяга трансляцияләдек. Ә Казаннын 1000 еллыгы бәйрәмен телевидение аша чит жирләрдә яшәгән милләттәшләребезнен күбесе карады. "Үзебезне Казанда йөргән кебек хис иттек",—дип рәхмәт хатлары яздылар. ТНВ тәлинкәләре әкренләп ил буйлап, дөнья буйлап тарала бара. Әлбәттә, хәзер милли телевидениене саклап калу өчен күп эшләргә кирәк. Башка каналлар белән конкуренция көчле. "Яна гасыр" каналын тәнкыйтьләү жинел ул. Әмма анын эшен яхшырту максатында иҗат әһелләре тарафыннан фикер, тәкъдимнәр кертеләме сон?

Менә Айдар Фәйзрахманов "Яна гасыр" каналында "Жырлыйк әле!" тапшыруын оештырып жибәрде. Үзем дә карыйм, һәрвакыт жаен табарга тырышам. Каян гына чакырып китерми кешеләрне! Сәләте булып та, мәйданга чыга алмаган талантлы кешеләрне халык арасыннан табып, экранга чыгару да яхшы бит. Бөтен кеше профессионал язучы, жырчы булып китә алмый, һәркемнен үз язмышы. Бер генә булса да чыгып алу да ярый, аны кешеләр күрә, шул исәптән, туган-тумачасы, балалары күрә, үрнәк ала... Авылга да бик тирән үтеп керде телевидение. Бервакыт туган якка кайткан идем, апам мина әйтә: "Татарча телесериалнын вакытын үзгәртеп булмый микән?"—ди. Шул сериалны карап, сыер саварга сонга калалар икән. Менә бит ничек тәэсир итеп була! Мина калса, иҗат әһелләре, бигрәк тә милли иҗат вәкилләре телевидениеда житәрлек дәрәҗәдә актив катнашмый әле. Ни өчен үз татар сериаллары барлыкка килми – кем гаепле сон бу очракта, кем комачаулый? Эш үзебездә бит...

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Шөкер, рухи мирасыбыз бинһая зур. Сүз-көйгә бәйләнешлеләре дә, агач-ташта калганнары да... Минемчә, төп бурычларыбызның берсе—аларны хуҗаларча саклау һәм дөньяга таныту, ягъни**

**пропагандалау. Бу җәһәттән соңгы 10-15 елда игелекле байтак гамәлләр башкарылды. Тарих институтын ачу, энциклопедияләр чыгару, Кремльдә музей комплексы булдыру... Милли мәдәни үзәкнең чын мәгънәсендә мәдәни-мәгърифәт учагына әверелүе... Мисалларны тагын китерергә мөмкин. Ләкин, күптән төзекләндерергә яки торгызылырга тиеш булган тарихи истәлекле, җанга якын урыннар бар. Әйтик, Тукай язмышы белән бәйле Болгар номерлары, заманында Г. Исхакый, С. Максудилар укыган "Учительская школа" бинасы, 70 елдан артык газета-журналларыбыз, Язучылар берлеге штабы булган мәшһүр Матбугат йорты... Кайсы харәбә хәлендә, кайсы—хуҗасыз йорт кебек, каралмаган... Шуларга өстәп, Китап палатасының мөшкел хәле турында да әйтеп үтәргә кирәк. 80 ел буе Республикабызда чыккан бөтен матбугат басмаларын туплаган, тәртипкә китергән, библиографик күрсәткечләрен төзегән шушы мөхтәрәм оешманың үзләре җыйнаган хәзинәне, ягъни китапларны, газета-журналларны тиешле рәвештә саклау урыннары да юк. Бәяләп бетермәслек шул байлыкның ташландык хәлендә булуы бик аяныч, әлбәттә. Мирасыбызда булган кульязма, китап байлыклары өчен әрмәннәрдәге шикелле Матенадаран төзергә күптән вакыт, минемчә.**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Моннан бер ун ел элек Казанның нинди хәлдә булуын әле хәтерлисездер. Ә бүген ул бөтенләй башка сурәткә керде. Шушы еллар эчендә без күп эшләдек дип уйлыйм. Сез санап киткән биналар безгә билгеле. Дөресен әйтим, без борчылып сөйләшкән тел, мирас, уку-укыту мәсьәләләрен хәл итүгә караганда, аларны төзекләндерү җиңелрәк. Мона безнең хәлебез җитә, без боларга тотынырбыз да эшләп тә чыгарбыз, иншалла.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Тарихта үсеш спираль рәвешле бара, диләр. Хәлләребезне моннан бер гасыр элеккеге вәзгыять белән чагыштырсаң, байтак охшашлыклар күреп була. Халыкның киләчәктәге язмышы, бигрәк тә рухи үсеше мәсьәләләре, хәзерге кебек үк катлаулы булган. Әмма шунысы факт: патша хөкүмәтеннән бернинди ярдәм алмаган заманда да безнең халыкның шактый камил мәгариф системасы, күпкырлы матбугаты, көчле әдәбияты булган, театрлары барлыкка килгән. Россия күләмендә алганда, татар теленең асыл нигезе, тамырлары бүгенгегә караганда ныграк булган. Бу өскорманың нигезен нәрсә тәшкил иткән соң? Халык үзе. Җаваплылык тоеп, киләчәген халык үзе кайгырткан. Әлбәттә, беренче чиратта, халыкның матди һәм рухи байлыкка ия булган катламы кайгырткан. Шул чорның байлары мәчет-мәдрәсәләр төзеткән, нәшрият-басмаханәләр ачкан, талант ияләренә ярдәм күрсәтеп, мәдәният үсешен тәэмин иткән. Шул заманның атаклы меценатлары—Хөсәеневләр, Рәмиевләр, Юнысов, Кәримов, Апанаев, Яушевлар кебекләрнең исемнәрен атау да күп нәрсә аңлата. Рустагы Третьяковлар, Мамонтовлар, Стахеевлар кебек, татар дөньясында якты эз калдырган шәхесләр алар. Казанда, Уфада яки Оренбургта булсын, алар салып калдырган, заманында мәгърифәт учаклары булган корылмалар, биналар әле дә исәннәр. Бүгенге көндә әдәбият һәм сәнгатьнең һәр өлкәсендә ирешелгән зур казанышларны таныган хәлдә, рухи дөньябыз, барыбер, матди ныгуга мохтаҗ. XX гасыр башында милли мәдәният үсешендәге проблемалар бер яссылыкта булса, XXI гасыр башында да шул ук мәсьәләләр, асылда, кала бирә, масштаблары һәм мәгънәләре генә үзгәрәк. Яхшы беләсез, мәдәният сферасын бюджеттан тәэмин итү "калдык принцибы" белән бара. Шуңа күрә мондый финанслау ихтыяҗны канәгатьләндерә алмый. Хәлне яхшыртырга хәзер дә мөмкинлекләр бар, минемчә. Элеккеге уңай традицияләрне яңартырга кирәк. Соңгы дистә елларда бездә дә зур байлыкларга ия төркемнәр барлыкка килде. Сез аларны безгә караганда яхшырак беләсез, кайберләрен татар халкының XX гасырдагы мәшһүр кешеләре дип тә билгеләп үттегез. Әдәбият һәм сәнгатебезне үстерүдә беркадәр алар ярдәменә өмет итә алабыз микән?**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Чыннан да, һәр халык үз киләчәген үзе кайгыртырга тиеш. Бу аның бердәмлек дәрәҗәсенә, милли үзаңына һәм матди куәтенә бәйле. Базар мөнәсәбәтләренә кучүгә карамастан, хөкүмәт милли мәдәниятне, телне саклап калу мәсьәләләреннән читләшмәячәк. Әле ныклап тотынырга исәп. Бездә булдыклы, ярдәм итәрдәй татар кешеләре, зур предприятие житәкчеләре, иң мөһиме — татар җанлы кешеләр күп. Бусы да очраклы хәл түгел. Чөнки 90 нчы елларда үткәрелгән хосусыйлаштыру чорында без мораторий игълан иттек һәм читтән кул сузучылар безнең байлыкка хуҗа була алмады. Республикадагы мөлкәт татарстанлылар кулында калды. Бу Татарстанның алга таба үсеше өчен төп нигез булды. Казанның 1000 еллыгын үткәргәндә дә байтак химаячеләр юмартлык күрсәттеләр. Безне еш кына спортка зур игътибар биргән өчен тәнкыйтьлиләр. Шунысын әйтим: спортка бюджет акчасы китми, республикада спортны безнең татар егетләре тоталар, спорт биналарын да алар төзи. Соңгы елларда Татарстан үзенең яңа спорт корылмалары белән танылды. Премьер-лига командалары уенын, дөнья масштабындагы кубоклар ярышын Казанның кайчан күргәне бар иде әле? Дөнья күләменә әнә шулай чыгалар. Әйтик, шул ук эстрада җырчыларына, талантлы балаларга да ярдәм итүчеләр бар. Ләкин хәзергә татар эшкуарлары күңеленә тулысынча ачкыч табылганы юк шикелле. Бирелә дә җаен белеп эшләргә кирәк, әйдә, акча бир дип кенә түгел. Кеше бу гамәлгә үз теләге белән, үз җаны кушканга килергә тиеш. Менә Сезгә бер тәкъдим: җыелыйк бергә: язучылар, җырчылар, рәссамнар, иҗат кешеләре, зур предприятие җитәкчеләре, эшкуарлар... һәм сөйләшик. Клуб оештырыйк, ана матур исем табыйк. Бәлки Язучылар берлеге каршында оештыру кулай булыр. Гомумән, безнең бу әңгәмә кайтавазы, Сез әйткәнчә, замана байларына да ишетелер дип уйлыйм. Алар да уйлансын. Александр Македонский, үләр алдыннан кулларын күтәреп, учларын күрсәткән ди, имеш: "Ярты дөньяның хуҗасы булсам да, күрегез, гүргә бернәрсә дә алып китә алмыйм".

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Сез Галиәсгар Камал театры премьераларында еш буласыз. Опера һәм балет театрында куелган музыкаль спектакльләрне дә шулай хуш күрәсезме? Бу мәсьәләдә үз фикеремне дә белдереп узыйм әле. Татар операсы, татар балеты күз алдында юкка чыгып, үлеп бара. Сәбәпләрен төрлечә аңлаталар: татарга опера кирәкми, ул аның рухына ят нәрсә; бездә югары кимәлдәге музыкаль әсәрләр иҗат итүчеләр юк; тиешле әзерлекле татар җырчылары җитешми һ. б. Ә бит сәнгатьнең бу төре заманында театрда нульдән башлап диярлек бар ителгән. Җырчылар, биючеләрне Мәскәүдә махсус укытып, иҗат коллективлары оештырылган, дәүләт заказы белән милли әсәрләр иҗат ителгән.**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Безнең халыкта опера сәнгатенә, югары музыкага тартылыш көчле. Бусы бәхәссез. Зур концертлар залына да, Татар дәүләт академия опера һәм балет театрына да халык йөри. Бу—үзе бер куаныч. Үзебезне цивилизацияле халык дип саныйбыз икән, башкача була да алмый. Безнең халыкның интеллект дәрәҗәсе дә, әлеге сәнгать вәкилләренә таләпләре дә югары. Безгә килгән артистлар үзләре үк шулай диләр. Минем бу хакта Ирина Архипова, Мария Биешу, Алибек Днишев, дирижерлар Валерий Гергиев, Фуат Мансуров кебек опера һәм югары музыка осталары белән фикер алышканым бар. Кешенең интеллект дәрәҗәсе үскән саен, аның музыкага омтылышы арта.

Татар операсы, татар балеты ни хәлдә? Ана йөрерләрме? Әзерлекле тамашачыбыз бар икән, югары кимәлдәге әсәрләр тудыра алабыз икән, һичшиксез, йөриячәкләр. Дөнья сәнгатендә опералар күп түгел, гасырлар буе бер үк опералар яки балетлар кабат-кабат куелалар, һәр яңа буын аларны үзенчә күрә. Сәнгати югарылыктагы опера-балет иҗат итү җиңел түгел. Күреп

торабыз, дөнья музыка сәнгатендә яналары да барлыкка килә, әмма күбесе төшеп кала. Ә классик опералар алар, чыннан да, бөтен халыклар өчен үрнәк булып торалар. Безнең дә электән үк иҗат ителгән әсәрләребез бар: "Алтынчәч", "Башмагым", "Шүрәле" һәм тагын берничә әсәр. Алар вакыт сынавын узып, тамашачы мәхәббәтен яулаган әсәрләр. Минемчә, безгә дә шуларны кабат-кабат куярга кирәк. "Шүрәле"нең яңа куелышын карарга килмәсләр дип уйлыйсызмы? Киләчәкләр. Соңгы вакытта куелган яңа балет "Кыйссаи Йосыф"ка да халык бик кызыксынып йөрде. Тамашачы операга җырчыларның тавышын бәяләргә килә. Мәсәлән, классик операларны күбебез яттан диярлек беләбез, әмма без мәгълүм арияләрнең яңа яңгырашын ишетергә телибез, бүгенге җырчыларның башкару осталыгыннан ләззәт алырга дип барабыз. Операда тел мөһим түгел, операда тавыш хакимлек итә. Классик операларны да һәркем үз телендә җырлый бит.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Н. Җиһанов, Н. Даутовлар исән чакта, ягъни 20-30 еллар элек бу өлкәдә күтәрелеш бар иде. Хәзер? Театр, республика мәнфәгатьләреннән бигрәк, читтәге тамашачылар өчен күбрәк хезмәт итә. Җыелма труппа төзеп, төрле шәһәрләрдән яхшы тавышлы җырчыларны алалар да, чыгып китәләр чит илләргә...**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Мин бу фикер белән килешә алмыйм. 20-30 ел элек без чикләнгән дөньяда яши идек. Безнең үз җырчыларыбызны башкалар белән чагыштыру мөмкинлеге юк иде. Ул елларда Татар опера һәм балет театры чит илләргә гастрольләргә чыга ала идемени? Әйе, искиткеч җырчыларыбыз бар иде, алар арасында дөнья күләменә чыга алмыйча калган олы талант ияләре дә юк түгел. Әмма без башка җырчыларны күрмәдек, ул заманнарда телевидение дә киң таралмаган иде әле. Минем берәүгә дә үпкәләтәсем килми, тик хәзер без дөнья киңлегенә чыктык, Лучано Павароттины, Пласидо Домингоны, Монтсеррат Кабальены ишеттек. Башкаларны күрдек, үзебезне дә күрсәттек. Бу нисбәттән Зөлфәт Хәким әсәрләрен искә төшерәсем килә. Зөлфәт, һич курыкмыйча, үз-үзебезне ачы итеп тәнкыйтьли ул. Кыргызларны тәнкыйтьләп, камчылап тәрбияләгән язучы Абай кебек. Әлбәттә, без тәнкыйтьне күп очракта күтәрә белмибез, үпкәлибез. Ләкин дөреслеккә күзебезне ачып карарга тиешбез. Европалардан йөреп кайткач, безнең башкаручылар үз-үзләренә бәһане бирделәр. Күрдек, аңладык, бар бездә лаеклы җырчылар, биючеләр, әмма барысына да үзебезнең генә көч җитми икән. Моны да танырга кирәк. Мин татар халкының үз театры эченә бикләнеп, кемнедер хурлап, кемнедер мактап яши торган халыкка әйләнүен теләмәс идем. Әйе, Татарстанда без беренче, ә читкә чыгып карасак? Бу башка өлкәләргә дә, икътисадка да кагыла. Дөнья ачык бүген—булдыра аласың икән, чык, эшлә. Булмый икән—тырыш, чарасын күр. Безнең опера һәм балет театры—ул 800 ләп кеше, аны саклап калырга да, дөньяга күрсәтергә дә кирәк иде. Европа бездән башка яши ала ул, ә без Европадан башка? Федор Шаляпин исемендәге опера, Рудольф Нуриев исемендәге классик балет халыкара фестивальләре, "Европа —Азия" халыкара заманча музыка фестивале бездә—Казанда уза бит! Әйе, хәзергә барысы да үзебезнең көч белән генә эшләнми. Һичшиксез, милли опера һәм балет та кирәк. Ә иң мөһиме, безгә дөнья дәрәҗәсендәге үз җырчыларыбыз күбрәк кирәк. Хәзергә бездә көчле башкаручылар аз. Михаил Казаков турында әйтеп киттем, хәзер татар егете Владимир Васильев күтәрелеп килә. Мәскәүдә Гнесиннар училищесында бер төркем яшьләребез укый, алар арасында өметле башкаручыларыбыз бар. Эш бара, иң мөһиме, хәзер без үз казаныбызда гына кайнамыйбыз, иҗатның чикләре юк.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Әңгәмәбез ахырына якынлашканда Сезгә әйтәсе килгән тагын бер уй-фикер. Бөтен дөньяга таралган татарлар Казанны үзләренең рухи башкаласы дип таный, Татарстан Илбашын үзенеке саный, аның кылган игелекле**

**гамәлләрен ихлас яклый, омтылышларына теләктәшлек белдерә. Аларны Татарстандагы авыл хуҗалыгы яки сәнәгать өлкәсендәге күрсәткечләрдән бигрәк, беренче чиратта, халкыбызның рухи өлкәдәге казанышлары кызыксындыра. Интеллектуаль дөньяда горурлык байрагы булырлык шәхесләр—әдәбият-сәнгать, фән-гыйлем каһарманнары кирәк аларга. Уйландыра: тагын ун, егерме, утыз елдан татар әдәбиятына кемнәр килер? Каян? Кемнәр сәхнә тотар, музыка иҗат итәр? Бу яктан хәлебез бик үк мактанырлык түгел. Татарча укып, татарлыкны сендереп үсүчеләр даирәсе кысыла бара. Россия төбәкләреннән яңа Такташлар, Җәлилләр, Кәрим Тинчуриннар, Рәшит Ваһаповлар, Җәүдәт Фәйзиләр килүгә исәп тоту читен. Татарстанда да вәзгыять үзгәрде, яңа Гомәр Бәшировлар, Сибгат Хәкимнәр, Илһам Шакировлар бик күренеп тормый. Аяз Гыйләҗев әйтмешли, өмет белән өретелгән яшьле күзләр аша киләчәккә—яшьләргә карап торабыз. Минемчә, хәзер яшьләрне житди, дәвамлы иҗатка җәлеп итәр өчен бик тә абруйлы гамәлләр кирәк. Бу, әлбәттә, һәммәбезгә карый. Әмма бүгенге көндә Сезгә күбрәк карый. Ни өчен икәне аңлашыла. Сезнеңчә алар нинди гамәлләр була ала икән?**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Безне ничек кенә тәнкыйтьләмәсеннәр, татар яшьләре арасыннан иҗат шәхесләре, зыялылар әзерләү, аларга ярдәм итү юнәлешендә берни дә эшләнми дип әйтү урынсыз булыр иде. Менә Татар дәүләт гуманитар университетын булдырдык. Аның педагогика университеты нигезендә оештырылуы да дөрес дип уйлыйм, чөнки тарихы, тәҗрибәле укытучылар, галимнәр коллективы бар. Без гыйлем юлына капканы ачып, төзеп куйдык, мөмкинлекләр тудырдык. Ә хәзер кинәшик, ничек эшлибез, яшь егет һәм кызлардан нинди иҗат төркемнәре туплыйбыз, бездән тагын нинди ярдәм кирәк? Без бу юнәлештә хезмәттәшлеккә әзер. Казанда консерватория, Мәдәният һәм сәнгать университеты һәм башка мәдәният уку йортлары эшли. Димәк, нигезебез бар безнең. Хәзер эш унганлыгыбыздан, кулга-кул тотышып эшли алуыбыздан тора.

Президент әйткәнне көтеп тормыйча эшләнә торган нәрсәләр дә бар бит ул. Мәсәлән, Театр әһелләре берлеген карагыз. Әле ишетеп торам, кышкы салкынга карап тормаганнар, Шәхсәнәм Әсфәндиярованың каберенә чәчәкләр салырга барганнар. Башка иҗади берлекләр өчен күркәм үрнәк. Чөнки Хәтер һәм Дәвамчылык янәшә йөри. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрын инде телгә алып киткән идем. Аларның төп принципларыннан берсе — дәвамчылык. Безнең күз алдыбызда: Хәлил Әбҗәлилов, Хөсәен Уразиков, Фатыйма Ильскаялар буынын Празат Исәнбәт, Асия Галиева, Шәхсәнәм Әсфәндияровалар буыны алыштырды. Соңрак, Щепкинчылар—Равил Шәрәфиев, Нәҗибә Ихсанова, Әзһәр Шакировлар... Алар белән бергә диярлек—Наилә Гәрәева, Наил Әюпов. Алардан соң театр Рамил Төхфәтуллиннар буынын тәрбияләде, хәзер инде алардан да яшьрәк Искәндәр Хәйруллиннар буыны сәхнә тота. Менә шуңа күрә 100 ел яши дә ул безнең театр, иманым камил, әле 200 ел да, алга таба да яшәр. Шуңа күрә дә аларның киләчәгенә ышанычлы.

Игътибар иткәнсездер, әңгәмә барышында мин берничә тапкыр бергәләп эшлик, фикерләшик, уйлашыйк дип әйттем. Моны үзенә тиешле эштән баш тарта дип аңламагыз. Минем мәдәниятка, сәнгатькә мөнәсәбәтем барыгызга да мәгълүм. Әңгәмәдән күренгәнчә, фикерләребез уртак. Ахыр килеп, без һәммәбез үз урыныбызда иҗат итәбез түгелме соң? Эшкә ныклап керешер өчен безгә нинди дер импульс житми, мөгаен. Әйдәгез, безнең шушы әңгәмә киләчәк гамәлләргә этәргеч булсын! Әмма ул журнал битләрендә генә калмасын иде. Бу әңгәмәдән соң иҗат әһелләрендә, гомумән, әдәбиятка, сәнгатькә битараф булмаган кешеләрдә күп фикер-тәкъдимнәр туар дип уйлыйм. Минем янга җыелып, ул фикерләрне уртага салып сөйләшергә кирәк безгә. Минем тарафтан Сез көткән абруйлы гамәлләрнең берсе шул булсын!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН: Сезнең сүзләрдән соң моннан утыз еллар элек язган шигырь юллары хәтергә килде. "Кирәк безгә!" дип атала ул. Кайбер юллары безнең әңгәмәнең рухына туры килә шикелле.**

*Тәкъдир шундый: бик аздан да*
*Олы шатлык*
*таба алырга,*
*сөенергә кирәк безгә.*

*Олимп уты ягар чакта,*
*сүнеп барган учагыңа*
*тын өрергә кирәк безгә.*

*Заманга иш булыйм дисәң,*
*Кем бер янса—*
*ун яшьнәргә,*
*ун янырга кирәк безгә.*

*Тормыш дигән халыкара Сабантуйда*
*батыр булып*
*калалырга кирәк безгә!*

**Илбашлары белән еш очрашып булмый. Һәркемнең үз эше, үз миссиясе. Мондый әңгәмәләр үткәрүдә тәҗрибәм аз. Шуңа күрә сорауларым да озынрак, киңәшләшү-уйлану рәвешендәрәк булып чыкты. Шунысына сөенәм: күңелдәгесен әйтеп, ихлас сөйләштек. Ышаныч артты. Үзегез әйтмешли, фикерләребез уртак. Димәк, Әдәбият һәм сәнгать елы да дәвамлы булачак, алга таба да һәр яңа ел иҗатчыларга ихтирам һәм игътибар еллары булачак. Шулай булырга тиеш тә! Әгәр кеше рухи яктан бай, көчле икән, андый зат тормышта да үз урынын тизрәк таба, дәртләнеп хезмәт тә итә, бәхетле дә була. Без шуның өчен яшибез түгелме соң? Рәхмәт Сезгә!**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:** Сезнең шигырьне болай дәвам итәр идем:

*Ниятләгән зур эшләрне*
*Булдырырга кирәк безгә!*

Үзегезгә зур рәхмәт. Күптән күңелемдә йөргән уй-фикерләремне дөньяга чыгардыгыз. Барчабызга исәнлек-саулык телим. Иҗат уңышлары юлдаш булсын!

*февраль, 2006.*



Мөхәммәт
Мирза

# РОБАГЫЙЛАР

* * *

Эшлексезнең төп шөгыле—сафсата,
Эш башлардан әүвәл ул акыл сата...
Ук алмаслык аралыкта—ерак тор:
Хакыйкатьтә ул агулы ук ата...

* * *

Ишек, тәрәз уелмаган тикмәгә,
Үзеңне дүрт дивар эченә бикләмә:
Син ишет, күр—киң вә якты бу дөнья,
Күрә торып, киләчәгең чикләмә.

* * *

Хак бүләге—һәрнәрсәнең үз төсе,
Яз, көз, җәй, кыш үзгәрмәктә—күп төсе.
Камиллекнең булсын дипме өлгесе,
Күзләрең ул зәңгәр иткән—күк төсе?!

* * *

Белмәс иде һичкем югың, барыңны,
Чәчеп йөрмәсәң дөньяга зарыңны.
Инде белдек—танылмакта ниятең:
Күпертеп, борчак ясамак тарыңны...

* * *

Әйтерең хаклыгын әүвәл ачыкла:
Кылчыклы булмасын бәян, ашыкма...
Даһи иҗат—түгел тары боткасы,
Кабып йотып булмый салып кашыкка...

Мөхәммәт МИРЗА (1953) — *шагыйрь; "Турайгыр", "Киек каз юлында", "Кәккүк тавышын санадым" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Җан биргәнгә җүнен биреп тора гел,
Гамәлләрне саваплыдан кора гел:
Ирешергә теләсәң нәрсәгәдер,
Фатихасын Раббыңның сора гел.

* * *

Шөкерана кылу фарыз—барына,
Теләгәндә сыеп була тарына...
Бер алдын, бер артын күрсәтер дөнья:
Күтелмәгән газапларга тарыма...

* * *

Бу дөньяның бердәнбер "Мин"нәре күп...
Һәрберсенең бәхетле "Миң"нәре күп...
"Миң"ле "Мин"нәр арасында тагы да
Мин-минлеге азганга тиңнәре күп...

* * *

Тыңласаң, бетәсе түгел—күп хәбәр...
Хаклыгына төшенәм, дисәң әгәр:
Кемнән чыккан сүз?—ачыкла иң әүвәл:
Бәһасе—сөйләүчесенә бәрабәр...

* * *

Вәгазьчеләр күп үрчеде—исәпсез...
Авызлары гөрләп тора, и шәп сүз...
Ул вәкарьлек Имамында!—һич тә сез
Кичәге ата коммунист, димәссез...

* * *

Алынганчы бер-бер эшкә, уйла син,
Ният кылсаң, инде читкә куйма син.
"Бер тарыдан ботка пешерә" заман:
Шул тәгамнән өлешеңне җуйма син...

* * *

Маллы һәрчак билдән биек сикерә,
Кирәк—таба, җитеп җирнең читенә...
"Барлык", "юклык"—фани дөнья ваклыгы,
Җанның ни хаҗәте—елан итенә?..

* * *

Ягылмаган мичкә арка куймыйлар,
Корылмаган йортка ишек уймыйлар.
Буш хыялдан арына алмаганнар
Аркылыны буйга алып куймыйлар...

* * *

Фатиха—гади сүз, җөмлә түгелдер...
Әйткәне—тел, әйттергәне—күңелдер...
Ирешсеңгә җиде буын катына—
Чын мәгънә биеклегенә үрелдер...

* * *

Чүп чиләге—иң кирәк бер әсбаптыр,
Булмаса шул—дөньяның өстен-астын
Нәҗес басар... Тик шулай да тормышта
Чүп чиләге булудан син ерак тор!..

* * *

Гадел хисап лязем мирас бүлештә.
Нәфес-шайтан котыртыр, бел, бирешмә...
Һәм бел шунсын: ызгыштырыр барысын,
Әгәр бер хатын кысылса бу эшкә...

* * *

Туган туганнан бизенә—мал тапса,
Ишеген ача—тик үз ише какса...
Дуслар бизә беркөн—барын югалтса,
Үзе туган тупсага килеп баса...

* * *

Чиксез иде көч-куәте, гайрәте,
Төзек иде, тигез иде дүрт саны.
Инде дөнья чәчеп йөри гайбәтен—
—Бер-берсен ашый татар!..—дип, нәкъ аны...

* * *

Гомер итү—бер катлаулы җөмләдер:
Ымлык, кисәкчәләр сүзгә теркәлер...
Сан—сыйфатка әверелер, мәгънәгә,
Исемне—биеклегенә күтәрер...

* * *

Ул мәкам, ул ыспайлык сүзләмәктә:
Гашыйк итәр ишеткән тәү сәгатьтә...
Рәвешенә әйтмәс һичкем кайтыш сүз—
Мәгънәсе бер тиен тормаса хәтта...

* * *

Йомышлы булсаң да, йогышлы булма...
Яллыга ялланып, юк эшле булма.
Үлгәч булса да җавап тотарсың;
Азгын уйнашчыга йомышчы булма...

* * *

Бәләкәйдән даулап алдың барысын,
Йомырканың хәтта гел куш сарысын.
Алтмышыңда да алтыда калырсың:
Тар түшеңә калай тәтәй тагырсың...

* * *

Әдәплелекнең шома битлеген каплап,
Төп-төз басып, йөрисең кыек атлап...
Дөнья чүбен чөям дисең күтәреп,
Чәнечкеңә сәнәк саплыгын саплап...

* * *

Язганнары гел урта кул югыйсә,
Даһилыкка дәгъвасы зур бихисап...
Шәп күтәрә үзен, табып җай-исәп,
Нишләр—дөнья үзгәреп китсә кисәк?!.

* * *

Күп белдеклеләр күп булган элек тә...
Үзгә фикерне тормаган элеп тә...
Барсын бергә җыйсаң да тиң булалмас:
Син—бөекләр бөеге мин-минлектә...

* * *

Милләт, динең мәнфәгатеннән биздең,
Дөнья рәхәтендә шул хакка гиздең...
Фиргәвенгә тиң зурлап озаттылар...
Хак каршына килеп басарсың тиздән...

* * *

Көтмәгәндә, буең җитмәс биеккә
Күтәрерләр, сынап карыйк диеп тә...
Гамәлләрең чагышмаса чамаңа,
Мәтәлерсең бер чыра-ук тиеп тә...

* * *

Түгелгән тир микъдарына бәрабәр
Бөртек белән билгеләнгән бәһаләр...
—Бер телем,—дип теләнмәсме бер көнне
Бүген хакын тиен иткән бәндәләр?

* * *

Ал, җаный, ал йөрәгемне учыңа,
Синең учыңа төшәм дип очына...
Үпкән-кочкан җилгә очкан,—дисеннәр...
Җилнең аның җаны да юк, учы да...

* * *

Әле куеныма алып җылыталам.
Әле үзем дә куеннан җылы табам...
Шул рәхәтнең газабыннан аермасын...—
Әле көнләп, көнләштереп яраталам...

* * *

"Галиләр күп, мин—Галиләр Галие,
Сүз сөрешенең Хәйяме, Кол Галие",—
Дип, инанган үзе турында үзе.
Баксаң—гап-гади тәмуг Галилие...

* * *

Киңәшенә һичберкемнең карамый,
Икеләнми: ярый, дип, йә ярамый...
Мәртәбәле исемнәрнең барын да
Алып бетергән үзенә—хәрами...

* * *

**Синдәй шәпләр булып киткән элек тә,**
**Үзгә фикерне тормаган элеп тә.**
**Шуңар истә калган тик гадәтләре,**
**Исемнәрен һичкем әйтми, белеп тә...**

* * *

**Көрәшәмен,—дисең,—үзем аямый,**
**Милләт дисең, халкым, дисең һәрдаим...**
**Шәһәр саен—ташлап качкан гаиләң...—**
**Ишетмисең вә күрмисең ай-ваен...**

* * *

**Тормыш—диңгез, йөздем дисең аркылыга,**
**Тиңләп үзеңне иң киме—акулага...**
**Авыз ачып тыңлап торыр идек тә бит:**
**Фәлсәфәң сай—таңгал килька акылына...**

* * *

**—Ал,—дисәң дә, алырга һич ашыкмый!**
**—Кап,—дисәң дә, читкә этә кашыкны...**
**Тыштан боз да, эчләрендә янартау:**
**Хәлен һичкем аңлый алмый гашыйкның...**

* * *

**Антлар эчеп, тугрылыкка алындык,**
**Даһилар дип, җаһилләргә табындык... —**
**Аяз көнне тигез юлда абындык.**
**...Без шул — тулаем шайтанга кабымлык...**

* * *

**Әйткән сүз — атылган ук — ни шәп бәя,**
**Кемнәргә атыйм дип алдың җәя?..**
**Тияре — колак булса да, төшәре —**
**Йөрәкне өшеттерерлек киная...**

* * *

**Тәвәккәлнең төп шөгыле — таш вату,**
**Ничекләр ватыйм икән? — дип, баш вату.**
**Зирәкнең төп шөгыле — шул ташларны**
**Тәвәккәлләрдән ваттыра башлату...**

Марат
Әмирханов

# И, КЫЛГАН ДОГАМ МИНЕМ...

ПОВЕСТЬ

БИШЕНЧЕ ТАСМА

## Мәхбүс

Гадәттәгечә, калын тимер ишеккә уелып ясалган тәрәзә капкачын бүген дә дөбер-шатыр китереп ачтылар. Иң аргы почмакта аркасын стенага терәп утырган Байтимернең җыры ярты юлда киселде. Хәер, аны җыр дип тә әйтеп булмый. Ул һаман шулай үзенең "почмагы"нда көнозын авыз эченнән нидер көйли, моңлана. Сагынулары моң булып чыга, күрәсең. Баштарак күңелгә тия иде, тора-бара күнегелде тагын. Әйттең ни, әйтмәдең ни, барыбер үзенекен эшли. Бездә "Кире башкорт" дигән әйтем бар иде. Әлеге әйтемнең хаклыгына шушы ерак алман илендә тәмам ышандым.

—Әбәт!—дип оран салды аш таратучы.

Сәгать көндезге бер икән. Монда аш таратучыга карап сәгатьне дөресләргә мөмкин.

Без ашыга-ашыга әлүмин җамаякларыбызны тотып, тәрәзә янына килеп бастык. Ризыксыз да калуың ихтимал, монда ике сөйләшеп тормыйлар, шап итеп тәрәзә капкачын ябып кына куялар. Һәр гамәл эчке тәртип кагыйдәләре нигезендә минуты-секунды белән нәкъ вакытында башкарылырга тиеш. Таләп катгый. Ул башкарылырга тиеш гамәлләр көннән көнендә бернинди үзгәрешсез кабатланып тора. Сәгать алтыда йокыдан уяталар. Юынабыз, парашаны чыгарабыз, камераны җыештырабыз. Сигездә—иртәнге аш. Бердә әбәт ашыйбыз. Дүрттә—саф һавага алып чыгалар. Җидедә—кичке аш. Аннан соң бер сәгать сәяси дәрес, фюрер хезмәтләрен өйрәнәбез. Унда—йокы. Болар барысы да төгәл үтәлә. Чын мәгънәсендәге классик төрмә бу. Услаптай тап-таза ир-егетләр ич без, күбебез. Камерадашларым алтау. Байтимер белән үзбәк кешесе Хәмзә акәдән кала, барыбыз да буйдаклар. Байтимер сугышка кадәр үк өйләнеп, биш бала әтисе булырга да өлгергән. Уналты яшендә башлы-күзле иткәннәр үзен. Аңлашыладыр, камерабыз мөселманнар камерасы. Төрмәдә мулла да бар. Ул ике көнгә бер мәртәбә кереп, вәгазь укып чыга, догалар өйрәтә. Үзе төрек милләтеннән.

*Дәвамы. Башы 1 санда.*

* * *

Эрна китеп, ай ярым чамасы вакыт узгач, бер көнне кичләтеп кенә мин яшәгән келәткә Смирнов килеп керде. Аптырап киттем. Чөнки аның монда беренче тапкыр күренүе иде. Мин үзем дә бимазалап йөрүен теләмим. Һәрхәлдә, хуҗа кешенен күзеннән ераграк тору мәслихәт.

Смирнов ничектер күлен таба алмаган бака шикеллерәк тоелды. Күзләре дә уйнакламый. Башка вакытта учактагы куз шикелле көйрәп тора ич аның бәбәкләре. Бер карауда үпкә-бавырларынны айкап чыгара. Борчулы димме, басынкы иде агай. Эрна өчен борчылдымы икән? Хәер, мин ана кем сон? Ник дип әле ул мина эч серләрен бушатсын ди. Хәлбуки, шушы ут кеше дә кызы белән ялчысы арасындагы якынлыкны сизенми калды бит, әй. Сизенгән булса, Сафура бураннары чыгармый калмас иде. Эрнага каты бәрелергә кыймаган очракта да, бөтен гаепне мина аударып, үч алу берни тормый иде ана. Һичьюгы, эт урынына тәпәләп, кире лагерьга илтеп ташлый ала иде.

Курт эшләпәсен салып чөйгә элде дә, ин түрдәге урындыкка килеп утырды. Берара бармакларын өстәл өстендә биетеп торды. Шуннан сон гына:

—Иртәгә безне полициягә чакыралар,—диде.

—Лагерь комендатурасынамы?—дип кайтарып сорадым. Чөнки әсирнен полиция белән нинди мөнәсәбәте булсын икән.

—Полициягә дип торалар ич, һундук,—диде хуҗа бүртенеп. Тик үзе шунда ук кайтып төште. “Кая, стаканың бармы?”—дип кесәсеннән җәлпәк шешә чыгарып өстәлгә куйды. Икебезгә яртышар касә шнапс чыкты. Ул аны авызына каплап кына куйды. Мин дә ана иярдем.

—Полициядә артыгын сайрап ташлама, аң бул,—дип кисәтте хуҗа.—Авызынны ачканчы минем күзләремә кара, анда барысы да язылган булыр.

Кырын гамәлләрен бар, ахры, агай, югыйсә болай коелып төшмәс иден, дип уйлап куйдым. Ялчысына шнапслар тәкъдим итәрлек булгач, эшен хөрти димәк ки. Бераздан үземне дә курку басты: мине нигә чакыралар икән сон? Хуҗаның кыек-мыек хәлләрендә бер катышым да юк лабаса.

Ләкин... Куртнын хакимият каршында гаебе булгандырмы-юктырмы, анысы мина караңгы. Әмма гоманнары туры килмәде. Аны да аңларга мөмкин, әлбәттә. Сугыш чорында полициягә чакыру һич тә уен-муен эш түгел. Смирновтан күпкә дәрәҗәлерәк саф канлы немец агаларынын да башларын очыргалап кына торалар ич.

Округ полиция идарәсенә чакырылган вакыттан шактый иртә килеп җиткәнбез. Яшел төскә буялган тимер капка янында шырпыдай төзгә каткан сакчы хуҗа биргән документларны күзеннән кичерде дә, борын төбендә капканы шап итеп бикләп тә куйды. Әйтерсен лә, без полиция йортына басып керергә чамалыйбыз.

—Бер сәгатьтән сон килерсез,—диде сакчы эре генә. Эрелек, тәкәбберлек тә немецларга хас сыйфат. Аларнын урам себерүчесе дә үз урынында үзен ин зур түрәләрчә тота. Әнә, ил белән элекке ефрейтор идарә итә ич.

Смирнов кыбырсык кеше, бабасырлы бала сыман тик кенә утырып тора алмый. Әле дә түземлеге төкәнде. “Син атны караштыр, мин әйләнештереп килим әле”,—дип, каядыр китеп югалды.

Атның нәрсәсен караштырасын инде анын. Аркалыгы төшерелгән, авызлыгы алынган, солы капчыгы башына эленгән. Бераз тире катсын дип җаймәсен япмаган идем. Хәзер кипшенгән, ябарга да була.

Бахбай керт-керт итеп солысын чәйни, мин тирә-якны манзара кылам. Дөресрәге, полиция йортын күзәтәм. Бина ике катлы. Зур, саллы. Тәрәзәләре генә анын үлчәменә туры килми. Кечкенәләр. Күрәсен, саклану чараларын күз уңында тотып салганнар. Күршесендә башка корылма юк, үзенә бер ябык утрау. Монысы да шул максаттандыр, мөгаен. Кереп-чыгып йөрүчеләр

шактый, тоткарланып тормыйлар, кергәне кереп югала, чыкканы тиз-тиз элдерту ягын чамалый. Килгән-киткән полицискийларның барысы да мотоциклга атланган. Ара-тирә җиннәренә СС билгесе тегелгән гестапо кешеләре дә күренештерә. Кыскасы, мыж киләләр. Ниндидер мөһим дәүләткүләм эш башкара ич инде болар. Әнә, Смирнов агайны да шул орбитага тартып кертмәкчеләр. Әтдөнья хәйләтен, Әндри Михайләтен диярсең. Мине, кирәге чыга-нитә калса дип, хужа үз белдеклелеге белән генә иярткән булырга охшый. Югыйсә, ни хаҗәткә кирәк мин немец полициясенә? Лагерьда булса бер хәл иде. Ә анда, хак булса, мөселман легионы оештыралар ди. Бозау караучының туганы лагерьда эшли икән, шул әйтте. Ятма монда тизәк арасында, барып легионга языл, ди. Дәрәҗәсе дә бар, трофейга да төенерсең, ди. Аяк-кулларым сау булса, үзем дә шушы килмешәккә арка бөгәр идемме соң, солдатка китеп барыр идем, ди.

Немец кешесе өчен, ихтимал, шулайдыр да, мин бит әсир. Үз илем, үз ватаным, үз туган җирем бар. “Азиат”ларны менә ни өчен бер лагерьга тутырганнар икән. Атасын атып, асасын асып, чирләшкәләр үзләре кырылып беткәннән соң, әнә, чират легионга җиткән. Эшли, каһәр, немецның башы. Тамак тәмугка кертә ди, ач кешегә ипи күрсәтсәң, әллә нәрсәләргә ризалашыр.

...Тыны-көне бетеп, Смирнов килеп җитте. Ләкин идарәнең зур ишеге өстенә эленгән сәгать буенча тагын ун минут көтәргә кирәк иде әле.

—Маллар нишли икән анда, бөтен эш чуалды шайтан,—дип сукранып куйды хуҗа.

Вакыты җитүгә, сакчы тимер капкасын ачып, безне ишек алдына кертеп җибәрде. Бина эчендә дә сакчы каршы алды. Сакчы өстендә сакчы. Анысы тентеп, документларны кабат тикшереп, кайсы кабинетка керергә икәнен өйрәтеп җибәрде. Иләнә торгач, нинди дер кабул итү бүлмәсенә килеп эләктек. Монда үз иләкләре. Башта утырттылар, аннан соң исем-фамилияләребезне бер калын журналга теркәп куйдылар. Үзе өчен дә, минем өчен дә хужа сөйләшә. Ләкин ике катлы имән ишек тарафындагы бүлмәгә безне аерым-аерым чакырдылар. Шәрә башын ялтыратып, иң беренче Смирнов элдертте. Ул озак тормады, ун минут дигәндә (мин стена сәгатеннән карадым) әйләнеп тә чыкты. Кешелеге беткән иде хужаның. Йөзе мәетнеке шикелле ап-ак, күзләре тонган, куллары калтырана...

Искәрмәстән шул калтыранган куллары белән муенымнан эләктереп тә алды бу. Буыпмы-буа.

—Һундук, кандала урынына сытам бит, һовна...

Секретарь кыз сакчыларны чакырды, күрәсең, Куртны бөтереп алып, бүлмәдән алып чыгып киттеләр. Берара коридорда аты-юлы белән сүгенгәне ишетелеп торды.

Инде тикшерүче каршында мин басып торам. Ләкин әле һаман тынычланып житә алмыйм: тез буыннарым дер-дер калтырый, чүгеп-чүгеп китәм. Ә башымда, хужага минем хакта нинди начар сүз житкерде икән бу, дигән уй кайный.

Тикшерүче хатын-кыз икән. Яшь нәмәстә. Хәрби кием дә ыспай гәүдәсендә бик килешле утыра. Тик йөзенә карамаска мең тәңкә бирерсең. Карашы усал. Бу немец кызларының барысы да шундый, ахры, шайтан камчылары. Әллә күзгә төтен җибәрүләре генәме? Эрна да башта котны алган иде бит.

—Әй, сасы азиат, ничек итеп Гитлерюгенд оешмасының актив әгъзасы Эрна Вальдхаймны көчләргә батырчылык иттең син?—дип күкрәгемә суд хәнҗәрен батырды тикшерүче. Ул рус телендә сөйләшә иде.

Шыр җибәрдем. Күз алдымда әллә нинди кара шәүләләр биешеп алды. Иске авыздан яңа сүз дигәндәй, нинди көчләү ди ул? Алайга калса, Эрна үзе

мине көчләде! Менә ни өчен котырынган икән Смирнов? Кызынны батрагын көчләгән дип ышандырган аны димәк ки тикшерүче. Бөтен гаепне минем өскә аудармакчылар. Һәм аударалар да. Аларнын сүзе сүз. Фашист рус әсирен якламас ич инде. Монын ахыры ни белән бетәсен белү өчен һич тә әүлия булырга кирәкми. Җә ходай, тагын ниләр күрәсем бар икән?

—Мин Эрнаны көчләмәдем,—дидем кыюсыз гына. "Ул үзе башлады", дип өстәмәкче идем дә, тыелып калдым. "Егет бул, Хисам, хатын-кыз өстеннән тору ир-ат өчен хурлык ул",—дип кисәтте эчке бер тавыш. Дөрестән дә, кем башлаган, ничек башланган—хәзер инде анын әһәмияте юк. Эрна белән сөешеп, яратышып, бербөтен булып үткәргән ул бер атна вакыт минем ин бәхетле көннәрем иде. Әсирлекнен ана бернинди катнашы юк. Бәхет сорап килми, өстенә ишелеп кенә төшә. Бәхет шулай ук озакка да сузыла алмый, ул мизгелләрдән генә тора.

—Сафсата сатма,—дип өстәлгә китереп сукты тикшерүче,—мин Эрнага тулысы белән ышанам!

Күрәсен, Эрна инде монда булган. Ни хажәте чыкты икән? Ирекле баштан ярәшелмәгән кыз бала көчләнүе хакында полициягә мәгълүмат бирмәс бит инде. Бәлки, кулын сорыйлардыр? Бәлки, ирләр якасын яшьли исни башлавын каплап калу өчен уйлап табылган уйдырма гынадыр әлеге тамаша? Шулай да гаепне тулысы белән үз өстенә алырга кирәкми. Барыбер минем сүзгә карап тормаячак алар, үзләренчә хәл итәчәк. Шуна күрә:

—Минем гаебем юк,—дидем.

—Ә ул корсак җилдән тулганмыни?

—Корсак?

Эрна балага узган, күрәсен. Тик, әгәр ул чыннан да миннән икән... Бәхет ләбаса бу!

—Шатланырга ашыкма, йолкыш, немец кызы, ә Эрнанын әнисе саф арилар нәселеннән, азиаттан бала таба алмый! Алмый!!! Эрна баласын төшереп, үзенен чын патриот икәнен раслады. Молодец!

—Герр капитан...

Тикшерүче янә бәбәкләре белән мина кадалды. Дерт итеп киттем, әйтерсен лә, электр тогы сукты.

—Закон буенча Германиядә бала төшерү тыела,—дип тезеп китте ул,—әмма мәсьәләнен сәяси ягын истә тотып, Гитлерюгенд житәкчелеге Фюрерга мөрәҗәгать итте. Фюрер Эрнаны ярлыкады...

Тикшерүченен сүзен телефон шалтыравы өзде. Ниндидер түрә иде булса кирәк, бүлмә хуҗасы аны "яволь" дия-дия аягүрә басып тынлады.

—Ун минуттан килеп житәм, штандартенфюрер әфәнде. Хайль Гитлер!

Трубканы куюга, ханым кынгырау төймәсенә басты. Шул ук мизгелдә бүлмәгә сәркәтип кыз атылып керде. Ул да хәрби формадан иде. "Хайль Гитлер!" дип уң кулын алга сузды.

—Хайль Гитлер!

—Тынлыйм,—диде сәркәтип.

—Хәзер үк машинаны чакырт, ун минуттан мин штандартенфюрер янында булырга тиеш!

—Ә син, азиат, жинаятен өчен жавап тотачаксын,—диде тикшерүче папкасына кәгазьләр тутырган арада,—прокурор эш кузгатты инде, алда—суд!

* * *

Эшне коры тотты фрейлин. Өч көннән суд залына алып килделәр. Кем әйтмешли, барысы да чин по чину иде: җилкәсенә кара мантия салган судья, прокурор, адвокат, шаһитлар, тәржемәче—һәммәсе бар. Калган урындыклар гына буш. Нишләптер Смирнов та күренми.

Иң гаҗәбе, судта Эрна юк иде. Мин аны бик көткән идем. Үзен ничек тотуы бик кызыксындыра иде. Дәгъвачы лабаса ул. Ләкин немец юриспруденциясенә бу яктан да тел-теш тидерә алмыйсың. Законны бозмадылар, дәгъвачының ышанычлысы катнашты. Имеш, мораль-этик мәнфәгатьләрдән чыгып, суд зыян күргән якның үтенечен канәгатьләндерергә хаклы.

Шаһитлар дигәне—өч хатын-кыз. Мин күргән-белгән затлар түгел, кайдан чокып чыгарганнардыр. Эрнаны кунактан алып кайткан чагында, янәсе, алар урманда булганнар. Минем ничек итеп кызны күтәреп куаклар арасына алып кереп китүемне, Эрнаның йөрәк өзгеч тавыш белән ярдәм сорап өзгәләнүен күреп-ишетеп торганнар. Ләкин якын килергә кыймаганнар, үтереп ташлар дип курыктык, диләр. Эрнага да, телеңне тыймасаң, утарыгызның көлен күккә очырачакмын, дип янаганмын, бу хәлне кешегә чыгармаска, дип сүз бирдергәнмен.

Мине җиде елга ирегемнән мәхрүм иттеләр. Прокурор тугызны сораган иде. Адвокат чыгышыннан соң, төрмәдә булу вакыты ике елга кыскарды. Үзенә күрә, компромисс.

Нигә кирәк булды икән әлеге фарс? Бу хакта шактый баш ваттым мин. Бөек Германиянең демократик ил булуын дәлилләү өчендер, бәлки? Һич очына чыга алмыйм. Шулай да уйлана торгач, асылына төштем бит тәки. Суд Эрнаның намусын саклау өчен оештырылган лабаса! Әйе, әйе. Хак шулай. Ари кызы үз ирке белән ниндидер кыргый азиат әсирен кочагына кертә ала димени? Үз араларында Эрнаны талкыганнардыр, билгеле, ләкин абруен рәсми дәрәҗәдә бик нык күтәрделәр. Безгә, татарларга, көнләшергә генә кала.

Ә ул вакытта күңелемне бармакка кадалган шырпы кебек икенче бер аңлашылмаучылык тырнап тора иде: хәрби әсирнең эшен граждannар суды карый аламы, аның карары гамәли көчкә ияме? Шуңа бәйләнешле тагын бер нюанс, судья миңа "Германиядә вакытлыча яшәүче" дип мөрәҗәгать итте. Бу нинди термин? Нәрсәне аңлата?

—Минем шәхси юридик статусым кызыксындыра, шуны аңлатыгыз әле, зинһар,—дип үтендем судьядан.

Судья калын иренле, юантыгырак кеше. Чәчләренә инде чал кунган. Утырышны бар кагыйдәләрен туры китереп алып бара.

—Суд сезнең юридик статусыгызны ачыкларга түгел, кылган җинаятегезгә хокукый бәя бирергә җыелды,—диде ул үтә дә рәсми тон белән.—Соравыгыз көн тәртибенә ярашмый.

—Алай да минем якланучы җавап алырга хокуклы,—дип сүз кыстырды адвокат.

—Тәкъдимегез кабул ителә,—диде судья адвокатка. Аннан соң миңа таба борылып төшендерде,—сезгә Германиядә вакытлыча яшәүче статусы бирелгән. Хокукларыгыз шуннан чыгып тәгаенләнә. Сез ирекле шәхес. Шуңа күрә эшегезне граждannар суды карый. Тик сезне порукага алганда Смирнов әфәнде шундый шарт куйган, аңа өч ел буе түләүсез хезмәт итәргә тиешсез.

Әгәр әлеге хәл килеп тумаган булса, ихтимал, мин үземнең әсирлектән азат ителгәнемне белми дә калган булыр идем. Смирнов батраклыкта тоту өчен мине тоткынлыктан азат иткән. Һәм минем кебекләр ул чакта Германиядә шактыйга җыелган булган. Бу хакта мәгълүмат күп хәзер. Берәүләр аны хуплый, дөресрәге, бичарага ни чарадан килеп туган хәл дип аңлата. Икенчеләре бар сәбәпләрне дә инкарь итә, андыйларга хыянәтче тамгасы тага. Ә тормышның үз кануннары. Ул аерым кысаларга гына сыймый шул. Әсир тунын үзе киеп караган кеше генә белә чын дөреслекне.

Совет кешеләренең үз ватанын яратуы, аның өчен соңгы тамчы канына кадәр көрәшергә әзер торуы хакында ул елларда бөтен ил шаулады. Көнозын

радио шуны тәкрарлады, газета-журналлар зур-зур мәкаләләр багышлады...

Һәм... аяз көнне яшен! Тарихка "Курск дугасы" дигән исем белән кереп калган орыш аның ачык дәлиле. Билгеле булганча, Сталинград янында жиңелүгә дучар ителгәннән соң, Гитлер Курск, Белгород юнәлешендә реванш алмакчы була. Яхшы коралланган "Үзәк" һәм "Көньяк" армия төркемнәренә һөжүмгә күчәргә боера. Тик монысында инде минем үз язмышымны да челпәрәмә китереп ташлаган Харьков фажигасе янәдән кабатланмый. Үзәк, Воронеж фронтларының башлыклары Рокоссовский һәм Ватутин житәкчелегендәге армияләр һөжүмне кире кайтаралар. Ә 1943 елның июль аенда Совет гаскәрләре үзләре немецның бугазыннан ала.

Әлеге жиңелүне Сталинградтагы шикелле һич тә генерал Морозга сылтап булмый иде инде. Чөнки—жәй уртасы! Хәтта, әнә, фюрер зур ышанычлар баглаган илле алты тонналы "Тигр" танкларыннан кырда тимер тау өемнәре генә утырып кала. (Күптән түгел генә бер гәжиттән укыдым, әлеге мәшһүр танкның хәзер дөньяда дүрт кенә данәсе исән ди. Берсе Россиядә, имеш. Бик зур реликвия санала икән. Шулай булмыйча, хакы гына да бер миллион доллар бит! Бездәге "Тигр"нын иясе дә табылган инде. Курск янында "тау өеме"нә әверелгән танк командирының улы Отто Зайдель дигән адәм, танкны үзебезгә, Германиягә кайтарыгыз дип дәгъвалый икән.)

Немецлар күпләп-күпләп әсир төшә. Араларында, ни гажәп, ватандашларыбыз да шактый була. Үз солдатларыбызның үз гаскәрләребезгә кул күтәреп бирелүе беренче мәртәбә шушында күзәтелә. Баш командующий даирәсе аны аяз көнгә яшенгә тиңли. Сталин әлеге хурлыкны бик авыр кичергән, төкерекләрен чәчә-чәчә тузынган.

Алманнар минем кебек "вакытлы"ларны үзара "хиви" дип йөртәләр иде. Бу сүз ирекле ярдәмчеләр дигән мәгънәне аңлата. Янәсе, без Бөек Германиягә үз теләгебез белән булышабыз. Хивилар хәрәкәттәге армия сафларында да булган. Тик аларга мылтык тоттырмаганнар, күбесенчә тылдагы подразделениеләрдә хезмәт иткәннәр. Шофер, тимерче, итекче, ат караучы шикелле вазифалар башкарганнар. "Курск дугасы"ндагы сыман өер-өер әсир төшүчеләр бөтенләй икенче, алар—армия. Рус азатлык халык армиясенең кансызлыгы хакында, мәсәлән, легендалар йөри. Ул колхозлашу елларында Орел һәм Брянск якларында большевикларга каршы көрәшкән партизан отрядларының калдыкларыннан оешкан. Соныннан СС РОНО гренадер дивизиясе итеп үзгәртелә. Командиры Каминский атлы адәм тыныч халыкка карата күрсәткән коточкыч ээзрлекләүләре өчен ССның үз хәрби-кыр суды тарафыннан атарга (!) хөкем ителә. 1944 елда Варшаваны канга батыручы да ул була. Вәхшилектә хужаларыннан да уздыра, бәдбәхет, тегеләре хәтта аннан котылуны мәгъкульрәк күрәләр.

Рус милли халык армиясе исә Смоленск тирәсендә оешып, шул төбәктәге сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Асларына су кера башлагач, немецлар, ниһаять, Власовка да ышаныч күрсәтергә мәжбүр булалар. Моңа кадәр власовчыларның аерым частьләре генә сугышта катнаша. Инде дивизия төзергә фатиха бирәләр. Беренчесе 1945 елның гыйнварында фронтка аяк баса. Гитлерның хәле мөшкел икәнен күреп, Власовның гына ниятләре үзгәрә. Еш-еш жиңүчеләр ягына күз ата. Әлбәттә, аны союзниклар кызыксындыра.

Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, ди. Жае да чыгып тора. 1945 елның 5 маенда Прага халкы восстаниегә күтәрелә. Күтәрелешне бастыру өчен Германия командованиесе анда ашыгыч рәвештә СС гаскәре жибәрә. Прагалылар радио аша туры эфирдан ярдәм сорап мөрәжәгать итәләр. Власов әлеге форсатны кулыннан ычкындырмый, ярдәмгә ашыга.

Аларны чәчәкләр тотып каршы алалар. Ә икенче яктан шәһәргә маршал Конев армиясе якынлаша. Власовка бу очрашу һич тә файда вәгъдә итми.

Шуна күрә тиз генә таю ягын карый. Өлгерә генә алмый, контрразведка кулына эләгә. 1946 елның 1 августында исә атып үтерелә.

Каршылыклы һәм катлаулы шәхес. Ил язмышы хәл ителгән Мәскәү янындагы авыр бәрелешләрдә дан яулаган хәрби башлык. Чын җиһангир. Ә ярты елдан үз теләге белән немецларга бирелә. Ни уйлаган ул? Хикмәт шунда, яна хуҗалары да аңа ышанып карамый. Гиммлер хәтта "дунгыз" дигән кушамат та тага.

Аңа тәгаен генә бәя бирү авыр. Моның өчен Сталин булырга кирәк. Ул бәяне бирә белә иде. Ике генә төсле иде аның буявы. Берсе—ак, икенчесе—кара. Табигатьтә төсләр биниһая күп, югыйсә. Гомумән мин (ихтимал ялгышамдыр) Гитлер фашизмы белән Сталин фашизмы арасында аерма күрмим. Бөтен бер милләтләрне пыран-заран китереп ташлады бит ул, җәллад. Кырым татарлары, чеченнар әле булса тернәкләнеп җитә алмыйлар. Хак булса, Сталин Казан татарларын сөрү турында да хыялланган, имеш. Моны фашизм дими, нәрсә дисең?

Легионерларның үз юлы. Беләм, беләм, белә торып бөләм, дип әйтте ди бер җилбәзәк адәм. Төкерек белән үрдәк ату сыманрак килеп чыга. Үзегез уйлап карагыз, кырык өченең февралендә күп көч түгеп төзелгән 825 нче Идел-Урал батальоны, немец офицерларын кырып бетереп, Витебск партизаннарына кушыла. Сентябрьда Каюм ханның Төркестан батальоны да (арилар!) шул ук юлны сайлый. Шуннан соң легионерларны Көнчыгыш фронттан бөтенләй чакыртып алалар.

Мескен бәндәләр! Туган ил һич тә якты чырай белән каршы алмады шул үзләрен. Кулга алулар башланды. Сөргенгә сөрделәр. Чөнки СССРда әсир төшү җинаять санала иде. Немецларның архив чыганакларына караганда, сугыш елларында барысы 5,5 миллион солдат һәм офицер әлеге язмышка дучар була. Биш миллион ярым җинаятьче, сатлык җан! Хивимы син, солдатмы, легионермы—аерып тормадылар, Сталинның корымлы буявына мандылар.

* * *

Безнең камерада гел мөселманнар гына булуын беләсез инде. Алманнар динле халык. Шуңа күрә бу яктан шартлар тудыруны да кирәк саныйлар. Аның башка сәбәпләре дә бар иде, ахры. Әйтик, русларга карата дошманлык хисләре тудырырга тырышуларын күреп-белеп тора идек. Һәрхәлдә, безнең ише "нацмен"нарны (совет документларында башка милләт кешеләре шушы исем белән теркәлә иде) мөмкинлектән чыгып, алардан аералар иде. Безгә мөнәсәбәт тә үзгәрәк иде кебек.

Шәхсән мин үзем русларны дошман күрмим. Вакытында араларында дусларым да күп иде. Серафим әле булса исемә төшеп, йөрәкләрем әрнеп китә. Анысы немецлар үзләре дә "нацмен" дип тормыйлар, сәбәбе генә чыксын, тоталар да асалар. Жамбулны, әнә, дар агачына бер гаепсезгә элделәр, калганнарга сабак булсын, янәсе.

Мәхбүс "ачмасаң күренми, сөйләмәсәң беленми" дип кенә яшәргә күнеккән. Дус бар, дошман бар дигәндәй, берәү дә чишелеп китәргә атлыгып тормый. Хәмзә әкәнең генә уендагы—телендә.Ул немецларга тел-теш тигерми. Ә менә русларның измәсен изә мәгәр. Кулыннан килсә, дөньяда яшәтмәс иде. Мин дә соңгы вакытта үземә кырын каравын сизеп йөри башладым. Нилектән, һич күнелемә сыйдыра алмыйм. Югыйсә, элек тә, хәзер дә юлларыбызның кисешкәне булмады. Ни өчен утырткannar—анысы белән бөтенләй кызыксынмыйм. Мәхбүсләр төпченүне гомумән өнәмиләр, үзем дә шул исәптә.

Хәмзә диндар зат. Биш вакыт намазын калдырмый, авызында гел бисмилла. Итагатьле, ипле. Саранлыгы гына бар. Кешегә бернәрсәсен бирмәс, үзе дә сорамас.

—Дин кардәш булса да, мал кардәш түгел,—дип авызыңны яба.

“Әкә” дип без ана чынлыкта сакал-мыегы өчен, никахы өчен әйтәбез. Ул үзе мондый мөгаләмәгә бик разый. Күрәсең, егерме биш яшь үзбәкләрдә абруйлы яшь санала.

Хәмзә сакал-мыегы булмаса, үсмер егет кебек кенә күренер иде, мөгаен. Юантыграк булса да, гәүдәгә кайтыш ул. Сакал-мыегын бигрәк тә шуның өчен тәрбиялидер әле. Сәгатьләр буе җамаяктагы суга текәлеп (көзге!), пыяла кисәге белән төкләрен матурлый, рәткә кертә.

Байтимер моңлана, Хәмзәсе тәзәнә. Калганнарыбыз шушы ике әсәрлегә карап юанабыз.

Хәмзә тәзәнү-ясанулардан, намазыннан бушаган арада русларны сүгә.

—Үзбәкстанны руслар гына бозып бетерде, бөтен тәртипсезлекләрне алар алып килде,—ди ул ике сүзнең берендә,—Алланың каһәре төшсен, башлары тәмуг утыннан чыкмасын, дөньялыкта да рәхим-шәфкать күрмәсеннәр...

—Хәмзә әкә, нигә шулкадәр яратмыйсың син русларны?—дип сорадым мин аннан баштагы мәлдә.

Ул күмердәй кара күзләрен чекрәйтеп:

—Көфер булганга яратмыйм, чучка булганга!—диде.

—Алар да Алла бәндәләре ич.

—Көфер Алла бәндәсе була димени?—дип акайды Хәмзә.—Ерткычлар алар, юлдан яздыручылар, азгыннар...

Соңыннан шул беленде, бертуган сеңлесен рус егете мыскыллаган булган икән. Үтерергә дә йөргәннәр, тегесе качып кына котылган. Үзбәкстаннан китеп үк барган. Хәзер мөселман кызы көфер малаен сөя-сөя үстерә, имеш. Шуңа үртәлә абыйсы. Германия төрмәсендә ятучы язмышы кыл өстендәге мәхбүс кешегә бу хакта өзгәләнүләр мәгънәсез бер фал гына инде, югыйсә. Ләкин Хәмзә башка камырдан изелгән кеше иде. Һәммә нәрсәгә борынын тыга, акыл өйрәтә, юкка-барга тыкшына.

Аның миңа акаеп карауларыннан ни эссе түгел, ни салкын түгел аңысы. Хәмзәнең ачуы—минем аякчуым. Шуңа күрә борын астыннан гына елмаеп йөри бирәм. Тик барыбер беләсе килә, ни-нәрсәм ошамый икән үзбәк әкәгә? Ни белән бетәр икән бу тавыш-гаугасыз күз уйнатулар?

Чуан көтелмәгәндә тишелде. Кичтән Хәмзә юк сәбәпләрне бар итеп, миңа бәйләнмәк итенде. Янәсе, ул намаз укыганда кычкырып сөйләшкәнмен, догасын чуалтканмын.

—Көферләр белән капма-каршы очрашкан чакта, Коръән-Кәрим аларның муеннарына каты итеп тондырырга куша. Сиңа да ул көн килеп җитәчәк әле, бел,—дип янады ул йодрыкларын селки-селки, иман китермәгәннәрнең йөзе аска килер, ди пәйгамбәребез.

—Каян беләсең минем иман китермәгәнемне?

—Аллаһу Тәгаләнең кодрәте киң... Кыямәт көне килеп җиткәнче үк монафыйклар кирәген алыр, үзебез дә көн күрсәтмәбез,—дип, Хәмзә янавында булды.

Башкалар безнең тарткалашуны тыңлап утыралар, ләкин кушылмыйлар.

Әллә нинди авыр көн булды ул. Йокларга яткач та, саташып беттем. Имеш, мин ком чүлендә. Нindидер ак чалмалы, кара сакаллы усал кешеләр арасында басып торам. Бервакыт әйлән-бәйләнуйный башладылар болар.

—Туктагыз, башымны түнтәрәсез,—дип кычкырам. Тегеләр шырык-шырык көләләр генә. Кәтүк буе бер кәрлә барысыннан да уздыра. Әле телен күрсәтә, әле ботларын чәбәкли. Ныклабрак карасам, үзбәк әкә.

—Хәмзә, мине танымыйсыңмы әллә, Байтимерләр белән бер камерада утырабыз ич,—дим.

—Ул көфер, кәсафәтен йоктырырга килгән, әнә, муенында тәресе бар,—

дип, Хәмзә миңа таба бармагын төртеп кычкырмасынмы?—Коръән-Кәрим андыйларның арт сабагын укытырга куша. Ни карап торасыз, тукмаклагыз!

Шушы сүзне генә көткәннәр, күрәсең, өерләре белән өстемә ябырылдылар...

Төш түгел иде инде бу. Баштанаяк бөркәгәннәр дә тәпәлиләр генә...

—Муеныннан теге нәмәхрәмен өзеп ал,—дип әмер бирде кемдер. Таныдым. Хәмзә тавышы.

Бөркәнгеч эченә бастырык юанлыгы көчле кул керде дә, догамны умырып та алды. Монысы Байтимер иде.

Нишлиләр болар, нинди экзекуция бу?

Бермәл барысы да тынды. Тырыша-тырмаша япмадан арындым. Тәнем ут кебек яна. Ару биргәләделәр бит. Янымда бер кеше дә юк, камера эче тып-тын. Иптәшләрем йоклый. Дөресрәге, йоклаган атлы булып яталар. Хәзер барысы да ачыкланды. Мина "темный" оештырганнар ич болар. Безнең яктагыча әйтсәк, капчык кигергәннәр. Төрмәдә еш була торган хәл. Аның сәбәбенә дә, очына да чыга алмыйсың. Оештыручыны, башлап йөрүчесен эзләүнең шулай ук бер фәтвәсе дә юк. Алай бик казына башласаң, отыры котыралар гына. Иң кулае, сүз кузгатмау, белмәмешкә салыну. Тик мин әлеге очракта кесәдән генә йодрык күрсәтеп йөри алмый идем шул. Ник дисәң, иң кадерле нәрсәмне, күп бәлаләрдән, үлемнәрдән саклап калган догамны муенымнан умырып алдылар бит алар. Ниндидер юлын табып, догамны үземә кире кайтарырга кирәк.

Камерадашларым иртән гадәттәгечә берни булмагандай көлешәләр, сайрашалар. Мин дә үземне нәкъ элеккечә тоттым. Сызлануымны да сиздермим, догам турында үзләре сүз кузгатмасмы дип көтәм. Андый ниятләре күренми. Димәк, үземә башларга кала. Бернинди боргалануларсыз турысын ярып салырга булдым.

—Кардәшләр, сезгә бер үпкәм дә юк, зинһар, догамны ташлый күрмәгез. Аллаһы Тәгалә насыйп иткән саклаучым ул минем,—дидем.

"Кардәшләр" мәгънәле генә бер-берләренә карашып, тынып калдылар. Камерада Байтимернең сыер кебек мыш-мыш сулавы гына эленеп калды.

—Нинди дога хакында лыгырдыйсың син, монафыйк?—дип сорады ачу белән Хәмзә.

—Аятелкөрси. Аны миңа сугышка киткәндә әнкәем бөти итеп язып биргән иде. Шушы вакытка кадәр муеныма асып йөрдем. Лагерьда да саклап калдым мин аны, гестапо да тимәде...

—Дога т-тәре түгел, аны муенга та-акмыйлар,—диде Хәмзә әкә тотлыгыбрак. Ул аптыраште иде. Башкаларның да колаклары үрә торды.

—Саклау өчен шуннан да уңайлы урын юк,—дип сүз һөҗүмемне дәвам иттем.—Авызга кабып йөргән чаклар да булды, яка эченә дә тегеп карадым. Шартына карап инде. Берсен дә гөнаһлы гамәл дип санамыйм.

—Мин уны парашага ташланым бит, кустым,—диде Байтимер аклангандай,—бед бит уны тәре тиеп бендек, үденне керәшен тиеп...

—Күп лыгырдама,—диде аңа Хәмзә.

Минем аларның аңлашканын тынлап торырга вакытым юк иде инде. Йөгереп барып параша ләгәнен актарырга тотындым. Шул чак: "Чиләкләрегезне чыгарыгыз!"—дигән әмер яңгырады. Бәхетемә, догам кулымда иде инде. Күннән тегелгән бөтигә зыян килмәгән иде.

* * *

Авылда Гүзәлия белән Илһан турында чыш-пыш йөри башлады. Имеш, бер караватта йоклыйлар икән, имеш, төрекнең үз илендә хатыны, бала-чагасы бар икән, имеш, Гүзәлия икенче хатынлыкка риза булып бара икән...

Хисамның җен ачулары чыкты. Онычына күтәрелеп бәрелергә кыймаса да, улы белән киленен утлы табага бастырды.

—Кеше күзенә күренмәслек иттегез бит инде, бу хәлгә чик куярга уйлыйсызмы-юкмы?—диде.

—Каш ярылып күз чыкмаган, әткәй, алай бик дулама әле,—дип, әтисен тынычландырмакчы итте улы Харис.

Карт отыры кызды гына.

—Килде-китте сөйләп, ачуымны кабартмасана, җә сыптырып җибәрермен...

—Ярар инде, әткәй, юкка-барга йөрәгенне бозма,—дип килене Сәлиха да сүзгә кушылды.—Була инде ул...

—Булмый торсын әле,—дип төкерекләрен чәчте Хисам,—таяк ике очлы ул. Менә син үзен, ягъни дә... Харис сездә туйга кадәр атналар буе кунатөнә яттымы соң?

—Аллам сакласын.

—Шул-шул менә...

—Хәзер бит дөнья үзгәрде, әткәй, яшьләр үзләренчә каера...

—Әнә, шәһәрләрендә каерсыннар, авылның гореф-гадәтләре үзгә аның.

Кызып-кызып аңлашкан бер вакытта, һич көтмәгәндә, бүлмәгә Гүзәлия үзе килеп керде. Ак тәстәге кыска чалбар кигән, җинсез блузкасын да җилкәсенә эленгән ике тар тасма гына тотып тора. Үзе кыска, әледән-әле кендеге күзен кысып алгалый.

—Нәрсә, Хисам Сабир, балаларың белән тәрбия дәресе үткәрәсеңмени?—дип, ул иң элек дәү әтисенә игътибарын юнәлтте.

—Синең аркада,—диде Харис ачулы тавыш белән.

Кызның кыйгач кашлары ак маңгаена сикерде.

—Ә миңа ни булган?

—Кызым, Илһанның кунак вакыты озаккарак сузылды бит, шуны сизәсеңме?—диде Сәлиха. Әнисе киеренкелекне йомшартырга, эшне зурга җибәрмәскә тели иде.

—Ул гайбәт сезгә дә килеп җиттемени? Кеше сүзен азрак тыңлагыз,—диде кыз үпкә белдергәндәй.

Харис хәтер саклап торуны кирәк санамады, эчендәге түгәргә ашыкты.

—Юк инде, безнең һич тә адәм мәсхәрәсенә каласыбыз килми. Әгәр кәләшенең абруе кадерле икән, егет үзе дә аңларга тиеш. Карасана, өсбашыңа. Сиксән яшьлек бабаң, әти-әниең янында шәрә йөрергә оят түгелме? Бар киемнәреңне алыштыр!

Гүзәлия тырт-тырт басып чыгып китте.

Үпкәләттек ахры кызны, дип уйлап куйды Хисам, сабырлык җитенкерәми шул, иплэп кенә аңлатырга да була иде ләбаса. Илһан дигәнен әйтер иде, никах укылмаган килеш кыз йортында шулай озаклыйлар димени? Кәбир җебегән, әнә, сүз катырга да оялып йөри.

Гүзәлия урап кергәндә алар игә киләләр иде инде. Кыз да баягы шикелле тәртәгә тибәргә тормый, җитди күренә. Киемен дә алыштырган.

—Дорфалыгым өчен гафу итегез,—диде ул мескенләнебрәк,—мин сезнең белән андый тонда сөйләшергә тиеш түгел идем...

Шул сүзләрне әйтте дә, әнисенең иңенә башын салып, үксеп еларга тотынды.

—Ярар, кызым, ярар, күңеленә авыр алма, без бит сиңа әйбәт булсын өчен тырышабыз. Әллә газиз баланны Каф тау артларына биреп җибәрү җиңел дисеңме?

Сәлиханың тавышы калтыранып куйды.

—Борчылма, әнием, дәү әтием син дә борчылма, әтием син дә, мин беркая да китмим.

—Ничек инде, китмисең?

—Шулай, әтием, мин кире уйладым. Илһан балыкка киткән иде, кайткач аңа да әйтермен. Бүген үк озатачакмын.

—Вафасызлык булыр ул, кызым, мондый җитди эштә сабырсызланырга ярамый. Соңыннан гомереңбуе үкенүең бар,—дип, Сәлиха кызының чәчләреннән сыйпады.

—Мин арыдым, бакчага чыгып бераз хәл алыйм әле,—диде Гүзәлия.

Хисам сүзгә катнашмыйча бер читтәрәк утырып торды. Хәтта берара онытын кызганудан, нигә башладым икән бу мәрәкәне, дип борчылып та куйды.

Авылга гайбәт керсә, атна-ун көнсез тынмый бит ул. Хатыннар белән суга ияреп төшә, печәнчеләр белән бергә чүмәлә сала, кибән коя, савымчылар аны үзләре белән көтүлеккә алып китә... Кат-кат әйләнә. Әйләнгән саен ян-якларына үсентеләр үсеп чыга, байый, киңәя, тирәнәя... Аны инде туктатырмын димә. Бердән-бер юл—битараф кына уздырып җибәрү. Ләкин Хисам кебек чәүчәләк кешенең кулыннан килми бу. Түземе төкәнде бит әнә. Шулай да морадына ирешге.

Аңлашуның менә шушылай үзе теләгәнчә тәмамлануын көтмәгән иде ул. Чөнки оныгы үзсүзле, иркә... Баксаң, акыл теше чыккан икән ләбаса үзенә. Күр, нинди кискен карар кабул итеп куйды бит. Шаккатырлык. Борчылыр, әлбәттә, ансыз гына булмас. Яшь вакытта гыйшык-мыйшык дип төнне керфек тә какмыйча үткәрүләр барыбызның да башыннан узган. Мәхәббәткә дәва юк, диләр. Бу дөрес түгел. Мәхәббәткә дә дәва бар. Ул—икенче мәхәббәт! Башкасы, тагын да кайнаррагы пәйда булыр, Аллаһы боерса, тегесе онытылыр. Менә шушы инде ул дәва.

Хисамның мелт-мелт итеп торган иреннәре буйлап елмаю дулкыннары йөгерешеп узды.

Шул күтәренке күңел белән ул бакча эчендәге "Иҗат йорты"на юнәлде. Монда җиләс тә, салкынча да иде. Чөнки йорт биек-биек алмагачларга сыенып утыра. Ә кызыл шомыртның ботаклары җил искәндә тәрәзәләргә кагылып-кагылып китә. Чәчәк вакытында бүлмә эче хуш ис белән тула. Үзе аулак, бимазалаучы юк. Рәхәтләнеп иҗат ит.

Бу араларда Хисам, оныгы өчен борчылып, әллә ни алдыра алмады. Шөкер, инде барысы да җайга салына шикелле. Өстәвенә, Гүзәлия, мин киткәләгәнче эшеңне төгәллә дип, җанына тиеп тора иде. Өстендә торганда эшкә кул бара димени? Хәзер монысы да көн тәртибеннән төште.

Хисам, шөгыленә керешкәнче, тирә-якны күзәтеп алды. Карашы иң беренче булып, Илһан бүләк иткән затлы диктофонга төште. "Үзенә кире кайтарып бирергә кирәк", дип күңеленә беркетеп куйды.

Биш-ун минутта иске магнитофонын көйләп, тамагын кыргалап алды да, сөйли башлады.

* * *

Без монда йортсыз йомран хәлендәге бәндәләр инде. Хәлбуки, өстебездә түбә бар, җил-яңгыр тими, җан сакларлык кына булса да тәгаменнән дә аермыйлар. Шуңа шөкерана итеп яшәп ятыш. Хәер, соңгы вакытта яшәү-яшәмәү кыл өстендә калды. Ул төрмәнең яңа баш түрәсе кыяфәтендәге Газраил кулында. Мәхбүсләрнең гомерен өзәргә аның бер ым кагуы җитә. Газраилебез—Зоммерфельд фон Эрлах атна-ун көнгә бер мәртәбә камерага кереп, тоткыннарның "хәлен белеп" чыга. Телеграф баганасы кебек төзгә каткан, какча гәүдәле урта яшьләрдәге кеше ул. Һәрвакыт энәдән-җептән киенә, кулыннан ак перчатка төшми. Искиткеч тәкәббер.

Мәхбүсләргә сүз катмый, безнең дә аңа мөрәҗәгать итәргә хокукыбыз юк. Алдан ук кисәтеп куйдылар.

Ин хәвефлесе шул, Зоммерфельд кергән көнне кичке прогулкадан бер кешегә кимеп керәбез без. Кая була ул иптәшебез, кай арада юкка чыга— сизми дә калабыз. Югыйсә, ишек алдында жылы якларга китүче кыр казлары сыман тезелешеп кенә йөрибез лабаса!

Бервакыт колакка төрмә башлыгының тоткыннарны жәзалап күнел ачуы турындагы хәбәр иреште. Камераларга кергәндә күнеленә хуш килгән мәхбүсне билгеләп ала икән дә, шуны төне буе садистларча газаплый икән. Аннан соң теге мескеннен шәхси кәгазьнәмәсенә "Качарга омтылыш ясаганда атып үтерелде", дип язып куялар, ди.

Беренче булып без Байтимерне югалттык. Тагын бер-бер артлы ике егет прогулкадан кире кайтмады. Безгә дә чират житәчәк бит инде дип, энә өстендә утыргандай утырабыз. Һай, кыен да икән ул Газраилнен кайчан киләсен алдан белеп торулары. Башта һаман шул бер уй: дон-дон, бәрепме бәрә. Акылдан шашарсын, жүләр. Әнә, Кафил исемле Себер егете күз алдында жиненләйде бичара, бу психологик йөкне күтәрә алмады. Тиктомалдан кычкырып көлеп жибәрә башлады бу, тузга язмаган сүзләр сөйли, лингвистларча әйтсәк, жыен абракадабра.

—Төрмә башлыгы минем дустым, үзе шаярып түйгач, ул сезне мина бирәчәк. Ну, өшкерәчәкмен, ну, рәхәтләнәчәкмен. Их! Ә аннан? Аннан сон кых!— дип шаккаттырды берсендә.

Пошаманга төштек.

— Ычкынган бу мәхлүк,—диде Хәмзә.

— Мутлана гына...

—Сөйләштереп кара сон,—дип Хәмзә иреннәрен кыйшайтты. Ә мина кызганыч. Егетебез үзебезнен ыру кешесе, татар милләтеннән ич.

—Кафил, жорланам дигәч тә, чамасын чамага китерергә дә онытма, кеше әллә нәрсә уйлар,—дип дусларча гына тегенен аркасыннан каккалап алдым.

Ул исә дуамал көлү белән көләргә тотынмасынмы! Иреннәре салынган, селәгәйләрен дә жыя алмый.

—Беренче булып синен ыштаныңны салдырам, әйдә, телисенме, хәзер үк... ха-ха-ха...

—Тилебәрән котырыгына әйләнгән, мескен,—диде яна кергәннәрнен берсе,—дөрестән дә, эш узганчы сакчыга әйтергә кирәк.

—Бәлки айныр?

Минем әле һаман ышанасым килми, тетер кебек егет бит.

—Барыбызны да суеп чыкканын көтәргәме?—дип, Хәмзә әкә янә учакка кура өстәде.

Гөнаһ шомлыгына, Кафил, чыннан да, төнлә Хәмзәгә ташланган бит, каһәр. Бугазына пычак тигән дунгыз тавышлары чыгарып чыелдавыннан уянып киттек. Сакчы да ишеткән. Хәлне аңлатуга, берни булмагандай елмаеп басып торган Кафилне егып бәйләделәр дә, алып чыгып та киттеләр. И һәм вәссәлам.

Шуннан соң озак та үтми, Фон Эрлах та юкка чыкты. Зуррак эшкә күчергәннәр дип сөйләделәр.

Ниһаять, тынычлап йоклый башладык. Өмет кайтты. Зур нәрсә икән ул өмет. Яшәешнен тоткасы икән. Шул чакта йокыга киткәнче өмет турындагы мәкаль-әйтемнәрне күнелемнән барлауны үземә бер гадәт итеп алган идем. Бу гадәтемә әлегәчә турылыклы булып калдым. Шунын өчен үз-үземә рәхмәт әйтеп йөрим. Халкыбызның зирәклегенә исем-акылым китә иде. "Юлда ат очратырмын дип өмет иткән жәяүле арымый" дигән мәкальне мин, мәсәлән, өмет хакындагы әйтемнәрнен тажы дип саныйм. Шуна бәйле рәвештә безнен эрага кадәр 1250 ел элек яшәгән яһүдләр башлыгы Моисейны бик ихтирам итәм. Кырык ел буе ком чүлләрендә адаша-адаша йөргәндә дә ул халкын юлда ат очраячагына ышандырып килгән, өметләрен сүндермәгән, үз илләренә

Ханаанга (Фәләстинның борынгы атамасы) алып кайтып житкергән. Яһүдләрнең оптимизмы, бердәмлеге, үзара ярдәмләшүе әнә шушы авыр чорлардан ук килә булыр, мөгаен. Әйтергә кирәк, мөселманнар да әлеге Иуди дин әһелләре Моисейны да, Авраамны да, Иисус Христосны да, Муса, Ибраһим, Гайса исемнәре белән үзләренең пәйгамбәрләре итеп таныганнар. Бу һич тә юкка гына түгел, билгеле. Әнә ич, өмет турындагы уйлануларыбыз да әллә нинди тарих төпкелләренә алып кереп китте...

Янә әйтем-мәкальләргә әйләнеп кайтыйк әле. Мисал өчен куен дәфтәремә икенче сан белән теркәлгәнен генә алыйк: "Адәм яхшылыкка өмет итеп яманлыкка түзә." Бу бит нәкъ безнең шикелле чарасызлар турында. Хак, бәхетсезнең кардәше ул өмет. Өмете киселмәгәннәрнең генә ризыгы киселмәс, ди.

Төрмә шартларында, билгеле, өметнең канатлары шактый өтелә. Чөнки алдагы өметләр чынга ашсын өчен иң әүвәл исән-сау калырга кирәк. Ә анысы мәхбүстән тормый. Немец җирендә Фон Эрлахлар бик күп.

Үземә килгәндә, догам—иң зур юанычым. Ул һәрвакыт янымда. Аятелкөрсигә иреннәрем дә җайлашып беткән иде инде. Үзләреннән-үзләре пышылдарга тотыналар:

—Әллааһү ләәәә иләәһә илләә һүү. Әлхәййль, каййүм.

* * *

Беркөнне таң белән нindидер дөбердәү тавышына уянып киттем. Ятагым да чайкалып алгандай тоелды. Әйтерсең лә, кемдер бинаны урыныннан кыймшатырга маташа иде. Башкалар да күзләрен уа-уа торып утырдылар. Һични аңлашылмый, әллә соң чыннан да төрмә җимереләме?

Ул да булмады, коридорның тимер идәненә дөп-дөп басып, сакчылар йөгерешеп узды. Әмер авазлары ишетелеп китте.

— Ахтунг!

— Шнелл!

Урамда нидер булган. Монысы бәхәссез. Күреп кенә булмый. Чөнки камераның тәрәзәләре юк.

Безнең шик-шөбһәләребезне урталай ерып, ишек уемыннан сакчы җикерде:

—Урыннан тормаска! Сөйләшмәскә!

Дөбердәү бер тынып тора, бер кабынып китә. Бер көчәя, бер сүнә. Стеналар калын булгангамы, ул каяндыр җир астыннан ишетелгән шикелле.

—Җир тетри,—дип пышылдады Хәмзә,—көчле кузгалыш вакытында менә шулай дулкын-дулкын булып килә ул.

— Тетрәде ди, үзеңне Үзбәкстанда дип белдеңме әллә?

—Нәрсә соң алайса?

—Нәрсә, нәрсә, бомбага тоталар, менә нәрсә,—дидем үз сүземә үзем дә ышанмыйчарак.

—Бомбага тотсалар, сирена акыртырлар иде,—дип, һаман үзенекен куәтләде Хәмзә.

—Тоткынның гомерен тишек бер тиенгә дә санамый ич алар, сирена сиңа тагын.

—Урра-а-а!.. Безнекеләр!..—дип кычкырды кемдер, тыела алмады, шатлыгы тышка бәреп чыкты.

Шуны гына көтеп торгандай янә ишек уемы ачылды. Сакчы буыла-буыла бакырды:

—Барыгызга да өчәр тәүлек карцер!

Без дә тындык, дөбердәүләр дә тынды. Нәкъ вакытында аякка бастырдылар. Иртәнге баланда да соңламады. Без эчке бер тынгысызлык һәм сызлану белән карцерга алып китүләрен көтәбез. Төш вакыты җитте, прогулкага чыктык, кичке аш килде...

Тәки тимәделәр. Бу немецларның беренче мәртәбә сүзләрендә тормавы иде. Күрәсең, иртәнге мәхшәр вакытында андый янаулар күп булгандыр. Ничек карцер житкермәк кирәк.

Без элеккечә чукрак, элеккечә сукыр. Сугыш турында бернинди мәгълүматыбыз да юк. Югыйсә, мең тугыз йөз кырык дүртнең көзе килеп житте. Димәк, Кызыл Армия һаман алдыра алмый. Тик бүгенге дөбердәү фикерләрне чуалтып жибәрде. Безнекеләр дә тик ятмый икән дип куанышттык. Баксаң, сугыш хәрәкәтләре мин гомамлаганча, Урал таулары итәгендә түгел, Алман илендә бара бугай ич. Һәрхәлдә, самолетлар үтеп керә алгач, немецларның оборонасы шактый какшаган була түгелме соң?

Шулай, без сугышның асылын үзгәрткән Сталинград орышы булганын да, фельдмаршал Паулюсның күп гаскәр белән әсир төшкәнен дә, Ленинград блокадасын да белми калганбыз. 1943 елның җәендә Курск янында да шәп кенә тәпәләгәннәр икән ариларны. Иң мөһиме, 1944 елның июнендә Икенче фронт ачылган. Һейнхагенны инглизлар бомбага тоткан булып чыкты. Соңыннан алар аны бөтенләй пыран-заран китереп бетерделәр. Хәрабәләрен үз күзләрем белән күрдем.

Таң ата да, кич була, өстемдә бер күлмәгем, дигән зимагур жыры бар иде. Безнең яшәеш тә нәкъ шуна охшаш. Дөрес, ристаннар тормышында да көннәр төрләнеп куя. Әле менә берәм-берәм карцерда утырып чыктык. Теге вакыттагы сүзләрен онытмаганнар, мөртәтләр. Онытыр фриц, су кирегә акса агар, немец сүзеннән чигенмәс. Карцерда утыруның ни-нәрсә икәнен тасвир иткән идем инде, кабатлап тормыйм.

Төрлелек дигәннән, безнең бит әле дин көнебез дә бар. Һәр җомгада яныбызга мулла керә. Башта зур өметләр баглаган идек без аңа, мулла аша азмы-күпме дөнья хәлләрен дә белеп торырбыз дип уйлаган идек. Кая ул, имамыбыз бик тешләк кеше иде, илгә калган бер имгәкле шунда. Сөйләшкәндә дә түшәмгә карап, күзләрен яшереп кенә сөйләшә, суфыйның суфые инде менә. Үзенең чеметеп алырлык та гәүдәсе юк, кипкән балык шикелле какланып беткән. Җиләне карачкыга кидерелгәндәй җилфердәп тора. Аның урынына, муллабыз сакал-мыегын бик ыспай йөртә. Хәмзә булып Хәмзә дә аңа көнләшеп карый.

Без мулланың ни атлы икәнен дә белми идек. Үзе дә беренче очрашуда ук кисәтеп куйды, мина хәзрәт дип, мөрәҗәгать итәрсез, диде. Хәзрәт, имеш. Берәр шомбайдыр әле. Минем төрекләрне яратмавым шул вакытлардан бирле килә булса кирәк.

Бүген ул безне Корбан бәйрәме белән котларга кергән икән.

—Мәрхәбә, мөселман кардәшләр! Мин сезнең барчагызны да иң мөбарәк бәйрәмнәребезнең берсе булган Гайдел-Корбан бәйрәме белән тәбрик итәм,— диде ниндидер моңлы йомшак тавыш белән,—Аллаһ Тәгаләнең берлегенә, Пәйгамбәребезнең Мөхәммәд саләллаһу гәләйһиссәлату вәсәләмнең хаклыгына иман китереп, догаларыгыз аша күңелләрегезгә нурлар иңдерегез. Бу изге мәлдә күк капусы ачык булыр, барлык фәрештәләр Аллаһтан Адәм балаларының гөнаһларын кичерүне сорап, һәрдаим тәсбихта булырлар. Ходаем догаларыбызны кабул ит, Бөек Алман иленә җир йөзендә гаделлек урнаштырырга булыш, и, рәхимле Табынучыбыз.

Минем догам үзем белән. Моны мулла белми. Белгертәсем дә килми. Әйткәнемчә, аңа күңелем ятмый. Хәлбуки, ул миңа бер начарлык та эшләмәде. Була бит сөймәс сөякле кешеләр. Сәбәбе дә юк, ә җан кире кага. Бүген исә нидер булды, ике арадагы боз эреде дә китте. Үзеннән-үзе телем ачылды.

—Хәзрәт, котлауларыгыз өчен рәхмәт, үзегезнең дә илаһи теләкхыялларыгыз тормышка ашсын,—дип ирен очында торган соравымны юлладым: "Шәһәр мәхәлләләрендә бәйрәмнәр ничек уза соң?"—дидем.

Бер генә мизгелгә мулланың карашы түшәмнән төшеп мине сыйпап узды. Аскы ирене бүлтәеп йөзе аңа хас булмаган ниндидер кырыс төс алды. Соравымнан яшерен мәгънә эзли иде, ахры. Шулай булмыйча, төрмә мулласы лабаса ул. Ә мин тоткын. Әсир тоткын. Дошман. Шуңа күрәдер, мөгаен, соравым һавада асылынып калды.

—Иртәгә Корбан ашы алып килерләр,—диде мулла хезмәтен тәгәлләгәч,—Аллаһ гамәлләренә шөкерана итеп, Ислам диненең бөеклегенә, пакълегенә, сафлыгына сокланып, үзегезнең мөселман булуыгызга шатланып, горурланып, җирдәге яклаучыбыз Адольф галиҗәнапларының исәнлек-саулыгы өчен авыз итәрсез ул нигъмәтләрдән.

—Амин!—дип җөпләде аны Хәмзә. Мулланың бу ясалма теләкләре миңа тәэсир итмәде. Ике арадагы боз үз урынына кайткан иде инде.

Сугышка кадәр авылда корбан чалдырмыйлар иде. Картлар яшеренеп, кача-поса гына берәрсенең бакчасында гает үткәргәлиләр иде. Сизенеп алсалар, йорт хуҗасын кәнсәләргә чакырып, штраф салалар, Советка каршы яшерен эш алып барасың дип, битәрлиләр иде. Германиядә исә дингә ирек, тоткыннар да үз диннәрен ачыктан-ачык тота алалар. Ихтимал, мулла гестапоның яшерен шымчысыдыр, ләкин дин ирегенә берәү дә кул сузмый. Догалы кешегә әйләнгәч, бу минем үземнең дә күңелемә бик якын иде.

Корбан ашы төрмәдә ничек оештырыла икән? Сүз юктан сүз булсын дип, кичен шул хакта сүз көрәштереп утырдык. Берәүләр: гадәти тәгам шикелле сакчылар өләшәчәк, дип гоманлады; Кафил белән мин прогулка вакытында өстәл хәзерләрләр бәлки, дигән фикерне алга сөрдек. Тик мулланың сүзен генә хәтердән чыгарганбыз. Ул “китерерләр” дигән иде ич. Һәм шулай эшләделәр дә. Иртәнге баланданы чөмереп утырганда шатыр-шотыр ишек ачылды. Сакчы зур гына төргәк кертеп куйды. Аның артыннан камерага көлеп-елмаеп, кырык-кырык биш яшьләрдәге бер кеше килеп керде. Озын чәче, ат ялыдай җилкәсенә төшеп тора, кара мыегын борын астында гына калдырып кырган, тач ямаулык. Фырт күренә, киемнәре дә әйбәт. Тел бистәсе дә икән үзе.

—Исемем Галимҗан булса да, килеш-килбәтем шул мөртәтне хәтергә төшереп торса да,—дип тезеп китте,—минем ул бәлшәвикләргә сатылган эсэр Галимҗан Ибраһимов белән берниндн урталыгым да юк.

Чынында да Галимҗан Ибраһимовның мин күргәләгән портретларына охшаган иде бу адәм. Дөрес, без укыганда халык дошманы Галимҗан Ибраһимов дигән язучының китапларын җыеп алганнар иде инде. Мин аның үзен дә, әсәрләрен дә юньле-башлы белмим. Шулай да, очраклы гына булса да, сурәте күңелдә сакланып калган икән әле.

—Монда татарлар бар дип әйттеләр, карыйк әле, кемнәр икән алар?—дип керүчебез безне күз уныннан үткәрде.

—Бар, мин менә Татарстаннан, Хисам Сабиров буламын.

—Бик мәслихәт, әйдәгез, милләттәшләр, танышып алыйк: мине Галимҗан Сәгъди дип белерсез, эмигрант журналист. Туган җирем—Чистай шәһәре.

Герман җирендә иркле якташыңны очрату үзе бер могҗиза икән. Дошман дисәң, дошман түгел, дус дисәң, дус түгел. Гаҗәп.

Ә якташыбызның үз миссиясе.

—Хисаметдин энем, син табын хәзерли тор,—диде дустанә кыяфәттә,—мин ул арада башка мөселман кардәшләр белән дә кул биреп, күрешеп чыгыйм. Гает көнне туганнарның хәлен белү, якыннарың өчен дога кылу ифрат саваплы гамәл. Әлбәттә, иң зур савап—корбан чалып, шуның итен мохтаҗлар, сезнең ише мәхбүсләр белән бүлешү. Әлхәмдү лилләһи раббиль гәләмин. Ошбу хәлләргә дә ирештек, шөкер.

Без, ач этләр шикелле аш-суга ябырылдык. Мондый ризыкларның дөньяда барын да оныта башлаган идек ич инде. Кунагыбыз да вакытын бушка

уздырмый, сөйли дә сөйли. Аның безнең янга керүе дә Корбан ашыннан битәр, кылларыбызны тартып карау, үз шәхесен таныту иде булса кирәк.

—Ходай татарларга егерменче гасырда икенче форсат бирә инде,—диде ул үз ачышына үзе сокланган хәлдә,—беренчесендә большевикләр, үзебезнең арадагы хаиннар аркасында морадыбызга ирешмичә калдык, форсатны кулыбыздан ычкындырдык. Сез әле яшьләр, ул зилзиләләрне күрү насыйп булмагандыр. Ә бу фәкыйрегез әлеге вакыйгаларның эчендә кайнады. "Идел-Урал өлкәсе" гәҗитенең хәбәрчесе идем.

—Нинди вакыйгалар иде соң ул? Идел-Урал дигәне тагын...

Галимҗан Сәгъди җөнтәс кашлары астыннан, безең китек икән ич энекәем дигәндәй, мыскыллабрак карап торды. Хак, Идел-Урал дигән сүз тезмәсе минем өчен географик атаманы гына аңлата иде.

—Үктәбер инкыйлабы алып килгән буталчыклардан файдаланып,—дип төкрекләрен чәчә-чәчә аңлатырга керешә эмигрант журналист,—Милли Мәҗлес татар һәм башкорт халыкларының дәүләти берәмлеге сыйфатында инде күптән хыялларыбызда йөрткән Идел-Урал Штаты төзүне муафыйк күреп, аны үз өстенә алды. Олы зыялыбыз Галимҗан Шәрәф эшләгән проект яхшы дип табылды. Бу Русия эчендәге милли дәүләт берәмлеге Казан, Уфа губерналарын, шулай ук Нократ, Ырымбур, Пермь, Самара һәм дә Сембер губерналарының аерым өлешләрен үзенә беркетәчәк иде. Икенче Бөтенрусия мөселманнарының хәрби корылтае Идел-Урал Штаты төзелүне игълан итү датасын 1918 елның 1 мартына билгеләде.

Менә шунда башланды инде хәмер капмыйча кыҗыкыян-дупыян килүләр. Югыйсә, мәзһәбебез, тоткан юлыбыз гадел иде. Башта киңәшмәләр үткәргәндәй итеп кыландылар. Янәсе, тагын да мөкаммәлрәк нөсхә тәкъдим ителәчәк. Бу инде Мәскәү кубызына бию иде. Киңәшмә 1918 елның апрель урталарында, әлбәттә, Мәскәүдә үтте. Көн тәртибендә—Татар-Башкорт Җөмһүрияте төзү мәсьәләсе. Нөсхә дигәне шушы инде. Киңәшмәдә татарлардан Мирсәет Солтангалиев, Мулланур Вахитов, Камил Якубов һәм, әлеге дә баягы, Галимҗан Ибраһимов катнашты. Ул вакытта Ленин хөкүмәтендә милли мәсьәләләр белән шөгыльләнүче Сталин киңәшмәне алып барды. Ә оештыру корылтае Уфада үтәчәк диделәр.

Әлеге киңәшмәләрнең, резолюцияләрнең күз буяу икәнлеген аңлау өчен әллә ни гакыл кирәкми иде. Татар белән башкортның берләшүе Мәскәүнең тамагына сөяк булып утырасы көн кебек ачык лабаса! Алар бит Русиядән аерылып чыгу ягын да каера алырлар иде. Ә мона юл куя аламы соң Мәскәү? Бердәнбер юл—кичекмичә зөбаниларның тамырына балта чабу. Һәм бу балтаны татар кулына тоттырдылар. Шул дулкында Татар-Башкорт Җөмһүриятенә каршы торучы көчләр тарафыннан Казанда Болак арты җөмһүрияте пәйда булды. Большевикләр тиз арада монысының да бугазына бастылар. Үзләре үк болгаткан суда балыкны бик шәп тоттылар алар. Хәрби Шура да, Милли Идарә дә таратылды. Кулга алулар башланды. Политбюро, Совет хөкүмәте, үз чиратында, Татар-Башкорт Җөмһүрияте турындагы шартнамәне юкка чыгарды. Ә 1919 елның мартында Башкортстан автономиясе төзелү буенча Ленин чыгарган декрет әлеге изге ниятләргә бөтенләй дә нокта куйды. Әлеге буталыш чорда Колчакка хыянәт итеп, Советлар ягына авышкан башкорт әһеле Әхмәтзәки Вәлиди дә үзенең тар карашлы кеше икәнен күрсәтте.

Бу вакытта Мулланур да, Камил дә юк иде инде. Икесе дә бик яшьли кеше кулыннан бакыйга күчте. Шуннан соң Галимҗан Ибраһимов тулысынча большевикләр юлына басты. Барыбер ярамаган үзе, җәзалап үтергәннәр мескенне. Кызганыч, умырткасыз булса да, талантлы зат иде.

Шушы бер сәгатьлек Корбан ашы мәҗлесе вакытында татар тарихы буенча мин бик күп мәгълүмат алдым. Мәктәптә дә, техникумда укыганда да милли

тарихыбызга фәкать кара яктан гына кагылалар иде. Безне татарның наданлыгына, кансызлыгына, мәрхәмәтсезлегенә, ялкаулыгына, пычраклыгына, тагын әллә нинди начарлыкларына күндереп бетергәннәр иде инде. Баш күтәрергә дә кыймыйча, сүз әйтергә оялып йөрдек ич.

Хәер, бу ак эмигрантның сүзләренә ышанып бетеп тә булмый.

—Үткән эшкә салават,—дидем битараф кына,—хәзер тел кашуның хәҗәте юк.

—Хаталанасың, егетем-әфәндем,—дип каршы төште Галимҗан Сәгъди,—беләсең килсә, хәзер нәкъ вакыты! Көлдән көмеш булмасмы, дип кул кушырып утыра торган чак түгел. Феникс кошы шикелле Идел-Урал Штаты янә көлдән калкып чыкты. Мин моны СССРны истә тотып әйтәм. Көнбатышта исә әлеге сәяси омтылыш бервакытта да сүнеп тормады. Ник дисәң, аның төп фикердәшләре нәкъ менә Көнбатыш цивилизациясендә үзләренә җирлек табып, тәрәккыятькә ирештеләр. Садри Максуди унсигезенче елларда Русиядә чакта милли-мәдәни автономия белән саташып йөрсә дә, монда тулысынча Идел-Урал тарафдарына әверелде. Гали Акыш гамәли юнәлештә үз җилкәсенә зур йөк алды. Гаяз Исхакый 1933 елда "Идел-Урал" исемле тарихи хезмәт язып, милли-азатлык хәрәкәте учагын тагын да дөрләтебрәк җибәрде. Идел-Урал Штаты теориясе хәзер кайчангга караганда да тирәнрәк эшләнгән бербөтен тәгълиматны тәшкил итә. Менә-менә СССРга сугыш игълан итәргә торган Төрек хөкүмәте мөстәкыйль дәүләт сыйфатында Идел-Урал Штатын танырга әзер. Адольф Гитлер да Идел-Урал Штатын тулысынча хуплый, ярдәм итәргә, булышырга вәгъдә итә. 1918 елда аны Русия эчендә төзү хакында хыялланган булсак, бүген инде аңлашылганча, мөстәкыйль дәүләт борынларга тора. Әлбәттә, Бөек Германия протектаратында. Алтын Урданың кыйпылчыгы булачак, Аллаһ кушса, Идел-Урал Штаты!

Монысына минем колаклар әзер түгел иде әле, үрә тордылар. Алтын Урда вәхшиләренең татар белән нинди уртаклыгы булсын икән? Арттырам дигәч тә...

Авызымнан исә башка сорау ычкынды:

—Ә русларны, украин... чувашларны кая куясыз?

—Алар өчен башыңны ватма, үзләре җаен табар. Минем менә синең ише акыллы егетләрне "Идел-Урал" легионына кыстап йөрешем. Ник дисәң, сезгә дөресен әйтәм, беренче батальон ышанычны аклап бетермәде. Бу Кормаш, Гомәрев кебек ашаган табакларына кәкәй иткән сансыз бәндәләр йогынтысы. Менә дигән фатирларда яшәделәр, бәгъзеләре башлы-күзле булган иде. Төкерә алар татарның азатлыкка омтылышына. Мөстәкыйль дәүләт тә кирәкми. Ибраһимов сынарлары. Шуңа күрә ышанычлы яңа кешеләр туплау белән мәшгульбез. Ниятләребез анык, рәхәтләнеп иҗтиһад ит.

—Без мәхбүсләр ич...

—Бу мәсьәләне җайлап булыр дип саныйм, немецлар амнистиягә риза.

Күп еллар үткәч, мин Гомәревнең шагыйрь Муса Җәлил икәнен белдем. Беренче батальон дигәннәренең белорус партизаннарына кушылганы хакында алдарак та сүз булган иде инде. Галимҗан Сәгъди безгә Корбан ашы оештырып йөргәндә Кормаш төркеме егетләре гильотинода башларын салган булган инде. Дөресен сөйлим дисә дә, яшерен серләре дә калган икән журналистның.

Ни өчен агай Галимҗан Ибраһимовны күрә алмый—монысын төпченергә вакыт җитмәде. Үзе хакында да җентекләп сораштыра алмадым. Идел-Урал Штаты әһелләрен кулга алулар башлангач, Төркиягә китеп баруы, Германиягә яшьлек хыялларын тормышка ашыру өчен килүеннән гайре аның хакында бер мәгълүматым да юк. Чөнки мин кабат күрешербез дип уйлаган идем. Ә ул башка күзгә чалынмады. Немецлар тоткыннарны ирекккә чыгарудан баш тартканнар иде, ахры. Легионнар җыеп кына хәлне төзәтеп булмасын аңлаганнар булса кирәк. 1944 елның җәендә-көзендә, әйтик, Белоруссия,

Украина, Балтыйк буе республикаларының күп өлеше фашистлар кулыннан азат ителә. Кичәге әшнәләре Румыния белән Венгрия Германиягә үзләре сугыш игълан итә. Бу вакытта Ялта конференциясенә хәзерлек башлана. Анда инде башлыча сугыштан соңгы дөньяның бүленеше мәсьәләләрен карау күздә тотыла. Гитлерның җиңелүен берәү дә шик астына куймый.

Шул кыска гына вакыт эчендә Галимҗан Сәгъди тагын бер яңалык житкерергә өлгерде. Баксаң, Татар-Алман бәйләнешләренең тарихы тирәндәрәк ята икән, ул әлеге легионнардан күпкә алдан башланган икән ич. Немец идеологлары Беренче бөтендөнья сугышы чорында ук мөселман факторыннан файдаланып калырга омтылган. Нигездә бу татар факторы. Чөнки Антанта илләре—Россия, Франция, Англия мөселман әсирләре өчен оештырган Вюнсдорф лагере ике өлештән торган. Беренчесендә уникe мең татар тупланa, икенчесе гарәпләр өчен. Алар нибары өч мен кешегә җыела. Церенсдорф дигән авылда 1916 елда мөселман зираты да ачыла. Гөрләп мәчет эшли. Ашау-эчү әйбәт. Корбан чалулар Хәрби министрлык исәбеннән башкарыла. Татарларның үз театры, үз оркестры була. "Әл-Жиһад", "Татар иле", "Яңа тормыш" гәҗитләре чыгып килә.

1921-1922 елларда әсирләрне туган илләренә кайтарып җибәрә башлыйлар. Шулай да хәтсез татар Германиядә яшәп кала.

Кызганыч, ГДР чорында лагерь һәм зират мәйданы ябык хәрби зонага әләгә. Анда танк полигоны коралар. Татар тарихының кара сакалы инде бу. Хәер, японнар кара сакал дип тормаслар иде, мөгаен. Әнә, милләттәшләренең Алабугадагы каберлекләрен ничек тәрбиялиләр. Алар бер Алабугада гына булса икән?!

Идел-Урал Штатына килгәндә исә, мин аны хуплыйм. Тик кайчан да булса гамәлгә ашуына гына ышанычым аз. Хәер, өметсез бер шайтан гына ди...

* * *

Илһан киткәннән соң Гүзәлия сулган гөл шикелле шиңеп төште. Ул инде хәзер әүвәлгечә шаянланмый да, шукланмый да. Чырык-чырык көлгән тавышы да ишетелми. Бүлмәсенә кереп бикләнә дә, көннәр буе күзгә-башка күренми. Ни эшли ул анда, ни-нәрсә белән шөгыльләнә—белгән кеше юк. Вакыт-вакыт иртәдән кичкә кадәр Сөн буенда йөри. Тамактан да калды бугай инде, кеше белән ашарга-эчәргә утырмый. Әнисенең ялыну-ялваруларына:

—Апитетым юк,—дип кенә җавап бирә.

Хисамның, киресенчә, дәрте канатланган чак. Төрек егетенең китүе ана бәлзәм шикелле тәэсир итте, ике басасы урынга бер генә баса картың. Ул үзен ай битле чибәр кыләшен усал Дөю пәрие тырнагыннан йолкып алган кыю ханзадә кебек хис итә иде.

Беркөнне оныгы белән бакча капкасы янында күзгә-күз очраштылар. Шаккатты Хисам. Гүзәлия как сөяккә калган лабаса, йодрык кадәрле йөзендә борыны гына утырып тора. Күңел күзе күрмәгәч, шулай икән ул.

—Дәү әти, эшеннең тәгәлләнүе белән кайчан котлыйбыз инде, — диде кыз сүрән генә. Моңа кадәр ул ана мондый очракларда Хисам Сабир дип мөрәҗәгать итә иде. Шуңа күнгән иде Хисам. Бу да йөрәген чеметеп алды. Тик белгертмәде.

—Германиядә батып ятам әле һаман, һич туган илгә кайтып җитеп булмый,—дип, шаяртыбрак җавап бирде. Шулай да түзмәде, сорады:

—Кызым, алай-болай сырхауланмыйсыңдыр ич, суырылып киткәндәй күренәсең, — диде.

—Да так, ерунда,—дип кулын селтәнгәндәй итте кыз.

Хисам эчтән генә сыкранып куйды.

—Ерундага гына охшамаган шикелле әле бу, кызым,—диде,—әйдәле, керик, сөйләшик, анлашыйк...

—Нәрсә белмәмешкә салынган буласын инде, дәү әти, — диде кыз үпкә катыш ачу белән, — сезненчә булды ич инде, хәзер урамда кешеләрнең күзенә туры карап сөйләшәсездер дип уйлыйм, гайбәтләр беткәндер...

Хисамның авызы ябылды, ни дип акланырга да белмәде.

—Шул хакта анлашыйк соң, — дип кенә мыгырданды.

—Соң инде, дәү әти, поезд китте, ул турыда авыз чайкауның мәгънәсе калмады.

Кыз тырт-тырт басып китеп барды. Бара-барышка җилкәсе аша гына башын борып:

—Бигайбә, Хисам Сабир, мин киттем әле, — дип кычкырды.

Хисам берара аптырабрак басып торды. Оныгының мондый мөнәсәбәтенә көнмәгән ул. Күрәсен, күнеле бик нык кителгән иде кызның.

Ярар, чебен тимәс—чер итәр, ди, үтәр әле.

Кәтелмәгәндә күнеленә килгән шушы уена сөенеп, карт бакча эчендәге өенә юнәлде. Иртән уянгач ук, төрмә белән араны өзәргә кирәк дип, ният итеп куйган иде. Шуна күрә озын-озак юанып тормады, магнитофонын электрга тоташтырып, урындыгына җайлап утырды да, тамагын кыргалый-кыргалый сөйләргә җыенды. Төртелеп тормас өчен исемнәрне, вакыйгаларны, даталарны алдан теркәп, билгеләп куйган иде.

Ләкин бу юлы, ни кадәр генә тырышмасын, элекке эзенә төшә алмады. Чәй эчеп тә карады, юк, бармагач бармый, кем әйтмешли, кулы каткан. Уенда һаман шул Гүзәлия. Теге төрек татары чистый башын әйләндергән икән кызның. Эшләре тирәнгә кермәгән булса ярый ла, көмәнгә уза-нитә калса, нишләрсең? Хәзерге яшьләргә ышаныч юк. Ул кара мыекны Төркиягә барып эзләп йөрергә язмасын. Баланы әтисез калдырырга да ярамый.

Хисамның уйлары адашкан тай шикелле шушы куркыныч юнәлештән кереп китте. Оныгым үзен-үзе кая куярга белмичә изаланып йөри, ә мин, мәнсез, җәелеп утырам, дип урыныннан сикереп торды да, кулына пинҗәген алып тышка чыкты. Иң элек килене белән улының тетмәсен тетәргә дип өйгә керде.

—Сәлиха, Харис, йөрәгегезне мүк баскан нәрсәләр, кайда сез?

Әле бер бүлмәгә, әле икенчесенә барып төртелде карт, ләкин тавыш-тын ишетелмәде. Шунда гына исенә килде: эштә ләбаса алар! Әй, Ходай орган затлар... әйттерерсез әллә ни...

Сүгенгәнен сизми дә калды.

—Хисаметдин абзый, изүләренне ачып, җил-җил атлап, кая китеп барыш болай?—дип сорады капка төбендә үткән-сүткәнгә сүз кушып утыручы күршесе.—Бераз хәл җыеп ал.

—Минем синең шикелле көннәр буе арт җылытып утырырга вакытым юк шул, кем-энем. Ятасың шунда күләгәдә күзәтчелек итеп. Бер дә шөгылең юкмыни соң синең?

—Пенсиямнең рәхәтен күрәм, күрше. Шуның өчен гомер буе бил бөктек бит. Әйдә, ялындырма, бергә-бергә вакыт тизрәк уза ул...

Хисам сүз көрәштереп тормады, туры мәктәп сукмагына төште. Оныгы шундадыр кебек тоела иде ана. Күнеле дөрес сизенгән икән.

—Гүзәлия белән Кәбир әле генә парлашып Актанышка төшеп киттеләр шул, Хисаметдин абый, — диде дежур хатын, — шуларны бергә күрсәм, сулышларым кинәеп китә инде минем...

Хисамга канат куйдылар диярсең, өенә атлап түгел, очып кайтты. Вәйт, карт җүләр, дип үзен-үзе сүкте, тузга язмаган уйлар уйлап бер гөнаһсыз балага нинди гаепләр ташлады бит, ә? Ярый, улы белән килене өйдә юк иде,

югыйсә, әлеге пычракны аларга да ата иде ич. Хет монысыннан Ходай саклады.

Һай, зирәк тә бала инде Гүзәлия. Гүзәлияме? О-о, Гүзәлия! Алтын ул Гүзәлия! Үзе чибәр, үз акыллы, үзе унган. Әнә, бабасының ниятен, уйхыялларын бик тиз аңлап алды лабаса! Боеккан булып кылануы күз буу гына булган икән. Шундый акыллы кыз Кәбир шикелле егет солтанын читкә тибәме соң? Әйе, әнә, бергәләшеп районга элдерткәннәр. Хәзер бөтен нәрсә Кәбиргә барып төртелә. Кыюлыгы, тәвәккәллеге генә житсен. Бәхет кошы жилкәсенә үзе кунам дип тора.

Хисам татлы хыялларга бирелеп, шактый ара тынычлана алмыйча ишеклетүрле йөренде. Эшенә дә төштән соң гына тотына алды.

АЛТЫНЧЫ ТАСМА

### Ирек

Кырык бишенче елга аяк басуга, шәһәрне бомбага тотулар шактый ешайды. Без инде аны беренче дулкында ук билгели алабыз. Хәтта Хәмзә дә жир тетрәү белән буташтырмый. Шунысын да сизеп алдык, бомбалар ничектер безне читләтеп узалар кебек иде. Монда меңләгән тоткын утыра, инглизләр дә, французлар да күп диләр. Төрмә хезмәткәрләренең дә акыру-бакырулары йомшара төште. Жинелүләрен сизенәләр булса кирәк. Ә жиңүне кайсы як бәйрәм итәчәге без—мәхбүсләргә дә ачык иде инде. Бомбалар сызгыруы безнең өчен гүя аһәнле музыка, көтеп алабыз.

Мин еш кына Эрнаны искә төшерәм. Аңа ачу тотмыйм. Киресенчә, төнге очрашуларыбызны берәмтекләп, бөтен нечкәлекләре белән күз алдымнан үткәрәм. Зөфаф кичем Эрна белән үтте. Ходай шулай язган иде, күрәсең.

Төшләремә дә керә Эрна. Бүген дә керде. Күн белән тышланган теге затлы фаэтонда икәүдән-икәү генә барабыз, имеш. Урман юлы яшел чирәм. Тәгәрмәч эзләрендә генә ара-тирә ямаулыкка охшаш көлсу туфрак утраучыклары күренгәләп китә. Агачлар хәтфә чабуларын жәйгән. Күзләр камашырлык матурлык. Әнә, каяндыр пошый колыны килеп чыкты да уйнаклый-уйнаклый ешлыкка кереп югалды.

—Бу гашыйклар урманы, — диде Эрна мина сарылып, — ишетәсеңме, сандугачлар сайрый. Болар егет сандугачлар. Син дә мине шулай сайрап чакырыр идеңме?

—Мәхәббәт ул үзе таба, ышаныч кына яулап алына,—дидем кайсыдыр язучының тәгъбирен кабатлап.

—Дөрес, мин сине үзем таптым, — диде Эрна.—Үзем таптым, үзем югалттым.

—Ничек югалттың? Без бергә лабаса!

—Юк, татар-малай, бу мин түгел, Хәтерем генә.

—Ни сөйлисең син, Эрна! Күр, дөнья ничек матур!

—Болар инде башкалар өчен. Үткәнне кире кайтарып булмый, сагынып кына була.

Карыйм, Эрна кошка әверелде дә очып китте. Гыйшыкларын эзләп өзгәләнгән сандугачлар да тынды.

Гажәп. Мин, мөгаен, төшемдә авылны, әткәй-әнкәйне, Рабиганы күрергә тиештер бит инде. Алар нигәдер төшемә керми. Эрна керә. Тик бер-бер кайгысы бар, ахры, боек күренә. Кайда ул, ни-нәрсә белән шөгыльләнә? Тикшерүче аны Гитлерюгенд оешмасының актив әгъзасы дигән иде. Баланы да шул сәбәпле төшергән ич инде. Дошман нарасыен көмәнендә йөртә димени саф канлы ари кызы.

Әтисе менә чын дуңгыз икән, чучка. Бер мәртәбә дә хәлне белергә килмәде. Ара унбиш-егерме чакрым гына, югыйсә. Күпме бил бөктем мин аңа. Һундук!

Их, туйганчы дыкысын чыгарып килергә иде шунын. Исән-имин котылсам бу төрмәсеннән, мулласын өшкерәм әле мин аның. Менә шунда күрербез, кем һундук та, кем дундук...

* * *

Әйдә, шушы очрашунын вакытын якынайтыйк әле, хөрмәтле укучым. Төрмә эпопеясы үземне дә ялкытты инде. Язарлык, сөйләрлек нәрсә дә калмады шикелле. Игътибарга лаек дип саналганнары барысы да теркәлде.

...Беркөнне шәһәр төне буе черек стена шикелле дер селкенеп торды. Ә иртән? Иртән без ирекгә идек инде. Хәл болай булды. Ятабыз-ятабыз шулай, парашаны да алмыйлар, баланда да китермиләр. Онытгылар.

—Бу фрицларга ни булды икән, бомбежка вакытында кырылып бетмәгәннәрдер ич?!—диде кемдер.

Без әлеге мәсьәләне уртага салып сөйләшергә өлгермәдек, киереп ишекне ачтылар. Ни булды икән дип куркышып калдык. Ышан син фашистларга. Ишек уемында—шаккатарлык хәл—лейтенант, безнен лейтенант басып тора! Бер мәлгә истән таеп тордык.

—Үзебезнекеләр!—дип кычкырды беренче булып аңына килгән егетебез.—Үзебезнекеләр!..

Без саргаешкан ярлар шикелле лейтенантка барып сарылдык. Күзләрдән яшь бәреп чыкты. Күнелне нindидер давыллы хис биләп алды. Бу хистә ашкыну да, сагыш та, үкенү дә, шатлык та, шөбһә дә—барысы бергә укмашкан иде. Өч ел мәхбүслек чорында казан төбенә утырган юшкындай ташка әйләнгән кешелек тойгысы берьюлы эреп тышка ургылды.

—Егетләр, нишләвегез бу, сытасыз бит, егетләр?!—дип, лейтенант та бәргәләнә. Безгә анын бәргәләнүе бармы да юкмы. Туган ил шундый сагындырган, әлеге чандыр офицернын гимнастеркасын сыйпап алу да тасвир канатына сыймастай ләззәт китерә иде.

Нишләп беткән булыр идек, анысын белмим, шул вакыт тавыш көчәйткеч аша рус телендә игълан яңгырады:

—Всем советским военнопленным собраться во дворе! Через пять минут перекличка!

Игъланны берничә мәртәбә кабатладылар. Без үрә катып тынладык. Немец төрмәсендә совет командирынын күрсәтмәләрен ишетү искиткеч якын, шул ук вакытта ифрат та сәер иде.

—Инде рус коллыгы башланды,—дип йөзен чытты Хәмзә. Ничек ачуым чыкканны күрсәгез, чак кына яңагына менеп төшмәдем. Шушындый истәлекле, шушындый куанычлы көндә ни сөйләп маташа бит, сарт тәре.

Шулай да, узгынчы уй гына иде бу. Билгеле инде, әлеге бәхетле көнне күтәп алалмастай идек ич. Менә килде, ниһаять! Без—ирекгә! Калганы ничек тә рәтләнер. Язмыш кыерсыткан үз улларына Туган ил гадел бәясен бирер. Хәер, хак бәясе кемдә икеләнү тудырыр икән? Хәзер шул каһәрле елларнын үчен кайтарырга гына калды. Берлинга, әнә, кул гына сузмалы. Бәлкем, аны алуда үзебезгә дә катнашырга туры килер. Шәп тә булыр иде мәгәр. Гел кирегә генә димәгән, безгә дә аркадан исәргә тиештер ич инде ул жил дигәннәре.

—Әйдәгез, киттек,—диде лейтенант,—анда көтәләр...

Анда, ишек алдында... чын мәгънәсендә пәри туе... Кай арада житешкәннәр, шәрабын да тапканнар, кыз-кыркын да килгән. Жырлыйлар, биилар, кочаклашалар, үбешәләр... Бер элмәк борынлы колгадай озын егет аккордеон уйный. Французлар, диделәр.

Ә без, көтүдән калган аңгыра сарыклар шикелле, кая барып сыенырга белмичә акай-чукай килеп торабыз. Дөресрәге, әмер көтәбез. Тезелешеп йөрергә күнгән ич инде без, нишләтәсен.

Шул чак жир астыннан гына калкып чыккандай былт итеп, жинел машина пәйда булды. Корт күче кебек гөрләгән халык арасыннан боргалана-сыргалана нәкъ мәйданның уртасына килеп туктады бу. Ачык машинаның алгы тәрәзәсенә таянып, бер полковник калыкты. Бермәл сабыр гына кешеләрнен тынычланганын көтте. Ә французлар һич нәрсәгә карамый бәйрәм итүләрен беләләр. Полковник та югалып калмады, автоматын алып, тәтегә бер басуда магазиндагы бөтен патронны чыгарып бетерде.

—Тра-та-та-та...

Тындылар.

—Совет Армиясе сезне тоткынлыктан азат итте. Сез иректә. Барыгызны да котлыйм! Ура!

Полковникның тавышы көр иде. Үзен чын хужаларча тота: кыю, тәкәббер, кыланчык. Мина ул кайсы ягы беләндер мишәр егете сержант Мөнир Исламовны хәтерләтә иде. Юк, дөрес әйтмим, бер калыпка салып суккан шикелле ошаган иде ул аңа. Бәлкем, бертуган абыйсыдыр? Ике-өч ел эчендә үзе сержанттан полковник дәрәжәсенә ирешкәндер дип уйламыйм.

Ничек искәрмәстән генә пәйда булган булса, шулай капыл гына китеп тә барды ул. Әмма тәртип урнаштырып, йөзләгән тоткыннарны төркемнәргә бүлгәләп, командирлар билгеләп китте. Мин аның булдыклылыгына, төгәллегенә шаккатып калдым.

Безнекеләрне хужалык ротасына беркеттеләр. Офицер сынары булгангадыр, мине комендант подразделениесенә яздылар. Юньле-башлы саубуллашырга да өлгермәдек, тиз-тиз генә тезделәр дә алып та киттеләр. Янадан күрешербезме-юкмы, Алла белсен.

Шәһәр танырлык түгел иде. Смирнов белән офицерлар ашханәсенә ит китергән чаклардагы гүзәл ренессанс каласы хәрабәгә әверелгән.

Күзләрем әле бер якка, әле икенче якка төртелә. Беләм, алар кайчандыр мине хәйранга салган зиннәтле соборны эзлиләр. Кызганыч, мәрхәмәтсез сугыш Һейенхагеннын йөзек кашы булган бу XV нче гасыр һәйкәленә дә канлы кулын сузудан тарсынмаган икән.

Урамда совет гаскәрләре мыж килеп тора. Жирле халык бөтенләй диярлек күренми. Посышканнар. Каннарына бүтән халыкларны буйсындыру сеңгән, фәкать үзләренең генә бөеклеген таныган арилар өчен оккупация зур фажига иде, әлбәттә. Дөнья шулай корылган инде ул. Мокыт Мәнди дә: "Бер мин жинәм, бер бәләкәй абыкай жинә",—дип әйтте ди ич. Яшәешнен бөтен фәлсәфәсе шушы тәгъбиргә сыя да бетә.

Без утырган машина яртылаш ишелеп төшкән бер йорт янына килеп туктады.

—Построиться!—дип әмер бирде төркем башлыгы капитан Фролов.

—Психушкадан качкан бу чукчаларны нишләтмәк буласыз, иптәш капитан?—дип тешләрен ыржайтты капка сакчысы.

—Теленә салынма, Шандыбин! Гауптвахта чәпәмәгәем.

—Мин болай гына, иптәш капитан, үз итеп кенә...

—Хәзер икешәрләп каптеркага керәсез, киемнәрегезне алыштырасыз,—диде Фролов безгә ишарәләп,—беренче рәт, шагом марш!

Сакчы, мөгаен, өс-башыбызга карап, безне психлар чутына чыгаргандыр. Дөрестән дә, зебр аты шикелле чуар төрмә пижамалары әлеге мохиткә һич тә ярашмый иде шул.

Әнә, хәрби киемгә төренгәч, ничек үзгәреп китте егетләр. Танырлык та түгел. Һәммәсенең жилкәсендә погон. Сәер. Мин армиядә вакытта погоннар юк иде әле. Хәзер форма үзгәргән. Яхшы якка үзгәргән.

Старшина ике йолдызлы погон тоттырды, мин кече лейтенант бит, дигәнне колагына да элмәде.

—Бөтен армия буенча көндез шәм яндырып эзләсәң дә кече лейтенант таба алмассың,—дип көлде генә.—Аннан соң, сезнең жиз иләк аша үтәсегез бар әле, контрразведкадан алай җиңел генә котыла алмассыз. Кем өлкән лейтенант, кем кече лейтенант, шунда аңлатырлар. Хәзергә просто лейтенант булып йөр. Әсирлектә ничә ел булдың соң?

—Өч елга якын.

—О-о, сугышны әсирлектә үткәргәнсең икән...

Кемдер хуҗаларча нык-нык атлап эчкә узды.

—Смирно!—дип оран салды старшина.

—Вольно, вольно,—диде керүче.—барысы да тәртиптәме, дәгъваләр юкмы?

Таныдым. Бу төрмә ишек алдында нотык тоткан полковник иде. Кызыксынып аны күзәтәм. Ул да минем якка борылды. Күзләребез очрашты. Икебез дә авызны ачкан килеш катып калдык.

—Командир? Синме бу, командир?—дип, миннән алда полковник исенә килде. Икеләнүләрем юкка чыкты.

—Сержант! Исламов!

—Трибуналның сине атарга хөкем итүе турындагы карарын мин соң үз күзләрем белән күрдем бит, Хисам. Чыннан да, синме бу?—дип, Мөнир базардагы маклер шикелле әйләндереп-әйләндереп карады.

—Әйе, мине атарга алып бардылар ул чакта,—дидем күз яшьләрем аша.—Аттылар да...

—Ничек исән калдың соң?

—Һәрвакыттагыча, немецлар бу юлы да өлгерлек күрсәтте. Мине мушкага алган егетләр үзләре җиргә ауды. Контузия белән котылдым. Хәтерлисеңме артиллерия мәхшәрен? Язмышымны бер секунд хәл итте.

—Хәтерләмичә соң, тәмугның тәмугы...

—Хәтерләсәң шул, мине үлемнән фрицлар йолып алды.

Мөниргә аятелкөрси догасы хакында әйтеп тормадым. Чөнки ул аны барыбер кабул итмәячәк иде. Яп-яшь полковник дини уйдырмаларга ышана димени?

—Тәмугтан үзең ничек котылдың соң?

—Нәкъ синекенә охшаш очрак,—диде Мөнир,—фәкать баштан аякка гына әйләндереп куясы. Әлеге дә баягы, шул артиллерия мәхшәре булышты. Безне штрафнойга тәгаенләгән булганнар. Документларын кулыма тотып карадым. Үзең беләсең, мин дуамал мишәр, йә унам, йә туңам. Туплар тынуга, егетләрне землянкадан алып чыктым. Сине алып киткәннән соң, устав буенча старшой булып мин калдым бит инде. Хәрби трибуналга килеп кабуыбызны төшенеп алган идем. Карыйм, землянкаларының көле күккә очкан. Ә иң яшерен документлар аларда саклана. Сейфларын эзләргә тотындык боларның. Һәм таптык та. Сыдырылмаган да, малай. Алдык та, урман эченә шылдык. Анда үзебезнекеләргә тап булдык. Әнә шул сейф мина трамплин ролен үтәде. Тиз генә офицер дәрәҗәсенә күтәрделәр. Шуннан китте дә китте...

Бер кечерәк буйлы майор булмаса, без әле һаман кочаклашкан килеш аңлашуыбызны дәвам иткән булыр идек.

—Иптәш полковник, гафу итегез, каршы ала алмадым...

—Зыян юк, Абервах,—дип, полковник дусларча кул биреп күреште. Әшнәләр иде, ахры.

—Майор, бу минем беренче командирым, якын дустым,—диде Мөнир,—киендер, урнаштыр, офицерлар ашханәсенә беркет, кич үзен кунакка көтәм.

Күрсәтмәләрен бирде дә, Һейенхаген каласының яңа коменданты полковник Исламов җил очыртып чыгып та китте.

Мөнирнең, кунакка көтәм, дип турыга ярып салуы сыйлanудан битәр, пропаганда өчен әйтелгән иде, әлбәттә. Янәсе, без агай-эне ак мыек, шуны мыек очына чорнап куегыз.

Очраштык без. Бер генә түгел, күп мәртәбәләр очраштык. Дустым мина, чыннан да, зур һәм ныклы терәк иде. Ул мине үз карамагындагы комендант взводы командиры итеп билгеләде. Безнең взвод тимер юл узелында урнашкан иде. Союзга җибәреләсе эшелоннарны тикшерәбез, аларны тоткарлыксыз озату хәстәрен күрәбез. Билгеле, барысына да тәтеми мондый игътибар. Беренче чиратта документларына фронт командующие кул куйган составлар кузгала иде. Йорт-җир җиһазлары, кием-салым, савыт-сабага кадәр ташыдылар. Машиналар, станоклар, сәнәгать кирәк-яраклары турында әйтәсе дә юк. Тулы бер заводларны тәгәрмәч өстенә утырттылар. Булса—бохарай, булмаса—сохарайга канәгатьләнеп яшәмәгән немец, кисмәгән тулы тоткан.

Әле дә хәтеремдә, берсендә тыны-көне бетеп, вокзалга комендант үзе килеп төште. Гадәттәгечә, бөтенесен аякка бастырды. Кемнедер эт итеп сүкте, кемнендер аркасыннан какты, кайсыларын үрә бастырды. Ләкин берәү дә ана ачу тотмый, яраталар, ихтирам итәләр иде. Эчендәгесе тышында иде Мөнирнең.

—Биш йөзенче поездга юл арчыгыз!—дип әмер бирде ул. Әлеге состав артыннан аның тәүге тапкыр гына килүе түгел. Ни өчен кырык эшен кырык якка ташлап, биш йөзенче поезд артыннан йөри икән соң бу комендант? Беләсе килә бит, каһәр. Югыйсә, мина моның бер хаҗәте дә юк үзе.

—Стратегик материаллар, ахры,—дип, ерактан суктырып кына, полковникны сүзгә тартып кертмәк иттем. Ул ирен читләре белән генә елмаеп алды.

—Урыс колагыңны кисәр, һәр тишеккә чөй булма,—диде чын татарча.

—Ярар соң, әйттем исә кайттым...

Мөнир күздән югалуга, егетләр дә әлеге аерым исәптәге состав хакында тел кашып алдылар.

—Вермахтның яшерен коралларын тапканнар,—диде интендант Соловьев бик белдекле кыяфәттә,—шуларны Мәскәүгә куалар. Немецлар өлгерә алмый калган, ату эшләр хөртигә әйләнәсе булган.

—Ха, иштең ишәк чумарын,—дип тешләрен ыржайтты лейтенант Никитин,—хатын-кыз лифчиклары анда, ха-ха-ха!

—Синең шул булыр инде, хатын-кыз дигән сүздән дә селәгәйләрең ага.

—Агамы-юкмы, командующийның трофейлары ул, бик беләсегез килсә.

—Кайсы командующий?

—Беренче Белоруссия фронтының командующие бер генә...

—Маршал Жуков?—диде Соловьев күзләрен шарландырып.—Мондый сүзне дөрес булса да сөйләмә, лейтенант!

Мөнирнең кисәтүеннән соң әңгәмәләрдә яңгыраган әлеге гайбәтләрне колак очыннан гына очыртып җибәрә башладым. Дөресен генә әйткәндә, минем фикерем белән исәпләшүче дә бик күренеп тормый иде. Мона үпкаләргә дә, авыз-борын җимерергә дә туры килми. Ник дисән, мин сугышны әсирлектә үткәргән чит кеше. Кары эресә дә бозы эреми, диләрме әле, шуның кебек инде. Якын итмиләр. Полковник Исламовның үз канаты астына алуы гына кырын күзләрдән саклый иде. Юк, кырын карыйлар дип әйтергә дә телем әйләнми. Шул ук вакытта ачылып та житмиләр. Үзләре, әнә, җаен чыгарып, әйбер җыя, посылка сала. Төшемле җирләргә дә иярмиләр. Бераз мая туплаганда начар булмас иде анысы. Мөниргә әйтүе унайсыз, үзе сүз кузгатмый. Тапкан малдан мина да өлеш чыга дип уйлый иде, күрәсен.

Ә интендант хаклы булган икән ләбаса! Советлар Союзы таркалып, дөньяларның асты өскә әйләнгәч кенә ул яшерен мәгълүматлар калкып чыкты. Партия билетларын яндырган сары сакаллы элекке коммунистларның елгырлыгы иң әүвәле шунда күренде. Чос егетләр. Кичәге боссларын тәнкыйтьләп, сәяси капитал тупладылар.

Минем кулга да килеп керде аларның бер гәҗите. Меленберг атлы бер

яһүд, үзе әйтмешли, "Маршал Жуковның чын йөзен ачкан". Эзләнгән егет. Һәр фикерен дүкәмитләр белән дәлилли. Аңлашылганча, сүз маршалның шәхси трофейлары турында иде.

Менә оборона министры Булганинның 1946 елның 23 августында Сталинга язган хатыннан бер өзек: "Ягодинская таможнясында (Ковель шәһәре янында) йорт җиһазлары (85 әрҗә) төялгән 7 тимер юл вагоны тоткарланды. Документларны тикшергәндә шул ачыкланды: йорт җиһазлары маршал Жуковныкы иде".

Немец аристократларының диван-кәнәфиләрен үзләштерү җиһангирның башка комсызлыклары белән чагыштырганда тәртәгә киртә ялгау кебек кенә икән әле. Чөнки СССР Дәүләт иминлеге комитеты башлыгы Абакумов (соңыннан үзе дә эзәрлекләүләргә дучар ителеп, исем-фамилиясе Зур энциклопедия сүзлегеннән бозып ташлана) иптәш Сталинга юлланган үтә яшерен белешмәсендә юлбашчыга Жуковның Германиядән алып кайткан яшерен чемоданы, шкатулкасы турында мәгълүмат җиткерә (10 гыйнвар, 1948 ел). "Сезнең күрсәтмәләрегез нигезендә,—дип тәкрарлый генерал,— агымдагы елның 5 гыйнварында Мәскәүдә Жуков фатирында яшерен тентү үткәрелде... Тентү вакытында чемодан табылмады, ә шкатулка йокы бүлмәсендәге сейфта иде. Шкатулкадан 24 кул сәгате, шул исәптән 17 алтын сәгать, асылташлар белән бизәлгән 3 сәгать бар иде. Алтын кулоннар һәм балдаклар—15 данә, арада—8е кыйммәтле ташлар белән, башка алтын әйберләр..."

Тентү маршалның дачасында да уздырыла. Андагы мал-мөлкәтне тәфсилләп язып торуның хаҗәте юктыр, мөгаен. Шунысын гына ассызыклыйм: бу мөлкәт илле бер зур сандыкта һәм чемоданда саклана. Георгий Константинович исә үзе ВКП(б) Үзәк Комитет секретаре Ждановка биргән аңлатмасында ялгышын таныса да, "тукымалар өчен эш хакы итеп бирелгән акчаларны түләдем", дип белдерә. Акт төзүне мәслихәт күрә, "мин моны дөрес түгел дип саныйм", ди. "Ау мылтыклары—6-7 данә—миндә сугышка кадәр үк бар иде, 5-6 данәсен Германиядә сатып алдым, калганнары—бүләкләр".

Исеме данга күмелгән маршал—дүрт мәртәбә Советлар Союзы Герое, Кызыл Мәйданда ак атка атланып Җиңү парады үткәргән легендар Жуков бит бу!

Бик нык рәнжедем мин аңа. Бәй, мәйтәм, атаклыларның да куллары үз якларына кәкре икән ич. Теге чаклар хәтергә төшкәч кенә, бераз эчкә җан керде. Чөнки Жуков солдатларны да онытмады. Германиядән посылка агылды гына бит. Үзем шаһит. Миңа килгәндә, булдыксызлыгым аркасында гына буш кул белән кайттым дип саныйм. Кыюрак булырга кирәк иде.

Аннан соң, тарихтан беләбез ич, җиңүчеләр гомер-гомергә ганимәт төяп кайткан. Өстәвенә, контрибуция. Шушы күзлектән чыгып караганда, Жуковны гаепләве дә авыр ич. Әгәр чыннан да әлеге хәлләр дөреслеккә туры килсә инде, әлбәттә.

Татарның акылы төштән соң шул аның, мин дә Меленберг әфәнденең мәсләген ахырдан гына аңладым: Жуков дигән бөек җиһангирны тарих мөнбәреннән төртеп төшерергә чамалый лабаса ул, һичьюгы, пычракка буяу, мәсхәрә итү. Хәер, мисалга ерак йөрисе юк, үзебезнең арада да хәттин ашкан андый бәндәләр. Күр, әнә, демократия сылтавы белән, инде Муса Җәлилгә теш кайрый башладылар. Имеш, илен саткан, имеш, әсирлектә типтереп яшәгән. Берәү дә фәрештә түгел, билгеле. Пәйгамбәрләрнең дә аягы таеп киткәли ди китап. Тик үз халкының намусын чагылдырган кагылгысыз шәхесләр була. Муса Җәлил дә шундый зат, милләтебезнең пакьлеге, горурлыгы. Мин аны шундыйлар рәтенә кертәм.

*Ахыры киләсе санда.*



Клара
Булатова

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

* * *

Шундый мәкаль бар безнең халыкта,
(Мәкальгә таян кирәк чагында!):
"Табынсаң табын Тимер казыкка,
Аңа йолдызлар хәтта табына!"

Чын даимилек үрнәген тотты,
Береккән җирен ташлап кузгалмый...
Хәсән Туфан да Тимер казыкны
Табыну өчен Кыйбла дип саный.

Ая, Каләмем! Иҗат коралым!
Заман куша дип илереп ялыкма,
"Дүрт ягым кыйбла," — диеп чайкалма,
Туфандай табын Тимер казыкка.

## Без үзебез бүген бүтәннәрдер

Ни-нәрсәсе белән безнең дәвер
Начаррак соң үткәннәреннән?
Без үзебез бүген бүтәннәрдер —
Бүтән хисләр, бүтән гамь белән.

Хисләребез чик-чаманы белми,
Тәннәребез белми оятны.
"Үзгәрешләр чоры" дигән нәрсә
Вәхшилекне бугай уятты.

Бер карасаң, болар барысы да
Булып үткән инде дөньяда.
Тик шунысы начар: үткәннәрнең
Иң кабихе бүген уяна.

* * *

Тургайлы яз, Былбыллы җәй үтте.
Торналар да китте көзләрен.
Канатлы Ат кышка китереп кертте —
Ни күрсәтер кышкы көннәрем?

“Шигъри кышлар әле алда”, — дигән
Бәя алган иде иҗатым.
Ничек үтәр кышкы бураннарны
Каурый канат кигән бу Атым?

* * *

Мин шуны яхшы беләм:
Китүеңне аклап була
Яңадан кайту белән.

Аны да, тагын, беләм:
Үлемеңне җиңеп була
Яшәвең калу белән.

## Бар да язмыш иркендә

Озак көткән бөре кипкән,
Инде өмет калмады.
Ачылмыйча шиңеп беткән
Ясминемнең таҗлары.

Ясмин, ясмин!
Йә син, йә мин
Бәхетсездер бу көндә:
Күпме яшем?
Күпме яшим! —
Бар да язмыш иркендә...

## Берүк инде дуслык өзелмәсен

Син кагылма уйнап. Бу күңелдә
Шайтан вәсвәсәсе тудырма.
Кабул күрсәм чынлап, мин бүген дә
Ияреп китсәм шушы уенга —

Әллә ниләр килеп чыгуы бар.
Әллә ниләр... Ходай сакласын!
Берүк инде дуслык өзелмәсен,
Өмет итеп шуннан башкасын...

## Никләргә дип инде?..

Ник инде? Ник инде?
Никләргә дип инде
Җан тагын илерде?
Ник тагын тилмерде?
Ник тагын хис-ялкын
Яндырды, көйдерде?

Ник инде? Ник инде?
Никләргә дип инде?!

Көн узган бит инде, көч тузган бит инде,
Гөл сулган бит инде, тән туңган бит инде,
Су туңган бит инде, көй тынган бит инде,
Кыш, буран бит инде, үткәнен көт инде.
Янасың ник инде?
Никләргә дип инде?!

## Нәрсә булды сиңа?

Инде үтте, инде бетте дигән,
Инде китте дигән чагында
Кем кагылды тагын күңеленә,
Кайсы тиде тагын җаныңа?

Ник туздырдың тагын чәчләреңне,
Нигә сүттең үргәч толымга?
Кем үзгәртте ипле яшәвеңне?
Нәрсә булды сиңа бу елда?

"Инде үтте җилдәй җиңел чак", — дип
Акыллыга үзең санагач,
Чәчләреңне җилдә җилфердәтеп,
Ник йөрисең язда яланбаш?

Инде булды, күңел суынды дип
Тынарга дип йөргән чагында,
Кем кагылды тагын күңеленә?
Кайсы керде быел җаныңа?

## Мин инәләм көнгә

Таңга чыга алмас төн кебек,
Кара кайгы килде ишелеп.
Урап алды уңнан, сулымнан.
Каләмемне алды кулымнан.
Кемнәр тотып барыр юлымнан,
Кем чыгара алыр соң моннан?
Бармы бирәр ярдәм итәр зат? —
Мин инәләм сезгә соңгы кат:
Бармы, бармы, бармы шундый зат?
Мин инәләм көнгә,
юк җавап...

* * *

Китәргә дип йөрим бик күптән...
Күкләр инде күптән чакыра да —
Гөнаһларым җиргә береккән.

Җаным йөри җәннәт тирәли,
Күк капусы, юкса, ачык анда —
Гөнаһларым гына җибәрми.

## Тик... шул күлгә быел Аккош төште

Бу ташландык, онытылган күлгә
Күптән инде беркем килмәгән.
Аучылар да, балыкчылар да юк,
Камышлыкта җил дә йөрмәгән.

Безнең эзләр күптән югалган да,
Мүк түшәлгән — сукмак өстенә.
Тик... шул күлгә быел Аккош төште:
—Сиңа илтәм, — диеп, төшемдә.

## Җитмешенче җәйгә җитеп киләм

Җитмешенче җәйгә җитеп киләм,
Гомер юлын, әйе, үтеп киләм.
"Каурый каләм" дигән Җил-Атымны
Гомерем буе юлдаш итеп киләм.

Әле һаман "Язлар алда" дигән
Алдануны чынга санап яшим.
"Һәрвакыт Янымда" дигән булып
Өметләрне саклап-барлап яшим.

"Җәйләр җитсә" дигән шартны куеп
Урак урам, зурат салам әле.
"Һәрбер язның үз җырлары"н тоеп,
"Гел кояшка карап" барам әле.

"Печән өсте"ндә дә, күбәләктәй,
Йөрелмәгән чәчкә утлап кына.
Китапларым шуңа чын тормышчан
Татлы "Миләш кагы" булып чыга.

Якты "Хәтер тәрәзәләре"ндә
Үткән юлларыма кер кунмаган,
"Шушы яктан, шушы туфрактан без",
Ватан төшенчәсе онытылмаган.

Укытучы эшен кушып язып
"Якты сагыш", "Яшел каләм" белән,
"Әрнү"емдә ил-көн гамен алып,
Җитмешенче җәйгә җитеп киләм.



Заһид
Мәхмүди

# ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ ЮЛЫ

РОМАН

*Кыллы уен кораллары ясаучы мәшһүр оста*
*Иттакый ага Халитовның якты истәлегенә багышлыйм.*

**Кайту**

Төн иде. Поезддан төшкәч, Әхәт, аркасындагы биштәре авыр булуга да карамастан, Казанның танымаслык булып үзгәрүенә аһ-вах килеп, энесе яшәгән Ерганак урамына жәяүләп кенә юл тотты. Һәр тарафта элекке тузган йортлар урынында берсеннән-берсе затлырак таш биналар, супермаркетлар, кибетләр, казинолар тезелеп киткән. Игътибарлырак булмасаң, адашып калуың да ихтимал. Кайчан өлгергәннәр?

Ярты сәгать чамасы атлагач, ул Ерганак урамына борылды. Аның бер очы Островский урамыннан башланып, икенче очы Айвазовский урамына барып тоташа. Гел авылдагыча монда! Кайдадыр «фиют-фиют» итеп ялгыз сандугач сайрый. Бер катлы, ике катлы иске таза агач йортларның бакчаларыннан үрелеп торган шомырт һәм сирень чәчәкләре тирә-юньгә хуш ис тарата. Әхәт тә—ялгыз сандугач кебек. Чечняга контракт белән китеп бер ел хезмәт итү дәверендә, уйлый-уйлый чигә турлары агарып бетте.

Ә уйланырлык, борчылырлык нәрсәләр күп. Милициядән куылгач, дүрт елдан артык өйдә ятты ул. Бер гаепсезгә эштән куылу иллә дә авыр кичерелә икән. Төннәр буе йөрәген тотып ята иде. Алар эләктергән йорт карагы район администрациясе башлыгы хатынының туганнан туган энесе булып чыкты. Кулга алган вакытта, карак, качарга маташканда абынып, борынын сындырган иде. Гаепне Әхәткә һәм аның ике хезмәттәшенә сыладылар. Имеш, алар сугып сындырган. Карга күзен карга чукымый дигәндәй, прокурор белән милиция начальнигы да аларны якламады. Кадрлар бүлеге башлыгы майор Кәримов хәтта Әхәтнең «Яхшы хезмәт иткән өчен» медален өстәл тартмасында качырып калдырды (аны ана милициядән китеп, ике ел узгач кына тапшырдылар). Эш судка барып житте. Ярты елдан, дәлилләр житмәү

Заһид МӘХМҮДИ (1960) *– язучы, публицист; «Профессор Миңүгәл», «Ак болыт», «Тәмуг чәчәге» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

сәбәпле, җинаять эше туктатылды. Әхәт берничә тапкыр республика эчке эшләр министрлыгында да булды. Ләкин анда сөйләшеп тә тормадылар. Күрәсең, район администрациясеннән алдан ук кисәтеп куйганнар.

Дүрт елдан артык эшсез йөрде Әхәт. Шул дәвердә прокурор, Казан юлында җинел машина белән исерек килеш бер яшь кызны таптатып, эшеннән куылды. Аның артыннан милиция начальнигы белән кадрлар башлыгы да пенсиягә китеп барды. Хәзер берсе адвокат булып йөри, икенчесен паралич суккан. Өченчесе исә рюмочный төбен таптый. Өстәвенә, начальникның кызын наркотиклар белән сату иткән өчен утыртып куйдылар.

Яңа начальник—милиция майоры Искәндәр Фәритович Әхәтне яхшы каршы алды. Әмма аны эшенә кайтару турында сүз чыккач, иннәрен генә сикертте.

—Документларыңны нык пычратканнар, энем,—диде ул.—Бәлки министрның үзенә кереп чыгарсың? Аның сүзеннән башка мин бернәрсә дә эшли алмыйм. Ә безнең яктан ходотайство булыр.

Керде Әхәт министр янына. Аны инде Мәскәүгә алалар, дигән имеш-мимешләр йөри иде.

—Безгә яхшы хезмәткәрләр муеннан кирәк,—диде министр, Әхәтне тыңлагач, һәм календарьга нәрсәдер язып куйды.—Уйлашырбыз.

Бер айдан министр алышынды. Озак та узмый, Эчке эшләр министрлыгыннан тискәре җавап килеп төште. Хат астында элекке түрәнең имзасы тора.

Яңа министр янына керәсе килмәде Әхәтнең. Болай да гарык иде барысыннан. Өметсезлеккә бирелеп, бик каты эчә башлады. Шул ук Кәримов белән рюмочныйда бер өстәл артына туры килгән чаклары булды. Бер-берсен күрмәмешкә салышып сөйләшмәделәр генә.

Соңгы очрашу һаман күз алдында тора. Рюмочный ишегендә Кәримов күренгәч, Әхәт ана аркасы белән борылып басты. Теге шактый исерек. Күрше өстәлдә әле генә төрмәдән кайткан Митька—«форточка» үзенең әшнәләре белән аракы эчеп тора. Ул төрмәдә вакытта Кәримов аның сөяркәсе янына баргалап йөргән икән. Бу турыда Әхәт соңыннан рюмочныйдагы алкашлардан ишетеп белде. Шәмәрледә иң матур хатын-кызларның берсе иде Маруся. Тегүче булып эшли иде. Күпләр башы төрмәдән чыкмаган каракның шундый сөяркәсе булганга гаҗәпләнеп тә йөрде. Ә моның сере гади: Митька—«форточка» бөтен урланган алтын-көмешне Марусяга бүләк итеп бара.

—Ну что, мент поганый, поговорим?—диде Митька, Кәримовны якасыннан алып.—Я слышал, ты Маруськину как креветку ... ?

Барысы да шаркылдап көлә башлады.

—Ты что?—диде Кәримов, көч-хәл белән аның тимер кебек бармакларыннан ычкынып..—Придумываешь всякую чушь.

—Син мине фантазиягә бай димәкче буласыңмы?

—Борчымале, болай да баш авырта,—ментның бер күзе инде ишеккә карый.

—Хәзер минекен татып кара инде?—Митька «форточка» зур йодрыгы белән аның авызына китереп сукты.

Типкәләделәр. Хәтта өстенә сиеп киттеләр.

Кәримов урынында башка кеше булса, Әхәт аны яклар да иде. Ә бу хайванны ул тамчы да кызганмады.

Менә шундый инде мент язмышы. Итәк-җиңеңне җыеп йөрмәсәң, гражданкада башыңны да өзеп китүләре бар.

Эчте Әхәт. Әче су беркадәр вакытка онытгырып торды. Тик бу онытылу ана кыйммәткә төште. Үгетләп тә, елап та җинә алмагач, Сәриясе биш яшьлек кызлары Гөлияне алып, әнисе янына—Казанга китеп барды.

Берәр атна чамасы вакыт узгач хатыны артыннан килгән иде дә, соң

булып чыкты. Сәрияне күрше мужигы Витя белән кинотеатрдан кайтып килгәндә тотты ул. Ә әнисе, Сәрия эшкә китте, дигән була. Кем белә, хатынын подъездда тотмаган булса, бәлки, алар кире кушылган да булырлар иде. Әхәт дуламады да, сугышмады да, гарьлегеннән авызын кыйшайтты да, «черт!» итеп асфальтка төкереп китеп барды.

Хатыны янына бүтән килмәде. Ә бу вакытта инде Чечнядагы сугыш кызганнан-кыза бара иде. Русия армиясенә өере-өере белән контрактникларны яллый башладылар. Анда үткәргән бер көнен монда өч көнгә исәпләнә. Акчаны да шәп түлиләр икән. Исән-сау кайтканнар затлы машиналарда гына утырып йөри, имеш. Аннары милициядән эштән куылганнарны, Чечняда хезмәт иткән тәкъдирдә, эшләрендә торгызалар икән, дигән сүзләр дә йөри башлады. Өйдә ятып булмый, Әхәт тә бәхет сынарга булды. Чүрәкәй авылында яшәүче әти-әнисе ( жиде-сигез ел элек ул энесе Кәбир белән анда йорт салып чыккан иде, чөнки әтиләре Шәмәрледә калырга теләмичә, туган авылына кайтып төпләнергә уйлады ) анын бу фикерен хупламады. Аларнын күз яшьләренә, лаф оруларына карамастан, үзенекендә торды Әхәт. Тиз арада район хәрби комиссариатыннан кирәкле кәгазьләрне алды да, ит комбинатында эшләүче дүрт кызны өенә фатирга кертеп, Казанга китеп барды. Анда бер генә көнгә энесе Кәбир йортында тукталды. Ул гәзиттә хәбәрче булып эшли иде. Энесе дә анын бу гамәле белән ризалашырга теләмәде.

—Ай, абыем, ялгышасын,—диде ул, башын чайкап.—Мөселманга каршы барасын. Русия ягыннан жинаятьчел сугыш бу. Андагы солдатларнын ни кыланганын көн дә телевизордан күрсәтеп торалар. Конституцион тәртип урнаштырабыз, дигән булып, Грозный кадәр Грозный шәһәрен жир белән тигезләделәр.

Төне буе гәпләшеп чәй эчеп утырдылар. Энесе аракы да чыгарган иде, Әхәт эчмәде, сугышка аек китәсе килде.

Тарихны шәп белә Кәбир. Татарнын дәүләтчелеге турында әллә нинди кызыклы нәрсәләр сөйләп бетерде. Ә Әхәт урыс мәктәбендә укыды, ул Явыз Иваннын Казанны кайчан һәм ни өчен алганын да белми. Әллә, кыланып, әллә үткен сүзле булып күренергә теләүдән, ул хәтта: «Син акгвардияче, ә мин кызыллар ягында»,—дип күкрәк какты. Нигә? Бу чагыштыруның һичбер мәгънәсе юк лабаса. Икебез ике төрле кеше димәкче идеме? Юк ла, ул да энесе кебек Аллага ышана, татарнын Муса Жәлил кебек батыр уллары булуына горурлана бит. Татардан сугышта немецлар да өркеп торган. Хәер, башка язучыларны, шагыйрьләрне, каһарманнарны белми дә белми инде. Урыс мәктәбендә белем алган барча татар балалары өчен дә хас күренеш бу. Алар Муса Жәлил белән Тукайдан ары беркемне дә атый алмый.

Кирәк бит, әти-әнисе, нәрсә килеп чыгар икән дип, Әхәтне—урыс, Кәбирне татар мәктәбенә биргәннәр. Хәзер билгеле инде нәрсә килеп чыкканы. Әхәт офык, шәфәкъ дигән сүзләрнен дә мәгънәсен белми. Ятлап караган иде, барыбер бутала. Татарча сөйләшкәндә ин әүвәле урысча уйлый. Хәзер ясап кара син аннан чын татар кешесен!

Күп сүз куерттылар ул төнне. Иртәнге сәгать икеләр тирәсендә ишегалдына тәмәке тартырга чыктылар. Сандугачларнын сайрап туктаган гына мәле. Каяндыр скрипка тавышы ишетелде.

Кем уйный дип кызыксына башлагач, Кәбир аны күрше урамдагы бер таш йортка алып китте. Анда кыллы уен кораллары ясый торган Иттакый исемле бер карт яши икән.

Йорт сарыга буялган дүрт катлы ике бинадан тора иде. Аларны дугалы биек таш капка тоташтыра. Заманында НКВД хезмәткәрләре яшәгән монда. Хәзер дә юк-бар кеше яшәми, күбесе—медицина өлкәсендә эшләүчеләр.

Урам якка караган йортның беренче катындагы тәрәзәдән һаман скрипка моны агыла. Кәбир, аяк очларына басып, кычкырып сәлам бирде:

—Хәерле иртә, Иттакый ага!

Скрипка тынды. Тәрәзәдә калын күзлек кигән какча гына йөзле картның башы күренде.

—Нинди иртә булсын әле, таң да атмаган ич,—диде ул, елмаеп. Аннары, кем килде икән дип, үрелеп аска карады.—Ә-ә, Кәбир... Йокы керми мәллә, балакаем?

—Синең скрипкада уйнаганыңны ишетеп килдек, Иттакый ага.

Карт көрсенеп әйтте:

—Уйнау түгел инде бу, шыңгырдату гына. Өзелгән бармаклар белән әлләни майтарып булмый. Тавышын тынлап карыйсы килгән иде, әле генә ясап бетердем бит.

Иттакый ага моннан ун ел элек скрипка ясаганда ике бармагының очочларын станокта кистергән икән. Консерваториядән китүенең сәбәбе дә шунда.

—Шәп скрипка килеп чыккан,—диде Кәбир.—Тавышы безнең урамга кадәр ишетелә. Син уйный башлагач, сандугачлар да тынып калды. Мин дә абый белән килеп җиттем менә.

—Рәхмәт, бик рәхмәт... Сандугач дигәннән, бу скрипканы ясый-ясый яз үткәнен дә сизми калам инде. Син дөрес әйтәсең, шәп скрипка килеп чыкты бу юлы. Мондый ук моңлы тавышлы булыр дип уйламаган идем.

Кәбир көлеп җибәрде:

—Син һәрвакыт шулай дисең, Иттакый ага. Скрипкаларың начар булса, Югославия, Германия кадәр җирдән музыкантлар килеп йөрмәс иде яныңа.

—Анысы шулай шулаен, заказлар күп,—карт каты итеп тамак кырып куйды.—Алга таба нишлисе булыр, сәламәтлек бетеп бара. Янымда бер-бер шәкерт булса да күңел тыныч булыр иде. Үзем белән китеп бара бит барысы да.

—Алай тиз генә биреşмә инде син.

—Әйттең сүз... Сиксән өченче яшемне барам ич. Яшьтәшләрем дә күптән кабердә. Алардан башка монсу мина. Кайвакыт үземне поездга соңга калган кебек хис итәм,—картның җыерчыклы битеннән яшь бөртеге тәгәрәп төште.—Бигрәк тә Хөснулла нык сагындыра. Шәп композитор иде. Ничә еллар бергә консерваториядә эшләдек. Немецта пленда булганы өчен гел бимазалап тордылар үзен. Башта НКВД, аннары МГБ, аннары КГБ гел тикшереп торды бахырны.

—Иттакый ага, скрипкагызда уйнап карарга буламы?—диде аларны тынлап торган Әхәт.

—Син скрипкада уйный беләсеңмени?

—Беләм. Мәктәптә укыганда скрипка классына йөрдем мин. Дөрес, инде күптән уйнаганым юк.

—Бик һәйбәт, бик һәйбәт,—диде карт, елмаеп, һәм тәрәзәдән лак исе аңкып торган өр-яңа скрипканы сузды.—Мә, уйнап кара.

Скрипканы кулына алгач, Әхәт берара каушап торды. Күптән уйнаганы юк бит. Грифта берничә тапкыр бармакларын биетүгә, дөньясын онытып уйнап һәм җырлап җибәрде:

> Кайчак күзләреңнән көчләр алып,
> Биеклеккә таба ашам мин.
> Ә кайчакта башым түбән иям,
> Әй, Әминәм, синнән качам мин.

—Син дә Такташның «Урман кызы»н яратасың икән,—диде карт,

монсуланып.—Әллә нинди илаһи моң бар бу җырда. Гомерем буе уйныйм, ләкин уйнап туя алмыйм.

—Рәхмәт, балачагыма кайткандай булдым!—Әхәт тәрәзәгә скрипканы сузды.

—Үзеңдә калдыр, балакаем. Миннән истәлек булсын.—Иттакый ага скрипканы алмады.

Әхәт бик сөенде.

—Менә бу ичмаса бүләк!—диде ул, сөенеченнән балкып.—Страдиварий скрипкасының серен ачмадыгызмы әле?

Карт серле генә елмаеп әйтте:

—Бернинди дә сер юк монда. Страдиварий скрипкалары белән алыш-биреш итүче коллекционерлар уйлап чыгарган легенда гына бу. Җаныңны биреп эшләсәң, барысы да Страдиварий скрипкалары инде алар...

Иттакый ага өйгә чакырса да, Кәбир белән Әхәт кереп тормадылар. Чөнки өйдәгеләрне уятасылары килмәде. Карт белән саубуллашкач, алар өйләренә кайтып йокларга ятты.

Төшкә кадәр йокладылар. Әхәт кичке якта «Казан-Самара» поездына утырды. Самарадан контрактникларны самолет белән Төньяк Кавказга җибәрергә тиешләр иде.

Чечняда вакытта Әхәт музыкант картны еш искә төшерде. Кайда гына булса да, скрипкада уйнап, гел «Урман кызы»н җырлады:

> Нигә, нигә синең шаян күзләр
> Күзләремә болай багалар?
> Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
> Керфек очларыңнан тамалар?

Булачак хатыны белән Горький паркындагы «пятачок»та биегәннәр иде алар Такташның «Урман кызы»на. Әхәтнең милиция мәктәбендә, Сәриянең педагогия институтында укыган чагы. Шул ук көнне егет аны беренче тапкыр өенә озатып куйды. Сәрияне күрше егете Витя да яратып йөри иде. Сәрияләрнең подъездлары янында берничә тапкыр тукмашып та алдылар. Озакламый Сәрия белән Әхәт өйләнештеләр. Витя, бу хурлыкны кичерә алмыйча, Нефтеюганск якларына китеп барды. Һәм менә, Сәрия шул урыс егете белән...

Әйе, сагынды да, ачуланды да, рәнҗеде дә Әхәт хатынына. Чеченнар Грозныйны алган вакытта хәрабәләр арасында башын чыгармыйча гына автоматтан «тыр-тыр» һавага атып ятканда, Кәбирнең: « Ялгышасың, абый!»,—дигән сүзләрен дә искә төшереп елады. Дөрес әйткән энесе, бу каһәр суккан сугышта аңа берни дә калмаган иде. Сугыш түгел бу, суеш! Кайвакыт, кайда дошман, кайда үзебезнекеләр икәнен онытып, бер ротаның икенче ротаны кырып салган чаклары да булды. Ә һаваны дерелдәтеп очкан куәтле «Су-27» истребительләре бутала да бутала инде. Бомбалар теге якка да, бу якка да ява. Чөнки монда билгеле бер фронт сызыгы юк. Еш кына арматуралары гына тырпаеп калган бетон хәрабәләр көнгә берничә тапкыр кулдан-кулга күчә иде. Чеченнар юлбарыстай батыр сугыша, ә контрактникка нәрсә, сәгате бара, димәк, акча да бара, тик ят шунда һавага атып! Ватан дип, медаль дип башсыз каласың икән, йә тауларда, йә шушы хәрабәләрдә каргаларга ризык булып ят. Кыскасы, герой булып үләргә җыенучылар юк иде алар арасында. Аннары, күпләр нинди Ватан өчен сугышуын да аңлап житкерми иде.

Менә ул инде Кәбирнең сары төскә буялган бер катлы агач йорты янына килеп җитте. Каршы як бакчадагы карт чия агачы шау чәчәккә күмелгән. Хәерлегә булсын, китүе дә, кайтуы да яз аена туры килде. Коймалардагы яшел буяу, әллә кояш, әллә җил-яңгыр тәэсиреннән купшыкланып, инде менә-менә коелам дип тора. Тәрәзәдә ут юк. Кәбир инде йоклый торгандыр.

Өйләнмичә дә кала бугай инде энесе. «Заря» фабрикасында эшләгән Ркыясы үлеп киткәч, үзенә ярардай хатын-кыз таба алмады. Яман шеш авыруыннан китеп барды ул. Бер күкрәгеН алдырса, исән каласы булган. Кыз кеше өчен зур фаҗига инде бу, үлсә үлде, күкрәген алдырмады.

Чу! Тагын скрипка тавышы!

«Менә могҗиза,—дип уйлады Әхәт, аркасындагы парашют ефәгеннән тегелгән биштәрне сикертеп.—Әйтерсең, Иттакый ага минем кайтканымны көтеп торган. Димәк, исән-сау. Тагын скрипка ясагандыр.»

Агачлардагы яфракларны, салмак кына искән җилне, колакны иркәләгән илаһи музыкаль авазлар үксеп-үксеп адәм баласы елаганны хәтерләтә иде. Күк йөзен томалый башлаган кара болытлар да, бу аһәңнән күңелләре тулгандай, җиргә күз яшьләре кебек эре-эре тамчыларын койды.

Әхәт тә түзмәде, ике кулы белән башын тотып, ыңгыраша башлады. Үзенең язмышын җимергән, Чечня дип аталган тәмуг утына керергә мәҗбүр иткән түрәләргә, хыянәтче хатынына рәнҗеп елады ул. Ә бу тәмуг уты мәңге онытылмас. Шәһәр урамнарындагы танк сытып киткән, бомбадан эчәгеләре актарылып ташланган исәпсез-хисапсыз ир-ат, хатын-кыз мәетләре, наркоман контрактник тарафыннан штыкка күтәрелгән чечен сабые, БТРда янып үлгән яшь солдатлар—барысы да куркыныч төш булып күренә хәзер аңа.

Яшен ялт-йолт итеп алды да, утлы сөңге белән каршы як йорт түбәсендәге антеннаны сугып аударып, таш түәлгән арба тәгәрмәче тавышларын чыгара-чыгара, гайрәт чәчә башлады. Урам бер яктыра, бер караңгылыкка чума. Әйтерсең туплар ата, тимер кошлар җиргә үлем чәчә. Асфальтта җыелып яткан бихисап күлләвекләр дә шул бомбалардан өзгәләнгән адәм мәетләре сурәтенә керә. Элек ярата иде Әхәт яшен яшьнәгәнне. Күк дөбердәве дә үзенә күрә бер тылсымлы нәрсә булып тоела иде. Ә хәзер барысы да үзгәрде. Җимерек йортлар күрсә, шундук йөрәге кага башлый. Эт-мәче күрсә, күңеле болгана. Грозныйда вакытта күп ашадылар бу йорт хайваннарын. Ачлык кына түгел, бетләр дә җаңга тиде. Ул хәзер дә бетле. Шуңа күрә дә туганына капка дөбердәтергә ояла.

Бераз тынычлангач, Әхәт тәмәке кабызды. Яңгыр инде коя. Юньләп тарта алмады, тәмәке ике бармак арасында юешьләнеп, тәмам таралып бетте. Эре-эре яңгыр тамчылары, битендәге тозны юып, иренгә агып төшә. Әллә яңгыр тамчылары, әллә чәчтәге бетләр, корырак урын эзләгәндәй, арканы кытыклап, гимнастерка эченә үрмәли. Кәбир бет күргән кеше түгел. Ничек каршы алыр икән? Кычкырып көләр, мөгаен. Ә бәлки елап та җибәрер. Елый гына күрмәсен, юкса Әхәт үзе дә елап җибәрәчәк. Күңеле тиз тула хәзер.

Тәрәзәдә ут күренде. Кәбир йокламый, күрәсең, борчыла торгандыр. Әхәтнең инде күптән хәбәр салганы юк.

Фронтовик капка дөбердәтте. Дулкынланудан йөрәге менә-менә чыгам дип тибә. Мескен булып түгел, герой булып күренәсе килде аның. Шуңа күрә, елмайгандай итте, билендәге каешын рәтләде, урынындамы дигәндәй, күкрәгендәге медальне тотып карады...

—Кем бар анда?

Әхәт эндәшмәде. «Һы, кем бар анда, имеш,—дип уйлады ул.—Бер дә күңеле сизми микәнни?

Тагын тавыш:

—Кем бар анда, дим?!—Кәбир инде зәһәрләнә.

—Мин кайттым, энекәш!

—Ә?..

Кәбир йөгереп барып капканы ачты. Болдырда эленеп торган лампочка яктысында ябык кына чырайлы, кара тут йөзле солдатны күргәч, өнсез калып әйтеп куйды:

—Исән!

Кочаклаштылар. Икесенен дә күзләреннән яшь ага.

—Сине күрер көннәр дә бар икән әле, энекәш!—Әхәт пышылдап кына әйтте бу сүзләрне.—Менә... медаль дә бирделәр.

—Керик,—диде Кәбир, анын аркасындагы биштәрне салдырып.—Лычма су булгансың бит, әй! Мин сине ун көннәр элек төшемдә күргән идем. Имеш, елмаеп капка янында басып торасың. Чәчең жилкәнә житкән. Юлдадыр, дип юраган идем, хак булып чыкты.

—Дөрес юрагансың, безнен бригаданы ул вакытта Буденовск шәһәренә чыгарганнар иде.

—Ярты ел хәбәрең булмады. Кайгырып үлә яздык. Әти белән әни дә тәмам бетеренде.

—Гафу ит, энекәш, мөмкинлек булмады... Сәриядән хәбәр юкмы?

Кәбир нәрсә әйтергә дә белмичә тынып калды. Бар андый хәбәр. Тик абыйсынын күнелен төшерәсе килмичә, сүзне икенчегә борды:

—Уз, әйдә, күнитегеннe өйгә кергәч салырсын.

Өйгә кергәч, алар авызларын ерып бер-берсенә карашып тордылар.

—Чын фронтовик!—Кәбир тел шартлатып куйды.—Дары исе килеп тора үзеннән. Бер дә Рәсәй телевидениесе күрсәтә торган гаярь солдатка охшамагансын.

—Шуның өстенә, бетле дә әле.

—Бетле?

—Нигә шаккаттын? Рәсәйнең берләнбер байлыгы инде ул.

Икесе дә кычкырып көлеп жибәрделәр. Әхәт биштәреннән беткә каршы ике шампунь һәм берничә карабодай консервасы чыгарды. Шунда ук целлофан пакет рәвешендәге көмешсу «фляга», кыр шартларында коры спирт белән ризык жылыта торган шәмдәл кебегрәк дүртаяклы калай жайланма да бар.

—Без хезмәт иткәндә мондый нәрсәләр юк иде,—диде Кәбир, аларны караштыргалап.

—Дөнья алга бара, энекәш,—Әхәтнен кыяфәте бик беллекле.—Хәзер Совет армиясендәге кебек алюминий фляжка күтәреп йөрмиләр. НАТО солдатларыннан калышмаска тырышабыз инде.

—Медальне нәрсә өчен алдын?

—Күрмисенмени, «За боевые заслуги» дип язылган.

—Шулаймы? Үз халкын белән сугышкан өчен дә медаль бирә башлаганнар икән бездә.

—Медаль генә түгел, Герой исеме дә бирәләр, энекәш.

—Шампуньнәрең бик шәп икән. Мыраужаннын бетләрен коясы булыр.

Әхәт иң ахырдан кыршылып беткән скрипка чыгарды.

—Таныйсынмы?—диде ул, аны өстәлгә куеп.

—Танымыйча сон, Иттакый ага ясаган скрипка ич бу! Кәбир аны кулына алып карарга иткән иде, әллә ничек кенә кулыннан төшереп жибәрде. Бәхеткә, идәндә палас булганлыктан, аңа зыян килмәде.

—Саграк кылан, минем аны Чечняда вакытта да кулымнан төшереп жибәргәнем булмады,—Әхәт скрипканы кадерләп кенә өстәлгә куйды.—Кеше жаннары бар бу уен коралында, энекәш. Иттакый ага нихәлләрдә?

—Болай ярыйсы гына кебек. Картайды инде, инсульт та кичереп алды. Шуннан сон хәтере бик начарланды. Алай да ясый әле скрипкаларны.

Кәбир газ плитәсенә чәй кайнатырга куйды. Аннары, абыйсына чишенергә кушып, шифоньердан коры күлмәк һәм чалбар өстерәп чыгарды.

—Син боларны өйалдына чыгарып ыргыт инде,—диде Әхәт, трусик белән майкадан гына калып.—Бетләре мыжгып тора, иртәгә юарбыз. Мунчаң торадыр бит әле?

—Тора, кая китсен ул? Ике яктан да иске йортларны сүтеп-җимереп киләләр, рәхәтләндек утынга. Күршеләр белән ярыша-ярыша тарихны мичтә ягабыз. Андагы сагызланып торган нарат бүрәнәләрне күреп йөрәк әрни. Сала белгәннәр дә соң борынгылар! Ул тәрәзә, капка бизәкләрен генә әйт әле син, нинди генә юк араларында. Безнең ярты Шәмәрне бизәргә була алар белән. Әрәм мал!

Әхәт гимнастеркасыннан салдырып алган медальне майкасына тагып куйды.

—Син аны йоклаганда да тагып йоклыйсыңмы?—диде Кәбир, көлеп.

—Торсын бүгенгә,—фронтовик, йортны күздән кичереп, тел шартлатты.—Синең йортың да бик борынгы булырга охшаган.

—Борынгы булмыйча ни, инкыйлабка кадәр үк салынган инде. Заманында монда бер байның итек мастерское булган. Максим Пешков яшәгән йорт та яр өстендә генә утыра. Бәлки, ул да монда үзенең күнитеген ремонтлаттыргандыр. Ә аның янәшәсендә генә Володя Ульяновның йорт музее урнашкан. Аның да булып китүе ихтимал. Ул да ялан тәпи йөрмәгәндер.

—Булыр, булыр,—дип мыгырдады Әхәт.

Кәбир керләнеп беткән гимнастерканы караштыргалый башлады.

—Прәме йөгерешеп йөриләр! Сөйләсәң, кеше ышанмас. Кайда бетләп беттең шулай?

—Буденновскида... Анда безне, ике йөз кешене, япа-ялан басуга куып чыгардылар. Бер ай палаткаларда аунап яттык. Һәр тарафтан юеш салкын җил исә. Юынырга сабын да юк иде. Әле ничек ачтан үлмәгәнбез, белмим.

—Нишләдегез анда?

—Үзебезгә тиеш акчаны көтеп яттык. Без инде өч ай элек кайтып китәргә тиеш идек. Анда да сорыкортлар җитәрлек. Командование вәкиле, акчаларыгызны яшәү урыныгызга җибәрербез, дигәч, дивизиядә буза купты. Контингент бик чуар: контрактникларның күбесе элекке алкоголиклардан, наркоманнардан, милициядән куылган, төрмәдә утырып чыккан башкисәрләрдән тора. Яхшы тормышта яшәгән кеше акча өчен сугышка барып керми инде. Аларны тыеп кара син! Берәүләр, самоволкага чыгып, хатын-кызларны көчли, икенчеләре кибет талый, өченчеләре... Булды инде хәлләр. Казаклар тәмам гарык иде. Алар, боевиклардан бигрәк, бездән куркалар иде. Контрактниклар офицерларны да кыйный башлагач, төнлә казарманы спецназ әйләндереп алды. Барыбызны да коралсызландырдылар. Басуның дүрт ягына дүрт туп куелды. «Баш күтәрәсез икән, барыгызның да башы бетәчәк, әти-әниләрегез, хатыннарыгыз, балаларыгыз, туганнарыгыз өчен сугыш кырында геройларча һәлак булган кебек саналачаксыз!»,—ультиматум шундый иде. Алай да соңыннан акылга килделәр тагын, бөтенесен бирмәсәләр дә, азмы-күпме акча өләшә башладылар. Акча алган һәр контрактник конвой белән шундук поездга озатыла. Анда да тынычлыкта калдырмыйлар. Бер баштан икенче башка йөргән хәрби патруль үзенчә акча эшли: сәдәфең төймәләнмәгән икән, акчаңны чыгарып сал. Устав бозу дип санала бу. Юкса ике дә уйламыйча төшереп калдырачаклар. Ә төшеп калган кешенең язмышы билгеле. Халык безне яратмый. Анда син уч төбендәге кебек: йә бандитлар кулына эләгеп коллыкка китеп барасың, йә шундук башыңны кисеп ыргыталар. Контрактникларга мәрхәмәт юк. Шушы поездга утыргач кына аңладым мин отпускыга киткән солдатларның хәбәрсез югалу сәбәбен. Патруль миңа бәйләнә алмады, чөнки аек идем. Тәмәке дә тартмадым, башкалар кебек мактанып та, исерек күз яшьләре дә түгеп утырмадым.

Чәй кайнап чыккач, Кәбир тәбә пешерде, колбаса кисте. Аракысы да бар икән, суыткычтан «Распутин» шешәсен алып, кырлы стаканнарга тутырды.

—Синең исән-сау кайтуың өчен, абый!—диде ул, Әхәт белән чәкешеп.

—Рәхмәт.

Аракы исертеп җибәрде. Әхәтнен үтереп-үтереп күнел бушатасы килә. Шуна күрә ул, Кәбирнең нәрсәдер әйткәнен дә ишетмичә, сөйләвен дәвам итте:

—Шулай, энекәш, күреп кайттым мин сугышны. Турысын әйтим, әле хәзер дә исән-сау кайтканыма ышанып җитә алмыйм. Чеченнар язмышы эләгә күрмәсен безгә. Сүз дә юк, батыр халык. Ләкин батыр булып кына бу кадәр зур Рәсәйне җинеп булмый. Буденновскига чыккач, мин шаккатып андагы йортларның диварларын сыпырып йөрдем. Аллага шөкер, нинди матур, нинди төзек йортлар да бар икән бу дөньяда, дим. Грозныйдагы җимереклек нык туйдырды. Бу мәхшәрдән котылып, аркаларына гранотомет, автомат асмаган кешеләрне, блокпостлар белән шыплап тутырылмаган чатларны, клумбаларда чәчәк үсеп утырган урамнарны, төзек йортларны күрәсе килә иде. "Бабай"га рәхмәт, әгәр ул хәйләкәр булмаса, безне дә шундый язмыш көтә иде. Уртак тел тапты бит Мәскәү белән. Килешү дә төзи алды. Казан, әнә, ничек матурайган, исен китәр!

—Ул килешүнең гомере кыска булмагае, абый!—Кәбир авыр сулап куйды.—Ельцин властьтан, аракыдан мингерәүләнгән арада гына ирешә алган казаныш бу. Мәскәү бераз хәл алсын әле, аннары ул синең килешүенә дә, конституциянә дә, яна законнарына да шәпләп алыначак.

—Мөмкин, бик мөмкин,—дип тәкърарлады Әхәт, тәмәке кабызып.—Мәскәү хәйләкәр, ул татарга беркайчан да үсәргә ирек бирмәячәк.

—Ә беләсеңме нәрсәгә?

—Әйтеп кара.

Кәбир кызып ук китте:

—Чөнки бу халык хөрмәткә лаек түгел!

—Әйттең сүз...—дип көлде Әхәт.—Син, энекәш, халык кадәр халык белән авыз чайкама.

—Чайкыйк әле бераз... Нигә хөрмәткә лаек түгел дип сора башта. Бу халык инде менә ничә еллар үзенең сөекле композиторы Салих Сәйдәшевка һәйкәл куя алмады. Монда Мәскәү ризалыгы кирәкме? Элек Тукай яшәгән «Болгар» кунакханәсенең инде урам якка караган диварлары гына утырып калган. Бу кунакханәдә Тукай «Кисекбаш»ны иҗат икән, анда үзенең каләмдәшләренә шигырьләрен укыган. Аны торгызыр өчен Мәскәү ризалык бирергә тиешме? Тукайның каберенә барып кара. Белмәгән кеше аны тиз генә эзләп тә таба алмый. Анда мемориал ясау өчен Мәскәү комачау итәме? Урамнарның исемнәренә күз ат. Купчелеге исем булмаганга гына бирелгән кебек. Татарның үз тарихын, мәдәниятен чагылдыра торган исемнәр бирүгә дә Мәскәү каршымы? Танылган язучыларның балалары татар телен белми. Инде бусына да Мәскәү ризалыгы кирәктер, бәлки, ә? Урыс халкы исә үзенең бөек улларына гына түгел, хәтта яраткан персонажлары Василий Теркин белән Остап Бендерга да һәйкәл куя. Остапның һәйкәлен Рио-де Жанейрога кадәр барып куйдылар. Үз-үзен хөрмәт итмәгән халыкны нинди халык хөрмәт итсен?!

Шулай диде дә Кәбир кинәт туктап калды. Аннары, калган аракыны стаканнарга тутырып, битараф кына кул селтәде:

—Үзгәртик теманы... Без лыгырдап кына үзгәрсә иде дөнья. Татарлыгыбыз бетеп бара—бусы хак. Телне белмибез, тәмәке тартабыз, аракы эчәбез... Хотя, бүген Казан каласында, синең белән минем кебек, ике татар борчылып сөйләшеп утыра икән, өмет бетмәгән әле.

—Сөйләшеп утырырга гына калды инде...—диде Әхәт, каһкаһә белән елмаеп.

—Бер бөек шәхес әйтмешли, фикер һавада очып йөри. Фикер һавада очып йөри икән, димәк, җир йөзендә безнең кебек уйлаучылар да бар. Безнең кебек уйлаучылар бар икән, без ялгыз түгел... Йә, сугышта ниләр күрдең?

—Телевизор карамадыңмыни?—диде Әхәт, иренен пешерә башлаган төпчекне һаман да суырып.—Сез күбрәк белергә тиеш. Безнең анда телевизор карарга вакыт булмады. Боевиклар булганда боевиклар белән сугыштык, боевиклар булмаганда бетләр белән сугышып гомер узды... Ярый, бусы шаяртып кына инде. Ә сугыш мәсьәләсенә килгәндә, аның үз хикмәтләре бар, энекәш. Бер мәзәк хәлне сөйлим әле. Дөресрәге, мәзәк тә, кызганыч та инде.

Тауларда булды бу хәл. Иртәнге якта Казылык авылы янында безнең автоколонна засадага юлыкты. Бик каты бәрелеш башланды. Без—юлда, боевиклар—урман авызында. Ара нибары ике йөз метрлап булыр. Янгыр чиләкләп коя, сазда аунап атышабыз.

...Көндезге сәгать икегә кадәр атыштык.

Ниһаять, тынлык. Тирә-юньгә күз салам. Боеприпас тутырылган йөк машиналары, БТРлар инде күккә очкан. Һәр тарафта мәетләр өелеп ята. Исән калган «Ваз» машинасы яныннан рота командиры капитан Шевальчук кычкыра:

—Живые есть?

Тереләр әле моннан, әле тегеннән аваз сала башлады:

—Я живой!

—Я!

Мин дә исәнлегемне белдердем:

—Живой вроде...

—Всем, кто может, ползком ко мне!—дип команда бирә капитан.

Командирыбыз хохол егете. Озын буйлы, киң җилкәле ир-ат булса да, йөзе кызларныкы кебек матур. Шуңа күрә солдатлар аны үзара «Кызый» дип йөртәләр иде. Заманында баскетбол белән шөгыльләнгән. Бик аз сүзле. Авызыннан «әйе», «юк» дигән сүзләрне генә өстерәп чыгарып була. Йошкар-Олада ГАИ инспекторы булып эшләгән. Бер мотоциклистны эзәрлекләгәндә, тәгәрмәченә атам дип, аягына тидергән. Шартлы рәвештә бер елга ирегеннән мәхрүм иткәннәр. Чечняга китәр алдыннан бензоколонкада каравылчы булып йөргән. Утыз яшьтә булса да өйләнмәгән әле. Яраткан кызы бар. Монда килүенең сәбәбе дә шул кыз аркасында. Леонид шәһәрнең иң затлы рестораныңда гөрләтеп туй үткәрергә җыена.

Барыбыз да шуыша-шуыша командир тарафына җыелдык. Капитаннан тыш, нибары дүрт кеше! Бер-беребезне танырлык түгел. Көне буе пычракта аунап, дуңгыз кыяфәтенә кереп беткәнбез, күзләр генә күренеп тора.

—Кырылганбыз икән,—диде Шевальчук, нык кәефсезләнеп. Аннары урман ягын бинокльдән күзәтергә тотынды.—Күренмиләр... Киттеләр ахрысы...

—Вряд ли,—диде арадан берәү.

—Мин дә шулай дип уйлыйм,—диде Шевальчук, бинокльдән күзен алып, гимнастерка җиңе белән тирләгән маңгаен сөртеп куйды.

—Нигә вертолет килмәде, иптәш капитан?

—Ягулык юк диделәр!—Командир калтыраган куллары белән тәмәке кабызды да, бер-ике тапкыр суырып алгач, сүгенеп үк куйды.—Сволочи!.. Биш-алты сәгатьтән генә булачак вертолет... Никому не вставать... Үрмәләп булса да яралыларны бер тирәгә ташый башлагыз.

Мәетләр арасында мүкәләп йөри торгач, ротадан безнең белән тагын сигез кеше исән калганлыгы ачыкланды. Бөтенесе дә авыр яралы. Ыңгырашалар. Аңындагылар су сорый. Санинструктор Михаил Калакаев рөхсәт итми, иреннәрен генә чылатып торырга куша. Яралыларны бәйләргә, карарга без дә булышабыз. Яткан килеш кенә, әлбәттә.

Менә урман ягыннан «шарт!» итеп аткан тавыш ишетелде. Ни күрим, янымда әле генә бер яралыны бәйләп яткан удмурт малае Константин

Матюхин, күзләрен акайтып, тын да алмыйча сузылып ятты. Чигәсен тишкән. Шәп малай иде. Дискотекада берәүне кыйнаган өчен өч ел төрмәдә утырып чыккан. Аннары сәгать мастеры булып эшләгән. Хатыны, ике баласы бар. Утыз биштә иде, бахыр.

—Получай!—Капитан Шевальчук автоматтан сиптерә.

Без дә сиптерәбез. Тик кая сиптергәнебезне генә белмибез.

Команда яңгырый:

—Атуны туктатырга!.. Патроннарыгызны саклагыз.

Тынлык. Тагын көтәбез. Хәлләр кәкәй, снайпер телгә килде бит. Якында гына ышыкланырдай урын да юк. Мин Шевальчукка терәлеп диярлек ятам. Еш-еш сулый, куллары калтырый. Берничә тапкыр бинокльдән карарга итте, булдыра алмады.

—Каты торалар, гады,—диде ул, минем якка карап.—Ну что, Гафуров, өмет бармы?

Инде ул да шундый шик белдергәч, эчем суынып китте. Алай да сер бирмим, аны да, үземне дә юатырга тырышам:

—Өметсез—шайтан гына, иптәш командир?

—"Алла хаббар" ни дигән сүз?

—Улмы?..Ул Алла бөек дигән сүзне аңлата.

—Син Аллага ышанасыңмы?

—Ышанам. Бигрәк тә хәзер ышана башладым.

—Мин дә ышанам,—Шевальчук елмаеп куйды.—Менә без икебез дә Аллага ышанабыз, ә үзебез кеше үтерәбез... Акча өчен... Каһәр суккан акча! Алла түгел, акча идарә итә безнең белән. Галиҗанәб акча! Галиҗанәб булса да төшкә тизәк булып керә.

Шевальчук тынып калды. Тәмәке кабызып, тагын бинокльгә алынды.

—Ну что, капитан, пагаварим?—Рациядән яңгырады бу карлыккан тавыш.

—Кто это?

—А ты не узнал, дарагой?—Боевиклар тәҗрибәле, безнең дулкынга кергәннәр. Бу кадәресе генә инде могҗиза түгел.—Вертолет ждем?

—А тебе какое дело?—Шевальчукның тавышы гасабилы.

—Уезжай домой, капитан, а не то долго ни проживечь.

—Не учи, черножопый!

—А мы скоро это узнаем, чья жопа чище. И язык твой в задницу засуним.

—Говори, да не заговаривай.

—О, наглый командир папался,—дип хихылдады боевик.—Инвалидом сделаю, клянусь Аллахом!

Элемтә өзелде. Урман ягыннан тагын «шарт!» итте. Бу юлы снайпер капитанның үзенә төзәгән икән. Ул, җилкәсен тотып, ыңгыраша-ыңгыраша, йөзе белән җиргә капланды:

—А-а-а...

Санинструктор Михаил Калапаев Шевальчукның ярасын бәйләп бетергәч, аның аптечкасыннан промедол эзләргә керешге. Бу наркотик һәркемнең индивидуль аптечкасында булырга тиеш.

—Иптәш капитан, аптечкада сезнең промедолыгыз булырга тиеш иде. Таба алмыйм.

—Яхшылап кара!—дип елак тавыш белән ыжылдады капитан.—-Сөягенә тигән, шуңа сызлана.

—Күпме карарга була инде?! Юк ул монда! Ә минем запаста бирәү дә калмады.

Капитан, улап диярлек, минем артта яткан Савелийга эндәште:

—Варламов!

—...

—Варламов, дим!

—Ну нәрсә?

—Бирәм мин сиңа хәзер—ни нәрсә... Тиешенчә җавап бир!

—Слушаюсь, товарищ капитан!

—Аптечкадагы промедолны син алдыңмы?

—Нинди промедолны?.. Юк миндә берниндидә промедол!

Варламовның наркоман икәнен белә идек, инде командирның аптечкасында да актарынырга өлгергән! Капитанның хәлен җиңеләйтергә теләп, барыбыз да сүз куешкандай үзебезнең аптечкаларыбызны актарабыз.

—Вот крыса!—Санинструктор зәһәрләнә. Варламов өстенә ташланды.—Хәзер мин сине...

Миша кызу канлы егет. Кечкенә генә гәүдәле булса да, ачуын чыгарган кешенең ипи шүрлегенә менеп төшмичә калмый. Түгәрәк йөзле, сипкелле генә битле бу егет барысыннан да яшьрәк. Срочник иде. Контракт төзеп, тагын бер елга хезмәт итәргә калган. Пермь ягыннан. Миндә Себер татарлары каны бар дип мактанырга яраткангамы, аңа «татарин» дигән кушамат тагылып калды. Шул рәвешле, безнең взводта, миннән кала, тагын бер «татар» бар иде.

—Отставить!..—Капитан еш-еш сулый. Чибәр йөзе инде зәңгәрләнеп калган.—Калапаев, тынычлан!

Соң инде. Санинструктор, снайперны да онытып, Варламовның йөзен тәя.

—Үтерәм, гад!

—Отстань!.. А-а-а!

Бу кадәр кыйналуга чыдый алмаган наркоман, сикереп торып автоматы белән биштәрен җиргә ташлады да, үкерә-үкерә урманга таба чапты. Куркудан мингерәүләнү галәмәте бу. Юкса аңа бөтенләй икенче якка чабарга кирәк иде.

Барыбыз да шаккатып аны күзәтәбез. Снайпер өчен бер дигән форсат бу. Санинструктор Калапаев инде җиргә сеңде.

—Варламов!—Акырып та берни барып чыкмагач, капитан сәламәт кулы белән автоматтан һавага атып җибәрде.

Юк, Варламов безнең якка карамый да, һаман элдертүен белә. Урман авызына инде санаулы гына адымнар калды. Снайперның ни өчен атмавы аңлашыла, ул аны үзләре ягына чыгарга тели дип уйлый.

—Ат!—Шевальчук сул ягында яткан Свиридовка Варламовны атып үтерергә куша.—Ат дим! Барыбер тегендә башы бетәчәк!

—Аталмыйм, то... товарищ командир!- дип мыгырдады Свиридов, тотлыгып.—Бәлки акылына килер әле, ә?

Петр Свиридов безнең взводта өченче көнен генә. Екатеринбург малае. Гражданкада машиналар урлаган. Шуның өчен ике ел төрмәдә утырган.

—Нинди акыл!—дип акырды капитан.—Күрмисеңмени, ул инде урманга җитеп бара!

Шул мәлне арабыздан берәү атып җибәрде. Калапаев икән. Әллә тиде, әллә тимәде, Варламов инде күзгә күренми.

Вертолетны көтәбез. Бер күзебез урманга, икенчесе һавага карый.

... Ике сәгать яттык. Җиргә караңгы төште. Күктә эре-эре йолдызлар кабынды. Гимнастеркаларыбыз инде кипшерә башлады. Алай да—суык.

Урман ягыннан тәмле шашлык исе килә башлагач, мин башта ышанмадым. Бу исне тамак ачу галәмәте дип юрап ятам. Шашлык исен башкалар да сизде.

—Во дают!—диде Петр.—Шашлык жрут.

Берәү шаяртып куйды:

—Варламовны кыздырмыйлардыр ич?

Көлүче булмады.

—Вертолет килгәч, аларның үзләреннән шашлык ясаячак!—Капитан

Шевальчук теш шыгырдата. Йөзе ап-ак. Шактый хәлсезләнгән.

Миңа эндәшә:

—Гафуров, барып карале, зинһар. Крыса булса да, үзебезнеке бит. Бәлки исәндер?

Нигә мине җибәрә? Калапаевны җибәрсен әнә, ботканы ул пешерде. Күнелдән генә сүгенә-сүгенә, шуышып урман тарафына юл тоттым.

Үлән—тездән, тирләгән маңгайга озынборыннар килеп сарыла. Борыным кычытып, берничә тапкыр төчкереп тә алдым. Бара торгач, икенче тарафкарак килеп чыкканмын икән. Бернишләр хәл юк, тагын шуышам. Борынны һаман тәмле шашлык исе кытыклый. Сәлмәннекеләр кулына эләксән, шундук әппәр итәчәкләр. Аныкылар бик рәхимсез дип сөйлиләр. Элегрәк чеченнарда әсирне бәрән кебек сую гадәте булмаган. Гарәпләрдән килгән гамәл бу. Нигә кирәк болай кылану? Хәер, сугыш шундый мәрхәмәтсез нәрсә инде, бер кансызлык икенче кансызлыкны тудыра. Ә кансызлык ике яктан да хәтәр.

Хәл бетте. Урман авызына кадәр—инде биш-алты гына адым. Автомат үзе генә дә җиде кило. Өстәге «лифчик» та ( без бронежилетны шулай дип атый идек) гер кебек авырайды. Башымны югарырак күтәреп карыйм. Күренми Варламов. Чалбарымның тез турысы тәмам юешләнеп, тишелеп чыккан. Беткән баш беткән дип, кычкырып та карадым. Тынлык. «Кайда булыр бу адәм актыгы?—мәйтәм, эчем пошып.—Үле гәүдәсе булса да юк бит ичмаса».

Сәгатемә күз салдым, инде бер сәгать шуышып йөрим икән. Кайтырга кирәк. Йөгереп кайтсаң да булыр иде, снайперның төнлә күрә торган җайланмасы булуы ихтимал. Аларда бөтен нәрсә дә заманча. Без һаман да кирпеч кадәр рация белән йөрибез, ә боевикларның кулында—спутник аша элемтәгә керә торган кесә телефоны.

Тагын күтәрелеп карадым. Нәрсә бу? Каршыга сәер генә бер шәүлә килә. Кеше дисәң, мөгезе бар, хайван дисәң, бер дә хайванга охшамаган. Шундук җиргә сеңдем. Ятам көтеп. Үзем дер-дер калтырыйм. Каршыга боевик чыгып басса да болай шөлләмәс идем.

Якыная... Автоматны предохранительдән төшердем. Өскә ташланса, бөтен магазинны утыртып бетерергә исәп . Чү!.. Ап-ачык ишетәм: мәэлди бит бу җан иясе! Кәҗәме?.. Булмас, кәҗәнең арткы тоякларына басып йөргәне юк. Яхшылабрак карасам, Варламов икән! Йөрешеннән таныдым. Үрдәк кебек әле бер, әле икенче якка янтаеп атлый ул.

—Варламов!—дип пышылдыйм тегенә.

Ишетми. Өстендә кәҗә тиресе, кулында сумка. Һаман мәэлдәвен белә:

—М-ә-ә...

Тагын бер кат эндәшкәч, туктап калды.

—Баса күрмә, мине күзәтәләр!—дип пышылдады ул.

—Нигә мәэлдисең?

—Мәҗбүр иттеләр.

Аңлашылды. «Козел» ясаганнар контрактниктан. Ул мәэлди-мәэлди алга атлавын белде. Ә миңа шуышырга кирәк. Көләсе генә килә бит, каһәр!

Варламов безнекеләр янына килеп житте, ахры, шәүләсе инде күренми. Шаркылдап көлгән тавышлар монда кадәр ишетелә.

Бераздан мин дә килеп җиттем. Арка тулы шабыр тир. Суга чумып алсаң да болай юешләнмәс иден. Күрәм, барысы да нәрсәдер чәйнәп ята.

—Ахат, мә, шашлык аша!

—Нинди шашлык?—мәйтәм.

—Боевиклар күчтәнәчкә кәҗә ите җибәргән.

—Ә-ә...

Шул мәлне тагын рация телгә килде:

—Командир!—Элемтәдә боевик.

—Нәрсә кирәк?

—Мин анда кәҗә итеннән бераз шашлык һәм морфий җибәргән идем. Хәленә керим дидем инде.

—Шашлыгыңны ашадык, ә морфиеңны күрмәдем.

—Ха-ха-ха!.. Бирмәдемени? Шулай дип уйлаган идем мин аны. Ну, козел! Син аның беләгенә кара, наркоман бит ул. Шундый яугирләр белән безнең җиргә конституцион тәртип урнаштырырга килдеңме?

Варламовның сытык тавышы ишетелде:

—Миндә ул морфий, иптәш командир.

Аның янында яткан берәү кычкыра:

—Ыштан төбенә тыгып куйган ул аны, иптәш капитан!

—Сволочь!—Шевальчук тешен шыкырдатып куйды.—Исән-сау кайтып җитик әле...

Калапаев морфийны кадагач командирның кәефе яхшырып китте.

—Спасибо,—диде капитан, рация төймәсенә басып. Боевикка эндәшүе инде.

—Живи, дарагой.

Боевикка рәхмәт әйткән өчен аны берәү дә сүкмәде. Мондый чакта шайтанга да рәхмәт укырсың. Аннары безнең чеченнарга үчебез дә юк бит. Чеченнар үз җирләре өчен сугыша, ә без акча эшлибез.

Төн уртасында күктә хәрби вертолет гүләве ишетелде. «Ми-8» боралагы! Сәгатенә ике йөз илле чакрым чамасы ара уза торган куәтле машина! Ракеталар белән шыплап тутырылган бу очкычтан боевиклар нык курка. Вертолетның габарит утлары сүнгән, чөнки алар дошман өчен бер дигән мишень. Бирә хәзер кирәкләрен, дип уйлыйбыз, сөенеп. Капитан Шевальчук һавага сигнал ракетасы очырды.

Вертолет инде безнең өстә бөтерелә. Нигә боевикларны утка тотмый? Координаталар бирелгән ләбаса. Боеприпасы юк. Һаман да шул хәерчелек инде. Бичара Рәсәй, боевиклар өчен ике-өч ракета таба алмаган! Очкыч җиргә төшеп утырырга ашыкмый. Күпме бөтерелергә була?! Шикләнәдер, безнең урында Рәсәй солдаты киеменә киенгән боевиклар булуы да ихтимал.

Бу боралак урманда яшеренеп яткан боевиклар өчен бер дигән мишень. Аңа төбәп бер-бер артлы ике ракета җибәрделәр. Көчле шартлаудан күпмедер мизгелгә бөтен дөнья яктырып киткәндәй булды. Тирә-юньгә бөтерелә-бөтерелә утлы вертолет калдыклары оча. Берничә утлы тимер кисәге без яткан урынга да шапылдап килеп төште. Шаккатып бу мәхшәрне күзәтеп ятабыз. Һәммәсен бер генә уй борчый: ничек кайтып җитәрбез? Янда авыр яралылар да бар бит.

Рациядән боевик тавышы ишетелә:

—Извините за вертолет. Пока, ребята! Мы уходим. Может еще встретимся. Пути Аллаха неисповедимы.

Боевиклар сүздә торды. Снайпер безне бүтән борчымады. Яралыларны «Ваз» машинасына ничек сыйдырганбыздыр, белмим, аларны капитан Шевальчук белән озатып җибәрдек. Рульгә санинструктор Миша Калапаев утырды. Ә безгә үзебезнекеләргә кадәр һәр тарафтан үлем белән янаган чокыр-чакырлы, пычрак, ташлы тар тау юллары буйлап тагын бер тәүлек атларга кирәк иде...

Тәрәзәдән көн яктысы төшә башлады. Кәбир мәрхүмә Ркыясы чигеп биргән ак пәрдәләрне шудырып, газ плитәсенә тагын чәй куйды. Аракы шактый башка бәргән. Алай да арганлык сизелми. Бүген ул эшкә бармаячак. Зәм-зәм суына бик хирес булмаса да, аның тагын эчәсе килә иде. Эчмәгән кешедә ул һәрвакыт бар. Әхәт тә йокларга уйламый. Ул, суыткыч өстендәге радиоалгычны кабызып, заманча җыр-музыка эзли.

—Сүндер әле шуны,—диде Кәбир, көл савытындагы тәмәке төпчекләрен чиләккә бушатып.—Хәзер янадан чәй пешерәм. Гранулированный. Яхшы сорт түгел инде, салкын суга салсаң да төсе чыга.

—Безгә ярап тора,—диде Әхәт, радиоалгычны сүндереп.—Рәсәй Көнбатыш базарына әверелеп бара. Үзләрендә ашалмый торган нәрсәне безгә җибәрәләр. Буш ботларыннан баш тартып караган идек тә, Америка әнә нинди тавыш чыгарды. Чак кына икътисади блокада ясамадылар үзебезгә.

Кәбир аның сүзләрен җөпләп куйды:

—«Буш» ботын ашый-ашый, үзебезнең кошчылык фабрикаларын да таратып бетердек. Ә ул ботның "файдасын" беләбез инде. Минем бер танышымның улы шуны ашап хастаханәгә эләкте. Бизләре шешә, ди. Ә үзәк телевидение «Буш» боты сәламәтлеккә зыянлы түгел, дип көне-төне лаф ора. Олигархларның кесәләрен калынайталар. Аннары бу Америка белән яхшы мөнәсәбәтләрне саклап калырга да мөмкинлек бирә.

—Төкереп бирә Америка синең мөнәсәбәтләреңә. Җае чыкты исә, ул янадан безгә арты белән борылып басачак.

—Эшләр болайрак барса, безгә инде тиздән терлекчелек белән игенчелектән дә баш тартырга туры килмәгәе. Үзе житештермәгән дәүләт тора-бара кемнең дә булса колониясенә әверелә.

Өстәл астыннан тагын аракы чыкты. Берәр стакан күтәреп куйгач, Әхәт скрипкада уйнап җырлап җибәрде:

Вокзалларга арбалылар
Киләләр дә китәләр.
И... туган илем,
Елан керде лә куйныма

Җырга Кәбир дә кушылды:

Һай, дусларым, безнең башны
Яшьли әрәм итәләр.
И... туган илем,
Елан керде лә куйныма.

Бу җырны аларга кечкенә вакытта Герман сугышында булган сукыр Ярми бабалары өйрәткән иде. Җырның башка өлеше инде онытылган, күпме гомер узган бит. Йөз яшькә кадәр яшәде, бахыр. Соңгы ун елын гел урын өстендә ятып үткәрде.

—Шушы әче суны эчә-эчә, без дә синең белән кяфергә әверелеп барабыз, абый,—диде Кәбир.—Аракы урыс кешесе өчен—ризык кебек. Ә безнең корсакка ул килешми. Игътибар иткәнең бардыр, татар кешесе аракы эчсә, йә сугыша башлый, йә балтага тотына. Ни өчен дисеңме? Чөнки безнең ата-бабаларыбыз аракы эчмәгән, татарның геннарында аракының агулы тәэсиренә каршы иммунитет юк. Америка индеецлары да әнә аракыдан кырылып бетеп бара. Хәзер аларда бу милли проблема.

Әхәт кул гына селтәде:

—Кырылсак кырылырбыз инде. Без европалашкан халык. Милли гореф-гадәтләрне саклап калам дип бикләнеп ятып булмый. Бикләнеп ятам дисәң дә булдыра алмаячаксың. Чит культура өенә телевизор аша булса да килеп керәчәк. Французлар маладис ичмасам. Анда җәмәгатьчелек урыннарында чит ил музыкасын әйләндергән кешеләргә шәплэп кенә штраф чәпиләр. Ә бездә нәрсә? «Татар ашлары» ресторанында да, чәйханәдә дә, урамда да милли җырлар урынына урысча блатной җырлар яңгырый.

—Менә син, үзеннең кызың белән очрашкач, Чечняда нишләп йөрдем дип җавап бирәсең инде? Акча эшләдем дипме?

—Ә нигә яшерергә? Медаль бар, мин аның өчен хәзер герой.

—Илдә шундый геройлар күп булганга шәп буын үсеп килә. Балалар бакчасында эшләүче күрше хатыны сөйләп торды. Аларда тәрбияләнүче алты яшьлек Мишаның әтисе Чечняда булып кайткан. Берәү белән салып утырганда, «зачистка» вакытында унике яшьлек чечен малаен һәм аның әтисен үтерүе белән мактанган бу. Тәмам исереп беткәч, Чечнядан алып кайткан акчаны идәнгә чәчеп ыргыткан. Янәсе, күрегез, мин нинди бай! Миша моның барысын да ишетеп-күреп калган. Икенче көнне балалар бакчасына килгәч, әйтә икән бу тәрбияче апасына: « Илнар минем тубымны тартып алды. Мин аларның өйләренә лимонка ыргытачакмын. Илнар белән аның әтисен үтергән өчен Путин миңа күп итеп акча бирәчәк».

—Һы, булачак башкисәр үсә, ә! Юк, мин кызыма Чечняда булдым дип әйтмәячәкмен. Син бит минем акча өчен китмәгәнне беләсең. Биргәч, аласың инде!—Юлда йөреп инде болай да алҗыган Әхәтнең күзләре ачылмый башлаган иде. Ул терсәгенә таянып утырган хәлдә майкасындагы медальне суырып алып юынтык су чиләгенә ыргытты.—Акчалары да кирәк түгел, медальләре дә үзләренә булсын. Мин берәүне дә терәп атмадым. Атышканда булгандыр, бәлки.

Фронтовик өстәлгә башын куеп йокыга китте. Кәбир үзе дә көчкә генә аягында басып тора иде. Алай да абыйсын караватка алып барып салырга иренмәде.

—Фронтовик,- диде ул, елмаеп, һәм Әхәтнең башыннан сыйпады.— Ашатмаганнар икән үзеңне генераллар, гел сөяк тә, тире генә калгансың.

Чиләктәге менә-менә түгеләм дип торган юынтык суны урамга чыгарып түккәч, Кәбир ишекне дә бикләргә онытып иске диванга сузылып ятты. « Иртәгә махмыр булачак,—дип уйлады ул, йокыга китә барып.—Хатыны кайтканын әйтмәдем инде. Әхәттән хәбәр булмагач, һәлак булган дип уйлагандыр, Витясын да үзе белән өстерәп кайткан бит, юләр. Алдан кисәтеп куймыйча булмый, юкса үтерешәчәкләр».

## Моңсу хәбәр

...Әхәт белән Кәбир сәгать унда гына уянды. Шәп кенә махмыр төшсә дә баш төзәтмәделәр. Сүзсез генә чәй эчеп утырдылар. Кәбир өстәлгә прәннек белән кәнфит чыгарып куйды.

—Чәйне сыек ясагансың,—диде Әхәт.—Чефир ясап бир, зинһар.

—Болай да ап-ак булып утырасың, йөрәгеңә начар булыр бит.

—Нервадан ул. Әллә нинди начар төшләр күреп бетердем. Имеш, Грозныйда мәетләр демонстрация оештырган. Мине утта яндырмакчы булалар. Баганага бәйләп, аяк астыма өелгән чыбык-чабыкка ут төрткәч кенә уянып киттем.

—Төштә ут күрү һава алышынуга була. Бүген көн аяз булырга охшаган.

Әхәт чефирны шикәрсез генә эчте.

—Менә шулай көн дә чефир эчә идек без тегендә,—диде ул.—Минем медаль кайда икән?

Кәбир гаҗәпсенде:

—Хәтерләмисеңмени?

—Күбрәк киткән, баш эшләми.

—Юынтык су чиләгенә ыргыттың бит син аны.

—Кайда ул чиләк?

—Чыгарып түктем.

—Булган икән хәлләр.

—Соң, кирәк түгел миңа, диден ич.

—Кирәген кирәк инде ул, аны тагып министрга керәсе бар.

Алар урамга чыгып юынтык су түгә торган чокырның рәшәткәле капкачы аша медальне күзләргә тотындылар. Ләкин анда пычтырдашып кача башлаган күселәрдән кала берни дә күренмәде.

—Агып киткән,—диде Кәбир, өмет өзеп.—Хәзер күселәр тагып йөриячәк инде аны.

Әхәтнең кәефе кырылды. Шушы медаль аның язмышын хәл итәргә мөмкин.

—Ярый, таныклыгы бар әле,—диде ул, кул селтәп.—Киттек!

Мунча ягып кергәч, Әхәт Шәмәрлегә кайтырга әзерләнә башлады. Гимнастеркасы белән чалбарын юып тормады, кибеткә барып өр-яңа ак күлмәк, костюм, ботинка, кызы Гөлиягә зур гына плюш аю, әти-әнисенә банан, кәнфит ише күчтәнәчләр сатып алды. Энесенә дә бер күлмәк бүләк итте. Акча бирмәкче иде, Кәбир алмады. Нинди акча икәнен белгәнгә алмады. Мөселман, имеш! Алмаса соң, акчаның исе юк, Әхәткә күбрәк калыр. Нидер яшерә аннан энесе. Кайту турында сүз чыккач, бәлки тагын бер-ике көн торырсың, дигән булды бит. Юк, Гөлияне күрүгә үк бер генә минут та тормаячак ул Казанда. Анда бит аның йорт-җире калды. Квартирант кызлар нишләп яткандыр? Чит кеше барыбер чит кеше инде, аларга ышанып җитәргә ярамый.

«Казан—Вятка Аланы» поезды кичке сәгать сигездә кузгалып китәргә тиеш. Әле дүрт-биш сәгать вакыт бар. Инде Гөлияне күрергә кирәк. Ай, сөенер инде плюш аюны күргәч!

Әхәт җыена башлагач, Кәбир читтән генә сүз башлады:

—Абый, син әйтмәгәнгә ачуланма инде...—Әйтеп бетерә алмады, йөзен читкә борды.

—Нигә туктап калдың?—диде Әхәт.—Кичәдән бирле нәрсәдер әйтергә телисең инде миңа.

—Сәрия Казанда түгел, ул Шәмәрлегә кайтып китте.

Әхәтнең күзләрендә шатлык очкыны кабынды.

—Менә бу яңалык!.. Бигрәк әйбәт! Гафу итәм инде, кызыбыз бар бит.

—Үзе генә түгел ул анда.

—Ничек үзе генә түгел?—Әхәтнең йөзе үзгәреп китте.

—Витя да шунда... Алар бит сине хәбәрсез югалган дип уйлыйлар.

—Оятсыз икән Сәрия,—дип мыгырдады фронтовик, күзләренә яшь тыгылып.—Менә, күрәселәрең булса...

Кичке якта алар икәүләшеп вокзалга киттеләр. Берәр бокал сыра эчеп куйгач, Әхәт энесен кочаклап алды.

—Ярый, сау бул, энекәш!

—Исән кайтып җит,—диде Кәбир, аны аркасыннан сөеп.—Кайткач, юләрлек эшләп ташлама!

—Күз күрер.

—Сүз бир миңа!

—Ә сүземдә тора алмасам?

—...

—Ярый, сүз бирде дип уйла. Ничек тә түзәсе булыр инде.

Поезд кузгалып киткәч, Кәбир шактый вакыт перронда басып торды. «Менә бит язмыш ниләр кыйлана,—дип уйлады ул, хәер сорашып йөргән чегән балаларын күзәтеп.—Ләүхелмәхфүзенә язылган булгач, түзәргә туры килә инде. Үзе башлады бит барысын да. Егылып эчә башламаган булса, Сәриясе ташлап киткән була идемени?»

### Танышу

Кәбир дүртенче трамвайга утырып кайтты. Кондуктор аннан бу юлы да акча сорамады. Күрәсең, пенсионер дип уйлагандыр. Яшьләр дә, йә вакытны белергә

теләгәндә, йә тәмәке сораганда: «Отец»,—дип эндәшә аңа. Башта ул моңа бик хурлана иде. Югыйсә, әле кырыкны гуна тутырды бит. Тора-бара күнекте тагын. Чыраең карт булгач, кая барасың? Ә башкалар бу яшьтә егет кебек йөри. Никтер йөзләрен җыерчык та басмый, чәчләре дә агармый. Ничек шулай бик тиз картайды әле ул? Уйлаган кешегә яшәү авыр фани дөньяда. Кабих башкаланың милли төсе бетеп барганга да борчылып картайды ул. Тукай мәйданы әнә кызыл "фонарь"лар урамына әйләнеп бара. Җәй житте исә, анда һәр тарафта кулына сыра тоткан кызлар һәм егетләр күнел ача. Һәр тарафта шәрә ботлы чәчбиләр үзләренә клиент эзли. Арзанайды хатын-кыз, бәясе бетеп бара. Армиядә хезмәт итәрдәй сәламәт яшьләр калмады, дип лаф орабыз. Соң, хатын-кыз авыз күтәреп аракы-сыра эчкәч, борынынннан төтен чыгара-чыгара тәмәке тарткач, нинди сәламәт буын турында сүз алып барырга мөмкин?

Трамвайдан төшкәч, Кәбир Ерганак урамына юл тотты. Унсигезенче мәктәп турысына житкәндә, аның күзенә юлның икенче ягында зур соры пакет күтәреп барган сөйкемле генә бер хатын чалынды. Бөтен кыяфәте белән мәрхүмә Ркыяны хәтерләтә иде ул. Йөреше дә гел шуныкы.

Туктап күзәтә башлады. Шул мәлне хатынның пакеты ертылып китте. Асфальтка эре-эре әфлисуннар тәгәрәде. Ул инде аларны икенче пакетка тутыра. Аның белән бер-ике генә сүз булса да алышыр өчен шәп форсат бу. Кәбир тәвәккәлләп юлның икенче ягына йөгереп чыкты.

—Булышыргамы?—диде ул, елмайгандай итеп, һәм хатынның «әйе" дип әйтүен дә көтеп тормастан, әфлисуннарны аның пакетына тутыра башлады.

«Күзләре дә Ркыяныкы кебек,—дип уйлады булышчы, күз чите белән генә хатынны күзәтеп.—Күк йөзе кебек, зәп-зәңгәр!»

—Рәхмәт, бик зур рәхмәт!—дип тәкърарлады хатын, унайсызланып.—Бүген кызымның туган көне иде, шуңа әзерләнеп йөреш.

Сүз артыннан сүз чыгып, танышып та киттеләр. Рамилә исемле икән. Мәктәптә хезмәт дәресләре алып бара. Салмак искән жил, аның иңнәренә асылынып төшкән алтынсу чәчләренә гашыйк булгандай, аларны ара-тирә уйнатып, әле битен, әле иреннәрен иркәләп ала. И, бу хатын-кызны! Чәч дигәннәре дә нинди сөйкемлелек, серлелек өсти үзенә!

—Сезнең күзләрегез матур!—диде Кәбир, сихерләнгән кебек.—Чәчегез дә бик килешеп тора, алар—кояш төсендә.

—Ирләр бөтен хатын-кызларга да шулай диләр инде,—Рамилә кызлар кебек оялып башын иде.—Ярый, мин киттем. Рәхмәт сезгә... Комплиментыгыз өчен дә рәхмәт.

Юк, Кәбир инде Рамиләне болай гына җибәрмәячәк. Исән Ркыя белән сөйләшкәндәй булып китте аңа. Күнелендә әллә кайчан күмелгән якты хисләр тернәкләнде. Ул хисләр тагын шулай үләр микәнни?

—Ашыкмагыз инде!—Кәбир хатынның беләгеннән тотты.—Минем сезнең белән танышасым килә.

Рамилә аптырап калды.

—Сез урамда һәркем белән шулай танышып йөрисезме? Аннары... сездән аракы исе килә. Эчкән ирләрне беләм мин, аларны читкә тарта башлый. Хатыныгыз, балаларыгыз янына кайтыгыз.

—Минем хатыным юк. Балаларым да юк.

—Алдашасыз. Сезнең яшьтә ирләр инде ике-өч хатын аера.

—Ә миңа ничә яшь бирер идегез?

—Бик яшь булып күренәсегез киләдер инде,—дип елмайды Рамилә.—Кырыкны бирсәм, ни диярсез?

Кәбир пырхылдап көлеп җибәрде.

—Рәхмәт... Әле менә трамвайда утырып кайтканда да кондуктор акча сорамаганга борчылган идем. Алар бит пенсионерларны гына әйләнеп уза.

—Кыяфәтегез бик зыялы, шуна сорамагандыр. Сез рәссам түгелме?
—Юк. Нигә шулай дисез?
—Мина, никтер, рәссам кешенең генә чәче шундый көдрәдер кебек тоела.
—Ә сез көдрә чәчне ошатасызмы?
—Көдрә чәчле ирләр бик кире һәм үзсүзле була, дип ишеткәнем бар.
—Димәк, ошатмыйсыз?Бирегез пакетыгызны, мин сезне озатып куям.
—Кирәк түгел.
—Бирегез, бирегез,—Кәбир көчләп диярлек пакетны аның кулыннан тартып алды.—Сез кая кайтасыз?
Рамилә икеләнә, димәк, өмет бар.
—Әйтәм бит, көдрә чәчле ирләр үзсүзле була дип... Тик, карагыз аны, маршруткага кадәр генә озатасыз. Ә аннан безгә кадәр ике адым гына.
Автобус тукталышына барып җиткәч, Рамилә сорап куйды:
—Сез чыннан да өйләнмәгәнме?
—Юк.
—Алайса, бүген минем кызымның туган көненә килегез.—Шулай дигәч, ул кызарып ук куйды. Пешкән алма диярсең. Их, бер үбәсе иде үзен!
—Менә бәхет! Анда яшьләр була торгандыр. Бәлки, алар үзләренчә, без үзебезчә ял итәрбез?
—Алай да була. Табынны әзерләп кызым белән бераз утыргач, чыгармын... Кичке сәгать сигездә булса, соң түгелме?
—А, мин бәхетемнән үләчәкмен!.. Кайда очрашабыз?
—Фатих Әмирхан урамын беләсезме?.. Унөченче йорт, беренче подъезд. Шунда мине көтеп торыгыз. Адаша күрмәгез, безнен йорт «Эдельвейс» кибете каршында тора.
—Адашмамын,—диде Кәбир. Бу каләресенә ул һич тә өметләнмәгән иде. Хәтта каушап калды. Иреннәре дә дулкынланудан чак кына калтырый башлады.

### Якынлык

... Кәбир Рамилә яшәгән йортны бик тиз эзләп тапты. Ул инде менә-менә чыгарга тиеш. Кулына чәчәк тоткангамы, бөтенесе дә аңа карап уза. Бәхетле кеше дип уйлыйлар инде. Әйе, ул бәхетле! Ниһаять, ун елдан соң, ул үзенең яшьлегенә кайтып төшкәндәй булды.
Рамилә озак көттермәде. Ак кофтадан һәм кара чалбардан иде ул. Кәбирнең борынына баш әйләндергеч хушбуй исе килеп бәрелде. Кулдагы чәчәк нәрсә ул, Рамилә—үзе чәчәк!
—Кая барабыз?—диде хатын, Кәбирне култыклап. Ул инде көндезге оялчан хатын түгел. Аның хәрәкәтендә бераз гына көязләнү дә, иркенлек тә сизелә.—Бу букет минамы?
—Сина.
—Рәхмәт... Күрдеңме, без инде «син»гә күчтек... Аһ, исе тәмле! Каян белдең минем розалар яратканны?
—Сиздем... Бәлки, берәр кафега кереп утырырбыз?
—Кирәкми. Мин урамда йөрергә яратам..
Урам буйлап бара торгач, алар якындагы паркка кереп утырдылар. Башта балачак, пионерия, комсомол, укылган китаплар, яшәеш мәгънәсе турында сүз чыкты.
Аннары Рамилә үзе турында сөйләде.
—Ирем Галиябез туган елны Аракчинода янгын сүндергәндә һәлак булды,—диде ул.—Шуннан соң кияүдә булганым юк. Турысын гына әйткәндә, мин бу дөньяда ирләр барын оныттым да инде. Бөтен яшьлегемне кызыма багышладым дисәм дә арттыру булмас. Мәктәпне «бишле» билгесенә генә тәмамлады. Музыка һәм рәсем-сәнгать мәктәбен тәмамлаган дипломнары да

бар. Тик узган елны укырга гына керә алмады. Конкурс аша узганда бер балл җитмичә калды. Быел менә хәзерлек курсларына йөри. Хәзер бит акчасыз беркая да укырга кереп булмый, медалист дигәнең болай гына. Аллага шөкер, егете бик шәп булып чыкты. Университетның юридик факультетында укый. Татарча әйбәт сөйләшә, Рамилә апа дип кенә тора. Тик менә гел төнге дискотекаларга йөрүләре генә ошап җитми. Борчылам. Кызым кайтырмы дип, төне буе тәрәзә төбен саклыйм. Бәхете генә булсын.

... Таң атты. Паркта рәхәт. Монда урмандагы кебек. Кошлар да, әнә, уянды, «фиют-фиют» итеп сузып-сузып сайрыйлар.

—Кайтыйк инде,—диде Рамилә.—Инде кунаклар да таралышкандыр.

Тордылар. Кәбир хатынның битеннән үбеп алды. Аннары, тәмам тотнаксызланып, кочагына кысты. Сулышы гына түгел, бөтен тәне калтырый иде аның. Рамиләнең тәне дә калтырый. Чәч исе, хушбуй исе борынны кытыклап тора. Ничек рәхәт! Ләкин Рамилә шундук һушына килде, каршылык күрсәтә башлады.

Кәбирнең кочагыннан ычкынгач, ул тыныч кына әйтте:

—Ярамый... Юкса, беренче тапкырга күп булачак.—Ара тота. Сафлык галәмәте инде.

Кайтып җиттеләр. Тирә-юньдә, чырык-чырык килеп, чыпчыклар асфальтта чүпләнеп йөри. Берән-сәрән кешеләр дә күренгәли башлады. Яннарыннан капюшонлы куртка, озын кунычлы резина итек кигән ике балыкчы узып китте. Әнә, авызын зур итеп ачып иснәнеп, кулына себерке белән чиләк тоткан дворник хатын да чыгып килә.

Шулай кара-каршы баскан хәлдә бераз сүзсез генә дөньяны күзәтеп басып тордылар.

—Иртәгә киләсеңме?—диде Рамилә.

—Бүген, диген!

—Юк, бүген мин бакчага китәчәкмен..

—Алайса, берсе көнгә кадәр, матурым.

Рамилә һаман кереп китми. Нидер әйтергә тели кебек.

—Кәбир.

—Әү, матурым?

—Әгәр сине өйгә чакырсам, мине әшәке хатын дип уйламассыңмы?

—Аллам сакласын!

—Алайса, киттек. Минем сине чәй белән сыйлыйсым килә. Тик кара аны, бүтәненә өмет итмә. Юкса, бер йомшаклык күрсәтсәң, ирләр басымчак итә башлый.

—Юк, юк, мин андый түгел, Рамилә.

Дөрес әйтә, чукынчык. Нинди генә итәгатьле ир булса да, хатын-кыз өйгә чакыргач... Юк, бусы инде чын ахмаклык булачак. Шаяра торган вакытлар узган. Кәбир унҗиде яшьлек малай түгел, ул җитди кеше.

Рамиләнең фатиры җиденче катта иде. Тимер ишек бикле түгел. Эчтән музыка тавышы ишетелә. Кунаклар китеп бетмәгән әле.

Алар килеп керүгә, каршыларына озын гына буйлы бер кыз килеп басты. Рамиләнең кызы инде. Бусының да күзе матур—зәп-зәңгәр. Чәчен шәмәхәгә буяган.

—Вот и жених пришел,—дип шаяртты кыз.—Әни әйткәндер инде, минем исемем Галия. Проходите!

Рамилә Кәбирне кухняга өстерәде.

—Юк, юк, кызым, сез үзегезчә утырыгыз инде, ә без Кәбир абыең белән кухняга...

—Ты что?—диде ул, әнисенә күзләрен матур итеп акайтып.—Обоих прошу в зал!

Кәбир белән Рамилә читенсенеп кенә кунак бүлмәсенә уздылар. Табын артында ике генә егет утырып калган. Авызларында затлы тәмәке. Өлкәннәр күренгәч, тәмәкеләрен шундук сүндеререгә керештеләр.

—Я же вам сказала, не курите дома!—диде Галия, аптырап калган әнисе алдында акланырга теләгәндәй.—Будьте знакомы, друг моей матери Кабир абый. Писатель.

—О-о...

Аннары кыз берәм-берәм егетләр белән таныштырып чыкты:

—Илсур... Минем йөргән жегетем. Университетнын юридик факультетында икенче курста укый.

Озын буйлы егет торып басты.

—Очень приятно!

—Радиф... Друг Илсура. Учится в техникуме связи.

Бусы кечкенә буйлы, дустының ботыннан гына диярлек. Жирән чәчле. Андыйларны бик хәйләкәр диләр.

Утырыштылар. Галия барысына да чия компоты салды.

—Шәрәб эчәсезме?—диде ул Кәбиргә, елмаеп.

—Рәхмәт, мин компот кына эчәрмен инде.

—Үзебезнеке... Әни ясаган компот.

Чия суын эчеп утырганда, Кәбир Илсурның күзләре кызарган булуга игътибар итте. Аракыданмы? Тик нигә челт-челт киләләр? Әйтерсең, күзенә чүп кергән. Хәер, хәзер яшьләр чирләшкә. Май аенда кайберәүләрнең яшеллеккә аллергия дә була.

—Күзегезгә чүп керде мәллә?—дип сорады Кәбир.

—Нигә шулай дисез?

—Кызарган дип әйтүем.

—Арганнан ул.

—Илсурның экзаменнары башланды,—дип сүзгә кушылды Галия.—Йокы тими аңа бу арада.

—Яшь вакытта нинди йокы инде ул?—дип шаяртты Кәбир.—Картайгач та өлгерер әле.

Барысы да көлешеп куйдылар.

—Ә сез нәрсә язасыз?—диде Илсур.

—Соңгы вакытта бернәрсә дә язган юк әле.

—Хәзер детектив әсәрләр модада,—диде ул, белдекле кыланып.

—Сез хаклы. Детектив әсәрләр язу бездә жиңелрәк. Ләкин мин күбрәк балалар өчен язам.

—Әкиятме?

—Әйе.

—Фу! Мин кечкенәдән әкиятне сөймәдем.

—Ә нәрсә укыганыгыз бар?

—Берни дә укымадым. Мин үскәндә компьютер уеннары модада иде.

Бераздан егетләр саубуллашып чыгып китте. Галия алар артыннан иярде.

—Сиңа калсаң да була инде, кызым,—диде Рамилә, канәгатьсезлек белдереп.

—Мин аларны озатып кына керәм, әни.

—Тиз кайт!

—Конечно. Кая барыйм инде мин бу вакытта?

Рамилә белән Кәбир икәүдән-икәү генә калдылар.

—Тәмәке тартканнар,—диде Рамилә, бүлмәдәге истән күңеле болганып. Аннары ул балкон ишеген ачып куйды.—Сиңа Галиянең егете ошадымы?

Кәбир иңнәрен сикертеп куйды.

—Ярыйсы гына егет кебек. Яшь вакытта тәмәке белән шаяру була инде.

—Мин үзем дә шулай дип уйлыйм. Галия аның белән юридик факультетка

укырга кергәндә танышты. Илсур керде, Сәрия төшеп калды. Юкса, Илсурның аттестатында гел «өчле» генә.

—Ничек алганнар икән соң аны «өчле»ләр белән?

—Утыз биш мең долларың булса...

—Аңладым. Әти-әнисе бай, димәк.

—Шулай шул... Алар байлар, ә мин хәерче. Шуңа күрә кайвакыт уңайсыз да булып китә.

—Нәрсәсе уңайсыз булсын? Байлык ул бүген бар, иртәгә юк. Ә кызың синең чәчәк кебек.

—Рәхмәт, бик рәхмәт,—диде хатын, алсуланып.—Күз генә тия күрмәсен. Тьфу, тьфу...

Шактый утырдылар. Рамиләнең күзе гел сәгатьтә.

—Менә көт син аны,—диде ул, монсуланып.—Үземә генә җыештырырга туры килә инде.

Рамилә сәгать тугызга кадәр өстәл җыештырды. Кәбир дә аңа булышты: кухняга юылмаган савыт-сабаны ташыды, сузыла торган өстәлне җыеп куйды, палас какты, идән себерде.

Хатын-кызга шул гына кирәк, Рамилә эреде дә бетте. Гомер иткән ире белән сөйләшкән кебек, читенсенми дә, ара да тотмый.

«Кызык,—дип уйлады Кәбир, сөенеп.—Без бит әле бер-беребезне бөтенләй белмибез. Ә мин монда инде хуҗа булып йөрим. Рәхәт аның белән. Туйдырды буйдак тормыш. Миңа да гаилә корырга вакыт. Ә Рамилә әйбәт хатын булырга охшый. Үзе матур, үзе акыллы, үзе йомшак күңелле».

Алар инде йокы бүлмәсендә. Кәбир, шторaларны ябып, Рамиләнең изүен чиште, кулы белән аның күкрәгенә кагылды. Хатын еш-еш сулый. Бөтен бүлмәгә «дөп-дөп « итеп типкән йөрәк тавышы ишетелә. Кемнеке?.. Аерып булмый, икесенеке дә бугай. «Дөп-дөп, дөп-дөп»... «дөп-дөп, дөп-дөп»...

Ирен белән ирен очрашты. Рамиләнең бит алмалары ут булып яна. Кәбирнеке дә яна.

—Ah!

Алар инде икесе дә җирдә түгел. Рәхәт итеп баш әйләнә. Кәбирнең кайнар сулышы бер аста, бер өстә. Әйтерсең, ул чәчәккә кунган бал корты! Әйтерсең, ул нектар җыя!

Чәчәкнең яфрагын үбә. Исерә-исерә үбә!

Җиргә төшү генә бераз читен икән. Күпмедер вакыт сөйләшмичә яттылар. Кәбир торып киенде.

—Китәсең дә мени?—Рамиләнең күзендә сагыш.

Бал корты үзенекен алды, китәргә җыена, дип уйлыйдыр инде. Юләр!

—Юк, матурым, киенеп кенә куйдым. Галиянең кайтып керүе бар,—диде Кәбир, аның битеннән үбеп.—Хәзер мин чәй куям.

Рамилә ваннага кереп чыккач, чәй эчәргә утырдылар. Хатын күтәрелеп тә карамый, ояла. Кәбиргә дә уңайсыз.

—Сина рәхәт булдымы, Рамилә?

—Әйе.

—Сәрия нигә кайтмый икән?

—Илсурларга киткәннәрдер.

Төш вакыты җиткәч, Кәбир кайтып китте. Берсе көнгә кичке сәгать сигездә очрашырга сүз куештылар.

Канаты үсеп чыккан кош кебек хис итте ул үзен. Хәзер яшисе дә, яшисе инде! Шәп шигырь язарга кирәк. Бүген үк язарга кирәк!

## Әти кайтты

Төн иде. Поездлан төшеп Мәҗит Гафури урамына килеп житкәч, Әхәт туктап калды. Егерме биш малай үстеләр бит бу урамда. Чатта кибет торырга тиеш иде, ләкин ул юк инде. Бер катлы иске таш клубтан да җилләр искән. Торгынлык елларында әби-бабайлар көфер почмагы дип атыйлар иде бу урынны. Кич життеме, яшьләр клуб артына җыелып аракы эчә башлый. Аннары йодрык худка китә. Хәзерге яшьләр кебек үтерешүгә кадәр барып житмиләр иде. Бу йодрык болгау, галәттә, көч-гайрәт күрсәтүгә генә кайтып кала.

Сугышып туйгач, клубка керәләр. Кинога акча түләп керү юк инде, чөнки кассир хатын инде кайтып киткән. Егетләрнең бер өлеше кызлар янына килеп утыра, тасма телләләнеп, аларны үбәргә, кочакларга маташкан булып кылана. Ләкин чикне узмый. Бүгенге көн күзлегеннән карасаң, болар барысы да гөнаһсыз бер сабыйлык кына булып тоелыр иде. Кызлар алардан курыкмый. Чөнки монда һәркем бер-берсен яхшы белә. Икенче өер арткы рәткәрәк урнаша. Анда инде—сүз боламыгы. Авызларында—көнбагыш. Тынычлап кино карарга ирек бирмиләр инде. Кызык нәрсә күрсәтсәләр дә, күрсәтмәсәләр дә, шаркылдап көләргә һәм нинди дә булса бер әчерәк сүз кычкырырга гына торалар.

Кино беткәч берәү дә таралмый. Барысы да тәмәке тартып, лач-лоч төкеренеп, иртәнге сәгать бергә кадәр чатта басып тора. Берсе мәзәк сөйли, икенчесе көлә, өченчесе тегү фабрикасыннан төнге сменадан кайтучы кызларга «ah!» итә, дүртенчесе тиз генә күрше бакчасына кереп кыяр урлап чыга. Арада мунча карарга яратучылар да бар иде. Тик, ни гаҗәп, кызлар озатучы булмады.

Гомер уза. Егетләр бер-бер артлы армиягә китә торды. Алар өере белән басып торган урам чаты да бушап, ятимләнеп калды. Кайткан берсе житдиләнеп кайтты. Тәртипсезләнеп йөрү юк, һәркайсы бу чаттан кызларны гына култыклап уза. Аның каравы, паркта көн дә уенлык оештырыла. Кызлар-егетләр таңга кадәр гармун уйнап, җырлап-биеп, такмаклар әйтеп күңел ача. Их, бар иде күңелле чаклар! Хәзер яшьләр болай күңелле ял итә белми. Гармунны—магнитофон, җыр-биюне—дискотекалар алыштырды. Кич життеме, парк ягыннан колакларны тондырып чит ил һәм урыс музыкасы яңгырый.

Тәрәзәдә ут юк. Әхәт кыңгырау төймәсенә баскач берәү дә чыкмады. Тагын, тагын басты. Аның күңелендә инде өер кузгала. «Витясы кочагыннан тора алмыйдыр,—дип уйлады ул, тешен кысып.—Ярый, хәзер уятам мин сезне!» Һаман да ишек ачучы булмагач, Әхәт дулый-дулый тәрәзә кагарга тотынды.

Ниһаять, болдырда ут янды. Кем чыгар? Витямы, әллә хатынымы?.. Ничек түзәргә?.. Их, лимонка булса!.. Ярамый, чөнки Гөлия бар.

—Кем бар анда?—Гөлия тавышы.

Ә Сәрия белән Витя кайда?

—Кызым!—Әхәтнең йөрәге шатлыктан дөп-дөп итеп тибә башлады.—Мин кайттым, кызым!

—Әти!

Кыз йөгереп барып капканы ачты. Каршында басып торган ыспай гына костюмлы абыйны күргәч, ул сискәнеп артка чигенде.

—Танымыйсың мәллә мине, кызым?—диде Әхәт, аны кочагына алып.

—Танымадым шул, сугышта булган кеше мондый кием кими.

—Кем әйтте сиңа мине сугышта дип?

—Витя абый әйтте.

—Алай икән... Ә сугышта булган кеше нинди кием кия?

—Ул хәрби киемнән була. Аның күкрәгендә күп итеп медальләр була.

—Шулаймыни?—Әхәт кызны үбеп бетерде.—Икенчесендә хәрби киемнән булырмын, ямме, кызым.

—Мин сине бүтән сугышка җибәрмим,—диде Гөлия.—Мин бик тә сагындым сине!
—Ә әниең кайда?
—Ул эштә... Витя абый да эштә.
Өйгә кергәч, Әхәт ишек турысындагы элгечтә эленеп торган ак төстәге хатын-кыз плащына һәм кара күн курткага игътибар итте. Куртка Витяныкы инде. Кунак бүлмәсен тәмам үзгәртеп бетергәннәр. Диварларда өр-яңа обой, түрдә яссы экранлы «Л-джи» телевизоры, түбәсе түшәмгә тигән борынгы сәгать һәм кыйммәтле стенка күренә.
Плюш аюны күргәч, кыз сөенеченнән чыркылдап көлеп җибәрде:
—Аю! Минем аюым бар!
—Җә, кызым, Витя абыең сине рәнҗетмәдеме?—дип сорады Әхәт, чүгәләп.
—Юк, Витя абый миңа кичә туп алды. Күрсәтимме?
—Соңыннан күрсәтерсең, кызым. Ә хәзер сөйлә, кемнәр белән уйныйсың?
—Илшат белән,—диде кыз, аюны башыннан сыйпап. Аннан авызын турсайтты.—Ул хәзер минем белән уйнамый, аңа велосипед алдылар.
—Борчылма, иртәгә син дә велосипедлы булырсың.
—Чынмы?—Кызның авызы ерылды.
—Чын, кызым. Шәп велосипед булачак ул. Ә хәзер йокла, яме.
Гөлия киреләнә башлады:
—Әти, минем йоклыйсым килми. Миңа синең белән рәхәт. Сөйләле сугыш турында.
—Иртәгә сөйләрмен, балакаем.
—Ә немецлар нинди була?
—Нинди немец?
—Алайса, син сугышта булмагансың.
—Немецка каршы сугышмадык без, матуркаем.
—Ә кемгә каршы сугыштыгыз?
—Сугышмадык без беркем белән дә. Тик йөрдек шунда автомат күтәреп.
—Сугышта тик йөрмиләр. Анда безнекеләр немецларны үтерә.
—Шулаймыни?
—Ә Илшатның әтисе сугышта мең немецны үтергән.
—Алдаша, аның әтисе сугышта түгел, армиядә дә булмаган әле.
Гөлияне йокларга яткыргач, Әхәт кунак бүлмәсенә чыгып утырды. Сәрия белән Витя төнге сменада. Иртән алар кайтып кергәч, ул монда булмаячак. Чөнки бу очрашуның нинди буласын бер Алла белә. Әхәт хәзергә авылда—әти-әнисе янында яшәп торырга тиеш. Аннары күз күрер. Ире кайтканын белгәч Сәрия үзе дә йорттан чыгып китәчәк.
Гөлиянең өстәлдә яткан төсле карандашлары арасыннан авторучка эзләп тапкач, ул Сәриягә хат язарга утырды. Башта бик күп нәрсә әйтеп калдырасы килгән иде аның хатынына. Әмма яза башлагач, уйга берни дә килми интектерде. Кайбер җөмләләр аңа кирәгеннән артык дорфа, кайберләре кирәгеннән артык йомшак булып тоелды. Алай да, тырыша торгач, берничә җөмлә яза алды тагын.

Сәрия!
Мине иртәрәк көмгәнсең. Бераз акча калдырам, Гөлиягә велосипед алырсың. Мин әтиләргә кайтып китәм.
Әхәт.

Әхәт хат белән акчаны аш-су бүлмәсендәге суыткыч өстенә куйды. Чәй кайнаткан иде, эчә алмады. Күңелдәге гарасат һаман басылмый. Нәрсәгә генә кагылса да кулы тотмый башлады. Кайвакыт сугышка керер алдыннан

шулай була иде анын белән. Ә монда тынлык. Ләкин ул сугыш алдыннан була торган тынлыкка караганда да шомлырак.

Иртәнге сәгать өчкә кадәр йорде. Соныннан, йөрәге кага башлагач, йоклаган кызынын битеннән үпте дә, ишегалдына чыкты. Район үзәге зур, бикләп китәргә кирәк.

Ярты сәгать эзләде йозакны. Баксан, ул ишектә эленеп тора икән. Йөр син монда карак кебек эзләнеп. Тизрәк чыгып китәргә маташа бит. Әйтерсен, чит кеше өенә кергән. Ә монда бөтен нәрсә дә анын өчен якын. Туган йортта күгәргән калак та сагыш уята, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер инде...

Ишекне бикләгәч, ул урамга чыгып капканы элде. Рәхәт. Авыл һавасы гына шундый тәмле була. Еракта поезд тавышы ишетелә. Күк йөзендә бер генә йолдыз да күренми—тагын болытлаган. Ә кечкенә вакытта ул йолдызлар бик тылсымлы булып күренә иде Әхәткә. Ерак балачак... Нигә ул шулай сагындыра? Мөгаен, анын өчен алмагач ботаклары буйлап каядыр ашыгып йөгергән кырмыска да, болытлар артыннан караган кояш та, капка төбендә үсеп утырган үлән дә, аларны томшыклары белән чеметеп өзеп йөргән бибиләр дә—һәммәсе дә, һәммәсе дә серле булып тоелгангадыр.

...Ана алты яшь. Җәй уртасы. Дөбердәп кап-кара болыт килде дә җиргә йодрык кадәр боз ява башлады. Ул хәтта зур-зур тупыл ботакларын да өзгәләп ыргытты.

—Күктән нигә шундый зур боз ява?—дип сорады Әхәт әбисеннән.

Диванда йон оек бәйләп утырган әбисе сукранып кына әйтте:

—Зират янында күбрәк туп кусагыз, җиргә боз гына түгел, ут янгыры да явар әле, балакаем.

Шул сүзләрдән сон Әхәт зират янына футбол уйнарга менмәде, җиргә ут янгыры явар дип курыкты.

Үсеп житеп милициядә эшли башлагач та, Чечняда вакытта да бик күп канлы күз яшьләре күрде ул. Ләкин җиргә утлы янгыр яумады. Түзә Алла! Кем белә, бәлки анын явырына инде озак та калмагандыр. Гонаһылы бу кешелек дөньясын берниндн дә кер порошогы белән юып бетереп булмый. Юкса, аны шул утлы янгыр гына юа алачак.

Армиягә китәсе көнне ишегалдында әтисе белән сөйләшеп утырган төнне дә искә төшерде Әхәт.

—Йөзгә кызыллык китермә, улым,—дигән иде әтисе.—Безне сагынганда күктәге ә-нә теге өч якты йолдызга кара. Ул йолдызларнын исемнәре ничектер, белмим, әмма без, өч дус, сугышка киткән көнне аларга үз исемнәребезне куштык. Бик авыр минутларда шул йолдызлар аша бер-беребезгә сәлам әйтергә килештек. Шулай итеп, күк йөзендә безнен Ка (Кабил), ми (Минлеәхмәт), за (Зариф) йолдызлыгы барлыкка килде. Рәхәт бит, күк йөзенә карыйсын да, йолдызлар аша Кабил белән Минлеәхмәт дустан сәлам аласын, шунда ук үзләренә дә сәлам юллыйсын. Минлеәхмәт Сталинград янында һәлак булды, Кабил концлагерьга эләккән дип ишеттек. Ул йолдызлар мина гомерем буе дусларымнан сәлам ирештерә кебек.

Чечняда вакытта Әхәт тә менә шушы Камиза йолдызлыгы аша әти-әнисенә, энесенә, кызына сәлам юллый иде. Аларга карап торганда, ул үзен ишегалларында әтисе белән сөйләшеп, кинәшеп утырган кебек хис итә иде.

Әхәт үзенен балачагы узган урамнар, тыкырыклар буйлап атлый-атлый тимер юл вокзалына юнәлде. Поезд иртәнге сәгать алтыда кузгала. Шулай булгач, ашыкмасан да ярый. Чүрәкәйгә кадәр узгынчы машиналар да йөри, ләкин аннан әйләнгеч булачак. Ә поезд белән нибары ярты сәгатьлек юл.

Вокзал бинасы эчендә аркасына кара шәл салып китап укып утырган урта яшьләрдәге маржадан кала беркем дә юк. Ишек ачылуга, түрдә, тәрәзә янындагы озын эскәмиядә йокы симертеп яткан ике мәче күзләрен ачып берара Әхәтне күзәтте. Аннары ул поездлар расписаниесе белән танышып

маржа утырган эскәмиягә килеп кунаклагач, бер-бер артлы ялкау гына иснәнеп, тагын күзләрен йомдылар.

Тынлык та күнелсез була икән. Ун-унбиш минут бер ноктага карап уйланып утырганнан соң, Әхәт бу тынлыкны бозарга булды. Юкса, төрле уйларга бирелсән, акылдан язарга да озак түгел. Ул, биштәрендәге скрипканы чыгарып, башта бармакларын грифта йөгертеп алды, аннары смычок белән аның кылларын тирбәтеп куйды. Мәчеләр, скрипка тавышыннан куркып, шундук урамга чыгып йөгерде. Эскәмиянең икенче очында утырган маржа да китап укуын онытып, Әхәт тарафына гаҗәпләнү катыш кызыксыну белән карап алды.

Фронтовик мәчеләргә дә, маржага да игътибар итмәде, һәм дөньясын онытып уйнап җибәрде.

Туган җирем, сөйгән авылым,
Бигрәк якын күңелгә.
Кай илләрдә яшәсәм дә,
Оныта алмам гомергә.

Күңелдән генә җырлады ул бу җырны. Гади генә сүзләр, ә йөрәккә ничек үтеп керә! Мөгаен, аларны бөтен вөҗүдең белән аңлар өчен аз гына вакытка булса да туган җиреңнән аерылып тору кирәктер. Иң гаҗәбе шул, кайчандыр син бер дә игътибар итмәгән, яисә һич яратып кабул итмәгән көй дә чит җирләрдә якын булып китә һәм сагыну хисен көчәйтә.

Маржа скрипка моңын тыңлый. Яшен аеру кыен булса да шактый сөйкемле күренә. Хәзер хатын-кызга вакытлыча гына ун-унбиш елга яшәрү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Заманча чәч буяулары, прическа, косметика шундый үзгәртә ки, үз әниләре танымас.

Түзмәде, Әхәт янына килеп утырды.

—Суык!—диде ул урысча. Калтырана.—Туңып утыра идем, сез уйный башлагач бөтен бина яктырып киткәндәй булды... Матур уйныйсыз. Бала вакытта мин дә скрипка классына йөрергә теләгән идем, сәләтең юк, диделәр.

Әхәт аның комплиментын ишетмәмешкә салышты. Мактаганны кечкенәдән яратмый ул. Мондый чакта үзен уңайсыз хис итә башлый. Мактаучыга бурычлы булып калмас өчендер инде. Ә кемгә дә булса бурычлы булу үзенне аның көенә җырларга мәҗбүр итү ул.

—Нинди китап укыйсыз?

—Иисус турында.

—Иисус?..—Әхәт елмайды.—Үлеп терелгән пәйгамбәр... Аны бездә Гайсә дип атыйлар.

—Үлмәгән ул.

—Изге китапларда үлеп терелгән дип язылган бит. Үзем укымадым, әлбәттә, ишетеп кенә беләм.

—Бу дөньяда, бәлки, бөтен нәрсәгә ышанып та бетәргә ярамыйдыр?

—Соң, изге китап изге инде ул, анда ялган сүз булмас.

—Иисус һичшиксез бөек пәйгамбәр. Кайбер изге китапларда тарихи төгәлсезлекләр бар, дип кенә әйтмәкче идем мин.

—Мәсәлән?

—Безнең эраның утыз икенче елында Понтий Пилат кесарь Тиберийга язган хатында, Иисус күбрәк иудейларның түгел, римлыларның дусты кебек сөйләшә, дип язган. Аны ул хәтта әңгәмә корыр өчен Форумга да чакырган. Иисус килгән. Иудейлар наместнигы аның тәкъвалеген, күңел пакълеген күреп шаккаткан. Суны хәмергә әвереллдерә, үлгәннәрне терелтә, шашкын дингезне тынычландыра ала торган бу адәм чыннан да Алла бәндәсе булырга мөмкин, дип төгәлләгән ул үзенең хатын.

—Бу хатны кем дә булса уйлап та чыгарырга мөмкин.

—Тикшереп карый аласыз. Понтий Пилат хатынын төп нөсхәсе Ватикан китапханәсендә саклана.

—Кызык, димәк, ул аны хөрмәт иткән? Алайса, нигә Гайсәне Гарәфә тавында тәрегә кадаклаттырган?

—Минемчә, Понтий Пилат үзе дә христиан диненен яшерен тарафдары булган. Чөнки ул мәҗүсилекнен иртәме-соңмы империянен җимерелүенә китерәчәген аңлаган. Римлыларның аллалары аракы эчкән, үтергән, фәхишәлек белән шөгыльләнгән. Алар шундый тәртипсез булгач, нигә римлыларга тәртип бозмаска? Ә христиан дине адәм баласын бер генә аллалыкка чакырган. Бу яңа тәгълимат буенча Алланы беркем дә тудырмаган, Ул кодрәтле, Ул бөтен яктан камил, Ул һәркемнән тәкъвалык таләп итә. Шулай итеп, империяне саклап калу өчен кайсысы файдалырак булган: мәҗүсилекме, христианлыкмы? Әлбәттә, христианлык. Ул заманда римлылар христиан дине тарафдарларын бик каты эзәрлекләгәннәр. Христан дине секталар рәвешендә генә яшәп килгән. Яңа динне ничек күтәрергә? Иисус пәйгамбәрдән христиан диненең символын ясар өчен, Понтий Пилат аны тәрегә кадаклый. Аннары аны дәвалап шәкертләре каршына китереп бастыра. Күрегез, янәсе, Гайсә үлеп терелде!

—Ул ничек исән кала?

—Тәредән төшерелгәч, аның гәүдәсен тукымага төреп Аримафеидадан килгән Иосифның кыяда урнашкан бакчасындагы мәгарәгә урнаштыралар. Анда Иосифның йортына чыга торган яшерен юл була.

Тәүратның унтугызынчы баганасындагы утыз тугызынчы стихында болай диелгән: «Пришел так же и Никодим, приходивший прежде к Иисусу ночью, и принес состав из смирны и алоя, литр около ста».

—Хәзер ышана башладым кебек. Үлгән кешегә алоэ китермәсләр. Димәк, Гайсәнең үлеп терелүе матур легенда гына?

—Бу табигать кануннарына каршы килә. Аллаһы үзе уйлап тапкан кануннарны бозмас. Иисус йөз егерме яшькә кадәр яшәгән. Шушы вакыйгадан соң ул әле Һиндстанга бара, Тибетта була. Анда ул халык күңеленә Иса булып кереп калган. Ләкин моңа карап кына аның пәйгамбәрлеген шик астына куярга ярамый. Иисус Мөхәммәт тарафыннан да хөрмәт ителгән бөек пәйгамбәр. Кешелек дөньясын Аллаһы каршындагы гөнаһыларыннан коткарам дип, терелэй тәрегә кадаклanudан курыкмаган пәйгамбәр.

—Сез һөнәрегез буенча кем?

—Мин университетның философия факультетын тәмамладым. Егерме биш ел студентларны укыттым. Ә хәзер, картая төшкәч, бизнес белән шөгыльләнә башладым.

—Бу салада төнлә ни эшләр кырып йөрисез?

—Апама кунакка—Вятка Аланына кайткан идем. Ә Шәмәрлегә абыем янына дип килдем. Юл унае бит. Килсәм, ишекләре бикле. Хатыны белән Казанга—шифаханәгә китеп барганнар. Менә утырам инде хәзер вокзалда... Сез еракtan кайттыгызмы?—Маржа, кызыксынып, тагын бер кат аның өр-яңа костюмына карап алды.

Әхәтнең кайдадыр укыганы бар. Әгәр хатын-кыз сиңа игътибар итмичә узып китсә, ул, һичшиксез, кияүдә булырга тиеш. Игътибар бирсә, иреннән аерылган дип уйла.

—Воркутада яшим мин,—диде Әхәт, алдашып. Чечняда булганы турында әйтәсе килмәде. Чөнки белә, моңа берәү дә «ah!» итмәячәк. Итсәләр дә геройга караган кебек карамаячаклар. Урыс үзе дә өнәми бу хурлыклы сугышны. Хәзер халык надан түгел, аның телевизоры белән радиосы бар. Гәзитләрне дә даимән күзәтеп бара. Гәзит укымаганы Чечня вакыйгалары турындагы язмаларны башкалар авызыннан ишетә.

Алар сөйләшеп утырган арада вокзал тәмам терелде. Ух-пах килеп капчыгы белән ит, бәрәңге күтәреп кергән студент яшьләр, уйчан әкрен картлар, моңсу, йә елмаеп кына торган хатын-кызлар билет кассасына чиратка баса башлады.

Әхәт ишек өстендә торган электрон сәгатькә күз салды. Поезд килеп җитәргә—биш минут. Соңга калып килмәсә, диспетчер инде хәбәр салырга тиеш. Ана билет алып торасы юк, ветеран чүтеки.

Кузгалдылар. Әхмәт биштәрен аркасына салып, марҗаның ясалма нык җепле тукымадан тегелгән ике ак зур сумкасын күтәрде.

—Сез билет алырга оныттыгыз,—диде хатын, борчылып.

—Мин куян булып йөрергә яратам,—дип шаяртты фронтовик.

Электричка сәгатендә-минутында килеп җитте. Вагонга кереп утыргач, Әхәт андагы манзараны күреп шаккатты. Сумка куя торган алюминий киштәләр дә, элгечләр дә, кәнәфи аркаларына куелган тоткычлар да бөтенләй булмаган диярсең—барысын да сүтеп ташып бетергәннәр!

—Да, барып чыкканбыз икән!—дип тел шартлатты ул.—Төсле металлга тапшырып бетергәннәр.

—Болай барса, бөтен илне таратып бетерәчәкләр әле,—дип җөпләде аның сүзен марҗа.—Бичара Россия!

Казаннан кайтышлый Әхәт тукталышлардагы күрсәткеч такталарның юклыгына игътибар иткән иде. Аларын да алюминий булганга сүткәннәр, димәк.

Поезд кузгалып китә башлауга, ул тәрәзәгә күз салды. Йа, Раббы! Вокзал каршындагы баскычтан Сәрия йөгереп төшә! Чәчләре тузган, өстендәге плащын да сәдәпләмәгән, кулларын болгый-болгый нидер кычкыра.

Әхәт торып ишеккә таба чапты. Ләкин соң инде, поезд тизлекне арттырды. Аптырагач, тәрәзәдән башын чыгарып хатынына кычкырмакчы булды. Кычкыра гына алмады, нәрсәдер комачау итте... Горурлыкмы?

—Әхә-ә-әт!—Сәрия куллары белән йөзен каплап җиргә тезләнде. Елый.

Әхәтнен дә күнеле тулып китте. Ул тагын аңа кычкырырга теләде, ләкин тагын нәрсәдер комачау итте... Горурлыкмы?

—Нәрсә булды?—Марҗа аның өчен борчыла. Сәриянең баскычтан йөгереп төшкәнен ул да абайлады булса кирәк.—Хатыныгыз мәллә?

—Хатын шул,—дип җавап бирде Әхәт, авыр сулап, һәм гаҗизләнеп дермантины кубарып алынган эскәмиягә утырды.

Сәрия нигә вокзалга төште? Витя белән килешмәгәннәрме?... Аңлашылмый. Иреннең йортына сөяркән белән кереп утыр да артыннан вокзалга йөгереп төш, имеш. Тиле! Ике иргә дә ярап яшәп булмый. Әхәт аны барыбер гафу итмәячәк. Дөньяда хатын-кыз бетмәгән, табыр әле. Менә берсе утыра инде каршысында. Әниләрчә кайгыртып утыра. Юкса танышканнарына да берничә генә сәгать.

Поездга барыбер, ул берәүне дә күрми, берәүне дә белми, аның бөтен белгәне тимер тәгәрмәчләре белән ардыра торган моңсу бер ритмга сугудан гына гыйбарәт иде: ткт-ткт... ткт-ткт...

## Үкенү

Сәрия вокзалдан кайтып кергәндә өй тәмәке төтене белән тулган иде. Бик бетеренеп кайтты ул. Йөрәге генә түгел, бөтен башы сызлый иде. Өстендәге плащны элеп куюга ук кухняга узды.

—Озаттыңмы?—диде Витя, борыныннан төтен чыгарып. Тәмәкесе беткән, төпчек тартып утыра. Йөзе болытлы.

—Озаттым,—Сәрия су кранын ачып савыт-саба юарга кереште.—Өйдә тартма, баланы агулыйсың.

Витя гасабилана:

—Нәрсә сөйләштегез инде?
—Берни дә сөйләшмәдек.
—Алдашасың, алай була алмый.
—Мин төшеп житкәндә поезд инде китеп бара иде.
—Син аны һаман да яратасыңмы?
—Яратам.
—Кызык,—Витя тешен кысып тәмәке төпчеген кечкенә тәлинкәдә изде.—Алайса, нигә миңа кияүгә чыктың?
Хатын юган савыт-сабаны киштәгә урнаштыра башлады.
—Мин сиңа кияүгә чыкмадым әле. Бүген син Казанга кайтып китәргә тиеш, Витя,—диде ул, аның ягына карамыйча.
—Казанга кайтып китәргә?!—Ир сикереп торып аның каршысына килеп басты. Дулкынланудан йөзе генә түгел, сары кашларына кадәр кызарып чыккан.—Син нәрсә, мине Ванька-встанька дип уйлыйсың мәллә?! Алайса, нигә әнинең фатирын саттырдың?
—Акчаң үзеңдә, янасын сатып алырсың. Житми калса, үзем биреп торырмын.
—Юк, мин беркая да китмим. Гөлия дә инде миңа күнегеп килә.
Сәрия хәле китеп урындыкка утырды.
—Китәсең, Витя. Бу Әхәтнең йорты. Ә мин монда пропискада гына торам.
—Алайса, бергә китәбез.
—Мин сине яратмыйм. Аңла мине, зинһар!
Витя краннан стаканга су агызып Сәриягә тоттырды.
—Мә, су эчеп җибәр... Бәлки, бераз тынычланырсың.
—Эчмим,—диде Сәрия, аның кулын этеп.—Су гына тынычландыра алмый инде мине.
—Белмим, нәрсә табасың син ул Әхәтендә?—Витя, кулларын җәеп, иннәрен сикертте.—Алланың кашка тәкәсе түгел бит инде ул. Әгәр минем урыс булуымнан хурланасың икән, пожалуйста, сөннәткә дә утырам. Телисең икән, исемемне дә үзгәртәбез. Миңа Витя дип түгел, Валиахмед дип эндәшерсең. Мин бит сине үлеп яратам, юләр! Әллә син Әхәтнең акчасына кызыгасыңмы?
—Юк, мин берниндә дә акчага кызыкмыйм. Чыгып кит, зинһар!—Хатын үкереп елап җибәрде.—Чыгып кит! Юньсез хатын мин!
—Ярый, синеңчә булсын,—Витя башын иеп ишеккә атлады.—Тик кара аны, соңыннан үкенечле булмасын!
Озак елады Сәрия. Бу тавышка Гөлия дә куркып уянып чыкты.
—Әни, нигә елыйсың?.. Елама инде!
—Туктыйм, туктыйм, кызым,—Сәрия алъяпкыч итәге белән күз яшьләрен сөртеп, кызны кочагына кысты.—Еламыйча да булмыйдыр инде бу дөньяда.
—Елама. Син елагач, миңа авыр була.
—Туктадым.
—Ә әти кайда, әни?
—Ул китте.
—Кая?.. Тагын сугышкамы?
—Юк, авылга, әбиең белән бабаң янына китте.
—Ул бит миңа велосипед алам дигән иде.
—Акчасын калдырган. Иртәгә барып алырбыз.
—Минем әти белән барып аласым килә.
—Озак тормас ул, кызым, кайтыр.
—Әни, син әтине сагынып елыйсыңмы?
—Әйе, кызым.
—Ә Витя абый безгә кем була?
—Нигә шундый сорау бирәсең әле син?

—Илшат әйтә, Витя абый синең әниеннең икенче ире, ди. Сезне чын әтиегез ташлап китте, ди.

—Дөрес әйтми ул, кызым. Әтиең безне беркайчан да ташламаячак.

—Бөтен малайлар да шулай ди.

—Ә син аларга игътибар итмә.

—Мин алар белән бүтән уйнамыйм.

—Жә, жә, андый ук үпкәчел бала булма инде. Гел әтиенә охшагансың син.

—Чәй эчәсең киләме, әнием?—диде Гөлия, зурларча кыланып.

—Килә.

—Лимон беләнме?

—Лимон кирәк түгел, шикәр дә салма.

—Әни, сугышта лимон үсәме?

—Нигә шулай дисең?

—Әти алып кайткан лимон бу. Сугышта үскәнгә шундый әче инде ул, әнием, әйеме?

Сәрия җавап бирмәде.

—Әни, Витя абыйга бау нәрсәгә кирәк булды икән?—диде Гөлия, бераз тынып торгач.

—Нинди бау ул тагын?

—Ак бау. Син анын белән ел да помидорлар бәйлисең.

—Бау дисеңме?—Сәрия корт чаккандай сикереп торды.

—Әйе.

Агарынган хатын ишегалдына йөгереп чыкты.

—Витя!

Берәү дә дәшми. Кая киткән?

—Витя, дим!

Ул башта абзарны, аннары мунча эчен кереп карады. Витя анда да күренмәгәч, алма бакчасына чапты. Ир инде агач ботагына элмәк ясап куйган. Башын иеп елап басып тора.

—Юләр!—диде коты очкан хатын, җинел сулап.

—Үләргә ирек бир, Сәрия,—Витя почмакка бастырып куелган сабый өммәтендә.

—Үлүе бик җинел, Витя.

—Бик җинел түгел икән шул, нәрсәдер тота.

—Алайса, әйдә, өйгә кер.

—Кермим.

—Анла, Витя, мин Әхәтне генә яратам. Кичерә күр, зинһар. Алып ташла бавыңны, кеше күрүе мөмкин.

... Витя асылынмады. Кичке якта чемоданын тутырып китәргә әзерләнде.

—Озатасыңмы?—диде ул, моңсу гына итеп.

—Озатам,—дип җавап бирде хатын.

—Алайса, посидим на дорожку.

Урындыкка утырып икесе дә тын калды. Урыс гадәте инде. Юлга чыгар алдыннан алар һәрвакыт шулай эшли.

—Их, нигә мин татар булып тумадым икән?!

—Нигә шулай дисең?

—Сары булганга яратмыйсың син мине. Әхәт—каратут йөзле.

—Юләр.

—Аннары, картайгач, мине чиркәүгә йөри башлар дип куркасың, шулаймы?

—Кузгалыйк,—диде Сәрия, анын сүзеннән туеп.—Гөлия белән дә саубуллашырга онытма.

—Ул капка төбендә үзенең яшьтәшләре белән уйный.

Капканы ачып чыккач, Гөлия, Витя абыйсының кулында чемодан күреп, йөгереп үк килде.

—Витя абый, син сугышка китәсенме?—диде ул.

—Юк, Гөлия, мин сугышка китмим.

—Нигә?

—Ул Казанга китә, кызым,—диде Сәрия, аны бүлдереп.—Яхшылап саубуллаш Витя абыең белән.

Кыз үрелеп аның битеннән үпте.

—Сау бул, Витя абый!

—Сау бул, матурым.

—Ә мина кибеттән велосипедны кем алып кайта?—диде кыз, кинәт авызын турсайтып.

—Үзем алып кайтырмын, кызым.

—Анда ир кеше кирәк,—Гөлия инде күнә башлады.—Ярый, без кибеткә Илшатны алып барырбыз.

Сәрия Витяны вокзалга кадәр озатып куйды. Юлда очраган картлар, туктап-туктап, аларны күзәтте. Сүгәләрдер. Авыл жирендә бернәрсәне дә яшереп булмый. Әхәтнең иртә белән кайтып киткәнен бөтен кеше белә инде. Чыбыксыз телефон яхшы эшли. Тирә-юньдә кызыксынучан күзләр күп булгангамы, Сәрия Витядан арттарак барырга тырышты.

Диспетчер поездны игълан иткәч, ирнең күзләреннән яшь тәгәрәп чыкты.

—Әхәт белән берни дә барып чыкмаса, мина хәбәр сал,—диде ул. Күңелендә өмет уты сүрелмәгән икән әле.

—Салырмын.

Сәрия битараф иде. Витяның шушы минутта нәрсә әйтергә теләве дә, нәрсә уйлаганы да, кичерешләре дә кызыксындырмый иде аны. Никадәр тизрәк китеп барса, аңа шуның кадәр жинелрәк булачак. Йөрәгендә Әхәт аның.

Витя китте. Сәриядә тамчы да юксыну хисе юк. Ничек аның куенына кереп ятты соң әле ул? Кафеда утырганнар иде бит. Хәмер башны аңгырайтты. Витяларга ничек кайтып кергәнен дә, аның белән ничек йокларга ятканын да сизми калды. Алар икәүдән-икәү генә иде. Витяның әнисе инде ике ел элек дөнья куйган. Иртәгесен үкенде Сәрия, нык үкенде. Әхәткә карата кылган хыянәте өчен үз-үзен кичерә алмады. Шунлыктан яңадан өенә кайтып керергә дә намуссынды. Бөтенләйгә дип чыгып китмәгән иде Сәрия, берәр атна әнисендә яшәгәч, әйләнеп кайтырга уйлаган иде. Әмма тәкъдирдә икенче төрлерәк язылган икән.

## Әти-әни йортында

... Поезд Чүрәкәй станциясенә житә башлагач, маржа хатын Әхәткә үзенең Казандагы адресын бирде. Ләкин ул перронга аяк басуга ук аны төшереп калдырды.

Әхәт өйгә кайтып кергәндә, аның әнисе алгы як бакчада помидор утырта иде. Ул койма өстеннән башын сузып эндәшкәч, карчыкның кулындагы кәлшәләр жиргә коелды.

—Бәрәч, Әхәт түгелме соң бу?—диде ул, күзләрен чекерәйтеп.

Начар күрә аның әнисе. Шуңа күрә танымыйчарак торды. Күзләре чирле. Табибләр дөм сукырайганчы операция ясамыйбыз дигәннәр иде. Чөнки йөз процент уңышлы буласына гарантия бирә алмыйлар.

—Мин кайттым, әни!

—И, балакаем, исән-саулар икәнсен!—дип бытырдады карчык, күзләреннән яшь чыгарып.—Йокыбыз йокы, ашавыбыз ашау булмады бу араларда. Нигә бер дә хәбәр салмадың?

—Мөмкин булмады, әни.

Әнисе бакчадан чыгуга кочаклаштылар.

—Исән кайткач ярый, телевизор карый-карый котларыбыз очып бетте инде. Ул Ельцин дигәннәре бер дә юньле кеше булмады. Шундый сөлектәй ирләрне Чечняда үтертеп ята бит, имансыз. Алла сакласын инде сугышлардан!

Бераз хушына килгәч, карчык абзарга йөгерде.

—Атасы! Атасы, дим!

Абзар ишегеннән кулына көрәк тоткан уртача буйлы, ачәрвах кына гәүдәле, әмма шактый нык бер карт атылып чыкты.

—Нәрсә, пожар бар мәллә?

—Әхәтебез кайтты, атасы!

—Аяк-кулы үзендәме?

—Үзендә, үзендә. Соң, күрмисеңмени, әнә, болдыр янында басып тора бит.

Картның авызы ерылды.

—Бар, нәрсә карап торасың, тавыгыңны сайлый тор!—диде ул сөенеченнән биердәй булып торган карчыгына.—Симезрәге булсын, анасы!

—Исәнме, әти!

—Исәнме улым.

Кочаклаштылар.

—Нигә гражданскидан әле син?

—Кәбирдә салып калдырдым.

—Анда да кереп чыккансың икән әле. Рәхмәт. Өйләнергә уйламыйдыр?

—Өйләнер әле вакыты җиткәч.

—Йә сөйлә, ничек Чечняда хәлләр? Телевизорга ышанмыйм мин. Ялган сөйлиләр. Бу Грачев нинди кеше икән? Мәгънәсез! Күпме солдатның башына җитте. Узган айда Шәмәрлегә дә ике табут кайтты. Икесе дә унсигез яшьлек егетләр, мин синайтим.

—Генераллар сатлык, әти. Бөтен хикмәт шунда. Бетерәбез дисәләр, күптән бетергән булалар иде Чечняны.

—Тукта, син чеченга кагылма, улым. Мөселман бит алар.

—Мин Рәсәй көчлерәк дип кенә әйтмәкче булган идем.

—Күрдек инде нинди көчле икәнен. Әнә, генерал Лебедь чеченнар белән солых төзү турында сүз чыгара башлады. Мин болай дип уйлыйм. Масхадовны Рәсәйнең оборона министры итеп куярга кирәк. Менә шуннан соң армиядә тәртип урнашыр, сатлык генераллар да булмас. Флотны сатып бетерделәр, самолетлар иске... Америка басып керсә, кем белән, нәрсә белән якларлар икән илне?

Әхәт көлемсерәп кенә куйды, ләкин әтисенең соравына җавап бирмәде.

... Әңгәмә табын артында дәвам итте. Әниләре әти белән улның сүзенә кысылмады, аш салды, чәй ясады, өстәл сөртте. Икесенең дә тамагы туйгач кына, терсәгенә таянып, аларны игътибар белән тыңларга кереште.

Чечня темасын тетеп бетергәч, Сәрия турында сүз чыкты.

—Кайтып килден, ызначит?—диде карт, күңелсезләнеп.

—Килдем, әти. Көтеп тормадым берсен дә, иртәнге поезд белән сезгә ычкындым.

—Бик дөрес эшләгәнсең, улым. Чын ирләрчә булган бу. Анда аның сөяркәсе белән сугышып ятып булмый инде. Хатын-кызның үзендә булмаса, аңа чөй белән генә бәреп кертеп булмас.

—Нәрсә булды соң безнең киленгә?—дип сүзгә кушылды карчык. Аннары елап ук җибәрде.—Бик акыллы күренә иде бит. Үз кызым кебек күрдем, Аллага тапшырдык. Алтын балдагыма кадәр салып биргән идем.

—Әйтмәле шуны килен дип,—карт касәдәге көмешкәне каплап куйды.—Елама да. Синең белән минем бер яшь бөртегенә дә тора торган хатын түгел

ул. Иблис, настыящий Иблис! Әле ярый борынгы заманнар түгел, капкабызны инде күптән сумала белән буяп китәләр иде. Их, нинди заманнар булган бит! Еракка китәсе юк, безнең заманда да бот күрсәтеп йөрү булмады. Шәһәрдә булгандыр бәлки. Адәм хуры! Бу Америкасын әйтер идем, телевизорны тәмам иблис тартмасына әверелдерде. Махсус эшләнә бу. ЦРУ башлыгы Даллес әнә сугыштан соң әйткән, без ул советлар илен юлдан яздыру юлы белән тезләндерербез, дигән. Тезләндерде тәки. Хәзер ил башы да алардагыча президент дип атала, үз Ак йортыбыз да бар. Инде хәзер статуе свабудаларын да Кызыл мәйданга китереп куясылары калды. Аның пычрак демократиясе белән чүбе дә ияреп килде бит әле. Инеш буена гына күз салыгыз, анда шуннан килгән пластик шешәләр, кәнфит, сагыз, шоколад укалары аунап ята. Пыяла сөт шешәсе сагындыра башлады хәтта.

—Бер-бер җае чыгар әле, балакаем,—диде әни кеше, улын тынычландырып.—Тормышта төрле хәлләр була. Менә күреп торырсың, үзе эзләп кайтачак әле сине Сәриян.

—Бер кискән ипи кире ябышмый инде, әни.

—Үзең теләсәң ябышыр, бик ябышыр.

—Бигрәк кызык сөйләшәсең син, анасы. Бөтен Шәмәрлегә данга калган хатын белән ничек яшәргә кирәк!

—Сәрия начар килен түгел. Буталгандыр. Гафу ит син аны, улым. Бала хакына булса да гафу ит. Кызыгыз ятим үсәчәк бит. Илдә ятимнәр болай да җитәрлек. Телевизордан көн дә күрсәтеп торалар. Җиде-сигез яшьлек балалар да келәй иснәп мингерәүләнеп йөри хәзер.

Әхәтнең әтисе кызып китте:

—Бар, үз эшеңдә булале!.. Элекке заманда мәчет картлары иренә хыянәт иткән хатын-кызга бәддога укыган.

—И, сөйләшеп утырган була тагы! Синең анаңа да бәддога кылганнар бит.

—Анысы башка нәрсә аның. Муллага җиденче хатын булып чыкмас өчен ияреп киткән ул минем әтигә, аңладыңмы?!

—Ярый, ярый, кызмале син, атасы, аптыраганнан гына әйттем инде. Син, акыллы булсаң, улыңа башка төрлерәк киңәш бирер идең. Бер дә җитмеш ел гомер иткән кеше кебек сөйләшмисең.

—Нинди монда киңәш? Киленең башка кешедә кияүдә. Мылтык алып атып үтерергә кушыйммыни?

Әхәт аларны тынычландырырга кереште.

—Борчылмагыз әле сез шулай. Кырык ике яшьлек мужик бит инде мин. Беткәнмени җирдә хатыннар?

—Бозыклары күп аның, балакаем,—диде әнисе, еламсырап.—Адым саен андыйлар. Әйбәтен табуы гына бик читен. Витя синең йортыңда озак тормас. Бәлки инде бүген үк чыгып киткәндер. Белгәннәр бит инде синең исән икәнлегеңне. Кайт хатының янына!

Карт, башын чайкый-чайкый, каһкаһә белән әйтте:

—Ай, бу хатын-кызны! Акыл юк та инде үзләрендә.

—Һаман хатын-кызны хурлый ул,—дип дулады карчык.—Акыл хатын-кызда гына калып бара хәзер. Әнә, күрше Габделбәр хәзер беркайда да эшләми, хатыны туйдыра. Чулак Гарәфине, төлке Мәҗитен, каз Мансурын ал—алары да хатыннары җилкәсендә яши. Юньле кеше хатын алыштырып йөрми инде, вәт. Барып кайт, улым, янына. Балаң хакына барып кайт. Кире борып җибәрсә —китеп барырсың. Ышанмыйм мин Сәриянең бозык булуына. Буталган ул.

—Үгетләмә малайны. Сәрия үзе чишсен инде хәзер бу "каз ботын".

—Чишәр, Алла бирсә, чишәр, анысы да борчылмыйча гына ятмыйдыр.

—Юк, әни, мин Сәрия артыннан чабып йөрмим инде.

Самавыр авызыннан көмешкә акмый башлагач, шактый кызган карт карчыгына әйтеп куйды:

—Мулла абзыеңның көмешкәсе беткән, анасы. Нигә шулай бик аз салдың?

—Бусы да җитеп торыр, аннары авырта башлыйсың,—диде тегесе, сукранып.

Элекке елларда кайбер муллалар кеше күрмәсен өчен көмешкәне самавырдан агызып эчкәннәр. Әхәтнең әтисе дә менә шулар кебек кылана инде. Көмешкә белән күп шаярмый ул, бәйрәм-сәйрәннәрдә генә тоткалап куя. Ә бүген алар өчен зур бәйрәм инде.

Сүз ара сүз чыгып, авыл хәлләренә тукталдылар.

—Ике дуңгыз асраган идек, улым. Шуларны килосын егерме сумга да тапшырып булмады,—дип зарланды карт.—Печәләр авыл кешесен. Аптырагач, ит комбинатына унтугыз сумнан җибәрдек. Чит ил дуңгызы булса, әллә нинди акчалар чыгарып салырлар иде. Юк, үзебезнең дуңгызны кыйммәткә генә түгел, үз бәясенә дә сатарга ярамый. Файдадан бигрәк, зыянга гына булды дуңгызларыбыз. Әле мулладан күпме кыен ишеттек. Мәчеткә керергә оят.

—Ә сыер ите белән ничек, әти?

—Анысы өчен дә ташка үлчим генә түлиләр. Алга таба да болай барса, хуҗалыкларда мал бетәчәк. Дәүләт бүгенге муллык белән алдана. Ә бу муллык нәрсәдән килә? Крәстиәннең ашарга акчасы калмады, хәзер ул кул астына нәрсә туры килә, шуны суеп тапшыра. Авыл нигә хәерче? Чөнки аны шәһәр имә. Баланы вакытында имидән аерган кебек, шәһәрне дә авылны имүдән биздерергә вакыт. Юкса, ул моңа күнегеп бетәчәк. Ә авылның беркайчан да рәхәтлек күргәне юк. Аны Ленин бабай да имде, Сталин да, Хрущев та. Ельцинибыз бөтенләй үк таратырга тотынды. Син менә Ярми бабаңны хәтерлисеңдер инде, ул гомере буе нинди авыр елларда колхозда эшләп егерме сум пенсия ала иде. Кайда дөреслек? Хәзер безгә түләнә торганы да акча түгел инде аның. Гәзиттән укыган идем. Эстониядә бер кешенең уртача хезмәт хакы биш йөз долларга житә. Доллар безнеңчә утыз ике сум булса, тапкырлап карале шуны биш йөзгә. Уналты мең буламы? Менә шуннан соң чагыштырып кара инде безнең ике мең сум белән тегеләрнең уналты меңен. Авыл кешесе мондый акча алса, акылыннан язар иде.

... Әхәт Чүрәкәйдә ике кич йоклады. Әтисенә сыер абзарын, мунча мичен ремонтларга булышты, бәрәңге базын тагын да киңәйтеп, тирәнәйтеп, аны такта белән тышлады. Йорт каршында яңа гына төзелеп беткән мәчеткә дә керергә өлгерде.

Өченче көнне район үзәгенә—эчке эшләр бүлеге начальнигы янына юл тотты. Искәндәр Фәритовичка инде полковник дәрәҗәсе биреп куйганнар. Әхәтне жылы кабул итте. Шактый озак Чечнядагы хәлләрне сораштырып утырды. Әмма артыгын сөйләмәде Әхәт. Түрәләр алдында бигүк ачылып бетәргә ярамаганын яхшы белә ул. Кем белгән, бәлки ул син сөйләгәннәрне үзең чыгып китүгә үк ФСБга ирештерер. Әхәт Чечняда күргәннәрне сөйләмәскә дип кул куйган кеше. Дөрес, Искәндәр Фәритович андый кешегә охшамаган. Конкрет сүзле түрә ул. Була икән, була, булмый икән, извини брат! Бу юлы да Әхәт белән ихластан сөйләште .

—Хәлләр менә болайрак тора,—диде милиция начальнигы, аерылышыр алдыннан.—Әгәр министр булсам, мин сине берсүзсез эшкә алган булыр идем. Ләкин... бездә Чечняда булганнарны милиция органнарына эшкә алмаска дигән тәлдән приказ бар. Кереп карале үзең шуның янына. Тәкъдимнамәне хәзер үк язып бирербез.

Шулай диде дә, селектордан кадрлар бүлеге мөдирен чакыртып алды.

—Бу егеткә минем исемнән аны район эчке эшләр бүлегенә эшкә алу турындагы ходотайство язгыз. Хәзер үк кирәк. Аннары миңа алып кереп кул куйдырырсыз. Аңлашылдымы, Василий Петрович?

—Аңлашылды, иптәш полковник.—Сипкелле капитан шундук чыгып йөгерде.

—Ә хәзер коридорда утырып торыгыз,—диде Искәндәр Фәритович. Әхәтнен кулын кысып.—Уңышлы булсын инде юлыгыз. Ни пуха, ни пера, кем әйтмешли.

—Бездә, татарда, амин, дип әйтәләр.

—Амин!

Унбиш минуттан ходотайство инде Әхәтнен кулында иде. Вокзалга китешли, ул үзенең йорты тирәсеннән әйләнеп узарга уйлады. Җәяүләп булмый, күрәчәкләр. Бераз торгач, бер җинел машинаны туктатты. Руль артында япь-яшь кенә егет утыра иде. Алар Мәҗит Гафури урамына юл тоттылар. Акчаны кызганмады, кулына шундук йөзлек тоттырды. Бу акчага Казанны әйләнеп чыгарга була.

Машинаны ул су колонкасы янындарак туктаттырды. Аннан аның йорты яхшы күренә. Әхәтләрнең капка төбендә бала-чага уйный иде. Араларында Гөлия дә бар. Ул үзенең велосипедын тартып алырга маташкан бер малай белән тартыша. Әнисен ярдәмгә чакырып кычкыра башлады.

Ниһаять, Сәрия чыкты. Әшәке малайны сугеп куып җибәрде. Аннары ул юлдан узып баручы күрше Мәликә апа белән сөйләшә башлады. Икесе дә вакыт-вакыт Әхәт утырган машина ягына карыйлар. Бәхеткә, пыяла караңгылатылган, алар берни дә күрми.

Башта Сәрияне күрәсе килсә, хәзер аның китүен теләде Әхәт. Чөнки ул Гөлиягә дип бер сумка шоколад сатып алган иде. Инде машина рулендә утырган егет тә: «Озакка китте, абзый, без болай килешмәгән идек»,—дип, кымтырыклана башлады. Сәрия киткәч, күчтәнәчне шофер егет аша тапшырырга уйлаган иде Әхәт. Юкса хатыны шунда булса, кайдан, кемнән, дип сораштыра башлаячак.

Сәрия кереп китте. Менә хәзер инде шоферга пакетны бирсәң дә була.

Егет карышмады, кызны читкәрәк чакырып, ана шоколад тутырылган пакетны тоттырды.

—Нәрсә диде?—дип сорады Әхәт, егет машинага кереп утыргач.

—Нәрсә дисен, әти кайда, дип сорады.

—Нәрсә дип җавап бирден?

—Ул тиздән кайтып җитә дидем.—Егет аңа табан борылды.—Ә нигә сез монда Джеймс Бонд кебек утырасыз әле? Берәр шикле эшегез юктыр бит?.. Ә-ә, аңладым, хатыныгыз белән ачуланышкансыздыр, әйеме?

—Шулайрак шул. Инде мине вокзалга илтеп куй, энем.

*Ахыры киләсе санда.*



Рәдиф
Гаташ

## ГОМЕР СӘХИФӘЛӘРЕ

*(Төрле еллардан)*

* * *

Дусларымның бер дусы мин,
Ә мин үзем — мең дуслымын.

Исән чакта, дуслар, бүген
Әйтеп калыйм шушы сүзем:

—Сезнең өчен бер кеше мин.
Минем өчен, дуслар, сез — мең.
Шатлык сезгә минем гомер.
Үлсәм — кайгы, меңгә ул — бер...

Мөмкинме тик, дуслар, үлү?!
Мең дуска — мең кайгы бүлү?!
Мең дуска дус булып һаман,
Шатлык белән җирдә калам.

### Печән өсте

Аюдай болытлар өстә,
Сүрелеп бара эссе.
Кибәннәр үсә аланда...
(Күңелле печән өсте!)

Яшь кызый кибән башында,
Егеткә күз дә салмый:
Мул итеп алып бирсә дә,
Печәнен аның алмый.

Әй, кызый! Әллә нишләгән,
Гел күккә очынып бара.
Әйтәләр:
—Инде тотынгач,
Кояшка тотынып кара!
...Ә кояш баеп бара!

Рәдиф ГАТАШ (1941) — *шагыйрь; Һ. Такташ исемендәге премия лауреаты. Татар, башкорт, рус телләрендә басылган егермедән артык китап (лирик цикллар, поэмалар, газәлләр, робагыйлар) авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

* * *

Ничә тапкыр инде йөрәк мине
Әйдәп гөлбакчага китерде.

Чәчәк атып килгән яшь-яшь гөлләр,
Эсселектән арыган шикелле,
Су сорыйлар... яшь кыз ашыга-ашыга
Су китерә гөлгә сибәргә.

Гөл яраткан уйчан шул чибәргә
Бер серем бар. Ничек сөйләргә?

—Мин дә, мин дә шундый бер гөл, чибәр,
Чәчәк аттым — йөрәк ашкынды...
Синең алда җилдән бөгелгән бер
Чәчәк итеп идем башымны.

Оялчан да, таләпчән дә яшьлек —
Тели шашып-шашып сөяргә.
...Күрәсеңме, гөлләр су сорыйлар,
Су сорыйлар... Кирәк сибәргә.

## Айны тапмадылар

Алар ничә еллар буе инде
Берсен берсе сөйде.

...Кичә юктан гына күңелләргә
Кара болыт килде.

Төнен йокламады, үртәлде кыз,
Йокламады егет...
Бүген кичен килештеләр алар,
Берни дә юк кебек,
Күңел күгенә килгән шул болытны
Алып ташладылар.

...Ләкин инде күктә элек булган
Айны тапмадылар.

## Чакыру

Кайтыгыз, минем сөюнең
Былтыргы бураннары!
Югыйсә, артык бушанды
Күңелнең урамнары.

Кайтыгыз, җилне-давылны
Тынычтан артык күргән,
Тын йортның ишеген ватып,
Урамга чыккан көннәр.

Кайтыгыз, йолдызлы төннәр,
Беркатлы өметләрем;
Кайтыгыз, кыш үскән гөлләр,
Йокысыз минутларым.

Кайтыгыз, былтыргы карлар,
Кайтыгыз, сезгә карыйм!
...Гөнаһсыз чакның карына
Гөнаһлы исемем языйм.

Кайтыгыз, минем сөюнең
Былтыргы бураннары!
Бушанды, артык бушанды
Хисемнең урамнары!

## Кызлар бии

Кичә җем-җем көлгән гөлләр
Башын игән бүген таңда.
Башка гөлләр үсә хәзер,
Башка кызлар бии тауда.

Миләүшәләр сөя идем,
Бүген — алда резедалар...
Тауда һаман кызлар бии,
Яшьлек белән кочаклашып,
Таңга кадәр бии алар.

Үзгәрәме шулай Кеше?
Ошый иде миңа зәңгәр. —
Хәзер дә шул төскә гашыйк —
Бии алмыйм таңга кадәр.

Кичен кара иде бу чәч,
Кырау төште әллә таңда?!
Яшьлек үтә. Ләкин анда —
Яшь гөлләрне кочып, яшь-яшь
Кызлар мәңге биер тауда.

## Туганнар

Әнкәй, син моңаеп әйтә идең:
—Туганнардан да бар туйганнар...
Туймас иделәр дә, алар шул, дип —
Әзрәк кенә... баеган булганнар.

Мин дә уйлыйм бүген: кемнәр алар
Туганын чит күргән туганнар?

Яңа Кабил белән Һабил әллә?
Гаиләдә? Илдә, җирдәме?
Нигә туйган? Баеганга булса,
Байлык әллә хокук бирәме
Туганыңны хәтта онытырга?!
Андыйларга тагын ни кирәк?
Ни бар, юкса, туганыңнан газиз,
Җирдә — туганлыктан изгерәк?

Кем алданрак туган, әлифбасын
Кем укыган башлап, яшәүнең,
Җыр-дастаннар язган иң беренче,
Кем кабызган әүвәл фән шәмен,
Әдәбият нигезләрен салган? —
Кемнең күпме өлеше хакында
Бертуганнар — халыкларда әллә
Бәхәс бара?
Ә бит, барсында
Бүлешергә күпме байлыгы бар:
Матдиме ул, рухи, мәгънәви...
Туганнан, юк, туймас баеганга —
Уртак бар шатлыгы, бар гаме...

Әнкәй, ник моңаеп әйттең икән:
"Туганнар, дип... баеган булганнар"...
Баемаган, ярлыланган булыр,
Туганнарын җуйса туганнар —
Баемаган...

* * *

“Кара да гынай урман уртасында
Төлке уйный торган орлар бар...”—
Әй, халкымның тиңсез күңел фонды,
Синдә күпме алтын җырлар бар!
Тыңлыйм да мин, елыйм: яшьләремдә
Бик ерактан килгән моңнар бар...
Мин дә, мин дә эзлим алтын җырлар,
Табармынмы?
Сызган юллар бар.
Ләкин сизәм, һаман җыр алтыны
Табылмаган...
Бакыр сырлар бар
Маңгаемда,
чәчтә көмешләр бар,
Өметләрем — сизгер кыллар бар...

Уйга калып йөрим чит җирләрдә.
Урманнар бар, алан, орлар бар.
Тынлык белән ялгыз калсам, тоям:
Туган җирдән агыла — моңнар бар, —
Алтын җырлар шулар белән килер,
Килсә миңа — белән, юлда алар.
Ә хәзергә елыйм, оялмыйча:
Ил күңеленнән мирас җырлар бар!

* * *

Сагынсам оҗмах бакчасын, кәүсәрен,
Алдым шуннан мин-Адәм җан — җәүһәрем!

Уйда — аң, канны уяткан фирдәвес,
Ничә мең ел! — юатыгыз, тиргәгез,

Һаман Җирдән күкләргә ашса күңел, —
Дәшә, бәлки, аннан — назлы әнкә тел?

Йә хәтерне тарта изге сөт хакы?
Яратылган туфрагым ни? Күк заты...

Бу ямьле Җир, мең гамьле Җир, моң иле, —
Гел сагынып, яд итсә һаман мине,

Җирме — ватан? Җавап тапмыйм мин-Адәм...
Тәнгә туфрак — монда, ә рух — Галәмнән...

Ничек онытыйм мин фирдәвес — кәүсәрем,
Калдыргач шунда мәңгелек җәүһәрен?!

* * *

Иске саутыңда, тән, яңа шәрабмы? —
Сәрхуш җаным мәңгелектә корабмы?

Гомер җәе узган ирнең “азганы”,
Бәлки, бу хис? Әллә “Хакның язганы”?

Әллә табигатьтән соңгы мәрхәмәт
Синең сөю — канда яңа хәрәкәт?!

Гади генә бер җир кызы сагышы
Йолдызларга илтәчәк нур-балкышмы?

Сайлап менә нәкъ минем рух-хисемне
Юнәлтәсең нигә шунда син мине?

Гөнаһларым күп — моны беләә халык,
Биеклеккә нигә минем җан лаек?

Пәйгамбәр дә, тик үлеп, аша күккә...
Гашыйкны — ни илтә үлемсезлеккә?

Бөек Хыял һәм Ышаныч канаты
Биреп, мине яшәрттеме ярату?!

Иске саутында, тән, яшь җан шәрабым
Чайпалсын тик... Мәңгелектә корабым!

* * *

Күнегә алмам сәер бу җиһанга:
Йә, ни генә үзгәрмәс бүген анда?!

Ай тотыла... планеталар парады,
Нишләр мескен иске бу Җир корабы?

Кешедә мәңгелек гөнаһ! — сизелә:
Көн саен сугыш, һәлакәт, зилзилә...

Ачулымы Кояш? Нуры — агулы...
Якынаямы — шул дөнья ахыры?

...Ни уйларга, кадерлем, белмәгәнгә,
Әйттем: — Болар — мин Сине көнләгәнгә.

Ярамыйдыр — нахак сүз пакь җаныңа?
Җәзадыр шул — хаксыз елатканыма?!

Йә җавап бу, Яр, Син горур булганга?
Бик еш, сизми дә, җанымны кыйганга?

...Гаҗәпмени булса?! Чиксез Җиһан ла!



Рафис
Гыйззәтуллин

## ТӨРМӘЧЕ

ХИКӘЯ

Бүген дә өйдәгеләрнең барысыннан да алдарак аякка басты ул. Юынды, кырынды, ашап-эчеп алды. Аннан чөйдә эленеп торучы шиненә үрелде. Аны кия-кия ятакта бөгәрләнеп ятучы хатынына эндәште:

—Сиңа әйтәм, Хәмидә. Кузгалдым мин...

Тегесе башын күтәрде. Торып утырды һәм күзләрен уалап берара иренә гаҗәпләнеп карап торды.

—Таң тишегеннәнме?! Кая ашыгасың шулай?

—Кая, кая? Служба көтә!—диде ул.

Бу юлы сүзләре тупас, гөбедән чыккан кебек яңгырады.

—Нинди служба инде ул тагын?! Бүгеннән пенсиядә ич син!

Шунда гына Сәләхинең исенә төште. Чыннан да, аны кичә, бер урынында озак еллар эшләгәненә рәхмәтләр әйтә-әйтә, лаеклы ялына—отставкага озатканнар иде.

Сәләхи соңгы төймәсе каптырылмый калган шинелен чишәргә кереште. Үз гомерендә ул күпме шинель туздырды икән, моны бер Ходай үзе генә белә булыр. Күрче, башына да кереп чыкмады бит. Моннан соң ул үзе эшләгән, чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган мәйданга узып керә алмаячак, анда шапырынып-әтәчләнеп йөри алмаячак...

Күңеленнән узган шундый уйлар белән Сәләхи шинелен салып кире үз урынына—чөйгә элеп куйды.

"Менә сиңа, мә!.."—дигән уй талкыды аны. Мәңге шулай дәвам итәр кебек иде бит югыйсә. Һәр иртәне чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган таш коймалы ишегалдына узар, анда кергәч үз тәртипләрен урнаштыруны дәвам итәр кебек иде.

Күрче, дөнья дигәнең гел-гел синеңчә генә бармый икән лә! Баксаң, аның үз кануннары да бар икән әле.

—Ят, йоклап ал, ял ит...—диде кирәдән үз урынынаауган хатыны.

Тик Сәләхинең кире ятасы килми, аның йокысы качкан иде инде.

---

Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН (1955)—*прозаик; «Урман юлы», «Багалмада кунакта», «Төнге яңгыр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

—Тор. Ашарга әзерлә. Житәр сина болай таралып яту,—диде ул тавышын күтәреп.

Боларның шау-шуыннанмы, күрше бүлмәдәгеләр дә хәрәкәткә килде. Озакламый күрше бүлмәнең ишеге ачылды. Аннан иң элек чәчләре тузгыган килене, аның артыннан киерелә-сузыла чыгып килүче улы күренде. Мең мәшәкатьләре белән көн башланды.

Озакламый өйдә бары Сәләхи генә торып калды. Иң элек улы Марат, аннан килене Гөлнара эшкә, оныгы Әнвәр мәктәпкә дип чыгып киттеләр. Алардан соң хатыны Хәмидә дә озак тормады.

Аларның берсе дә чыгып киткәндә Сәләхигә авыз тутырып сүз әйтмәделәр. Чөнки алар аның аз гына ялгыш сүздән дә кызып китәсен, һәр басканны ялгыш итеп кабул итәчәкләрен беләләр иде.

Алардан соң Сәләхи озак кына бер урынында таптанып торды. Калган гомерен шушылай ялгызы гына шушы дүрт стена арасында ничекләр үткәрер икән ул?!

Хезмәттә вакытта көненең узганы сизелми дә кала иде.

Егерме биш елын ул төрмәдә—тоткыннар арасында үткәрде. Алар арасында ул үзен нык тота иде. Тоткыннарның һәр сүзеннән, ым кагуыннан, күз карашыннан куркып торуларына ул тәмам күнеп, гадәтләнеп беткән иде инде.

Дөрес, арада төрлесе бар иде тоткыннарның. Синнән курыкмаган, сиңа буйсынырга теләмәгәннәре дә. Хәер, алар "зона"га беренче аяк басканда гына шулай тоталар иде үзләрен. Ә инде бер-ике көннән соң алар аяк астыңа килеп егылырга әзер, көн итегенне ялардай булып юашланып кала торганнар иде. Моны ничек эшләргә кирәклеген Сәләхи яхшы ук үзләштерергә өлгергән иде инде. Бернчә тапкыр тоткынга көтмәгәндә, уйламаганда гына ипи шүрлегенә менеп төшсәң, колак төбенә кундырсаң, арт чүмеченә тондырсаң—шул житәр иде андыйларга. Төрмәдә сине "король" итеп тояргa өстеңдәге киемнәрең—әнә, чөйдә эленеп торучы шинелең ярдәм итәр иде...

Сәләхи шинеле янына килде, аны чөйдән алып кабат өстенә киде, тәненә рәхәтлек инде. Ул ишек тоткасына үрелде. "Бу стеналар арасында кангырып көнемне үткәрмим әле", дип, ул урамга чыгып якын-тирәдән әйләнеп кайтырга булды.

Урамда иркенлек, шау-шулы тормыш тантана итә иде.

Ул акрын гына урам буйлап атлап китте.

"Хезмәт", "хезмәт", "зона", "зона", дия торгач, ул үзе яши торган тирә-юньнең үзгәрүенә дә игътибар итми йөргән икән. Күр әнә, почмак саен диярлек яна кибетләр тезелеп киткән. Урам чаты саен үзләренең барлы-юклы товарларын тәкъдим итеп басып торучы карчык-корчык, карт-коры тезелешеп баскан. Алардан ерак түгел генә мона кадәр күрелмәгән "Кош базары" да барлыкка килгән. Мона кадәр Сәләхинең "Кош базары" турында ишеткәләгәне бар иде барын. Тик аның нindирәк икәнлеген генә үз күзләре белән күргәне юк иде әле. "Нindирәк була икән ул?"—дигән кызыксыну аны "базар" ишеген ачып эчкә узарга мәжбүр итте. Менә нindиерәк була икән ул "Кош базары"?! Тар гына читлекләргә тутырылган, каяндыр читтән китерелгән эреле-ваклы, чуардан-чуар кошлар чырык-чырык килеп сайраша. Тик шунысы—биредә тынчу иде. Мескен кошлар бер-берсе өстенә басып дигәндәй, очмакчы булып азапланалар. Тик башлары, канатлары белән читлек стеналарына бәрелеп егылып төшәләр. Әллә ашарларына да салмаганнар инде, эчәргә сулары да күренми. Чын мәгънәсендә мескенгә, йолкышларга әйләнгәннәр кошлар. Әмма бу хәл Сәләхидә кошларны кызгану хисе уятмады. "Кош базары"ндагы тынчу һава да ана әллә ни тәэсир итмәде. Бу бина төрмәне—күнеленә якын йортны хәтерләтте. Ул читлек янына елышкан

кешеләрне эткәли-төрткәли алгарак узды. Үзенә генә хас булганча, читлек эченә тутырылган кошларның кыланышларын ләззәтләнеп күзәтергә керешә. Берсен-берсе төрткәләүче, ирекккә чыгарга омтылучы бу гөнаһсыз затларның кыланышлары ана бик тә тансык, якын, үз иде. Аның күз алдыннан бер-бер артлы ялтыр башлы, тоньк күзле, битараф карашлы тоткыннар йөгерешеп узды. Ул кошлар карарга, сатып алырга килүчеләрнең әле берсе, әле икенчесенең иненә бәрелеп уза торгач, куллары кычыта башлауны сизеп, кызулык белән берәрсенең аяк астына кундырып, төзәтеп булмаслык хата эшләвеннән куркып, чыгу ягына борылды.

"Кош базары"нда туган рәхәт тәэсирләреннән арына алмыйча ул әле байтак кына урамда йөрде. Өенә кайткач та, йокларга яткач та әлеге тәэсирләр әсирлегендә калды ул.

Икенче көнне дә ул янадан "Кош базары"на китте. Өченче көнне дә, аннан соң да...

Кошларның тар читлекләрдә әнә шулай җәфа чигүен карап тору ана җан тынычлыгы, ул гына анлый ала торган рәхәтлек бирә иде.

Ә бер көнне... Ә бер көнне ул сатучыдан шул кошларның икесен яна читлеккә күчереп утыртуын сорады. Аларны сатып алачагын белдерде. Чөнки анлады ул: алардан башка ана картлыгын тынычлыкта үткәрү мөмкин булмаячак иде.

Ул читлектәге җан ияләрен күтәреп өенә ашыкты. Өенә кайткач, читлекне кояш нурлары төшми торган урынга куйды да, үз эшеннән үзе канәгатьләнеп, читлектәге кошларны күзәтергә керешә. Аларның янәшәдә булуларын тою ана үзен төрмәдә кичерә торган рәхәт хисләрне бирә иде.

Кичен хатыны Хәмидә, улы, килене, оныгы да ин элек өйдәге бу яналыкка зур игътибар иттеләр. Оныгы Әнвәрне әйткән дә юк иде. Ул инде күптәннән, башка малайларныкы кебек үк, кечкенә эте, ялтыр күзле песие булуны тели иде. Аның бу турыда әти-әнисенә, әби-бабасына берничә тапкыр әйтеп караганы да булды. Тик һәр чакта бабасы бу сүзгә нокта куйды.

—Сезгә өйдә бер эт—мин житмәгәнмени?—дип, киная белән кычкырып көлеп жибәргән иде ул.

Читлектәге кошларны—бу көтелмәгән яналыкны—күреп гажәпкә калган өйдәгеләр Сәләхинең пенсиягә чыккач шулай үзгәреп китүенә эчтән генә сөенеп тә куйдылар.

Көн дәвамында Әнвәр читлектәге кошлар—матур кыяфәтле тутыйлар тирәсендә бөтерелде. Һәм көтмәгәндә генә:

—Бабай, ә алар нәрсә ашыйлар соң?—дигән сорау бирде.

Улының бу сүзләрен ишеткәч әтисе Марат телгә килде:

—Иртәгә аларга яраклы ярмаларны үзем алып кайтырмын, улым...

Чыннан да сүзендә торды әтисе. Попугайларга дип махсус әзерләнгән ризыклар алып кайтты. Тик жимне кошлар алдына салганчы Сәләхи белән алар арасында житди генә сөйләшү булып алды.

—Кошларга ашарга үзем салачакмын. Ачтан үлмәслек итеп...—диде ул сүзләренә үзе генә белгән мәгънә салып һәм жим салынган савытларны улының кулыннан тартып алды.

Марат әтисенең үз сүзеннән кире кайтмый торган кире беткән бәндә булуын белә иде. Шуна күрә дә сүз көрәштереп тормыйча гына читкә китте. Әнвәр монa игътибар итмәде. Ул читлек янында басып калды. Бигрәк үз итте шул малай читлектәге кошларны.

Тора-бара аны читлектә очарга талпынган кошларны кызгану хисе биләп алды. Малай бабасына дәште:

—Бабай, әйдә, читлекнең ишеген ачып куябыз. Очсыннар кошлар бүлмәләр буйлап...

—Тагын нәрсә?!—диде Сәләхи һәм оныгына сөзеп егардай булып карап алды.—Аң бул! Аларның урыны бары тик читлектә генә.

Берничә көн тыныч кына узды. Әнвәр көн саен вакытын мәктәптә үткәрә. Әти-әнисе көн озын эштә була. Көндезләрен өйдә пенсионер Сәләхи һәм читлеккә бикләнгән кошлар гына торып кала.

Хәзер аның бөтен юанычы—читлектәге кошларның кыланышларын күзәтү.

Ә беркөнне, урамда йөреп кайткач, ишекне ачып кергәч, ул бөтенләй көтелмәгән хәлгә тап булды.

Читлек ишеге шар итеп ачып куелган, ә тутый кошлар пыр-пыр килеп, бер-берсе белән куышып бүлмә буйлап очып йөриләр. Оныгы Әнвәр исә бу тамашага исе китеп бүлмә уртасында басып тора. Ул бабасының кайтып кергәнен дә сизмәде хәтта.

Сәләхи аны-моны әйтеп тормады. Сакланып кына малай янына килде дә, төрмәдән калган гадәте буенча оныгының арт чүмеченә үзенең саллы йодрыгы белән китереп бирде. Аны-моны көтмәгән малай идәнгә ауды.

—Тор, имгәк!—дип зәхәрләнеп кычкырды Сәләхи хушсыз яткан оныгына һәм аны изүеннән күтәреп караватка ыргытты.—Мин сиңа әйткән идем бит: "аларның урыны читлектә"—дип. Бары читлектә генә!..

Ул аңына килә алмыйча яткан оныгына борылып та карамыйча, тутый кошларны читлеккә куып кертергә кереште.

...Күпме вакыт үткәндер, Әнвәр аңына килеп күзләрен ачканда йөзе качкан, чыгырыннан чыккан Сәләхи арлы-бирле бүлмәләр буйлап йөренә, тутыйлар читлеккә ябылган иде инде.

Алар әле генә йортта булып узган мәшһәрдән куркышып бер почмакка елышканар.

—Аңладыңмы инде?—дип кычкырды Сәләхи малайның йөзенә төкерекләрен сибеп.—Тагын шулай эшләсәңме?!.

Бөтен тәне ут янган, башы чатнаган малай бер сүз дә әйтә алмады. Күз карашы белән тутыйларны күзәтә иде ул. Ә күңеленнән: "Кайсы юньсезе сезне туган җирләрегездән аерып читлектә яшәтүне уйлап чыгарды икән",—дип уйлады ул.—Сезнең дә иректә, туган ягыгызда яшәргә хакыгыз бардыр ич?! Хәл кереп аякка гына басыйм менә. Коткарам мин сезне читлектән..."

Бабасына үч итеп, сүзендә торды малай. Икенчеме, өченче көннеме... бабасы өйдә юк чакны туры китереп, ул балкон ишекләрен ачып куйды. Аннан читлек ишекләрен... Шуны гына көткәннәр диярсең, тутый кошлар бер-бер артлы бүлмәгә очып чыктылар һәм берничә тапкыр пыр-пыр килеп аны ураганнан соң балконның ачык ишегеннән ирекккә юл алдылар...

Малай фатирда ялгызы гына торып калды. Ул балкон ишекләрен кире ябып куйды. Буш калган читлек янына килеп башын иеп озак кына басып торды һәм бүлмәләр буйлап әрле-бирле йөренергә кереште. Ә үзе әледән-әле ишек ягына карап-карап алды. Ана бары бабасының кайтып керүен көтәргә, күңелендә җыелган ачулы сүзләрен әйтергә генә калды. Тик әлегә ул бабасының аның белән ни-нәрсә эшләячәген, әти-әнисенең исә кайтып кергәч аның канга баткан җансыз гәүдәсен табып алачакларын, ә Сәләхинең калган гомерен анарга таныш та, якын да булган төрмә стеналары эчендә үткәрәчәген генә белми иде...



Шәмсия
Җиһангирова

## ЯРАЛАНГАН БЕР КОШ СЫМАН...

* * *

Күңелемә ниләр булды икән?!
Гомер нигә бик тиз үтеп киткән?—
Мин атымны тыеп калганмын.
Тарткан саен, ыграк төявемне,
Эштән генә бәхет эзләвемне,
Ай-һай, бигрәк соңлап аңладым.

Күңелемә ниләр булды минем?!
Бармы берәр тыныч торган көнем?—
Үз-үземне нигә битәрлим?
Йөгәнемне тартып кына торам,
Атын тыйган ерак юлчы сыман,
“Т-р-р! Ашыкма! Тукта! Җитәр!”—дим.

Күңелемә ниләр булды әле?!
Йөгреп кенә узган гомер җәлме?—
(Соң шул инде: җәллә-җәлләмә!..)
Безнең кебек җилкенмәсен өчен,
Соңга калып үкенмәсен өчен—
Бирче, Ходам, акыл бәндәңә!

* * *

Авыл җаны—шәһәрләрдә,
Дүрт стена эчләрендә...
Шигырь булып түгелә ул
Төннәрендә, кичләрендә.

Бәргәләнә читлектәге
Яраланган бер кош сыман.
Түзә алмас, өзелер күк,—
Калган инде нечкә кылдан...

---

Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА *—шагыйрә, прозаик; «Төсле моң», «Балачак кая китә?», «Җирсу» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Язмышмы бу, фаҗигаме?—
Авыл җаны—шәһәрләрдә!
Бу халәткә дучар булган
Үзеңнеме каһәрләргә,
Үпкәләргәме әнигә—
Җибәргән, дип, нигә читкә?
Йә Ходайга, кешеләргә
Сылтаргамы ахыр чиктә?!

...Беркемнең дә өлеше юк
Без яшәгән гомерләрдә.
Каерып алам да читлектән
Җаным—салам шигырьләргә.

* * *

Мин синсез дә яши алам икән,—
Өметләнеп ишек какма әле.
Сөю вәгъдә итә алмыйм сиңа,—
Йөрәгем буш түгел. Кайтма әле.

Елмайганымнан да көнләшеп, син
Бер сәбәпсез гаеп таккан мәлне
Искә төшерәм дә—исем китә;
Сагыналмыйм сине. Кайтма әле.

Картлык ни икәнен аңламыйча,
Баш әйләнеп йөргән чаклар әле.—
Син картлыкны күптән үз иткәнсең.
Миңа бераз иртә. Кайтма әле!

"Синсез яши алмыйм" дигән булып,
Төче сүзләр уйлап тапма әле.
Гомер үтә, әмма яратулар
Мәңге кала икән! Кайтма әле...

***

Син нишлисең икән бу минутта!—
(Үзәгемә үтте гаҗизлек!)
Ышаналмыйм сине минем кебек
Очар кош булырга әзер дип.

Гел "законча" гына булмыйк әле—
(Үзәгемә үтте "дөрес"лек!)
Офыкларда кояш байый әнә,—
Әйдә, язмыш белән килешмик!

Кайтыйк әле болыннарны урап,
Бездән башка гөлләр боектыр.
Мин килермен зәңгәр күлмәк киеп,
Офык чигендә син көтеп тор.

Күзгеләрдән карап торма инде!—
(Үзәгемә үтте көтүләр!)
Яннарыңнан меңәр урап киләм
Бер мизгел эчендә мин юләр.

...Син нишлисең икән бу минутта?—
“Сине уйлыйм!”—диеп алдама!
Йөрисендер: “Вакыт бар әле...”—дип,
Мәңге яшәр булып дөньяда.

...Баткан кояш таңда чыгар, беләм!
Безнең “кояш”, бәлкем чыкмас та.
“Кадерләрен белмәгәнбез...”, диеп,
Үкенербез кебек шул чакта...

* * *

Мәхәббәтне әче диләр,—
Шулайдыр. Мин дә тоям.—
Сине яратканым өчен
Көн-төн тозлы яшь коям.

Шул тоз тәме иренемдә,
Җанымда, йөрәгемдә...
Сагыну-сагыш—көннәремдә,
Әче яшь—төннәремдә.

Гел тозлы булмас яшьләрем,
Беркөн балланыр әле;
Җаныбыз, бербөтен булып,
Мәңге ялганыр әле.

Көнләшеп калырлар бездән
“Без парлы!” дигәннәр дә,
Мәхәббәтне, баллы диеп
Алданып йөргәннәр дә...



Эльмира
Җәлилова

# ТҮГЕЛЕР ДӘ ЙӨРӘК...

## Ара

Елмаю кунса да йөземә,
Яшимен күңелдән гел елап.
Ай — Кояш арасы күк ара —
Син миннән бик ерак, һай, ерак...

Йокымны еш кына бүләсең,
Яшимен аннары төш юрап.
Төш һәм өн арасы шикелле
Аралар бик ерак, һай, ерак.

Төшемме, өнемме, аермыйм,
Шаштыра инде төн акылдан.
Офыктай, син — минем җаныма
Шулкадәр ерак та, якын да...

## Бу—мин!

Акны кара дия белмим,
Ниләр кылыйм?!
Елмайганда елмаям мин,
Елаганда — елыйм.

Күңелдә ни, телемдә шул,
Инде нишлим?!
Туры әйткәч, күпләр белән
Борчак пешми.

Яктылыклар били җанның
Ак читлеген.
Бер киеп, бер сала торган
Юк битлегем...

---

Эльмира ЖӘЛИЛОВА *—яшь шагыйрә, журналист; "Кыз күңеле" исемле шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

## Гөнаһ

Мин яраттым... Гаепме бу?!
Гаеп булса, гаеплемен, таныйм.
Тик бер генә теләк телим:
Күзләреннән яшьләр булып тамыйм...

Мин яратам... Гөнаһмы бу?!
Шулай икән, мин гөнаһлы, беләм...
Ярлыкаулар сорамыймын, Ходам,
Озак яшәт шул "гөнаһым" белән?!

## Улыма

Күк гөмбәзе ачылды да,
Җиргә йолдыз атылды.
Шул мизгелдә теләгемне
Илаһым кабул кылды —
Мин әни булдым!

Яз сулышын өрде җиргә,
Яшь бөреләр ачылды.
Җаннан җан яралгандагы
Авыртулар басылды —
Дөньяга Улым туды!

Елмаю белән йөземдә
Бәхет яшем буталды.
Йөрәк парәм тәүге тапкыр
Җиһанга аваз салды —
Кычкырып елап алды!

Бисмилла, дип, тәүге тапкыр
Күкрәк сөтем имездем.
Бу вакытта мин үзем дә
Фәрештәгә тиң идем —
Җиде кат күккә мендем!

Ярдәм иттең, бу дөньяга
Газиземне яралтың.
Сабыема шәфкатеңне
Киң кыла күр, йа, Раббым!

***

Мин каләмнән "баш тартырга" булдым:
Бүтән чәчмәм шашкын хисләрне...
Шигырь язсам — түгелер дә йөрәк,
Фаш итәр ул мине-исәрне.

***

Кайчак "башны югалтасы" килә,
Тапмас өчен бүтән...
...Ләкин сизәм: акыл йөрәгемне
Йөгәнләгән күптән...



Лилия
Гыйбадуллина

# Ә ОЧАСЫ КИЛӘ...

* * *

**Мин язларны сиңа бүләк итәм,**
**Сиңа бирәм күзләр сихерен...**
**Башым күккә тисә, йолдыз явар...—**
**Ахры, артык биек сикердем...**

**Мин көннәрне синең өчен саныйм,**
**Мизгелләрне тезәм бушлыкка.**
**Хыялларым елап калыр кебек,**
**Ничек сыйыйм бу тар тышлыкка?!.**

**Мин җанымны сиңа атап сулыйм...**
**...Ә син кайтыр өчен кит тагын!..**
**...Мин—яңа җыр заман шаукымында:**
**Ачтым гына Яшәү китабын!..**

* * *

**Юатасым килә сине**
**Еллар аша.**
**Тик назларым, йолдыз булып,**
**Төнгә аша.**
**Син дә әрнегән йөрәгең**
**Күккә ташла...**

* * *

**Яшен телгән мизгел узып бара,**
**Ул—койрыклы йолдыз, күрәсең.**
**Сүзләремне тамчыларга салып,**
**Ятлыйм бүген хисләр сүрәсен.**

**...Яшьнәп узган гомер—гүя учак,**
**Белми дөрли тиздән сүнәсен...**

## Мәхәббәт!

**Өши-өши янам,**
**Дөрли-дөрли сүнәм.**
**Ялкынында салкын,**
**Кышларгамы күнәм?..**

---

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА—*яшь шагыйрә; "Мин Бәхетне күрәм!" исемле китап авторы. Казанда яши.*

* * *

Мәхәббәт дип шашкан дөнья,
Күз яшьләрен коя-коя,
Ясак җыя һәрбер күңелдән.
Ә бәясе сөю юлларына
Алтын (яфрак!) булып түгелгән…

* * *

Ә очасы килә—
Колач җәеп, үчекләп бер зәңгәр
Күкләрне.
Нәрсә булды бу тилергән җанга?
Мин җир кызы идем—
Күптәнме?

Ә очасы килә—
Каурыйларны коя-коя
Ташлы юлларга…
Син яварсың, яңгыр, тик иртәгә—
Соңга кала күрмә еларга…

Ә очасы килә—
Ак болытны йомшак түшәк
Итеп уйнарга…
Кояш көлә…
Тәрәзәне яптым.
…Кала исе сеңгән уйларга…

* * *

Тик бер мизгел—
Кире уйлап артка чигенермен.
Тик бер мизгел—
Йөрәгеңә мәңге чигелермен.
Тик бер мизгел—
Һәм йолдызың булып кабынырмын.
Тик бер мизгел—
Мин сөюгә генә табынырмын.
Тик бер мизгел—
…Һәм мин сине мәңге сагынырмын…

* * *

Монда бар да башка…
Монда күкләр югаладыр
Җирнең чигендә,
Монда күпләр шуышалар
кебек…

Син чигенмә, Кеше,
Чигенмә!..

Рәйсә
Юсупова

# АК САГЫШ ИЯСЕ

ОЧЕРК-ХАТИРӘ

*Татарстанның атказанган врачы һәм атказанган сәнгать эшлеклесе, "Мәхәббәт сагышы", "Зөбәйдә—адәм баласы", "Әни килде" кебек мәшһүр әсәрләр авторы, язучы-драматург Шәриф Хөсәеновның якты истәлегенә багышлана.*

## НАЗЛЫ, ЧӘНЕЧКЕЛЕ, КӨЙСЕЗ ГӨЛ КЕБЕК...

Ул көнне кар яуды да яуды. Күбәләкләр кебек оча-оча, бөтерелә-бөтерелә, тын гына яуды. Ак хризантема тажларыдай—ап-ак карлар... Илаһи Табигатьнең үз баласына, аклык яраткан бөек баласына, әйтерсең лә, ак бүләге иде бу. Ул көнне без—Наза ханым Сафина, Суфия ханым Мифтахова һәм мин—кар белән капланган Анын бакый йортын ал, кызыл чәчәкләр белән бизәдек.

Бу—1999 нын 26 ноябре—Анын туган көне иде.



Тәүге мәртәбә Анын чәнечкеле теленә эләккән теге көнне дә кар яуган иде. Җитмеш җиденче ел ноябренең соңгы көннәренең берсе иде анысы да. Машинабыз тәгәрмәчләре еш кына бер урында әйләнеп, бер дустыбызның өй туе мәҗлесенә без соңга калыбрак килдек. "Менә... сезне көттереп,—диде Шәриф әфәнде Хөсәенов, өстәл яныннан кыймылдамый гына,—ач утырталар әле монда. Инде китәргә җыенган идем..." Мөлаем хуҗабикәнең иремә: "Тәлгать Гомәрович", дип эндәшүе дә ошамады үзенә. "Мәҗлестә түрәләр булмый!"—дип аны да кызартты.

Мәҗлес барышында да безне "әзәрлекләвеннән" туктамады ул. Яшькелт күзләрендә шайтани очкыннар биетә-биетә, әле миңа, әле Тәлгатемә ишарәләп: "Шушымыни инде ирен—опера-балет яратмаучы, шуна күрә, понимаете ли, хатынын театрга ялгыз йөртүче ир",—диде. Җавапны да шул рухта бирергә тырыштым. "Әйе,—дидем,—Хәбирем шушы инде минем!"

Күрәм: Шәриф әфәндегә әлләни булды, ул сүзсез калды. Егерме еллар элек язылган "Мәхәббәт сагышы" героенын исеменә хәтле хәтерләвем тәэсир иттеме, әллә шул бер исем белән үзенә бик кадерле хатирәләрне исенә төшердемме—анын карашы җылынды. Һәм бу мәлдә Пушкин, Есенин сүзләреннән туган романсларны җырлаучы иремне дә гаҗәеп бер соклану белән тынлый башлады...

Шамил Усманов урамынын без бер башында, ул икенче, "Восстание" белән тоташкан башында яшәгәнгәме—без еш кына очраша һәм, күптәнге танышлар

кебек, исәнләшеп йөри башладык. (Безне хәтта фатирына да дәшеп, йөздән артык төрдәге кактусларына да сокландырды әле ул.) Матбугат йортына килгәндә дә "Азат хатын" редакциясенә керергә, сәлам биреп чыгарга онытмый иде.

Опера һәм балет театрында да без еш күрешәбез. Опера тыңларга, балет карарга, гадәттә, ул ялгыз йөри. Симфоник концерт тыңларга исә кара чәчле, сөйкемле бер ханым белән килә. Тәлгатем килгәндә, гадәтенчә, "О-о! Завод директоры килгән икән бит әле",—дип, яктырып бер ирония ташлый. ("Ничек вакыт таптың", янәсе.)

Һәм менә... минем күгемне болыт каплады. Газиз ирем, кадерле Тәлгатем дөнья куйды. Жанымны кая куярга белмәгән әнә шул көннәрнең берсендә, өемдә телефон шалтырады.

—Нәрсә, Юсупова,—диде гаҗәеп бер тавыш,—әллә акырып елап утырасыңмы— театрда күренмисең. Бүген операга ике урынлы билетым бар. Ә минем Суфиянең әнисе авырый. Барырга теләгең булса, жыен тизрәк. Юкса үземнең поликлиникадан барырга атлыгып торучы бер ханымны чакырам...

Бу—Шәриф Хөсәенов тавышы иде.

Апам белән улым, төрткәли-төрткәли диярлек, мине театрга озаттылар.

Ул, шул рәвешле, берни дә сорашмый, юатмый гына—кайгымны уртаклашты.

Әкренләп мин дә күземне ача, жиһанны күрә алырлык халәткә керә башладым. Авыру иремне карау өчен китеп торган эшемә янәдән кайттым. Музыка, театр дөньясына да аяк бастым.

Суфия ханым килә алмаган көннәрдә, Шәриф театрга, һаман-һаман, мине чакырды. Мондый бәхет бигрәк тә Шаляпин, йә Нуриев фестивальләре көннәрендә эләксә, мин сөенеп туя алмый идем.

Ә бермәлне, туксан алтының азагы булса кирәк, ул мине симфоник концерт тыңларга дәште. "Синең әле Зур концерт залын да күргәнең юктыр, барасыңмы?"— диде. Анда булырга, әлеге сәнгать сарае белән танышырга өлгергән идем инде мин. Бу турыда аңа әйтеп тормадым, мине сөендерә алуыннан үзенең дә балалар кебек сөенүен күз алдыма китердем дә концертка киттем.

Бу юлы ул, чынлап та, балалар кебек самими иде. Йөгерә-атлый каршыма килде, яңа туннан икәнемне күргәч: "Минем дә затлы туным бар, авыр булганга кимәдем",—диде.

Концертны да илаһи бер илһамлану белән тыңлады. Беренче скрипканың виолончель белән "әңгәмәсеннән", миңа калса, "күкләрдә очты", "дәрьялар колачлады", "кара урманнар кичте".

Кайтырга чыктык. Кузгалырга торган троллейбусны күргәч, мин йөгерә башладым. Ул да миңа кушылды, әмма без өлгермәдек.

—Борчылма,—диде Шәриф әфәнде,—икенчесе килер. Көн матур бит—ник ашыгасың?

Мин аңа Тэтчер исемле көчегем барлыгын, аның урамга чыгар вакыты житүен әйттем. Һәм... шул мәлдә—йә Хода!—мин аның кояштай балкуын күрдем.

—Чынлапмы?—диде ул, ихластан сөенеп.—Минем дә бит песием бар. Мине эшкә киткәндә озата, кайтуымны көтеп ала...

Тамагыма төер утырды.

Редакциядә телефон шалтырады. Берәү, исәнләшеп тә тормыйча, әрләргә тотынды.

—Сез—журналистлар—нәрсә анда, һәр үлгән кеше өчен һәйкәл даулап, газит-журналларны чуарлап утырасыз. Булганнарының кадерен белергә өйрәнегез башта. Аларны кош тизәкләреннән чистартып, сирәк-мирәк булса да чәчәк салырга да онытмагыз...

Бу—Ул иде.

—Менә шушыларны кәгазьгә төшереп килсәң иде, Шәриф әфәнде,—дидем мин.

—Басачаксызмы? Чынмы?..

Язма басылгач ("Чәчәкләр китерик һәйкәлләргә!", "Заман", № 41, 1997 ел), гонорар алырга чакыру өчен, мин аның номерын жыям. Үзем исә "кирәк иде

сезнең тиеннәрегез" кебек сүзләр ишетүдән шикләнәм.

Юк, Шәриф Хөсәенов мин шикләнгән сүзләрне әйтмәде—шул ук көнне килеп тә житте. Ә бер-ике сәгатьтән янә аның бик тә канәгать тавышын ишеттем.

—Гонорар акчасына,—диде ул,—Тукай, Пушкин, Жәлил һәйкәлләренә чәчәкләр салдым. Аларга бит инде берни дә кирәкми, без—исәннәрнең фәкать онытмавы гына...

Ә ул үзе онытмый иде. Һәйкәлләрне дә, исәннәрне дә. Отпуск елларын да аларга багышлый: Мәскәү-Петербург музей-театрларын да айкап кайта иде.

Бер тапкыр ул безне дә (газетаныңмы, әллә язма геройларыңмы?) мактагандай сөйләште. Хәер, аның мактавы да үзенчә иде. (Ялагайлануны, масаюны "жене сөймәгәнгә"дер, мөгаен, ул, гомумән, мактап жылы сүз әйтүдән тыела иде.) "Слушай,—диде ул,—мин синең София турындагы очеркыңны укыдым. (Сүз "Таһир-Зөһрә" газетасында чыккан, София Гобәйдуллинаның ижат тормышына багышланган язма турында бара.—Автор.) Анда Рудольф Нуриевне дә телгә алгансың икән. Туганнарга алып барып: "Татарның мәшһүрләре белән танышыгыз әле", дидем. Гел урыс гәзите генә укып ятмасыннар—күрсеннәр! Белсеннәр!.."

Менә шушы сөйләшүдән башлап, Шәриф әфәнде миңа иртә-кич шалтыратырга гадәтләнеп китте. Һәм сәясәт, һәм сәнгать дөньясы турында сөйләшеп алуга, күрәсең, ул мохтаж иде.

Чын дуслары күп түгел иде шул аның, күп түгел иде... Булганнары да... "югала" торды.

Бер көзе хәтердә.

Беренче кар төшеп, каз өмәләре узгач, ул базардан сигез каз алган иде. Нияте изге—һәр шимбә саен берәр каз кыздырып, берәр-берәр пар итеп кенә, дусларын чакыру...

Һәм чакырды да. Тик... кайбер парлар, хуҗаның юморын күтәрә алмаудандыр инде, табынны ташлап киткән икән...

Бу турыда Шәриф әфәнде айлар буе сөйләде. Газаплануын, үз-үзен битәрләвен яшерергә тырыша-тырыша сөйләде. Гүя, бу аның минем алда: "менә мин шундый шул инде", дип аклануы иде.

Бермәлне ул кулына зур байлык төшерде. Рудольф Нуриевнең ижаты һәм тормышы бәян ителгән өч-дүрт китап ул. Чит илләрдә басылганның русчага тәрҗемәсе. "Мин исән вакытта... татарның бөек улы турында белеп калыгыз" дия-дия, якын дусларын ул чиратка куйды.

Үземә бирелгән унбиш көн эченә генә мин сыеша алмадым, китапларны тагын берничә көнгә калдыруын сорадым. "Ярый,—диде,—тик бер шартым бар—аның турында очерк язарсың". "Балет сәнгатен тирәнтен белмим—моны син, бары син генә булдыра аласың",—дип, мин үзенең язуын үтендем.

Ул уйга калды һәм... иң кадерле серен ачты: "Исән булсам, мин аның турында китап язачакмын".

Һәм әзерләнә башлады. Мәскәүдән Нуриев ижатын чагылдыручы фильм-кассеталар жыеп кайтты (шул фильмнарны күрсәтеп, дусларын да куандырып алырга онытмады), Ана багышлап чыгарылган альбомнар туплады, Санкт-Петербургка—Рудольф белән бергә укыганнарга—хатлар юллады.

Әмма, күп тә үтмәде, Нуриев исемендәге фестиваль көннәрендә, театрда, шик-шөбһәләре белән дә бүлеште.

—Слушай, Рәйсә,—диде ул,—хәтта Нуриев кебек, татарны дөньяга танытучы даһилар да кирәк түгел бугай безнең халыкка. Балет сәнгате үзе дә—шул чутта... Син татардан залда кемнәрне күрәсең? Берничә бөртек интеллигентныймы?! Ә яһүд белән, әнә, зал тулган...

—Йөрерләр, һичшиксез, йөрерләр. Менә китабың да чыксын әле,—дидем. Һәм кәефен күтәрмәкче булып, ошбу фестивальнең безнең шәһәрдә тууына да аның өлеше керүен исенә төшердем. (Мин, чыннан да, опера һәм балет театры директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗановка, "Уфа, йә Петербург эләктергәнче", дия-дия, Шәриф әфәндедән идея бирүен ишеткән идем.)

Ул бик тә авыр итеп сулап куйды. Һәм, үзендә булган 16 фильм турында хәбәр итеп, Нуриев биегән шул балетларны халыкка күрсәтүне үтенеп, телевидениегә хат язуын сөйләде. Хәтта кадр артыннан аңлатып баруны да үз өстенә алачагын, бер тиен чыгым чыкмаячагын, гонорар алмаячагын да искәрткән икән хатында. Тик, өч айлап вакыт узса да, бернинди дә җавап килмәгән үзенә.

—Уйлап кына кара әле: балет Алласы—Маэстро—телевидениегә "үзе килеп керә". Бушлай, житмәсә... Башка милләт булсамы ?!!

Мин тетрәнеп киттем. Жан аһәне, чарасызлыктан гажиз калган әрнү, ачы әрнү иде бу.

—Рөстәм Яхиннын син соңгы көннәрен белмисендер инде,—диде ул бераздан.—Жебеп төште, бичара. Укол сорап тенкәгә тиде. Хәзер аңлыйм мин аны...

Әчке дөньясына керәүне дә якын жибәрмәүче Шәриф Хөсәеновнын—мин ишеткән—беренче зары иде бу.

Шалтыратуларынын берсендә ул, әле генә дусларыннан—Гөлнар һәм Марсель Сәлимжановлардан кайтуы, аларда бик күңелле кич үткәрүе турында хозурланып сөйләде дә, и-и, мин дә яшәдем инде, дип куйды.

—Син дә начар яшәмисең,—дидем.—Фатирын тулы жиһаз. Үзенә житәрлек абруй-дәрәжән бар...

—Карале, син минем "Мәхәббәт сагышы"ндагы Хәбир кебегрәк әйттең бит әле,—диде ул.—Әсәрнең соңгы эпизодын хәтерләмисенме?

—Бөтен мал-мөлкәтен, зиннәтен, дан-шөһрәтен, хәтта талантын да шып-шыр өйнең ялангач сәкесендә утыручы Мәдинәгә дүрт куллап алыштыруны бәхет санаучы бәхетсез Хәбирнеме?..

Телефон трубкасы тын калды.

Инде борчыла ук башлаган бер мәлдә, башта сулыш алу, ә бераздан сагышлы бер өн ишетәм:

—Шулай да Хәбир бик бәхетле булган. Кыярларга су сипкәндә... Рауза янәшәсендә...

—Мәдинә янәшәсендә...—дип төзәтә башлыйм һәм...

Һәм тыелып калам. Хәбир—Шәриф түгелме соң, Ходаем?!.. Шәрифнең үзе!.. Үзе бит!

Әйе, әйе, Мәхәббәтнең ачы шәрабен татымый торып, шушындый әсәр, шушындый образ—алтмышынчы елларның яшь кызлары кумирына әверелгән Хәбир Сыртланов образын!—тудыра алыр иде микән адәм баласы!?..

Очрашкан-сөйләшкән саен Шәриф әфәндегә мин соклана барам. Ул мине сөендерергә ярата. Бу юлы да минә: "Сиңа бер сюрприз әзерләдем, кил әле",—дип шалтыратты. Жавап бирергә ашыкмавымны аңлагач: "Слушай, килмәсәң, идәнемне себермим",—дип "янады".

Кырык эшемне кырык якта калдырып, ишеген шакыдым...

Балалар кебек балкып-куанып, ул мине өстәл янына чакырды, авыздан сулар китерүче персик-грушаларга ымлады: житеш, янәсе!.. Һәм, сынап бер карап алды да, буфетыннан шампан шәрабы чыгарды.

—Әллә берәр бәйрәм инде бүген?!..

Гажәпләнүем күңеленә хуш килде.

—Бүгенме? Бүген—сюрпризлар көне!—диде.

Анын бөтен барлыгы тантана итә иде. Кунак чакырган бит, кунак!.. Һәм мине сыйлый башлады...

Менә ул бик серле рәвештә кухняга юнәлде. Һәм... һәм илаһи бер горур кыяфәттә, кыздырылган бербөтен каз күтәреп чыкты. Каз янына затлы бокалларда сок куелды...

Бу дәрәжәдәге тәмле казны беренче тапкыр ашавым иде. "Кем кыздырышты? Суфия ханыммы?"—дидем.

"Үзем! Эшкә бармый әзерләдем..." Аптыравымны күреп: "Башта, егерме, ун ел элек, Аяз Гыйләжевнең Нәкыясе кыздырыша иде. Хәзер инде мин анын үзен дә өйрәтә алам... Ә минем Суфиянең әнисе койкада бит, ул мин кыздырганны ашарга

килергә бушаса да ярап тора",—дип өстәде.

Татар гадәте буенча—инде чәй килер, дип уйлыйм. Ә шул мәлдә өстәлне (мине чиксез куандырып!) морожный бизәде.

—Сюрпризларың өчен рәхмәт, Шәриф! Матур бәйрәм бүләк иттең,—дидем.

—Сюрпризның чыны—ике татар егете!—Һәм Шәриф әфәнде, ике кассета күрсәтеп, телевизорын кабызды.—Икесендә дә "Дон Кихот" балеты,—диде ул.—Тик берсендә Ирек Мөхәммәтов бии, ә икенчесендә—Нуриев... Бу шәхесләр иҗатындагы аерманы сиңа күрсәтү өчен—Мөхәммәтовны махсус яздырдым...

Билгеле, Шәриф әфәнде максатына иреште. Мин, чыннан да, аерма күрдем. Һәм ничек кенә әле!.. Шәриф табынган Нуриевның тын алуын да сизмисең, аяк "шапылдавын" да ишетмисең икән. Әйтерсең лә, Нуриев үзе түгел, аның җаны бии: синең күңелеңне били, йөрәгеңне били, рухыңны били...

Шушы мизгелдә бик бәхетле Шәриф янә кассета куйды. Бу фильмда Нуриев үз биләмәсендә—шәхси утравында—"патшалык итә" иде.

Тик... ни-нәрсә бу?!.. Таш өстендә утыручы, бөтен дөнья табынган Маэстроник бик боек? Дулкыннар өстеннән ерак-еракларга "очкан" карашы кайсы илләрдә йөри,ниләр эзли?.. Ходаем, бәхетсез ич ул, бик бәхетсез...

Моны мин кычкырып ук әйткәнмендер, ахры, Шәриф әфәндене ишетәм:

—И-и, Рәйсә, бу дөньяда—кем бәхетле инде?! Мин бәхетлеме? Синме?..

Мин өшеп киттем.

Кодрәтле Табигатьнең илаһи язы кешеләр күңеленә дә шифалы орлык чәчә диюләре—дөрестер, мөгаен... Әйе, әйе, шулайдыр. Язучылар союзы эшенә моңа кадәр "битараф булган" язучы Шәриф Хөсәенов мине гаҗәпләндергән мондый үтенеч белән шалтыратыр идемени, югыйсә.

—Карале, Рәйсә,—диде ул гадәти кичләрнең берсендә,—Язучылар съездына барасыңдыр бит инде. Ялгышмадыммы?

—Ялгыштың...

—Слушай, бар әле син анда, ниләр булуын миңа да сөйләрсең.

—Ник үзең бармыйсың?

—Андый җыелышларга йөрергә яратмыйм. Майлы калҗа өчен талашуларын, аннары, куштанлана-куштанлана, аны бүлешүләрен күзәтәсем килми. Холкыма ярамый.

—Ә миңа—ярый, дип уйлыйсыңмы?

—Һәр сүзгә бәйләнмә әле, яме? Болай да тынгымны җуйган чагым... Соңыннан аңлатырмын...

(Әйбәт яңалык иде бу. Димәк, ул язарга утырган; димәк, озакламый татар укучысы да балет сәнгатенең иң якты йолдызы Нуриев турында роман укыячак!)

—Мин бит Союз члены түгел, Шәриф. Чакыру да алмадым. Ә чакырмаган җиргә йөрергә яратмыйм.

—Ничек инде—син Союз члены түгел, слушай?! Ник кермисең? Һәр очеркың бәләкәй күләмле повесть, документаль повесть әле җитмәсә! Һәр язмаңда—кеше язмышы, аның рухи дөньясы, җан авазы... Хәер, син болай да язучы инде. Сиксәненче елларда ук язучы мөһере сугылган бер китабыңны укып, Кеше халәтен аңлый бу (!) дип, сөенгән идем. "Идел өстендә акчарлаклар" идеме әле ул китап? Аннары күпсанлы җыентыкларда...

Мин аны бүлдердем.

—Болай ук үсендермәсәң дә була—холкыңа ятышмый. Барыбер бара алмаячакмын—ашыгыч эшләрем бар; ачуланма, яме?

—Кызганыч... Таланган Язучылар союзы "хәрабәләрен" торгыза алырдай кешеләр барлыгына инанасым килгән иде. Фикер алышулар вакытында гына беленә бит андыйлар...

—Моны белүдән ни файда?!

—И-и, Рәйсә... Ярый ла безнең эшебез, һөнәребез бар. Пенсиядә генә яшәүче күпме кешеләрнең сөт алырлык та рәте юклыгын белсәң икән син?! Дарулар хакында әйтмим дә... Язучыларның хәле дә шундый ук бит... Әле минем "учакта",

оешма башына юньлерәк кешеләр килсә, андыйларның тормышы әзрәк рәтләнмәсме дигән өмет пыскый.

—Язучылар өстеннән дә шефлык итәргә җыенмыйсыңдыр бит, табиб әфәнде?!..

Ул җавапсыз калды.

Урынсыз шуклыгымны аңлап, мин дә телемне тешләдем... Кешенең изге хисләре, ихлас теләкләре, матур өметләре, самими гадәтләре белән шаярырга ярамауны белә идем бит, Ярабби!.. Җан ияләренә дә битараф булмаучы, авырулары янына да кучтәнәчләрсез бармаучы Шәриф атлы ошбу табиб турында чын риваятьләр йөргәнен дә ишеткәнем бар иде бит, югыйсә, бар иде...

Кеше кадере. Кешелеклелек кебек кыйммәтләребезне олылап, Кеше язмышы турында проза телендә Симфония иҗат итүче әдиптән мин гафу үтендем.

...Июнь башы иде. Редакциягә килгән бер артист, Шәриф Хөсәеновның юбилее уңаеннан[1], "Әни килде" спектакленә репетицияләр башлануын сөйләде. Бу юлы да Марсель Сәлимҗанов үзе алынган...

Җитмешенче елларда ук 500 мәртәбә куелып, дөньяны шаулаткан "Әни килде"не бүгенге тамашачы да күрәчәкме?!.. Йә Хода, инде Аның күңеленә дә кояш төшәр, шат...

Артист ханымны озату белән, мин телефонга ябыштым.

—Котлыйм, Шәриф! Синең өчен бик шатмын,—дидем.—"Әни килде"н янәдән сәхнәгә менә икән... Тик... тик Ана роленең Наилә Гәрәевага бирелүе генә күңелне борчый... Тамашачының олы мәхәббәтен яулаган мәрхүмә Галимә апа Ибраһимовадан соң бу рольдә башка берәүне күзаллавы, гомумән дә, бик кыен. Кызлар рольләрен оста башкаручы буларак дан казанган Наилә ханымны—бигрәк тә... Ничек мона риза булгансыңдыр—аңламыйм...

—Минем ризалыгымны беркем дә сорамады. Мин үзем, һәрхәлдә, Алсу Гайнуллинаның уйнавын өмет иткән идем.

—Шалтырат Марсель әфәндегә. Әле соң түгелдер—алыштырыр.

—Алыштырмаячак. Кысылганны яратмый Марсель.

—Ничек инде?!.. Син бит—автор!

—Минем эшемә тыгылсан—куймыйм, диюе дә ихтимал әле.

—Сез бит дуслар!..

—Репетицияләр башлануы турында ишеткәннән бирле борчылам, слушай; инде син дә өстисеңме?!!

Ул трубканы куйды.

Шатлыгыма күләгә төшкәндәй булды. Кәгазьләремне аннан-моннан җыештырдым да, үз-үземне битәрли-битәрли, кайтырга чыктым.

Фатирым ишегенә ачкыч тыгалмый азапланам, ә тегендә, бүлмә эчендә телефоным "дулый".

Дуласын! Алмыйм. Берәүне дә ишетәсем килми. Керәм дә... әйе, каты итеп чәй эчәрмен. Аннары... аннары телевидениенең берәр каналыннан музыка тотам...

Ярый әле дөньяда музыка дигән илаһи бер могҗиза бар. Бу юлы да аның кодрәте барча вак-төякне онытты. Шостакович аһәңнәренә ияреп, иртәнге шатлыгым кайтты. "Әни килде"нең сәхнәгә менү куанычы, дулкын-дулкын булып, күзәнәкләремә тулды, бөтен барлыгымны биләде. Әйтерсең лә бу әсәрнең авторы да—мин. Хәер, үзем өчен мин болай ук сөенмәс тә идем әле.

Әйе, инде бар дөньям түгәрәк. Шатлыгымны кемнәргәдер сөйлисем, аларны да шатландырасым килә. Һәм, кушучлап, өзлексез шалтыраучы телефон трубкасын кыстым.

—Гафу ит, Рәйсә?!—туры килүен күр, Шәриф тавышы.—Бая трубканы ташлаганга—үпкәләмә инде, слушай? Кәефсез чагыма туры килдең бит. Кучтәнәч дип бик симез бер тавык алып килгәннәр иде; бозылып әрәм булмасын дигән булып, күбрәк ашаганмын ахры—ашказаным борчый... Ә Гәрәеваны... Син аны "Гаугалы гаилә"дә карамадыңмы? Нинди шәп аның Мемесы, ә?!. Мин аның Ана ролен күтәрә алуына да шикләнмим, слушай. Тик буе гына...

[1] Шәриф Хөсәеновка 26 ноябрьдә (1999) 70 яшь буласы иде. 7 июльдә ул вафат булды.

—Шул гынамы? Моның өчен борчылмасаң да була. Бәләкәй буйлы аналар азмы әллә?!. Әйбәт уйнаса—буй күренми ул.

Һәм Наилә Гәрәеваның "Шәҗәрә"дә дә Сәлимә Сәетбәкова ролен гаҗәеп әйбәт башкаруын сөйлим. Моннан утыз ел элек үк—"Әни килде" спектаклендә Ананың кече килене Римма ролен башкарганда үк—әниләрнең олы образы артистның күңеленә кергән булуын исенә төшерәм. Инде үзе дә ана һәм кайнана булган ханымның шул образда сәхнәдә дә яшь алу мөмкинлеген искәртәм...

Шәриф әфәнде җиңел сулап куйды. Һәм без бу кичтә, телефон өзгән сүзләребезне ялгый-ялгый (ә телефон, ни сәбәптәндер, еш өзелде), бик озак сөйләштек.

Шушы сөйләшүдән соң Шәриф әфәнде мине оныткандай булды. Иртә-кич шалтыратмавына, күнегелгән гадәтен бозуына бераз гаҗәпсенсәм дә, мин тыныч идем. Яңа әсәр туа бит, яңа роман!.. Аның бөтен вакытын "Нуриев билгән", димәк. Үзем дә шалтыратмаска, иҗат эшен бүлдермәскә булдым.

Хәер, журналистның үз дөньясы да мең мәшәкать белән тулы. Әнә шундый көннәрнең берсендә Мәскәүдән София Гобәйдуллинаның апасы Ида ханым шалтыратып, София турында китап язучы алман галиме килүен хәбәр итте. Исәбе—мәшһүр композиторның ата-бабалары яшәгән төбәкләрне күрү, ди. Тәрҗемәче һәм аның америкалы ире дә килергә җыена; бик мәшәкатьле булмасмы, дип киңәш сорый Ида ханым.

Баш мөхәррирем Зиннур әфәнде Хөснияр белән киңәш-табыш итештек тә, газета эшемне бер якка куеп, мин Дәүләт Советына йөгердем.

Һәм анда аңлау да таптым. Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, "Татарстан хатын-кызлары" иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Зилә ханым Вәлиева бөтен мәшәкатьне үз өстенә алды. Маршрут билгеләдек. Ул шундук кунаклар барасы район-шәһәр җитәкчеләренә шалтыратып та чыкты.

Миңа исә аларны каршы алу, озатып йөрү, озатып җибәрү кебекләре генә калды.

Кунаклар килергә әле биш көнләп вакыт бар иде. 18 июньнең җомга иртәсендә мине йокыдан телефон уятты.

Әйе, бу—Аның тавышы иде.

—Карале, Рәйсә, иртәгә мине больницадан чыгаралар; бу турыда Марсель Сәлимҗановка шалтыратып әйт әле. Монда кергәндә киемнәремне Шамил Закиров алып киткән иде; китерсеннәр, слушай.

Мин аптырап калдым. Халәтемне тойды булса кирәк, Шәриф берара эндәшми торды. Аннары гына:

—Озак сөйләшә алмыйм, чират монда; телефонны эләм; ачуланма инде,—диде. Һәм... һәм:—И-и, Рәйсә, син бит берни дә белмисең!..—дип өстәде.

Телефон зыңлавының кайтавазы йөрәгемә кадалды.

Иртәгә... әйе, иртәгә чыгасы!.. Барып йөрмәсәм дә була икән. Больница шартларында күрәсе-күренәсе дә бигүк килеп тормыйдыр әле. Анда керәсен дә белдермәде бит. Бүген әнә аның янына Марсель Сәлимҗанов хатыны Гөлнар белән барырга җыена. Әйе, мин өенә генә барырмын иртәгә...

Әмма шимбә көнне шалтыратуларыма җавап бирүче булмады. Марсель әфәнденең телефоны да "эндәшмәде". Ял лабаса: Шәрифне дә үзләре белән бакчаларына чакырганнардыр, бәлки, дип уйладым мин.

Якшәмбе көнне дә Шәриф өенә кайтмады. Дүшәмбе, сишәмбе дә... Мин инде Аның Марсельләр бакчасында булуына тәмам ышандым. Ә чәршәмбе көнне килгән кунакларны ияртеп командировкага киттем.

Командировкадан җомга көн кич кенә кайттым. Алман, Мәскәү кунакларын да үземә чакырдым.

Кичке аш әзерләгән арада, колагыма сеңелем пышылдады: "Шундый курыктым әле, апа, шундый курыктым... Бер ир кеше шалтыратып: Рәйсә кая; ә син, карак кызый, ул өйдә юкта урлашырга килденме—хәзер милициягә хәбәр итәм, диде. Тизрәк трубканы ташладым..."

Мин көлеп җибәрдем: Ул! Әйе, Шәриф кенә шулай сөйләшә ала. Шөкер, авыруы үткән, димәк.

Төн уртасында шалтыраган телефонны шнурыннан алдым да (юлда арыган кунакларым уяна күрмәсен, берүк!), иртәнге жиделәрдә генә ялгадым. Ул шундук шалтырарга тотынды. Мин тиз генә трубканы күтәрдем.

—Иркәм!—дип эндәште таныш тавыш.

—Хәерле иртә, Шәриф!

—Әй, буталып беттем инде; минем Суфиямның телефоны дип сине җыйганмын, слушай. Туктале-туктале, ә ник ачуланмыйсын әле син мине?

Иркәм дигәнгәме? Йә, кем матур сүзгә ачулансын инде?!..

Мөгаен, мин бу уемны әйтмәгәнмендер, чөнки Шәриф үзе мине әрләргә тотынды.

—Слушай, өч көн буена кайда йөрисең, чукынып? Мин сиңа больницадан чыккан чәршәмбедән бирле шалтыратам... "Әни килде"нең премьерасына чакыру билетларымны да таратып бетердем бит инде. Сиңа дигәннәрен дә бирергә туры килде менә. Өенә үк килеп сорагач, ничек буш җибәрәсең, слушай... Әнә, кайсы көнгәдер, берне булса да калдыра алганмын әле...

—Борчылма, Шәриф, мин ничек тә керү юлын табармын. Бусы өчен дә рәхмәт! Килеп алырмын, яме?

—Киләсенме? Кайчан?

—Кичке жиделә. Мәскәү поездына кунакларымны озатам да...

—Подъезд ишеген ачарга төшеп йөри алмыйм, ачуланма?!.. И-и, Рәйсә, син бит әле берни дә белмисен...

Инде икенче тапкыр кабатланып шөбһәләндергән бу ят сүзләрнең ни-нәрсә аңлатуын сорашырга өлгергәнче үк, Ул трубканы куйды.

...Әмма мин соңгарак калдым. Вокзалына да кичке алтыда ук килеп житкән идек, югыйсә. Гәрчә күземне сәгатьтән ала алмасам да, поезд кузгалмыйча китәргә кыймадым. (Татар дөньясыннан бик канәгать калган кунакларны, үзебезнең гадәт буенча, матур итеп озатасы да килгәндер, күрәсең.) Такси да тота алмадым, житмәсә. Шәриф әфәнденең ишеген мин инде тугызынчы киткәч кенә шакыдым.

Ачучы юк. Кыңгырау төймәсенә дә басам, шакып та карыйм, эндәшеп тә—берәү дә җавап бирми. Катырак шакый башладым ахры, күрше фатир ишегеннән бер ханымның башы күренде. "Баш" пышылдап кына кемлегемне сорады да, ишеген чылбыр бигендә калдырган көе, "яхшы кеше иде" дия-дия, такмаклап еларга тотынды.

Булдыра алган кадәр тынычландырдым да, әйбәтләп сөйләвен үтендем.

Ханым сөйләгәннәрдән мин Шәрифнең бик каты авыру икәнен аңладым. Бүген дә көнозын янында ике хатын "кайнашкан" икән; аннары, кичкә таба, нинлидер машина килгән, ак халатлылар да күренгән.

Йөрәгем "жу" итеп китте. Шулай да, ханымның телефон аша шалтыратып каравын үтендем.

Бераздан чылбырлы ишек ярым ачылды, янә баш күренде. Һәм ул, "телефонны алучы юк" дигән ишарә ясады да, "яхшы кеше иде" дип, тагын үксерге тотынды...

Марсель әфәнденең өенә мин инде үз фатирымнан шалтыраттым. Трубканы алган Гөлнар ханымга әлеге хәлләрне сөйләдем. Ул белешергә булды.

Ә бераздан тынычландыра торган хәбәрләр дә иреште. Әйе, барлык больницаларга шалтыратып чыккан Гөлнар. "Бездә юк", "белмибез" дигәннәр. Шәриф үзе әле кичә генә "Әни килде" спектакленең генераль репетициясен караган. Бүген дә Марсель үзе белән сөйләшкән. Кәефе ярыйсы булган. Ул, тәгаен, өйдә. Тик... тик, "үзен туйдырып бетергән" туганнары дип белеп, ишеккә дә килми, телефонны да алмый торгандыр. Шундый ич инде ул—Шәриф, шундый!..

Икенче көнне ишекне миңа Суфия ханым ачты. Мин килгәнне белгәч, Шәриф әфәнде шундук үзе янына дәште.

Аны урын өстендә күреп, мин бер мәлгә югалып калдым. Ул исә, нәкъ саусәламәт вакытындагыча, мине жор сүзләре белән күмде.

—Авыру янына буш кул белән йөрмиләр, слушай,—диде,—күчтәнәчкә нәрсә алып килден?..

Пакетымнан жиләк, сок кебек күчтәнәчләр чыгардым. Боларны суыткычка

куюымны, ә суыткычтан ярты гына стакан салкын су китерүемне сорады...

Мин дә, ниһаять, сөйләшерлек хәлгә килдем.

—"Әни килде"нең генераль репетициясен карагансың икән,—дидем.—Бик тиз өлгерткән Марсель.

—Марсель бит ул! Аңа бер ай вакыт житә. Әллә нинди катлаулы әсәрне дә Марсель бер ай эчендә спектакль итеп әзерли.

—Канәгать калдыңмы соң?

—Әйе. Әйбәт спектакль туган. Сәярне башкаручы егет—Хәйруллиннар улы—шәп уйный. Хәтта мин көткәннән дә уздырган.

—Ә Наилә ханым ничек? Ана ролен күтәрә алганмы?

—Күтәргән, слушай. Син хаклы булдың: аның буй-гәүдәсенә игътибар ителми. Мин бик канәгать... Музыкасы гына бераз эчне пошырды. Ясалмалык өсти сыман. Ана бит ул, слушай, үлемнән курыкмый. Ул аңа әзер, аны көтә, белеп, котылгысыз итеп көтә. "Олы юлның тузаны"н кертү, аңламадым, ник кирәк булгандыр?!..

—Бу фикерне Марсельгә дә әйттеңме соң?

—Әйттем. Сизелер-сизелмәслек кенә калдырырбыз, диде.

Күрәм: Шәриф арый башлады. "Арыттым ахрысы. Йоклап алырга теләмисеңме?"—дидем мин. "Минем инде күптәннән йоклый алганым юк",—диде ул һәм Суфия ханымны залдан дәшеп, душ әзерләргә кушты. Ә минем китмәвемне үтенде.

Шәриф душта коенган арада, мин Суфия ханым белән сөйләшеп алдым.

—Бүген кәефе шәптән түгел әле: сәламәт кешенең дә желегенә үтә торган эссе бит—ярты сәгать саен салкынча душ ала,—диде ул.—Бу язмышның этлеген генә күр инде: июньнең берендә әнине жирләдем, Шәриф әнә нишләп китте... Иремне жирләгәнгә исә озакламый утыз ел була. Гомеремне балаларыма багышладым. Аннары әни... Шәриф өчен вакытым гел житмәде.

—Бәлки сезгә бергә яшәргә кирәк булгандыр?

—Шәриф—зур шәхес. Иҗат кешесе. Аңлыйсыздыр: балаларым белән аның янында яшәүне мин ярый торган хәл дип санамадым. Ә балаларны әни янында калдыруны башыма да кертмәдем. Бер ана да моны эшли алмый, минемчә. Хәер, Шәриф үзе дә минем мондый адымымны кабул итмәс иде. Аннары ул миңа гашыйк та булмады. Ә болай, институтта ук башланган дуслыгыбыз—саф, олы дуслыгыбыз—ярты гасыр сынау үтте... Бер-беребезгә "иркәм" дип кенә эндәшәбез без. Житмәсә әле икебез дә табиблар. Рухи дөньябыз да уртак: музыкага, театрга гашыйкбыз.

—Кеше сүзе, имеш-мимешләр куркытмадымы соң?

—Юк. Монын ише вак-төяктән өстен Шәриф. Ул—чын ир кеше! Ир-егетнең—гаярь заты!..

Ярый әле дөнья гел карадан гына тормый. (Шәриф әфәнденең авырып китүен ишетеп борчылуыма шаһит булган бер ханымның, әлеге борчылуымнан гына да гаеп эзләп, жанына кагылуы күз алдыма килде. Гарьләнүемнән мин ул чакта башымны идем—гаепсездән гаеп эзләп бу ханымның гөнаһлы булуында, әйтерсең лә, мин гаепле идем.)

Әле ярый бу дөньяның Суфия кебек ханымнары да бар...

Душтан соң Шәриф мине янә үзе янына дәште. Керсәм: китаплар өеме!

—Исән чакта үз кулларым белән бирим әле...

Бер мәлгә икебез дә каушап калдык. Тамагыма утырган төерне сиздермәү, дымланган күзләремне күрсәтмәү өчен—мин китапларга иелдем... Ул исә берни дә сизмәгәндәй дәвам итте:

—Беразын бүген алып китәрсең, калганнарын башка көннәрне... Тик иртәгә килмә: премьера көне—мәшәкатьле булыр. Житмәсә, Марсель әле мине каядыр алып барырга да жыена бугай...

Бик тә кадерле, әмма кайгы йөге кебек авыр бу китапларны кочагыма өйгән әлеге якшәмбедә мин үз фатирыма кайчан һәм ничек кайтып житүемне хәтерләмим.

28 июньдә (1999) тамашачы Камал театрына, "Әни килде" спектакленең

премьерасына жыелды. Рәтләрдә дә, рәт араларына өстәмә куелган урындыкларда да буш урын калмагач, кешеләр идәнгә чүктеләр; дивар, ишек яннары да—басып карау эләгүен дә бәхет санаучы тамашачы белән тулды.




Берәүләр спектакль карарга килсә, икенчеләрен исә әсәрнең авторын—гасырыбыз титаны Шәриф әфәнде Хөсәеновны соңгы тапкыр күреп калу кебек аяныч теләк китерде. Кычкырып сөйләшү дә, көлү дә—юк; бәйрәм рухы сагыш пәрдәсенә төренгән иде.

Спектакль барышында кемнәрнеңдер тыйнак кына борын мышкылдатуыннан—тавышсыз елауны тоясың. Хәер, кешеләр күз яшьләрен тыймый да, кыенсынмый да шикелле. Янәшәмдәге ханымның да күз яшьләре ага, бертуктаусыз ага. Аны сөртергә дә кирәк тапмый ахры ханым; үксемәс өчен генә—кулъяулыгын тешләгән...

Спектакль тәмам.

Тамашачы Авторны чакыра.

Тамашачы Авторны күтә.

Һәм менә Ул... үләр өчен кыя башын сайлаган бөркет кебек, үзе өчен кыяга әверелгән сәхнә түрендә, үз гаиләсенә әйләнгән театрында, дуслары, артистлар арасында, чәчәк бәйләмнәре уртасында, үзен аягүрә алкышлаучы тамашачысы каршында—горур башын тагы да югарырак чөйгән татар улы—Шәриф Хөсәенов.

Ә дүрт-биш минуттан соң сәхнә артында, сеңлесе (бертуган апасының кызы) Наза ханым белән Суфия ханым аның манма су булган күлмәген сыккан арада, үзенең дусты, режиссер Марсель Сәлимжановка әле Ул: "Мин бәхетле, слушай, сәхнәдә, тамашачым каршында, чәчәкләргә күмелеп китәм бит,—диярга һәм:—Шушылай, минем кебек, аяк өсте үлүче—йә, тагын кем бар?!.."—дип, шукланып алырга да көч табачак...

29 июньдә исә телефонда сеңлесе Наза ханым иде. "Бүген Шәрифнең хәле бөтенләй юк, хәтта күзен дә ачмый; безнең ярдәмне кабул итмичә, премьерадан соң фатирына да (бишенче катка) үз аягы белән күтәрелгән иде; күрәсең, күп көч сарыф иткән",—диде. Аннары: "Килүең бүген файдасыз, ул син килгәнне барыбер тоймаячак",—дип өстәде. Кичәге премьераны, "Котлыйм, Шәриф, спектакль искиткеч!"—диеп сәхнә уртасында ак розаларымны кочагына салуымны, һәм Аның күзләрендә "чынмы, ихлас әйтәсеңме", дигән сорау ялтыравын күзаллап, телефонны куйдым. Сүзләремнең ихласлыгын раслап кайнар-юеш аркасына куйган учларымның әле дә кайнарлыгын тою—өметне жылытты.

Ә 30 ында инде мин шалтыратып тормыйча гына бардым. Ишекне бу юлы Наза ханым ачты. "Кәефе бүген дә начар, сөйләшә алмый" дип пышылдады. Мин барыбер янына үттем. "Әни килде" спектаклен кичә дә (ягъни 29 июньдә дә) каравым, музыканың ишетелер-ишетелмәс кенә калдырылуын, артистларның гаҗәп шәп уйнавын, тамашачыларның аларны чәчәкләргә күмүен сөйләдем. Шәриф керфеген кагып кына мин сөйләгәннәрне хуплавын белдерде...

Бүген дә театрга ("Әни килде"гә, билгеле!) барачагымны әйтеп, мин китәргә җыендым. "Иртәгә-берсекөннәргә генә килмәм әле, үзенә бераз көч керсен",—дидем. Ул ризалыгын белдереп янә керфеген какты.

Мин могҗиза көтеп, аның булуына ышанып яши башладым. Телефоным шалтыраган саен Улдыр дип, "слушай, Рәйсә, нишләп йөрисең, чукынып, ник килмисең?" дигән кадерле тавышны ишетергә өметләнеп, трубканы алам.

И-и, могҗиза көткән, өмет белән мөлдерәмә ул көннәр!..

7 июльгә хәтле бу өмет өзелмәде.

*Ноябрь-декабрь, 1999.*

## БӘХЕТЛЕ ИДЕМЕ СОҢ УЛ—ГАЯРЬ ЗАТ?

Инде менә... көннәр, айлар, еллар үткән саен сагыш тирәнәя, истәлекләр калка, хатирәләр барлана. Һәм мин һаман-һаман Ул калдырган сорауларга җавап эзлим. Билгеле, алар арасында үземә кагылышлылары да бар. Нигә, мәсәлән, больницадан чыгаруларын әйтеп турыдан-туры Марсель Сәлимҗановнын үзенә, йә Шамил Закировка түгел, ә мина шалтыратты икән ул? (Авыру булуын шушы рәвештә белдерү өчен генәме? Әллә килүемне, янында утыруымны да теләдеме? Әллә инде шушындый юл белән үзенең мина булган дустанә мөнәсәбәтен Марсель һәм Шамил әфәнделәргә дә белдерәсе килдеме?) Әйе, җанны "ни өчен", "ник", "нигә" кебек сорау-үкенүләр дә биләгән. Әле һаман: нигә теге—кунакларым белән командировкадан кайткан төнне—телефонымны алмадым икән, дип үз-үземне битәрлим. Шалтыратучы, тәгаен, Ул иде бит, Ул иде! Кизү торучы сеңлесе—Наза ханым йокыга киткәч, иркенләбрәк сөйләшәсе килгәндер, әйтеп каласы сүзләре дә булгандыр. Аннары... Әйе, аннары кунакларымны озатканда... ник поезд киткәнен көттем инде мин, дигән үкенү бар күнелдә. Әмма сорауларнын иң зурысы, иң мөһиме—ул үзе, шәхси тормышы, ялгызлык афәтенә юлыгу сәбәпләре...

Бинийая серләр дә, әйтелмәгән сүзләр дә, и раббым, шул төннәрдә калдымы?

Менә тагын... үкенечле уйлар йөрәккә кага башлау белән, бик тә мөһим сорауга җавап сыман, хәтердә март ае (1999) янарды.

...Әйе, ул айның бер кичендә, минем туган көнем унае белән, радиодан котлау тапшырдылар. Әнә шул мәлдә телефоным да шалтырады.

Шәриф тавышы:

—Синең өстәл артына, дусларың, якыннарың арасына мин сыймадым инде, ә?!.. Ярый-ярый, акланма... Бәйрәм бер генә көн булмый ул, слушай. Аны берәр ресторанда дәвам итүгә дә—каршы түгел мин. Вакыт тапсаң, әлбәттә...

Юк, Шәриф моны онытмаган икән. Бер көнне ул мине "әбәткә", "Чәй йорты"на дәште.

Түрдән, тәрәзә яныннан өстәл дә алып куйган, рәхмәт төшкере. Ә өстәлендә... хрусталь вазада—алсу розалар!..

Минем сөенүемә үзе дә куанып, шушындый розалар өстәленне ешрак бизәсен иде, диеп, матур теләген әйтте дә, аннары: "Минем өемдә бик назлы бер гөлем бар, слушай. Чәнечкеле, көйсез кактус ул. Менә шул көйсез кактусым үзен бер генә минутка да онытмыйча кадерләгәндә генә чәчкә ата. Анын чәчкәсенең матурлыгын сөйләп-аңлатып булмый, слушай. Андый матурлыкны тасвирлый алырлык сүз юк татарда. Моны үз күзең белән күрү кирәк... Бу розаларның чәчкәсе дә шул кактусымныкына тартым",—дип өстәде. "Күр, таны, хозурлан", янәсе.

Мин дә җавапсыз калмадым, олы рәхмәтемне әйттем, романы өстендә уңышлы эшләвен, үзенең сау-сәламәт булуын теләдем. Күрәм: ул сагышлы гына елмаеп куйды һәм: "Бик язылмый шул әлегә. Иҗат өстендә утырырлык кәеф юк, слушай",—диде.

—Моң-зарларың ишетелә башлады әле, табиб әфәнде... Юбилееӊ якынлашу галәмәтедер инде бу?!—дип, мин күңелен күтәрмәкче булдым.

Әмма ул шул ук рухта дәвам итте.

—Адәм баласы гомеренә бер генә тапкыр бирелә торган олы хис турында олырак итеп сөйләргә дә өлгермәдем, слушай.

—Син аны Нуриев образы аша сөйләячәксең әле... Үз тормышыңны бәян итсәң дә—биш-алты китап туачак.

—Үзем һәм Зөлфә язмышын, дөресрәге, язмышларның башын—Хәбир белән Мәдинә образлары аша мин бер сөйләдем инде...

—Зөлфә?! Зөлфә дисенме? "Кыярларга су сипкәндә Рауза янәшәсендә" үзен бик бәхетле тойган Хәбир турында әйткәнең бар. Әйе, әйе, яхшы хәтерлим, Рауза янәшәсендә, дигән идең.

—Сине сынавым булгандыр, слушай. Кайбер артистлар кебек, син дә минем язмышны Рауза исеме белән бәйләмисең микән дип, беләсем килгәндер. Зөлфә исемле ул—"Мәхәббәт сагышы"ндагы Мәдинәнең прототибы—Зөлфә! Врач булуы

да хак. Бу исемне сиңа әйткәнем бар, слушай. Әһәмият кенә бирмәгәнсеңдер: икеөч мәртәбә әйттем!.. Карале, кадерле кешеннән исемен кычкырып йөрмисең аны, ул йөрәктә саклана...

...Ярый әле син бар, Хәтер! Шәрифнең сагышка уралган әлеге сүзләрен искә төшерү белән, зиһенне яшен уты яктырткандай, янә шул исемнәр калыкты: Рауза һәм Зөлфә! Ике хатын-кыз исеме: Зөлфә һәм Рауза!.. Тик... тик кем ул—Рауза? Кайда яши? Кем ул, кайда ул—Зөлфә?

Җанда берөзлексез "кем ул", "кем ул" дигән сорау сулкылдый. Шәриф атлы асыл ир-егетнең ялгыз яшәү серләре дә шул ханымнар белән бәйлеме?

Менә җавап та, мөгаен, ул ханымнарны тапкач кына табылыр. Әмма аларны ничек табарга соң? Кайдан эзләргә? Эзләүне каян башларга?.. Чү, чү, "кайбер артистлар" диде түгелме соң Шәриф үзе үк?!

Әйе, әйе, "кайбер артистлар"...

Һәм мин "кайбер артистлар"ны күрү, алар белән сөйләшү өчен Камал театрына юл алдым.

Иң әүвәл Марсель әфәнде Сәлимҗанов белән сөйләштем. Ул сүзен, билгеле, дустының исеме белән башлады:

—Шәриф җитми җанга, Рәйсә ханым, Шәриф җитми. Менә узган атнада[1], туган көнемдә, галәттә Шәриф утырырга яраткан өстәлем түрендәге кәнәфигә—ничектер үзем күрмичәрәк калдым—кунакларымның берсе утырган, җитмәсә. Шул кунагымны ул урыннан йолкып алудан көчкә тыйдым үземне. Мәҗлес буе күңелдә гел Шәриф булды. Шунысы җанга шифа: хәтергә ул елмаеп урнашкан. Йә туема өч көнгә соңарып килүе, ишек кыңгыравы төймәсенә баскач, үзенең бүләк итеп алып килгән ак суыткычы артына качуы һәм шуннан балкып күтәрелүе—искә төшә; йә бакчамда үткәргән бер туган көнемә бөтенебездән иртәрәк барып, яңа яуган кар өстенә кучтәнәч карбызларын тәгәрәтеп, агач ботакларына кып-кызыл алмалар элеп, канәгать елмаеп безне көтүе—күз алдыма килә... Шәриф—шук иде, җор сүзле, чәнечкеле телле иде, үртәшергә яратты. Боларның барысы да бер ширма—үзенең йомшак күңелле, игелекле, рәхим-шәфкатьле, намуслы, миһербанлы булуын яшерү өчен—битлек кенә иде. Ул һәр көзне капчыгы-ние белән көнбагыш сатып ала иде. Аннары кыш дәвамында песнәкләрне сыйлый. Балконында очына-очына, сызгырасызгыра көнбагыш чүпләүче шул песнәкләрне сәгатьләр буе күзәтүе, ул чактагы уйчан-сагышлы карашы—йөрәк төбендә. Ә эчке дөньясына ул берәүне дә якын җибәрмәде.

Зөлфәме? Мондый исемне ишеткәнем булмады. Ә Рауза исемле артистка белән Шәриф арасында нindидер мөнәсәбәт булуын—Шәүкәт Биктимеров сөйләве буенча гына беләм.

Шәүкәт Биктимеров:

—Шәриф Хөсәеновның "Профессор кияве" комедиясендә Рауза Уральская героиняны уйнады. Шәриф белән араларында мәхәббәт тә шул вакытта туды булса кирәк. Ләкин ул озакка бармады. Рауза соңыннан шушы ук спектакльдә баш рольдә уйнаучы Вәкил Закиров белән дуслашып китте.

Асия Галиева, Рауза Хәйретдинова, Гөлсем Исәнгуловадан да шундыйрак җавап ишеттем...

...Йә Хода: минем кулымда, ниһаять, биниһая байлык—Шәриф Хөсәеновның архивы! Аны миңа журналист эзләнүләрен ишеткән сеңлесе—Наза ханым Сафина китерде.

Архив тулы: хатлар, шигырьләр, язмалар, документлар, көндәлекләр... Таныш исемнәр. Таныш булмаганнар...

Әмирхан Еникинең ике хатын, Мөхәммәт Мәһдиев хатын, Равил Фәйзуллинның хатын һәм шушы хат белән юллаган Шәриф Хөсәенов турындагы очеркын, Миргазиян Юныс, Габдулла Юсупов хатларын һәм үз хатларының копияләрен укыйм. Кат-кат укыйм...

[1] 1999 нчы елның 7 ноябрендә.

Рөстәм Яхин, Кояш Тимбикова, Аяз Гыйләжев хатларыннан соң, кулыма чираттагы бер хатны алам. Һәм: "Хәерле көн, Шәриф! Моннан бик күп еллар элек мина Сезнен "Мәхәббәт сагышы" турында күп сөйләшүләрне ишетергә туры килгән иде. "Ул Яхинга багышланган әсәр, анда Яхин кичерешләре бирелә" дигәннәр иде... Менә май аенда, һич уйламаганда, "Мәхәббәт сагышы" басылган китап кулыма керде. Мавыгып укыдым. Уйландыра торган әсәр... Мин монда Яхин прототип дип әйтә алмыйм. Аның тормышыннан алынган бер факт кына: әнисенең авыруы, больницага керүе... Мин үзем, бу әсәрнең автобиографик булуы бик мөмкин, дип уйладым..." дигән юлларны укып, ахырына күз салам. "Ихтирам белән Зәйнәб", "минем Жәүдәттән сәлам", "Рөстәм Яхин Югославиядән авырып кайттым ди, кичә (27/V-77) шалтыратты", дигән хәбәрләрне укып, хатның авторын чамалыйм. Ул—шул чорның музыка сәнгате дөньясында билгеле кеше—Зәйнәп Хәйруллина булырга тиеш.



*Зөлфә белән Шәриф. 1964 ел.*

Инде үзем эзләгән исемнәргә юлыгуыма да ышанычым арта. Ашыга-ашыга актаруымны дәвам итәм. Һәм, өметем өзелә дигәндә генә... Рауза исеменә тап булам.

Төп сорауга ачыклык кертүче бу хатны да тулысы белән китерәм.

*"Шәриф!*

*Менә без тагын—өч елдан соң (!)—Свердловскида. Әйтергә генә ансат: өч ел! Ә күпме су акты шушы чор эчендә!*

*Һәм мин, күргәненчә, сиңа хат язудан үземне тыя алмадым. Һәм бу ниндидер хисләр аркасында түгел, Ходай хакы өчен алай дип уйлый күрмә. Син миңа просто иптәш буларак бик якын (гәрчә бу безнең барып чыкмаса да!), Син мине эткәләп төрткәләсәң дә, барыбер мин сине никтер бик якын күрәм... Һәм мин шулай күнеккәнмен дә, үзем читтә булсам да, яки син—кул үзеннән-үзе кәгазьгә үрелә. Гаҗәп, әйеме?*

*Мин сине язасың дип ишеттем. Ничек әйбәт! Мин бик-бик шатмын. Язмаска синең хакың юк. Яз, син язарга тиеш, чөнки табигать сиңа бөтенесен дә, бөтенесен дә биргән!*

*Ә хәзер хатын-кыз кызыксынуын да канәгатьләндер инде. Нәрсә турында язасың? Бөек материяләр хакындадыр, мөгаен? Мәхәббәт һәм башка мәсьәләләрме? Бик тә беләсе килә. Ахыры әйбәт тәмамланамы? Хәер, ни турында гына булмасын, иң мөһиме—синең тотынуың, яза башлавың! Оригиналь пьесалар бик кирәк бит. Бигрәк тә хәзер.*

*Кичә Уралмашта "кечкенә" бер күңелсезлек булган. "Егет сүзе" спектакле барганда, залдан: "Нәрсә күрсәтәсез сез безгә, берни аңлашылмый, без бит акча түләдек!"—дип кычкырганнар. Ну ничек, ошыймы сиңа бу! Менә сиңа—пьеса! "Хужа"ны һәм "Зифа"ны, билгеле, яратып карыйлар, әмма мондыйлар бер-ике генә шул. Драматург буларак бүген син кирәк. Һәм син бит үзең дә беләсең, теләгең генә булсын, син шундый пьеса язачаксың—бөтен Казан таң калыр! Син бит театрны, сәнгатьне шундый яратасың...*

*Мин сиңа уңышлар телим. Шайтанга олак диярсең, билгеле, әмма хат яз. Чкалов шәһәренең главпочта "до востребование" сенә җибәр. Пьесаның нәрсә хакында булуы турында яз, ярыймы! Түземсезлек белән көтәм. (Ходай хакы өчен, мине нәрсәгәдер өметләнә дип уйлама, юк, юк!! Ә просто—пьеса нинди булачак!) Үтенәм, мине дөрес аңла.*

*Сәлам белән Рауза".*

Әлеге хатны язучы кешенең мин эзләгән Рауза—Рауза Уральская[1] булуына шигем юк.

Рауза хаты белән янәшә үк диярлек... Зөлфә хатлары. Нәкъ "Мәхәббәт сагышы" повестенда бирелгәнчә, шундый ук эчтәлектәге—ике хат. Аерма бары исемнәрдә генә: әсәрдә хатлар "Исәнме, Хәбир!" дип башланып, "Сәлам белән Мәдинә" дип тәмамланса, минем кулымдагыларда исә "Исәнме, Шәриф!" дип башлана да "Сәлам белән Зөлфә" дип тәмамлана. Зөлфә Хәбибуллинаның Приморский крайдан язылган беренче хатында илле бишенче елның 20 май числосы тора, ә очрашуга чакырып Казаннан язылганына илле алтынчы елның 28 февраль числосы куелган.



*Рауза Уральская*

Һәм бу соңгысын, кыска язылганын тагын да кыскарта төшеп, укучы игътибарына тәкъдим итәргә булдым. Чөнки бу хат үзе генә дә теге, "кем ул—Зөлфә?" дигән сорауга җавап инде.

*"Исәнме, Шәриф!*

*Мин һаман синең белән очрашу хакында хыялланып яшәдем. Инде менә андый мөмкинлек туган иде. Әмма очрашуның минем өчен ни-нәрсә икәнен уйлап, мин бу хыялымнан баш тарттым. Тик ерактан гына булса да сине бер күрү теләге миннән көчлерәк булып чыкты. Һәм шушы кичкенә генә теләгем өчен дә язмыш мине аямады: без кара-каршы очраштык (хәтерләмим, синең сәламләвеңә җавап бирдемме икән).*

*Минем сине күрәсем килә. Вакыт таба алсаң, билгеле. Минем өчен бердәнбер җайлы көн—ул бүген. Иртәгә ирем Рөстәм киләчәк, гәрчә минем анардан яшерен серләрем юк—почти юк...*

*Җавабыңны көтәм. Мин өйдә булам.*

*Сәлам белән, Зөлфә".*

...Йә Раббым! Таптым бит, таптым!.. Ярты гасыр сакланган бу хатлар кулларымны пешерә, кычкырасы, бөтен дөньяга оран саласы килә.

Табышларыма хәйран калып, тынычланырга да өлгермим, Шәрифнең үз куллары белән "Зөлфәгә" дип язган шигырь хәзинәсенә тап булам. Мәхәббәт һәм Сагыш белән мөлдерәмә альбом битләре! Унике бит!!!

...Эзләнү нәтиҗәләрен инде кемгәдер сөйлисем, кем беләндер уртаклашасым, кемнәндер раслатасым килә. Күңелдән генә Шәриф әфәндenең дусларын барлыйм. Күңел күзе бердәнбер кешегә—Казан медицина институтында бергә укыган сабакташы, гомерлек җан дусты—Суфия ханым Мифтаховада туктала.

Сүзне, билгеле, ерактанрак башлыйм. Башта сорауларның иҗат мәсьәләсенә, яшәү рәвешенә кагылышлыларын бирәм.

—Шәриф Хөсәеновның архивында ачыклауны сорый торган хатлар да очрады. "Әни килде" ("Белое платье") спектаклендә Ана ролен башкаручы Айшет Магомаеваның (Мөслим Магомаевның әнисе) "Кадерле улым Шәриф!" дип башлап, "Хөрмәт белән әниең" дип тәмамлаган озын-җылы хатларының берсендә—сиксән алтының декабрендә язылганында—мондый юллар бар: "Белое платье"—Чемкент, Мурманск театрларының бер еллык планын ярты елда үтәгән иде. Гастрольләр вакытында да тамашачыны тетрәндергән спектакль һәрчак шушы булды. Хәзер менә Майкоп театрының директоры мине үзләренә дәшә. Ә мина инде—64. Бәлки, тагын бер җилпенеп алыргадыр, ә?! Әлбәттә "Белое платье" белән... Ә чәчәкләреңнең башка кулларга эләгүе, билгеле, әйбәт булмады. Ачыклап тормадым инде, бәйрәмдә[2] кәефләрен бозасым килмәде..."

[1] Рауза Уральская 1957 елда вафат.

[2] Майкоп театрының 50 еллык юбилее.

Әлеге чәчәк вакыйгасы, Суфия ханым, сезгә таныш түгелме?

—"Әни килде" драмасы башка телләргә дә тәрҗемә ителде һәм СССРның бик күп театрларында куелды. Шәриф спектакль барган шәһәрләрнең театр директорларына, яки "Хезмәт күрсәтү" бюроларына акча җибәрә, һәм Ана ролен башкаручы актрисага чәчәк алып тапшыруларын үтенә иде. Әлеге очракта яшь директор ялгышып, чәчәкләрне шундый ук фамилияле икенче берәүгә бирә... Хәтерлим, Шәриф бик кәефсезләнгән иде.

—Чәчәкләр дигәннән... Ленинградтан Евгения Лисецкая язган хатлар бик гыйбрәтле. Качалов театрына 50 ел гомерен багышлаган бу талантлы актриса "Әни килде" спектаклендә ("Белое платье матери") Ана ролен әзерли, әмма бу рольне башкаручы Валентина Павлова да, Людмила Маклакова да риза булмау сәбәпле, уйнау теләге хыял гына булып кала. Гомеренең соңгы 15 елын Евгения Владимировна Ленинградның картлар йортында уткәрә. Шул 15 ел дәвамында ул Шәриф белән хат алыша. Һәр хатын ул "добрый Шәриф", "дорогой Земляк", "шеф", "спонсор" кебек сүзләр белән башлый. Бер хатында посылка салуы өчен рәхмәтләр белдереп, "тәмле-тәмле ризыкларыңны, ул искиткеч чәк-чәкне койкадашларым белән бергәләп ашадык" дип, куануын белдерсә, икенче хатында "җибәргән акчаңны алдым; аякларым бөтенләй йөрмәгәч, улым каберенә бара алмый идем, рәхмәт яусын, такси ялларга да, чәчәкләр алып барырга да җитәчәк, әле артып та калачак; нинди ана тудырды икән сине, Шәриф, шушы хәтле шәфкатьле итеп", дисә, ә өченче бер хатында исә "даруларыңны алдым, шундый күп җибәргәнсең, "күршеләремә" дә өлеш чыгардым", дия-дия рәхмәтләр юллый... Лисецкая 80 яшендә 1997 елда вафат була. Шул елда Шәриф әфәндenең: "посылкаң кире кайтса, хатлар язар кешең дә булмаса..." диюе хәтердә.

Аның сәламәтлегенә бу актрисаның үлеме дә тәэсир итмәде микән? Сез ничек уйлыйсыз?

—Әни авыру сәбәпле, соңгы елларда Шәриф белән бик еш аралаша алмадым. Шулай да өлкәннәрне сыйларга кучтәнәчләрен күтәреп Буага[1] кайтып йөргәләгәнен беләм. Бик сизгер, нечкә күңелле иде шул ул. Бер нәрсә дә эзсез генә үтмәгәндер.

—Рөстәм Яхинның хатыны Хәлимә Таҗетдинова 1976 елның 16 ноябрендә Шәриф әфәндeнең ярдәм итүен үтенеп: "Рөстәм минем өчен кадерле кеше! Бала чагымда мин ул йөргән сукмаклардан йөрдем, үсмер елларым, һәм бөтен гомерем ана багышланды. Бакчамда мин аның исемен чәчәкләр белән яздым. Хәзер чебеннәр кебек аны хатыннар сырып алды. Ул инде ихтыяр көчен, талантын югалтып бара..." дип яза...

—О-о! Шәриф ул чакта... "Картаеп беткән Яхинны[2] бүлгәләргә тотындыгызмы? Моңынчы кайда идегез? Әнисен җирләгәч авырып бер ялгызы ятканда ник берегез дә күренмәде? Инде хәзер үзегезгә өйләнмәүнең үчен аласызмы?!"—дип, чын мәгънәсендә ул әлеге ханымнарга каршы сугыш ачты.

Һәм менә... гаҗәеп бер тәвәккәллек белән мин төп сорауларга күчәм.

—Архивта, шулай ук, Зөлфә Хәбибуллина хатлары да бар. Суфия ханым, сез аны белми идегезме?

—Зөлфәнеме? Беләм, билгеле. Ул да безнең институтны тәмамлады бит.

—Ә Рауза исеме таныш түгелме?

—Шул Рауза аркасында Шәриф белән Зөлфә арасындагы мәхәббәт чәлпәрәмә килде бит инде.

Катгыйлыгы белән хөкемдәй яңгыраган бу җаваптан мин өнсез калдым. (Белә идем бит инде, белә идем; шулай да табышларымның дөреслеген бу дәрәҗәдә үк

---

[1] "1929 елда Татарстанның Буа районы Өчмунча дигән авылында "кулаклыгыннан арындырып" ГПУ Тройкасы тарафыннан хөкем ителгән һәм Ак диңгез-Балтик каналын казырга сөрелгән Хөсәенов Нургали гаиләсендә төпчек бала булып туганмын.

1953 елда Казан медицина институтын тәмамлаганнан бирле Казанда дәвалаучы врач булып эшлим. 1959 елдан СССР Язучылар Союзы члены, 1960-62 елларда Мәскәү Әдәбият институты каршындагы Югары Әдәби курсларда укып чыктым". (Шәриф Хөсәеновның автобиографик белешмәсеннән.)

[2] Рөстәм Яхинга ул вакытта—55 яшь.

раслауны ишетергә әзер булмаганмын икән.) Менә ул—хакыйкать: Шәриф атлы егет солтанын буйдак калырга, гаярь ирне ялгыз яшәргә дучар итүче ике кеше—илаһи мәхәббәт иясе Зөлфә һәм бу мәхәббәтнең чәлпәрәмә килүенә сәбәпче, дөресрәге, күпмедер дәрәҗәдә катнашы булган Рауза. (Димәк... димәк, әдипнең "Мәхәббәт сагышы" әсәрендә Хәбир Сыртланов балетының төп каһарманын биегән балерина Хәлимә Баязитованың прототибы да—ул, Камал театрының талантлы артисты, Шәриф Хөсәеновның "Профессор кияве" спектаклендә баш рольдә уйнаган Рауза Уральская.)

...Башымда дулкын-дулкын булып "Шәриф белән Зөлфә арасындагы мәхәббәт", "Шәриф белән Зөлфә мәхәббәте чәлпәрәмә..." кебек уйлар йөгерешә. Ә йөрәктә... соклану һәм сагыш сулкылдый.

...И-и, мәхәббәт, мәхәббәт! Адәм баласын бөек эшләргә этәрүче—илаһи Мәхәббәт!..

Әйе, әйе, унсигез яшендә гашыйк булган Шәриф атлы чибәр егет тә бит сөйгән кызы Зөлфәнең игътибарын җәлеп итү өчен генә кулына каләм ала һәм... Камал театрын гына түгел, бөтен Казанны шаулаткан, алай гына да түгел, татар дөньясында вакыйгага әйләнгән "Профессор кияве"н иҗат итеп, легендар шәхескә әверелә. (Медицина институты студенты шундый пьеса язсын әле! Егерме ике яшьтә (!)—мәшһүр Камал театрын яуласын әле!)

... Һай, Зөлфә, Зөлфә!.. Татар дөньясында Шәриф Хөсәенов дигән үзгә бер драматург тууына сәбәпче туташ!..

Хәер, аннан соң да... Әйе, әйе, "Мәхәббәт сагышы" исемендә бөек Мәхәббәт повесте тууына да ул, ягъни Зөлфә сәбәпче бит инде. (Шәриф белән Зөлфә арасындагы илаһи мәхәббәт; Камал театрында—"Профессор кияве", һәм Шәрифнең данга күмелүе; аның спектакльдә героиняны уйнаган Рауза Уральская белән мавыгуы; Зөлфәнең кияүгә чыгып Ерак Көнчыгышка китеп баруы; 1956 елда кабат күрешүдән һәм аерылышудан тетрәнүләр; менә Рауза Уральскаяның үлеме өстәлү—болар барысы да повесть тууына китергән сәбәпләр. Әсәр 1958 елда языла.) Әйе, автор повестьта Мәдинә образы аша Зөлфәне, үзенең ана булган мәхәббәтен сурәтли. ("Үзем һәм Зөлфә язмышын, дөресрәге, язмышларның башын—Хәбир белән Мәдинә образлары аша мин бер сөйләдем инде".—Ш.Х.)

...Аһ, беләсе иде: Зөлфә ханым үзе бүген дә исән-саумы икән? Гомере буе Зөлфә исемен йөрәге түрендә йөрткән ("Кадерле кешеннең исемен кычкырып йөрмисең аны, ул йөрәктә саклана".—Ш.Х.), аның ике бөртек хатын шкафы түрендә саклаган, һәм шуның белән юанган кешене—Шәриф атлы гаярь затны... искә алгалый микән?..

...Минем уйларымны укыгандай, Суфия ханым өн сала: "Юк, Зөлфәнең бүгенге тормышы турында мәгълүматым юк минем. Зөлфә белән алай бик нык таныш түгел идем бит мин. Без төрле-төрле факультетларда укыдык. Шәриф тә шәхси тормышын ачарга бик ашыкмады. Без, институтны 1953 елда тәмамлаучылар, биш ел саен очрашу оештыра идек. Бу очрашуларга Шәриф йөрмәде. Берсендә Зөлфә яныма килеп, "очрашуга бөтен кеше дә килмәгән, ник икән",—диде. "Син тәгаен Шәриф турында сорыйсың",—дидем мин, ә аннары: "Күрәсең килсә—өенә бар".—дип киңәш бирдем. Менә шуны, ягъни Зөлфәнең кызыксынуын Шәрифкә әйткәч, ул "яраларны ачасым килми" дип, Зөлфә кияүгә киткәч тетрәнүен, Раузаның үлемен дә бик авыр кичерүен кыскача гына сөйләп бирде, һәм "алар икесе дә шушында" дип, миңа "Мәхәббәт сагышы" китабын бүләк итте..."

Суфия ханым тирән итеп сулады да, мине юатырга теләгәндәй, өстәп куйды: "Алар әле үз гомерләрендә тагын бер мәртәбә очрашалар. Шәриф белән Зөлфә турында әйтүем. Ленинградта. Хәрби медицина академиясенә белем күтәрү курсларына баргач.[1] Елын хәтерләмим инде..."

...Ленинградтагы ул очрашуның Шәриф күңелендә нинди давыллар кузгатуын,

---

[1] "СССРның оборона сәләтен армый-талмый ныгыту белән мәшгуль военкомат мине 1964 елның язында Ленинградтагы Хәрби медицина академиясенә җыемга җибәрсе итте". (Шәриф Хөсәеновның архивыннан.)

нинди яралар ачуын, йөрәк кылларының өзелергә житкән киеренке мизгелләрен—без инде беркайчан да белә алмабыз.

Шөкер, ул елларда әле аның үзен аталарча кайгыртучы остазы—мәшһүр режиссер Габдулла Юсуповның исән чагы. (Һай, Габдулла аганың ана язган хатлары! Шәкертенең пьеса арты пьеса язуын сорап, үтенеп, таләп итеп язылган ул хатлардагы жылылык һәм кайгырту!..)

Габдулла Юсупов фатихасы белән туган әсәрләргә генә күз салыйк: "Профессор кияве"—1951 елда, "Мәхәббәт сагышы"—1958 елда, "Зөбәйдә—адәм баласы", "Егерме ел үткәч"—1961 елда, "Әни килде", "Генеральная уборка" 1968 елда языла.

Әйе, ике дистәгә якын бәхетле ижат еллары!..

1969 елда Габдулла ага Юсупов вафат була. Һәм Шәриф Хөсәенов дигән талантлы язучының да ижат эше туктала.

Аның бу чордагы халәтен Тукаебызга мөрәжәгать итеп кенә аңларга мөмкиндер.

*Жир яшәрмәс, гөл ачылмас—төшми яңгыр тамчысы;*
*Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы...*

Нәкъ әнә шул чорда Шәриф әфәнденең кактус гөлләре үстерә башлавы билгеле. Зур югалтуларын, әрнү-сызлануларын, юксыну-сагышларын басу-жинеләйтү өчен үзе уйлап тапкан бер шөгыль булгандыр инде ул, мөгаен. Аның йомшак һәм романтик табигате дә шул елларда "үзгәрә"—чәнечкеле гөлләре кебек "энәләрен тырпайта" башлый. Бу—Марсель Сәлимжанов әйткәнчә, эчке халәтен яшерү өчен бер ширма булса, үзен яклау һәм саклану чарасы да булгандыр, дип уйлыйм мин.


*Хәрби курсларда.*

Үзен дә гөлләре белән чагыштырырга яраткан Хөсәеновның әлеге мавыгуы шул дәрәжәгә житә ки, аның фатирында 500 чүлмәктә 150 төр-сортта кактуслар үсүе хакында шәһәр "гөж" килә. Шәһәр генәме соң?! Кактус үстерү серләрен белешеп, үсентеләрен, орлыкларын сорап, СССРның төрле почмакларыннан аңа хатлар ява.

...Ижат эше туктала дисәм дә... ошбу хезмәтнең татлы да, газаплы да мизгелләрен искә төшереп, аның 50 яше якынлаша. Һәм Шәриф, дистә елдан соң, кулына янә каләмен ала.

1979 елда ул илне "чүп-чардан арындыру, тазарту зарурлыгы" идеясен салып, бер гаилә мисалында телевизион фильм өчен "Генеральная уборка"ның яңа вариантын эшли. Һәм шул ук елда, әсәр үзегенә "мәхәббәт изге хис, кеше гомеренә ул бер генә тапкыр бирелә, аңа хыянәт итүче нәфрәт дигән хөкемгә дучар ителә" кебек философик мәгънә белән, үзенең ялгызлыгына да киная булырдай "Мәхәббәт һәм нәфрәт" исеме куеп бер хикәя дә язып ташлый. ("Ташлый" дидем, чөнки хикәя ун ел үткәч кенә—1990 елда "Казан утлары" журналының февраль санында гына дөнья күрә.)

Билгеле, авторның бу әсәрләре ижаты башында язылганнарыннан нык аерыла. Чөнки инде боларны тормыш чынбарлыгына маңгае белән бәрелә-бәрелә жәрәхәтләнгән, әмма сатира-юмор хисен югалтмаган автор—чәнечкеле гөлләр үстерүче Шәриф Хөсәенов яза.

* * *

...Дистәләрчә китап герое булырлык галижәнап шәхеснең катлаулы тормышын бер язмада гына тулысынча сурәтләү—мөмкин түгел, билгеле. Әсәрләренә бәя бирүне дә мин үзмаксат итеп куймадым. Аларга бәяне халык үзе бирде. Аның ижат хәзинәсенә әдәбият галимнәребез дә битараф калмас, Аллаһы теләсә. Вә ләкин Шәрифнең: "И-и, Рәйсә, бу дөньяда—кем бәхетле инде?!" дигән сүзләре әледән-

әле күнелләә янарып, уйга сала, йөрәкне әрнетә икән, бу сорауга җавап табу кирәктер, мөгаен.

Чыннан да, бәхетле идеме соң ул—Шәриф атлы язучы?

Билгеле ки, тормышта шәхси бәхет булырга мөмкин, булмаска да мөмкин, һәрхәлдә ул кешенең үзе белән бергә бу фани дөньядан китә торган бәхет. Әмма аның кала торганы, үлгәннән соң да саклана торганы да була. Һәм менә мондые инде—исеме һәм эше белән халык күнелендә кала, халык хәтерендә саклана торганы—Шәриф язмышына тигән бәхет, үлемсез бәхет.

Шәриф Хөсәенов язмыш тарафыннан үзенә шундый бәхет әзерләнгәнен белеп, "Мин бәхетле, слушай, сәхнәдә тамашачым каршында, чәчәкләргә күмелеп китәм бит", дип, белгәнлеген әйтеп, халкы белән аягүрә хушлашып китте.

Шәрифтән соң үзе дә озак яшәмәгән, XX гасыр могиканнарының иң олпаты—Әмирхан ага Еники "Юбилей сабаклары" дигән соңгы язмаларында: "Шәриф Хөсәен бик үткен фикерле чын талант иде. Дөрес, безнең аралар шактый ерак булды, аның миңа мөнәсәбәтен дә мин ачык кына белмәдем, әмма минем өчен ул сугыштан соңгы драматурглар арасында иң көчлесе иде... Аның "Зөбәйдә—адәм баласы" һәм "Әни килде" драмалары иң беренче нәүбәттә "Тукай бүләге"нә лаек әсәрләр иде. Бу карашымны мин бервакытта да беркемнән дә яшермәдем... Бүләк алганнарның бик күбесе күптән инде онытылып бетте, ә Шәрифнең әнә шул әсәрләре чын мәгънәсендә үлемсез..."—дип язды.[1] Һәм шунда ук дәвам итеп: "Әсәрнең язмышын бүләк хәл итми, вакыт хәл итә. Ни өчен Тукайны онытмыйбыз, чөнки ул безгә бүген дә кирәк", дип, Шәриф Хөсәеновны бөек Тукаебызга тәңгәл куйды.

Гаҗәп, сүзләргә, гомумән һәр нәрсәгә сак килә торган Әмирхан ага музыка сәнгатендә Салих Сәйдәшне Тукай белән тиңләсә, әдәбият-театр дөньясында исә Шәриф Хөсәеновны шул ук "тәхеткә утыртты".

Күрәсең, бу шәхесләрнең язмышында да, иҗатында да ниндидер уртаклык, охшашлык барлыгын тойгандыр зыялы морзабыз.

* * *

...Минем шкафымда китаплар киштәсендә Шәриф әфәнде бүләк иткән китаплар да саклана. Алар арасында өч томда "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге" кебек академик басма да бар. Каләм эшем таләп иткәнчә, мин еш кына бу китапларны актарам, һәм актарган саен Аның исеменә юлыгам, җөмләләре белән очрашам. Менә ич—мин, дигәндәй, гасыр тәрәзәсе аша затлы да, саллы да, тирән мәгънәле дә чын татарча сүзләр белән Ул гүя бүген дә безгә—безнең күңелләргә дәшә.

*2004, октябрь.*

**<u>Автордан:</u>**

*Хөрмәтле Зөлфә ханым!*

*"Казан утлары" журналына адресыгызны әйтеп хат язсагыз, без Сезгә Шәриф Хөсәеновның "Зөлфәгә" дип аталган, 12 биттән торган шигыренең төп нөсхәсен җибәрер идек. Хатирәләр уртаклашуыгызны өмет итәбез.*

[1] "Юбилей сабаклары". 24 сентябрь, 1999 ел. "Мәдәни җомга".

Рашат
Низами

# КАЛӘМ АЛДЫМ КУЛЫМА...

ЭССЕ

(язучы хезмәте турында уйланулар)

## ИҖАТ ПРОЦЕССЫНЫҢ КАЙБЕР СЕРЛӘРЕ

*Ач сереңне, шигърият!*
Сажидә Сөләйманова.

Телиме-теләмиме, һәрбер әдип—үз заманының бер баласы, җәмгыять кыйпылчыгы. Шуңа күрә аның күп кенә язганнары, уйлану-борчылулары беренче чиратта үз заманына, үзе яшәгән вакытка барып тоташа. Малаймы, әллә кыз бала туачакмы—моның хикмәтен фәндә дә аңлатып бетерә алмыйлар әле. Иҗат эше дә әнә шуның шикеллерәк серле бер нәрсә.

**Туфан Миңнуллин:** *"Иҗат нәрсә ул дигән сорауга кешелек дөньясы күптән җавап эзли. Ләкин, белмим, төгәл җавап табылды микән? Ни ул мәхәббәт дигән сорауга да җавап юк бит. Иҗат ул, әлбәттә инде, рухи халәт. Иҗатчы буларак язучы да үзендә актарына, үзен аңларга тели. Аңлый алмагач, әсәрләре аша бүтәннәргә мөрәҗәгать итә, үзенә тәңгәллекне бүтәннәрдән эзли. Образлы фикер йөртү дигән нәрсә шулдыр инде ул. Әгәр әдәби әсәр язарга алынган берәү кеше күңеленең тибрәнешләренә диагноз куеп җавап бирергә тырыша икән, ул иҗатчы түгел. Йә ул фән кешесе яки шыр чыккан надан.*

*Язучының үзен иҗатыннан аерып карап булмыйдыр. Язучының рухи дөньясы, идеаллары әсәрләренең тукымасына салынгандыр. Әгәр аның рухы камил үк түгел икән, ул ничаклы яшерергә тырышса да, язганнарында сизелә. Күңелендә явызлык яткан кешенең миһербанлы, мәрхәмәтле әйбер язуына ышанмыйм мин.*

*Иҗат белән бәйләнгән бер сәер ягым бар минем. Үзем язган пьесалар буенча куелган спектакльләрне караганда автор икәнлегемне онытып куйгалыйм. Ошаган урыннарында шәп язган дип кул чабам, ошамаса, фикеремне кычкырып әйткәләп күршедә утыручы тамашачыны аптырашта калдырган чаклар да булгалады. Китап булып чыккан әйберләремне чит кешенеке кебек укый торган гадәтем дә бар. Гомумән, әсәрне язганда гына ул минеке, аннан соң минем аңа катнашым юк сыман. Яхшы гадәтме бу, начармы—белмим.*

*Иҗат процессы төрле язучының төрлечәдер инде. Һәркем үзенчә "акылдан яза". Мин язылася пьесам күңелдә язылып бетмичә өстәл янына утырмыйм. Язылып бетү дигән сүз һәр сүз, һәр җөмлә уйланган дигән сүз түгел. Язарга утыргач, төрле фикердәге, төрле холыктагы "кешеләрем" сөйләшә, яши башлый. Кайчак яңа персонажлар килеп кереп, әсәрдә үзләренә урын дәгъвалыйлар! Кайчак минем геройларым минем ихтыярга буйсынмыйча яши башлыйлар, мине тыңламыйлар.*

*Кайбер пьесаларны мин бер утыруда язам. Кайберләре еллар буена сузыла. Шагыйрь Хәсән Туфан турындагы "Агыла да болыт агыла" ун ел язылды.*

*Ахыры. Башы журналыбызның 1 санында.*

*Язучыны ялгышкан дип ачуланырга ярамыйдыр. Халтура язучы гына ялгышмый. Бервакытны берәү мине "Социалистик реализм" дип аталган ялган метод белән яза дип гаепләде. Ә мин, бичара, бернинди методны да белмим. Мин язам да язам гына. Күңелемдәгене язам, мең төрле сорауга җавап эзлим, бәхәсләшәм, шатланам, үпкәлим... Мин язганнарны методларга бүлгәләү тәнкыйтьчеләр эше."*

**Равил Фәйзуллин:** *"Бөек әсәрләрне—җырмы, көйме, рәсемме—исегезгә төшерегез—күбесен талантлы Шәхес ялгызлыкта—Дөнья белән бергә-бер калып, серле тынлыкта иҗат иткән бит! Әсәр туу—үзе бер тылсым! Аны, өстән яки кырыйдан әмер биреп кенә тудырып булмый. Андый очракта тудырганың да ясалма, гарип чыга. Попугайны нәрсәләрнедер кабатларга өйрәтә алсаң да, сандугачны көчләп сайратып булмый, бөркетнең канатларын сындырсаң да, күз карашын кисә алмассың. Иҗат—асылы белән иректә шөгыль. Иҗат ирегә диган гыйбарә тикмәгә генә тумаган!.."*

**Илдар Юзеев:** *"Бала чакта мин, шигырьләр язсам да, шагыйрь булуыма ышанмыйча, театр сәхнәсенә минү турында хыялландым. Үзем язган пьесаларда уйнап, сәхнәгә дә чыктым әле. Әмма мин барыбер профессиональ театр сәхнәсенә менәлмәдем, ул өлкәдә сәләт чамалы икәнне төшендем. Хыялыма ирешә алмасам да, мин күңелем белән артист, сүзләр артисты булып калдым. Шигъри сүзләрем белән мин Хәйретдин Мөҗәй кебек дөрләп утта да янам, Җәлил булып Мефистофель белән бәхәсләшәм дә, Ясминә булып кыр казлары артыннан талпынам да, күкрәге яраланган бөркет булып Күктән егылып төшәм, кирәк икән—маймылга, җенгә дә әйләнәм...*

*Илле еллык иҗат гомеремдә мин беркайчан да башка, йөрәккә ял бирмәдем, газета-журнал редакцияләрендә җаваплы сәркәтип, әдәби хезмәткәр булып, Язучылар берлегендә штатта торып эшләдем. Күпчелек язучыларның биографиясе журналистикага аерылгысыз бәйләнсә дә, беркайчан да аларны журналист буларак искә алмыйлар, язучы итеп кенә беләләр.*

*Илле ел штатта эшләү дәверендә мин беркайчан да иҗат итүдән туктамадым. Күпчелек әсәрләрем эштән соң яки бер айлык ял вакытында язылган.*

*Чыннан да, ничек түзә бу баш һәм йөрәк?!*
*Бәлки иҗат—тәнгә вә җанга үзе ялдыр...*

*Әсәр иҗат ителү мизгелләре—минем өчен дә аңлашылмый торган серле бер халәт. Материал инде табылган, әмма сюжеты, геройлары ачыкланмаган, башыңны түбән иеп йөрисең. Менә бер заман әсәргә ачкыч табасың, каләмгә тартыласың. Җирдәге ваклыклардан, кечкенә-зур мәшәкатьләрдән ычкынасың. Дөньяда синнән дә бәхетле кеше юк! Үзеңне намазлык өстендә утырып, Күк белән бәйләнешкә кергән изге зат итеп тоясың... Мондый халәттә урамга чыксаң, машина таптап китмәсен дип, куркып, сакланып йөрисең. Алла сакласын, башланган әсәрең тәмамланмый калса...*

*Әсәргә соңгы ноктаны кую—иң бәхетле мизгелдер. Әмма үзеңне бераздан бушап калган, иң якын дусларыңнан, сөйгән ярыңнан аерылган кебек, ямансу тоясың. Чөнки җаныңның яртысы геройларыңа күчкән".*

Үзеңне йә физик эшкә, йә иҗади эшкә җигү кешедән бик күп ихтыяр көче, рухи әзерлек, энергия көтә. Бальзакның көне-төне хөҗрәдә бикләнеп язып утыруы хакында әйтеп киткән идек инде. Бервакыт ул галлюцинация дәрәҗәсенә барып җитә... Якыннары баштарак Бальзакны аңламый торалар. Бактың исә ул, арлы-бирле йөренеп: "Мерзавец, күрсәтермен мин сиңа!"—дип үзенең тискәре бер героен сүгеп маташа икән. Г. Маркесның да иң яраткан баш герое үлгәннән соң ике сәгатьләп елап утыруы мәгълүм.

Тагын бер деталь. Әмирхан ага Еникинең: "Яңа язган әсәремне соңыннан укып чыгам да, боларны мин яздым микәнни?"—дип гаҗәпләнеп куям кайчакта. Чыннан да, иҗат процессында, кешенең индивидуальлегенә карап, әллә никадәрле серләр посып ята. Чыңгыз Айтматов нәрсә ди әнә: "Һәрбер китап белән үләргә һәм яңасын язар өчен өр-яңадан туарга кирәк безгә". Язучылык

хезмәтенең асылын ачып бирә торган бик тә хикмәтле сүзләр бу, миңа калса.

Яңа бер әсәр яки китап язар өчен өстәл-урындык, кәгазь-каләм генә җитми шул әле. Вакытны үзеңә буйсындыру, ихтыяр көче, үҗәтлек, үз-үзеңне мәҗбүр итә белү кебек сыйфатлар хәлиткеч роль уйный. Стефан Цвейг көненә 15әр сәгать эшләгән Бальзакны каторжникка тиңли. Джек Лондон һәркөн иртән язарга утыра һәм 1500 яки 2000 сүз язмыйча туктамый. Менә бу—ихтыяр көче!

Язучы, җәмәгать эшлеклесе Зөфәр Фәтхетдиновның болай дип әйткәне бар: "10-15 минут буш вакытым табылдымы, мин шундук язарга утырам, көндәлек дәфтәрләремдә чокына башлыйм". Бер халәттән икенче бер халәткә әнә шулай кинәт "бәреп" керә алу өчен аерым сәләт, фикер җитезлеге кирәк, әлбәттә.

Стивен Кит: "Язучы булыр өчен ике нәрсәне бик төгәл үтәргә—күп укырга һәм күп язарга кирәк",—ди.

Лев Толстой көндәлегендә болай дип язып калдырган: "Безнең эш бик хәтәр-авыр нәрсә, үзебездән башка моны берәү дә аңламастыр".

200дән артык роман яза алган Ж. Сименонны һич тә икеләнмичә легендар шәхес дип атарга мөмкин. Аның агач төребкәсе Сталинның агач төребкәсе кичергәннән күбрәкне кичермәде микән?

Жорж Сименон: "Минем биография хакында иллеләп китап (әсәр) язылды инде. Бу хакта мин үз вариантымны (!) тәкъдим итәргә булдым..." Көн саен 20 биттән дә ким язуны хурлык санаган бөек язучы әнә шулай дип белдерә, хәтта үзенең тәрҗемәи хәлен укучыга үзенчә аңлатмакчы.

Күп кенә әдипләргә хас булганча, аның да һәр нәрсәгә үзенчә бәясе-фикере бар. Италия журналисты 80 яшеннән узган Ж. Сименоннан сорый:

—Кайсы кыенрак: яшь булумы, карт булумы?

Картның берәүне дә кабатламый торган үзенчәлекле җавабы ишетелә:

—Боларны чагыштырып та булмый. Яшь булу кыенрак. Сайланасы, бик күп нәрсәләрне хәл итәсе бар: уку, эш, мәхәббәт, гаилә. Егерме яшь—тормышның иң фаҗигале чаклары дияр идем.

Толстойны хәтерлик. Үзендә дә, әсәрләрендә дә тормыш кыенлыклары, иҗтимагый активлык. Ул үзенең утарында мәктәп ача, балалар укыта, сука тотып яланаяк килеш җир сөрә... Һәммәсен үз күзләре белән күрәсе килә, тормышның яшерен дулкыннарын үз йөрәге аша кичерәсе килә, язарына азык эзли. Аңарда—гомере буе эчке көрәш, хакыйкать эзләү, һәм шушы барлык тартыш-омтылышлары әсәрләренә бәреп керә!

Минемчә, әдәбият—тормышны, дөньяны танып белүнең бер төре, кабатланмас ысулы ул. Кеше психологиясенең серләренә үтеп керергә тырышу. Юкса кеше, табигать, мәхәббәт турында күпме язылган! Иге-чиге юк әлеге дөньяны һәркем үзенчә кабул итә. Хакыйкатьне борынгы грек философлары да, гап-гади авыл агае да шактый дөрес аңлый, ләкин һәркем үз "аршыны" белән үлчи, әлбәттә.

"Мин эзләмим, мин табам",—ди Пикассо. Иҗат әһелләре, рәссамнар рухына шактый тәңгәл килә торган фикер бу.

Язучыларның күбесе иҗат хакына хәтта гаилә корудан да баш тарталар. Әйтик, Гоголь һәм Тукай...

Биредә контрастлар җитәрлек. 70 яшьлек Гёте картлыгында 17 яшьлек кызга үлеп гашыйк була. Ә инде Толстой, киресенчә, хатлар яза-яза, гомерлек хатынынннан ераклашуны, ялгызак сәфәргә чыгып китүне кулай саный...

Петрарка: "Мин яшәүдән туктаганнан соң гына язудан туктаячакмын".

Иҗат процессының кайбер серләре хакында сүз барганда Нурихан Фәттах шәхесенә аерым тукталмыйча булмас. Бәхеткә күрә дип әйтикме, Миргазиян Юныс "Мәгарә әдибе", Батулла "Кытыршы Нурихан", Туфан Миңнуллин "Киребеткән" дигән язмаларын көндәлек матбугатта бастырып өлгерделәр.

Өч әдип тә талантлы каләмдәшләре хакында мәкалә исемнәренең төгәллеге белән бөтен барлыкны ачып ташлаганнар. Шулай да, кайбер детальләргә игътибарны юнәлтәсе килә.

**Т.Миңнуллин:** *"Катгый режим, үз дөньясы белән яшәде. Еш кына без аның дөньяда барлыгын да оныта идек шикелле. Сәер тоелса да, ул Ходай биргән гомерен бары тик иҗатка, татар тарихына багышлады".*

**Роберт Батулла:** *"Кирелеге, принципиальлеге, үҗәтлеге, башбирмәслеге Фәттахның гәүдәсенә кире пропорциональ зурлыкта иде. Нурихан мәҗлесләргә атлыгып тормый, кунакка йөрергә яратмый. Чөнки ул аракы белән дус түгел иде.*

*Ул—милләтче түгел, ләкин милләт өчен җан атар. Казан кунакханәсенең түбәсенә "Казань" дип фәкать урысча язып элenгән була. "Ярар, татарчасын да эләрбез" дип тынычландырып җибәрәләр моны. Ремонттан соң "Казань" дип йомшаклык билгесе белән тагын ике урынга утлы язу-афиша элеп куялар. Түзми Фәттах, төнлә белән түбәгә менеп, бер яктагы нечкәлек билгесен каерып алып, ишегалды чүплегенә ыргытып китә. Шуннан бирле шәһәр уртасында саф татарча "Казан" сүзе дә яна башлый кичләрен.*

*Үзе әче телле тәнкыйтьче булып та, Н.Фәттах үзе тарафына әйтелгән тәнкыйтьне кичерә алмый иде. Үзенең кытыршы холкы аркасында, ул үз йортына, үз-үзенә һаман саен ныграк бикләнде".*

Язучының хатыны Руфина ханым да нәкъ менә шуларны раслый. "Нурихан абыйны бит ялгызлык, тынычлык ярата торган кеше диләр, чыннан да шулаймы", диган сорауга ул:

—Әйе, шау-шулы компанияләрне яратмады. Яшьтән үк безнең кунакка йөрешә торган берничә генә бөртек гаилә дусларыбыз бар иде.

Кыскасы, иҗат эшенең, иҗади процессларның сере шактый дәрәҗәдә индивидуальлеккә дә бәйле. Язучы шәхесе артында катлаулы, гамьле, давыллы эчке дөнья яшеренгән. Хәтта моны ул үзе дә белеп бетермәскә мөмкин. Реаль тормыш канат очы белән кагылып кына китсен, болар бар да берьюлы хәрәкәткә килә, кулга кәгазь-каләм сорый башлый. Язучы үзе каршында, һичшиксез, үзенең укучысын күрә-тоемлый, аның белән сөйләшә, киңәш-табыш итә. Чиләгенә күрә капкачы дигәндәй, авторына, аның тормыш-әхлак тәҗрибәсенә карап дөньяга өр-яңа әдәби әсәрләр туа. Калганын вакыт, заман иләге хәл итә.

Аңлашылса кирәк, язучы үзе өчен дә икенче яктан, язасы әсәре өчен дә һәрвакыт йөрәк маен түгеп яши.

## ӘМИРХАН ЕНИКИДӘ КУНАКТА

Студент чагым, иҗат эшенә бик нык тартылган вакытлар. Яраткан язучым Әмирхан ага Еникинең хикәяләрен укыйм да таң калам: ничек шулкадәр матур, сыгылмалы, саф татарча мөкәммәл тел белән язарга һәм сине әсир итәрдәй могҗизалар тудырырга мөмкин.

Иҗат эше серләренә омтылышым гаять көчле булганга күрә, тере язучы белән очрашасы, әңгәмәләшәсе бик тә килә иде. Андый форсат әлекте миңа. Архивымны барлап утырганда 1976 елны ук үткәрелгән шушы әңгәмә килеп чыккач, мин түшәмгә сикерердәй булдым! Чөнки, моннан 28 ел элек язылуына карамастан, андагы фикерләр тамчы да искермәгән һәм алар яшь каләм ияләре өчен иҗади бер остаханә булып тора дияргә мөмкин.

Шунысы кызганыч, ул чакта минем тормыш һәм иҗади тәҗрибәм аз булган. Аннары, совет цензурасының аяусызлыгыннан шикләнеп булса кирәк, икебез дә үткен мәсьәләләрдән качарга тырышканбыз шикелле... Хәер, әңгәмә үзе күп нәрсәләрне аңлатып бирер.

* * *

*Персонаж дәрәҗәсенә күтәрелгән идея—*
*бу инде югарырак сәнгать.*

Бальзак.

Минем өчен әсәрнең баш герое—язучы үзе, дип алдарак әйттем шикелле. Бу хакта Рафаэль Мостафинның кызыклы гына фикере бар: "Әдәби персонажлар тере һәм тулы канлы булсын өчен, язучы үз-үзен бүлгәли, ул үзендәге ниндидер сыйфатларны геройларына бирергә тиеш. Автор үз күңеленең, җаны-

ның ниндидер өлешен геройларына бирә алганда гына образлар ышандырырлык була".

Ә тискәре персонажлар? Автор аларга да җанының ниндидер өлешен бүлеп бирә микәнни? Минемчә, монда инде күңел почмагындагы икенче бер фактор—нәфрәт килеп керә торгандыр. Язучы күңелендә гаять күп төрле психологик тибрәнешләр хәзинәсе посып ята.

Әйе, теләсә нинди әсәр артында авторның күңел байлыгы, уйланулары, шатлык һәм газаплары ята: язучы кеше үзенең шәхесен иҗат белән раслап бирергә тиеш. Әмирхан ага Еники белән очрашкан вакытларда мин еш кына әнә шулар хакында уйландым.

Әмирхан ага Еники әдәбиятка шома юлдан гына килеп керми. Чын-чынлап язучылык эшенә керешкәндә аңа инде кырык яшьләр тирәсе була. Аның турында "аз яза, акрын яза", диләр. Ләкин хикмәт санда, акрын язуда түгел ич. Әдәби әсәрнең кыйммәте беренче чиратта сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе, икенче төрле әйткәндә, сыйфат дәрәҗәсе белән үлчәнә. Бу яктан мин Әмирхан аганы бәхетле язучы дияр идем. Китапларының укучы кулыннан төшми укылуы, минемчә, иң югары бәя ул.

Иҗат эшенә чагыштырмача соңрак тотынуга карамастан, Әмирхан ага татар әдәбиятына дистәләгән повесть һәм хикәяләр биргән кеше. Үзенең стиле, нәфис теле, психологик тирәнлеге һәм куелган проблемаларының кыю хәл ителүе белән аерылып торган бу әсәрләр хаклы рәвештә әдәбиятыбызда үз урыннарын таптылар. Әмирхан аганы кайта-кайта укыйсың, аның хикәя һәм повестьлары беркайчан искерми, туйдырмый. Укыган саен уйландыра, һаман саен ниндидер мәгънә табасың.

Әмирхан Еники иҗаты—бер-берсен кабатламый торган күптөрле образлар галереясы ул. Менә "Тауларга карап" хикәясендәге "яшеннәрдән, давыллардан сынмаган Локман карт..." яки "Әйтелмәгән васыять"тәге "әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөзьяшәр Миңлебай карт!" Ә инде Акъәбине искә төшерсәк, бу башкорт корткасының язмышы кемнең генә күңелен телеп алмас икән! Үлем түшәгендә ятучы карчык түгел, киресенчә, әнкәләренең күңелен аңламаучы "дәү" балалар кызганыч булып тоела башлый. Тагын күпмедер яшәргә, газиз балаларына әйтелмәгән васыятен әйтергә тиеш иде бит бу карчык! Әсәр әнә шундый кешелекле идея белән сугарылган. Балалары һәм оныклары өчен йөрәген бишкә бүләргә әзер торучы соклангыч Акъәби... Бер Америка журналисты, безнең илдә әнә шундый әбиләрне очраткач, шакката һәм бу хакта үзләренең газетасында язып чыга.

Әмирхан ага "Рәшә" дигән повестенда Зөфәр Сабитов кебек катлаулы социаль типны да "ачкан" кеше. Кыюлык булмауданмы, әллә көч җитмәүдәнме шикләнделәр—бездә әле андый типларны күрсәтү юк дәрәҗәсендә иде. Хәлбуки, максатым язучы тудырган образларны барлап чыгу түгел, ә бәлки иҗатындагы кайбер үзенчәлекләргә тукталу иде ләбаса.

Әмирхан ага хикәяләрен моңсу хикәяләр дияр идем мин. Аларда тел белән аңлатып булмый торган ниндидер моң, серлелек бар. Моны бары укыганда тоярга мөмкин. Ничектер, сизми дә каласың, ул үзе күңелгә саркып керә, бар куәтенә әләктереп ала. Кайчак хикәяләргә кушылып елыйсы, бушанасы килә башлый.

Нәрсәдә соң тәэсир итү көче? Ни өчен битараф калып булмый? Моның сәбәбен хикәяләрнең үзеннән эзләргә кирәктер. Моңсулык—җан хәрәкәте ул. Моңсу әйберләрдә беркайчан да ялган, фальш булмый. Ә аннары язучының сүзләрдән могҗиза ясый алуын кая куясың! Әсир итүнең тагын бер хикмәте телдә түгел микән? Әмирхан ага телебездәге сүзләрнең чагыштырма авырлыгын, төсен, тәмен, бизәкләрен гаять нечкә сиземли торган язучыларыбызның берседер.

Никадәрле образлар, күпме кичерешләр, күпме рухи байлык!. Әйткәнемчә, болар берсе дә күктән төшмәгән, алар иң элек язучының йөрәк кырында бөреләнеп, аннан соң гына чиста кәгазь битенә күчкәннәр. Шуңа күрә язучы шәхесе—минем өчен үзгә шәхес.

...Без Әмирхан аганың өендә, дөресрәге, эш бүлмәсендә сөйләшеп утыра-

быз. Ул ашыкмый гына, һәр сүзнең тәмен белеп кенә сөйли (миңа язганда да шулай язадыр кебек тоела). Кайвакыт сирәкләнгән һәм чалара төшкән чәчләрен артка сыйпап куя. Аның язу өстәле пөхтә җыештырылган, артык әйберләр күренми. Бер як читтә чип-чиста кәгазь битләре, арырак тәмәке көле савыты. Безнең арада сүз, нигездә, тормыш һәм иҗат турында бара.

—Әмирхан ага, сезне каләмгә, иҗат эшенә нәрсә этәрде икән? Бу хакта уйлап караганыгыз бармы?

Ул, гадәтенчә аз гына уйланып торганнан соң, сүзен башлый:

—Иҗатка тотынуым әдәбиятны бик яратканга күрә булгандыр инде. Татар язучыларын бик яратып укыдым. Шуның тәэсирендә үземдә дә нәрсәдер язып карау теләге тугандыр дип уйлыйм...

—Минем биография хакында күп уйлаганым бар. Язучының язмышын билгеләүче фактор түгел микән ул?

—Биография... язучы таланты—катлаулы күренеш. Аның серләре әлегәчә ачылып беткәне юк. Хикмәт биографиядә генә түгел. Дөньяны аркылыга-буйга йөреп тә, берни язалмаска мөмкин. Дөньяны гизмичә генә дә яхшы әйбер язарга була. Әдәбият тарихында моның мисаллары бар.

—Ә күңел биографиясе?..

—Менә монысы инде икенче нәрсә... Күңелнең нечкәлеге, тирәнлеге тумыштан билгеләнә. Аннары, хыяллана белү, хыялга бирелү дигән нәрсә дә бар. Төрле кешедә төрлечә. Берәү хыялланганнарын оста иттереп сөйли ала. Әкиятләр чыгару да шуның галәмәте. Икенче берәү исә әчтән хыялланырга ярата. Мин соңгысына керәмдер, ахрысы. Язучылар бу җәһәттән бер-берсеннән нык аерыла. Әйтик, фантастик яки мажаралы әсәрләр язучыда хыял, әлбәттә, көчлерәк булырга тиеш. Инде дәһи язучыларга килсәк, мәсәлән, Гоголь белән Достоевскийда хыял искиткеч бай һәм тирән булган.

Креслосына иелә төшеп утырган Әмирхан ага мавыктыргыч, җанлы итеп сөйли. Сөйләгәндә ул хәрәкәтләр ясамый диярлек. Бары тик ара-тирә сигаретының көлен генә каккалап куя. Бу кулларның берсендә мөштек булса, икенчесендә күпвакыт каләм була торгандыр, дип уйлыйм үзалдыма.

—Әмирхан ага, әйтегез әле, иҗаттан башка яши алыр идегезме?

—Яшәп булмас кебек. Канга сеңгән... Холыкка, гадәткә.

—Язучының язудан туйган, гаҗиз булган чаклары да була торгандыр бит.

—Төрле вакыт була. Бер әйбер язгач, бушап калганлык сизелә... Туктап та торасың. Мин шундук икенчесенә тотына алмыйм. Гаделсез мөнәсәбәтләр аркасында "бизеп тору" да булырга мөмкин. Бәхеткә каршы, үтеп китә торган вакытлы күренеш.

Игътибар белән карасаң, Әмирхан аганың йөзендә, күзләрендә ирләрчә бер моңсулык, уйчанлык бар. Мин, үземдәге тарсынуны җиңеп, сүзне әнә шул якка борырга тырышам.

—Сездә моңсу хикәяләр. Үзегездәге моңсулыкны ни белән аңлатасыз?

—Моның тирән сәбәпләре бар, әлбәттә. Тумыштан моңлы булу нәтиҗәсе генә түгел бу. Мин, сәүдәгәр баласы буларак, 15-16 яшемдә типкенгә очраган кеше. Настроение тормыш белән бик нык бәйле бит ул... Шулай да моң күбрәк туган җиремнән күчкәндер. Дим буенда үстем, мин яшәгән ил-җир, авыл, табигать бик матур иде. Бездә, Каргалы авылында, җыр бик күп. Атай мәрхүм дә оста җырлый иде. Җырны үзем дә бик яратам.

—Тормыштагы кеше күзе "ияләшкән" вакыйгаларны ачу өчен язучыга нәрсә кирәк дип саныйсыз?

Әмирхан ага сүзен сорауга каршы сорау белән башлады:

—Иҗат нәрсәдән башлана?.. Ишеткән-күргәннән. Яки хыялда кызыклы бер нәрсә туа. Шуның берәр ягы сине уйландыра, дулкынландыра. Орлыгын табасың, нинди дер мәгънә күрәсең һәм шуның өчен генә дә язу теләге туа. Чөнки мәгънә бар—ачасы килә. "Бер генә сәгатькә", "Матурлык", "Кем җырлады" һәм башка хикәяләр—болар бар да күргән-ишеткәннән туган әйберләр.

—Әмирхан ага, уйлаганыгыз бармы, язу өстәле артына сезне нәрсә утырта: ихтыяр көчеме, әллә язмый торып тынычланмаумы?

—Дөресен әйткәндә, күбрәк үз-үзеңне мәҗбүр итү утырта. Чөнки язарга

утырганнан соң гына теләк кузгалып китә, дәрт уяна. Башта кайчак утыра алмый азапланасың, сузасың... Шуны әйтәсем килә: әгәр ихтыяр көче дигән нәрсә җитмәсә, язучы туа да алмас иде. Әгәр бу эш җиңел эшләнә торган булса, язучылар буа буарлык булыр иде. Хәтта хат язар өчен дә ихтыяр көче кирәк.

—Тагын бер сорау. Күп кенә язучылар сәнгатьчә шартлылык ярдәмендә эффект тудырырга омтылалар һәм, әйтергә кирәк, максатларына ирешәләр дә. Ә менә сез сәнгатьчә шартлылыкка бөтенләй мөрәҗәгать итмисез диярлек. Бу аңлы рәвештә качуыгыз түгелме?

—Юк. Бу үзе шулай килеп чыга. Мин табигыйлекне яратам, ясамаска тырышам. Ләкин табигыйлекне натурализм белән бутамаска кирәк. Язучының иң зур осталыгы, минемчә, тормыш материалыннан иң кирәген генә сайлап алуда һәм шуны табигый, ышандырырлык итеп бирә белүдә.

—Һәр язучының бер остазы, укытучысы була. Сезнең бармы, кем ул?

—Берәүне генә атап күрсәтергә кыенсынам. Мин татар әдәбияты үрнәкләрен укып үскән кеше. Иске әдәбиятны да шактый укыдым... Язучылыкның тамырын беренче чиратта әнә шулардан эзләргә кирәктер инде. Шуның өстенә, шәһәргә килгәч, рус әдәбиятын да шактый укыдым. Иң нык тәэсир иткәне Чехов булды. Аны кайчак хәзер дә кулыма еш алам. 18-19 яшьләремдә Достоевский белән мавыктым, "авырдым" дияргә ярый.

Минем хикәя остасыннан иҗат процессының кайбер серләре турында да сөйләттерәсем килә:

—Әсәр язганда каршыгызда кырыс укучы басып торамы, әллә фәкать геройлар арасына күмеләсезме?

—Тегесе дә, бусы да түгел дип әйтер идем. Укучыны, әлбәттә, истә тотам. Ләкин ул минем өстән контрольлек итми. Язганым барып җитәрме, кабул итәрме—әнә шул яктан истә тотам. Героема килсәк, ул бер тере кеше, мин аны шул килеш укучыга бирергә тырышам.

—Иҗат иткәндә "салкын кан" белән язасызмы, әллә бик нык күңелдән кичерепме?

—Нигездә "салкын кан" белән язам дип уйлыйм, үз хисләремне кушмыйчарак, аларны мөмкин кадәр тыебрак язарга тырышам. Чеховның кызыклы сүзләре бар: "Кешене елатасың килсә, үзең елама, кешене көлдерәсең килсә, үзең көлмә",—ди ул. Мин моның белән килешәм... Язып бетергәч, укып карыйм да кайчак үзем дә әсәрләнеп китәм... Хәтта күз яше бәреп чыккан вакытлар да була.

—Әдәбиятта бик күп әйберләр язылды, әле дә языла тора. Сез ничек уйлыйсыз, киләчәктә темага кытлык булмасмы?

—Тормышның үзендә темалар бетмәячәк. Тормышта алар тулып ята, дәрья кадәр. Ләкин әдәбият берьяклырак китсә, үзенең максатларын чикли башласа, теманың да чикләнүе мөмкин. Тормыш бит үзенчә яши, объектив яши. Анда темалар, конфликтлар беркайчан да бетми, таба белергә генә кирәк.

Алга таба сүз хикәя жанры турында барды. Мин үз чиратымда бездә повесть-романнарның күп булуы, ә хикәяләрнең киресенчә аз күренүеннән зарландым. Бәлки, хикәя жанрының авыр булуыннан киләдер бу?

—Аның асылда берсе дә җиңел түгел,—дип сүзгә кушылды Әмирхан ага.— Хикәя язу зур осталык таләп итә. Хикәяче тормышны бик нык белергә тиеш. Бик үткен күз кирәк, вакыйганы тотып ала белү кирәк. Хикәядә мәгънә булырга тиеш. Хикәя аша романдагы мәгънәне бирергә мөмкин. Яхшы хикәяләренең азлыгы тормышны сай белүдә, кечкенә нәрсәдән олы мәгънә таба алмаудадыр дип уйлыйм мин. Чехов әнә вак кына нәрсәләрдә дә мәгънә күрә белгән. Шуның белән үлемсез Чехов булып калды да ул.

—Поэзияне яратасызмы?

—Яратам, укыйм.

—Бездә поэзия яки проза алда дип сөйләүчеләр күренгәләде. Сезнеңчә, болай дип әйтү дөресме?

—Кемдер боларны чагыштырып карый икән, дөрес түгел дип исәплим. Сан ягыннан, әлбәттә, шигырьләр күп языла. Ләкин сыйфат ягын да искә алырга кирәк. Мин үзем прозаны артта димәс идем.

—Сез талант төшенчәсен ничегрәк аңлыйсыз?

—Моны билгеләү безнең кулдан килә торган эш түгел. Бер генә нәрсә әйтә алам: аның оясы баш миендә булса кирәк. Берәр нәрсә әйбәт язылса, талант нәтиҗәсе дибез. Бүтәнчә әйтергә кыенсынам.

—Әмирхан ага, хәзерге әдәбиятта даһилар аз булуын ни белән аңлатырга? Тизлекләр чорында яшибез бит. Бәлки язучы тормышны куып җитәргә өлгермидер?

—Хикмәт тормышның тизлегендә, кызулыгында түгел. Минемчә, төп сәбәп бүтәндә. Даһи ул күп хакыйкатькә үз акылы белән ирешә, үзе ача. Ә без әзер хакыйкатьләр белән яшибез, бу заман өчен табигый. Бара торган юл сызылган, кыйбла, сәясәт билгеле. Үзебезгә хакыйкатьләр ачуның кирәге юк шикелле. Ә менә фәндә ни дә булса ачарга мөмкин. Ләкин хәзер фәндә дә ачышны аерым кешеләр түгел, коллектив белән ясыйлар, бу да кызыклы. Әдәбиятта хәзер нинди дә булса яңа хакыйкать әйтү шактый читен эш.

—Хәзерге заманның иң актуаль проблемалары дип нәрсәне әйтер идегез?

—Миңа калса, кеше тәрбияләү. Яхшы кешеләр кирәк, шунсыз яхшы җәмгыять тудырып булмаячак. Андый кешене тәрбияләргә кирәк. Моны әдәбият та башкара. Безгә үгет-нәсихәт түгел, уйларга мәҗбүр итү, уйларга өйрәтү кирәк. Аның өчен уйландыра торган әсәрләр язарга кирәк. Ә инде уйландыра торган әйберләр язу өчен тормышны бөтен катлаулылыгы белән күрсәтү, конфликтлардан качмау, курыкмыйча язу кирәктер дип саныйм.

—Хәтерлисездер, сезнең йөзъяшәр Миңлебай карт, самолеттан бүре атып йөрүчеләр турында ишеткәч, болай ди: "Моның ни кызыгы да, ни комарлыгы бар? Юк, әллә нишләде замана! Машина да машина, ә кешенең үз йөрәгенә, үз кулына ни кала?!"

Чыннан да, уйлап карасак, хәзерге кешегә бөтенесе әзер. Сез аны ялкаулыкта гаепләргә җыенмыйсызмы?

Әмирхан ага үзе дә сөйләшүгә шулкадәр бирелгән, хәтта тәмәкесенең фильтр төпчегенә җитеп, сүнеп калуын да сизми утыра икән... Ул салмак хәрәкәтләр белән икенчесен кабыза башлады.

—Бирелә "ялкаулык" дигән сүз туры килеп бетми кебек. Чыннан да, эшне ансатлаштырдылар хәзер, табигый күренеш. Бүрене ат өстендә килеш сугу өчен кыюлык, батырлык, зирәклек таләп ителә. Ә вертолеттан сугу өчен боларның берсе дә кирәкми—чөнки хәтәр юк, кеше бүрегә якын да килми. Монда сунарчылык ләззәте күренми. Бүре кебек ерткыч белән күзгә-күз очрашу кызыклырак. Бергә-бер булганда ихтыяр көче, җитезлек, өлгерлек тә ачыла...

—Буш вакытыгыз бармы? Аны ничек үткәрәсез?

—Буш вакыт күп миндә. Мин алай көне-төне язып утыра алмыйм. Ничектер гадәткә кергән: эшләсәм көннең беренче яртысында дүрт-биш сәгать эшләп алам. Төштән соң һавага чыгам, укыштыргалыйм.

—Сезнең "хобби"?

—Анысын юк дияргә була.

—Иң яраткан ризыгыгыз?

Бу сорау сирәк елмая торган Әмирхан аганы елмайтып ук җибәрде.

—Мин үзем талымлап тора торган кеше түгел. Балачактан бирле катыкны яратып ашыйм. Хәзер дә аерылган юк.

Әмирхан ага белән күп тапкыр очрашканым, сөйләшкәнем бар. Беренче очрашу аеруча хәтеремдә. Китап кибетендә таныштык. Минем беренче хикәяләрем турында "тере" язучының үз авызыннан бәя, киңәш, сүз ишетәсем килә. Ул язмаларымны карап чыгарга, үзенең фикерләрен әйтергә ризалык белдерде. Шунда "Вакытым юк бит, энекәш", дип әйтсә дә, бер чара юк иде. Алай димәде, олы башын кече итеп дигәндәй, сөйләшер вакыт тапты. "Язучы булыр өчен күп укырга, күп эшләргә кирәк",—дигән гади, әмма бик тә мәгънәле сүзләре исемдә калган.

Әмирхан ага мине беренче күрүдә үк инде үзенең гадилеге, киң күңелле һәм игътибарлы булуы белән сокландырган иде. Аңарда һавалану, тәкәбберләнү, эрәю, масаюның эзе дә юк. Чыннан да, үзендәге бик күп гүзәл сыйфатларны үзенең геройларына тамчылап өләшкән, тараткан ул. Тыштан

болай гаҗәеп сабыр, тыныч, салмак күренсә дә, мин аны андый димәс идем. Геройлар кичергән халәт, психологик тибрәнешләр, шатлыклар һәм борчулар—болар бар да авторның йөрәгеннән саркып чыккан нәрсәләр. Әмирхан ага турында Леон Вертның сүзләре белән "иң сабыр һәм иң тынгысыз кеше" дип әйтәсе килә.

"Астроном өчен йолдыз никадәрле кирәк булса, үзләрен тормышны өйрәнүгә багышлаучылар өчен мин дә нәкъ шулай кирәкле". Монысын Чехов әйткән. Әгәр Әмирхан ага бу сүзләрне үзалдына кабатлый икән, мин моңарда бернинди мактану күрмәс идем. Чөнки язучының бөтен иҗаты, персонажлары безне тормышның иң тирән, иң серле һәм иң нечкә катламнарына алып керә, андагы мәхәббәт һәм нәфрәтне, матурлыкны тоярга ярдәм итә.

## ВАТАНЫҢНЫ... ЭЗЛӘП КИЛГӘНДӘ

*Һәрбер кабер ташы астында*
*Дөнья хәтле тарих посып ята.*

Гёте.

Кеше һәм җәмгыять меңнәрчә җепләр белән бер-берсенә бәйләнгән. Язучы шәхесе белән бу бигрәк тә шулай. Беренче тапкыр тәпи атлап китүләр, Кояш һәм Айны күреп гаҗәпләнүләр, өлкәннәрдән һәм әби-бабайлардан ишеткән сүзләр, табигать һәм аның фасылларына бәйле күренешләр, үсә төшкәч, мәхәббәт, кешеара мөнәсәбәтләр кешене гомер буе чарлый, озата килә.

Талант тумыштан бирелә, дидек. Ләкин аны кер кундырмый кадерләп сакларга, үстерергә, баетырга, кешеләр һәм җәмгыять файдасы өчен дөрес эзгә юнәлтергә, тиешле нәтиҗә белән җавап бирерлек хәлгә китерергә кирәк. Булачак язучы һәм аның язмышы өчен болар—бик тә мөһим нәрсәләр.

**Ренат Харис:** *"Иҗатчы буласы кеше "кирәгенә күрә ярагы" (на спрос и предложение) дигән иҗади этәргечне, үзенең кирәклеген тоярга сәләтле булырга тиеш. Бу сәләт аңа геннар аша бирелергә дә, тәрбия аша килергә дә мөмкин дип уйлыйм. Сәләтеңне үстерү йә үтерү—инде мәсьәләләрнең дә мәсьәләсе!.."*

Әдипнең үзе яшәп яткан җәмгыять белән бәйланышы—шулай ук колоссаль фактор! Есенин "Ватанымны эзлим..."—ди әнә. Некрасов исә, шушы темага кагылганда, аңардан да уздырыбрак, усалрак итеп әйтә: "Предмет югарырак булган саен, син аңарда йә яңача ачыласың яки, киресенчә, талантсыз икәнеңне күрсәтәсең".

Язучының "мин"е (шәхесе) халык масштаблары зурлыгына күтәрелгәндә генә әдәби әсәр тирән, колачлы һәм искерми торган була. Пушкин үлгәннән соң Достоевский: "Ул үзе кинәт халыкка әверелде",—ди. Татар әдипләреннән Ә.Еники, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев турында да әнә шулайрак әйтеп булыр иде, минемчә.

Әйе, һәр язучының язганы артында аның күрер күзгә күренмәс шәхесе ярылып ята. Аның исеме—коры "мин" генә түгел әле. Моның артында—социаль-иҗтимагый шартлар, фәлсәфи-психологик педагогика, җәмгыятьнең гасырлар буе җыйналып килгән һәм рухи, һәм тарихи тәҗрибәсе ята.

Язучы физик яктан гына җәмгыять баласы, кирәксә һәм көче җитсә, ул җәмгыятьне дер селкетә ала!

Сәгать уклары һәрчак алга бара. Язучы да иҗатында әнә шулай булырга тиеш. Бер адым алданрак барган очракта гына ул тормыштагы тектоник тетрәнүләрне сиземли ала, прогноз ясисә художестволы анализ ясый.

XIX гасырда ике китап кешелеккә чын-чынлап тарихи йогынты ясады: Бичер Стоуның "Том агай алачыгы" романы Америкада коллыкны юкка чыгаруда искиткеч роль уйный. Ә инде Чернышевскийның Шлиссельбург төрмәсендә ике ел чамасы язган "Нәрсә эшләргә?" романы черек Россияне айкап ташлады, кешеләрне революция юлына этәрде.

Гүя вакыт үз чоры, заманы, үткен проблемалары турында сөйләтер өчен әдәбият даһиларын тарих сәхнәсенә калкытып чыгаргандыр шикелле: "Сөйлә, Пушкин, Толстой... сөйлә, Тукай, Җәлил..."

Достоевский турыдан-туры әйтә: "Әгәр мине үлемгә хөкем итмәсәләр, аннары бу карарны каторга һәм сөргенгә алмаштырмасалар, мин күп әсәрләремне язалмый калган булыр идем".

Ул төрмә-сөрген дигәннәре безнең татар әдипләрен дә читләп узмады. Кәрим Тинчурин, Шамил Госманов, Фатих Кәрим, Фәтхи Бурнаш, Мирсәй Әмир, Ибраһим Салахов, Аяз Гыйләҗев, Гурий Тавлин... Санап бетерерлек кенәм түгел!

Уйлап карасаң, алар ни сөйләмәс, ни язмас иделәр! Исән кайта алган Хәсән Туфан ул 16 ел буе күргәннәре хакында үзе язса, без никадәр тулырак, дөресрәк мәгълүмат алган булыр идек...

Ярый әле Рафаэль Мостафин һәм Газиз Кашапов аның турында укучыга байтак гыйбрәтле язмаларын матбугатта чыгарып өлгерделәр. Рәхмәт үзләренә!

Аяз Гыйләҗевнең, Хәсән Туфанның, Ибраһим Салахов һ.б. төрмә шулпасын "татып" чыгулары аларның иҗатына йогынты ясадымы? Һичшиксез, ясады! Әдәби әсәрләрен мисалга китереп укучыны ялыктырасы килми. Тик алар арасында А.Гыйләҗевнең хөкүмәткә, җәмгыятькә карата оппозициягә басуы аеруча күзгә ташлана иде. Бу очракта аның "Балта кем кулында" романын әйтеп китү дә бик җитә.

**Ренат Харис:** *"Әдәбият сөючеләр белән очрашулар вакытында еш кына автор һәм аның персонажлары турында сораулар ишетергә туры килә: әсәрнең герое рухи яктан автордан өстенрәк була аламы, автор тормышта—бер, ә иҗатта бөтенләй икенче кеше булып яшиме һәм башкалар...*

*Бу сораудан "Язучы" дигән биеклеккә күтәрелгән автор, әлбәттә, үзенең персонажларыннан бик күп ягы белән өстенрәк була",—дип җавап биреп тә котылып булыр иде. Чынлап та, минем фантазиям җимеше генә булып туган персонаж ничек инде миннән акыллырак, кыюрак, булдыклырак була алсын—ул бит, ахыр чиктә, минем акылымның бер бәләкәй кыйпылчыгы гына! Андый персонажлар бер әсәрдә дистәләгән булырга мөмкин, һәм иҗат гомерендә язучының дистәләгән күпперсонажлы әсәр иҗат иткәнен дә онытмаска кирәк. Алмагачның бер ботагы бөтен алмагачтан баерак булуы мөмкинме? Ләкин, әйтик, Җ. Тәрҗемановның "Көмеш дага" романындагы Лобачевский роман авторыннан "акыллыракмы"? Муса Җәлил турында поэмалар, романнар язган авторлар рухи яктан үз персонажларыннан өстенрәкләрме? Йә булмаса, романдагы Лобачевский тормыштагы Лобачевскийдан өстенрәк була аламы? Бу сорауларга ничек җавап бирергә?"*

Урысның күренекле язучысы Александр Солженицын да төрмәләрне кичкән кеше. Тик аның язмышы башка төрлерәк. АКШта озак еллар яшәп, "Архипелаг Гулаг"ны язып, ул хакыйкатькә сусаган совет кешеләрен тәмам әсир итте: һәркем КГБ күзеннән кача-поса, яшертен төстә шул китапны табарга һәм укырга тырышты.

Кайтты Солженицын, ләкин үзе яшәп киткән СССРга түгел, яңа бер илгә—Россиягә әйләнеп кайтты. Акыл сата башлады, сәясәткә кереп китте, Россиядәге милли республикаларга каршы мәсхәрәлерәк сүзләр дә әйтеп ташлады. (Әйтик, Татарстан һәм Чечня турында).

Кыскасы, үзенең империячел һәм шовинистик мәсләген ачып салды.

Юкса нинди популяр, халыкчан бер әдип иде. Мин аңа ачы гына бер хат та язган идем, нишләптер, җавап бирмәде.

Атаклы спортчыны бернинди патша яисә президент та өреп-кабартып ясый алмый... Әдәбиятта бу бигрәк тә шулай. Әмма элек тә сарай шагыйрьләре булганы мәгълүм. Хәзер дә бардыр мондый хәлләр, алар битлекләрен, төс-кыяфәтләрен генә үзгәрттеләр бугай.

Айдар Хәлимнән "Заман" газетасы сорый: "Сез бәхетлеме?" "Мин үземне ничек бәхетле саныйм ди, әгәр халкым коллыкта, дәүләтчелегебез юк икән",—

шулай ди язучы. Туры сүзне әнә шулай әйтә белергә дә кирәк шул.

1856 елда Россия Кырым сугышында җиңелә! Тютчев шул чакны ничекләр бәргәләнә (патриот чиновник, дворян). Ә безнең Совет заманында тирестән (гафу итегез, авылдан...) күтәрелеп чыккан язучылар илнең-хөкүмәтнең күпме хаталарын күрмәмешкә салыштылар. Хәзер дә менә ун елга сузылган Чечня сугышы турында юньләп сүз әйткәнебез, чаң какканыбыз юк. Бер уйласаң, гаҗәп хәл бит бу. Гаяз Исхакый исән булса, инде әллә кайчан әллә кайларга хәтле барып җиткән булыр иде...

Совет заманында әдипләр җилкәсен ике авыр таш басып торды: берсе, әйткәнемчә, цензура, икенчесе—социалистик реализм. Беренчесенә тукталып та тормыйм. Икенчесе хакында бер-ике мисалны әйтеп китәсе килә.

"Казан утлары" журналында эшләгәндә миңа Газиз Кашаповның "КамАЗ" турында язылган романын редакцияләргә туры килде. Андагы эт эчәгесе кебек җөмләләр—карурман инде менә. Ләкин иң кыены—социаль заказ рәвешендә, "ура-патриотизм" рухында язылган бу әсәрдә күңелсез урыннар, репортажга тартым сәхифәләр аның художество сыйфатына хәйран каты суга иде.

Әлмәт якларында яшәүче Җәмит Рәхимов шулай ук роман алып килгән. Анда—Себер урманнары, нефть, бәхет эстәүче һәм акча эшләүче үзебезнең "күчмә татарлар"... Автор белән эшләү процессы шулай ук авыр булды.

Әмма шунысы куанычлы: соңыннан Газиз Кашапов—Хәсән ага Туфан, ә инде Җәмит Рәхимов легендар Батырша турында менә дигән роман яздылар. Җаваплылык, әдәби материал тукымасы үзеннән-үзе яңа тел-стильне сорап алган, ахрысы, дигән фикердә калдым мин.

Заманы шундый булгач, гаепләп тә булмый, ләкин соцреализм хәтта талантлы әдипләрне дә үзенең җәтмәсенә "эләктереп" алды. Мисал. Фатих Хөсни коллективлашу хакында "Җир авазы" дигән роман яза. "Син советка, колхозлашуга каршы әсәр язгансың, үзгәрт, давай!"—дип китереп кысалар моны. Кыям Миңлебаев әйтүенчә, әлеге әсәрнең беренче варианты әдипнең кызында сакланырга тиеш. Менә шуны табып алып, "Җәяүле кеше сукмасы" белән чагыштырып карыйсы иде безгә!

Бөтен әдипләр дә социалистик реализм методына сукырларча ябышып ятты дип уйлау дөрес булмас. М.Шолоховның "Тын Дон"ын искә төшерик. Миңа, һәрхәлдә, коммунист Кошевой образына караганда аклар белән кызыллар арасында шактый буталып йөргән Мелехов образы ныграк ошый иде. А.Фадеев "Метелица" әсәрен язганда да як-ягына каранып тормаган, үз принципларын алга сөргән. Үзебезнең әдәбияттан Галимҗан Ибраһимовның "Кызыл чәчәкләр"ен генә хәтерлик. Ике дусның, ике туганның фаҗигасе бик тә кыю сурәтләнә анда...

Мин студент чакта остазым, укытучым, мөгаллим Ибраһим ага Нуруллинның: "Шигырь ул академикка да, сыер савучыга да бердәй дәрәҗәдә аңлаешлы булырга тиеш",—дигән сүзләре белән берничек тә килешә алмадым. Бәлки, ул бүтәнчәрәк фикер әйтергә теләгәндер, белмим. Лорка, Блок, Хлебников, Вознесенский кебекләр, һәрхәлдә, элита өченрәк язганнар. Ә инде Д. Бедный, М. Хөсәен, Р. Гәрәй һ. б. шагыйрьләр иҗаты халыкка якынрак.

Алай дисәң, ике якка да аңлаешлы әсәрләр дә күп бит әле әдәбиятта:

Пушкин, Есенин, Тукай шигырьләре, А. Чехов, М. Шолохов, Шукшин, Ә. Еники, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев прозасы... Шулай, әдәбият ул ике икең дүрт шикелле гади генә кагыйдәләргә сыеп бетә алмый.

**Анар:** *"Язучы өчен тормыш тәҗрибәсе бик мөһим. Әмма күзәтүчәнлек, тормыш вакыйгаларын һәм тәэсирләрне туплау—бу әле язучы булдым дигән сүз түгел. Төрле буяулар сатып алу әле синең рәссам булуың турында сөйләми, шуның шикеллерәк"*. Сүз һаман да талант һәм тырышлык мәсьәләсенә кайтып кала.

**Туфан Миңнуллин:** *"Дәүләт Советы утырышларыннан сюжетлар димим, әмма кайбер фикерләр, детальләр алам үземә. Әйе, шулайдыр, сессия эше—үзе бер спектакль бит ул. Аның режиссерлары да, массовкалары да җитәрлек, минем күзәтүемчә"*.

Язучы кеше күктә, фәрештәләр янында яшәми. Алар белән дә нинди генә хәлләр булмаска мөмкин.

Шулай берчакны Мәскәүдә зур гына халыкара симпозиум бара икән. Шолоховка сүз бирәләр—юк та юк теге. Югалган. Бактың исә, Бразилиянең атаклы язучысы Жорж Амаду белән ресторанда пирәшләп утыралар икән—сагынышканнар, минсиңайтим.

Язучыларның Аккош күлендә бер яшь шагыйрь күршесенең одеялын чәлдергән икән... Мин аны гаепләр диган идем, юк, Сибгат ага Хәким: туңгандыр, кирәк өчен алгандыр, дип шагыйрьне аклап чыкты.

Сергей Михалковның бер очрашуда: "Кайчакны миңа ак кәгазь каршында утыру оят булып китә",—дип ычкындырган иде, рәис Гариф Ахуновның ут чагы, бер дә югалып калмады, әйтте:

—Ә сез, Сергей Владимирович, андый чакта соры кәгазьгә язарга тырышыгыз.

Казан университетының Актлар залы тулы студентлар шаулатып көлде ул чакта.

Каховский, бер язмасында, ни өчендер шәраб белән дус булган шагыйрьләрнең бу гамәлен яклап чыга. Икенче яктан, күпме талантлар еш кына шешә төбенә кереп баткан була...

**Роберт Батулла** мәкаләсеннән: "*Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов утны, суны, җиз торбаларны кичкән егет. Гаиләсез дә, фатирсыз да, паспортсыз да калып, урамда, суыкта дистәләрчә еллар каны һәм җаны калтыраган кеше... Ләкин зарланмады. Зарланып кем аны аңлар иде икән соң? Ниһаять, иҗади дуслары ярдәмендә паспортлы да, йортлы да булды ул.*

*Әйе, үзенең җылы куышын үзе кора алмаган кеше, шагыйрь булса да, композитор, рәссам булса да, мактауга лаек түгел, шиксез. Миңа калса, Мөдәррисненң һәм холыклары аңа охшашларның фәлсәфәсе бер. Андыйлар: "Мин—талант иясе, бәс, миңа шартлар тудырыгыз. Талантлы кешегә ни кыланса, шул килешә. Сез мине кичерегез, минем турыда кайгыртыгыз",—дип гамәл кылалар сыман".*

*Шактый бәхәсле фикер, ләкин дөреслек орлыклары да юк түгел, бирәдә, миңа калса.*

*Тагын бер нәрсә борчый: яшьләр арасында масаю, даһилек, йолдызлык чире шактый еш күренә. Андыйларга инглиз мәкале белән җавап кайтарасы килә: "Кемдә зур акыл икән, моның белән идарә итү өчен аңа тагын да зуррак акыл кирәк".*

Джек Лондон әнә булган бөтен акчасына "Бүре йорты" дигән бик затлы-зур йорт салдыра. Менә шуны яндыралар, ә ул гаепләне эзләп азапланмый, берәүгә дә үпкәләми. Кечкенәдән әтисез үсеп, бик күп кыенлыклар кичергән кешенең егетлеге, киң күңеллеге инде бу, күрәсең.

Шунысы кызганыч, алтын приискасы тоткан шагыйрь Дәрдемәндтән башка бездә бер генә татар язучысы да бай яшәмәгән. Ул да совет чорында, гомеренең соңгы көннәрендә, байлыкларын тартып алгач, кызганыч хәлдә вафат була. Мин совет заманында Кавказ, республикаларының Мәскәү әдипләрен ничек каршылавын ишетеп тә, күреп тә беләм. Язучы Нодар Думбадзе ничә еллар шәраб базында "көч җыеп" яткан виноград мичкәләрен тәгәрәтеп чыгарганда мәскәүләрнең күзе маңгаена менә иде, дип сөйлиләр...

Кемдер әйтмешли, талант Ходайдан бирелсә дә, аның нәтиҗәсе һәрвакыт үзеңнән тора.

## СҮЗ ЧЫГАР ШАГЫЙРЬЛӘРДӘН ХИКМӘТ БЕЛӘН

*Тел байлыгы—фикер байлыгы дигән сүз.*
Н.Карамзин

Әйе, тел байлыгы белән фикер байлыгы—язучы өчен кошның ике канаты кебек.

Әдипнең төп максатларыннан берсе—гап-гади сүзләрне художестволы (тылсымлы) сүзгә әйләндерү. Татар телендә якынча ярты миллионнан артык

сүз бар дип исәпләнә. Без, әдипләр, каләм ияләре—барыбыз да халыкның әнә шул мәңге саекмас хәзинәсеннән файдаланабыз. Әмма, бик тә гадиләштереп әйтсәк, Галинең язганнары—Галичә, Вәлинең язганнары Вәличәрәк килеп чыга шул. Димәк, бөтен хикмәт энҗе бөртегедәй сүзләрне уйната, файдалана белү осталыгына әйләнеп кайта.

Фатих Хөсни әдипләр турында: "Кеше күңелен тылсымлый белүчеләр",—ди. Шул ук вакытта "Урынындамы сүзләр-солдатлар?" дигән бер тәнкыйть мәкаләсендә сүзләрне, тәгъбирләрне, җөмләләрне дөрес һәм оста итеп куллана белмәгән каләмчеләрне бик усалланып камчылый да.

Достоевский, һәркемнең үз грамматикасы бар, дигән фикер әйтә.

Аяз Гыйләҗев яза: "Мөхәммәт Мәһдиев теле—Илһам Шакиров моңнары, Рөстәм Яхин фантазиясе шикеллерәк". Дөрес һәм матур әйтелгән!

Бетховен органда уйнау осталыгын төгәл бәяли: "Бу бик гади эш. Тиешле клавишларга бармак белән дөрес баса белергә генә кирәк".

Билгеле булганча, әдәбиятның төп объекты—кеше, кеше җаны, кеше рухы. Тормыш давылларының уртасыннан атлап баручы кеше кискен хәлләрдә кайсы юлны сайлый, нинди идеалларны юлдаш итә? Яңалык тойгысын, беренче чиратта, әнә шундый сорауларны сәнгатьчә хәл итә белү, димәк, кеше рухын ача белү, туган тел осталыгы, тел йогынтысының тәэсир көче белән билгеләргә кирәктер.

Әйе, сәнгать әсәре чын мәгънәсендә ачыш булырга тиеш. Шул чагында гына ул йөрәгебезгә һәм акылыбызга йогынты ясый ала, дөньяны танып-белүдәге рухи тәҗрибәбезне баета. Мисаллар эзләп ерак барасы юк. Әйтик, үзенең "Тынычлану" дигән хикәясендә гомернең бик тә кадерле нәрсә булуы, кешеләр арасындагы мораль, әхлак һәм социаль мөнәсәбәтләрнең гаять зур фактор икәнлеге турында сөйләп, Әмирхан ага Еники һәммәбез өчен дә ачыш ясады. Драматург Туфан Миңнуллин исә кыю рәвештә "Адәм баласына ял кирәк!" дип чаң сукты. Һәм шушы аваз һәммәбезне сискәндерде, айнытып җибәрде, тормыш гаменә чумган акылыбызны яшәешкә бүтәнчәрәк карарга этәрде. Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән" исемле повесте да яшәү мәгънәсе, кеше күңеленең матурлыгы хакында кат-кат уйландырды. Әдәбиятыбыз тагын да үссен һәм көчәйсен, милли рухыбыз баесын өчен әнә шундый ачышлар мул кирәк.

Прозаикмы ул, шагыйрьме—яңалык тойгысы язучы дигән исемне йөртүче шәхеснең иң элек үзендә, күңелендә, йөрәгендә, төгәлрәк әйтсәк, баш миенең кайсыдыр бер почмагында булырга тиеш. Әгәр язучының үзендә шушы тойгы юк икән—ничек инде әдәбиятка яңалык, яңа фикер, фәлсәфә, яңа ачыш өстәлсен ди?! Без—бүгенге көн балалары. Шулай булгач, яңалыкның бүгенге көн төсмерләре белән баетылуы, заманның катлаулы һәм нечкә проблемалары белән яктыртылган булуы мәҗбүри дип беләм. Тирә-ягыбыз тормыш белән, серлелек белән, яңалык белән мөлдерәмә тулы. Яңалык үзе һәр язучыны сагынып, көтеп тора...

Ләкин сүзнең кадерен, тәэсир көчен беркайчан истән чыгармаска кирәк.

**Айдар Хәлим:** *"Иҗатның "чишмә башлары" турында. Күз алдыгызга китерегез: сабый баланың беренче тапкыр күңеленә сүз килә. Сүз йә матурлыкка соклану, мәхәббәттән мөкиббән китү, йә нәфрәттән, гарьләнүдән ярала. Минем үземдә шагыйрьлек укый-яза башлагач та, Матурлыкка һәм Батырлыкка соклanудан яралды, дип әйтә алам. Бераз ушым ачыла төшкәч, Кальбем гаделсезлекнең күп булуыннан рәнҗеде. Инде балигъ булып, ир-егет чорына кергәч, миндә кешеләрне матурлык тойгысы аша тәрбияләү, матурлык тойгысы аша Гаделлек Патшалыгын урнаштыру теләге—Иман дигән иман туды. Бәхетсез милләтнең бәхете өчен көндәлек һәм гомерлек көрәш, гомерлек турытукайлык минем рухи кыйблама әверелде. Шушы тойгы мине бер юлы—бер мизгелдә мине шагыйрь, публицист һәм чәчмә әсәрләр язучы итте. Чөнки әдәбиятның барлык жанрлары нигезендә шигърият вә шагыйрьлек ята. Яхшы шагыйрь булмаган кеше яхшы публицист һәм кайнар фикер иясе була алмый!"*

Шагыйрь Р. Гаташның өч кенә сүздән торган шигырь юлын хәтергә төшерик:

*Европада татар шагыйрьләре!*

Әйе, нибары өч сүз... Ә менә шулар артында никадәрле шигъри куәт, киңлек,

уфтану һәм горурлану, татар шагыйрьләренең ут эченә килеп эләгүе, сугыш фаҗигасе ярылып ята. Алга таба укыган саен шагыйрь әнә шул фаҗигане өр-яңа сүзләр белән көчәйтә, тирәнәйтә, татар җанлы кешеләрнең күңелен айкап сала.

Александр Блок сүзнең көче-тылсымы хакында: "Ә тирәндә аваз дулкыннары ята",—дип яза.

Менә Равил Фәйзуллинның элегрәк язылган бер шигырен искә төшерик:

*Чайкала-чайкала*
*Иделдә Ай кала...*

Әлеге юллар Атилла җиһангир заманнарыннан, моннан меңәр ел элек язылгандыр шикелле тоела миңа. Гап-гади сүзләрдән шагыйрь бөек образ тудырган, тарихның әллә кайчангы катламнарына хәтле үтеп кергән. Гап-гади, ә бәлки илаһи-бөек күренеш әнә шулай поэзия югарылыгына күтәрелә.

Дөньяны сүз бизәр, дигән безнең бабайлар.

**Мөдәррис Вәлиев:** *"Китап сүзенә хөрмәт традиция-йола буенча гына түгел. Китап кешене үз-үзенә—зурлыгына, көченә, матурлыгына инандырып килгән, шул ышаныч ярдәмендә сират күперләреннән алып чыккан.*

*Кешенең шәфкатьсезлеген күрсәң, балачагында ул әкият тыңлап үсмәгәндер, дип уйла.*

*Кешенең күңел күзләре сукыр икәнен абайласаң, аның үз гомерендә шигырь укып әсәрләнгәне юктыр дип кызган".*

Менә шуңа бүгенге шигырьләрне укыганда иңгә җаваплылык тойгысы баса, күңелгә Тукайның мәгълүм юллары килә:

*Күкрәгемдә минем шигырь уты саумы?*

Ходай безне әнә шушы рухи чукраклыктан, мескенлектән, мәнсезлектән, олы хис ятсә гамь белән янып яшәүләрдән мәхрүм итә күрмәсен.

Әдәби-художестволы сүз осталары әдәбиятта күп, әлбәттә. Әмма, Чеховтан кала, Купринны атыйлар. Бу—дөреслеккә туры килә шикелле. Мин заманында аның "Кояш сукканда" хикәясе һәм "Арсеньев тормышы" дигән романын укып чыкканнан соң андагы тел байлыгына, вакыйгаларны сурәтли белүгә, сүзтезмәләрнең ифрат камил урнашуларына, геройлар психологиясенең мөкаммәл бирелешенә таң калган идем.

Бальзак һәм Джек Лондон, ни әйтсәң дә, тормыш ваклыкларына тирән кереп баталар. Флобер исә һәрбер җөмләсен энҗедәй кат-кат эшкәртергә тырышкан, диләр. Бездә Әмирхан ага Еники әнә шулайрак иде: "Берәр җөмләмне ахыргача төгәлләми торып, икенчесенә тотына алмыйм",—дия торган иде. Фатих Хөсни, Аяз Гыйләҗев тә—көчле стилист, оста психологлар. Ә инде яшьрәкләрдән Марсель Галиев һәр җөмләсеннән берәр хикмәт коярга тырыша. Ркаил Зәйдулла да бу җәһәттән аңардан бер дә калышмый диярлек.

Әгәр әсәрдә яшьлек-аваз, (В. Маяковский), сүз сулышы (Мандельштам), прозага гына хас ритм юк икән (Паустовский), моны—талымсызлык, җаваплылык, талантсызлык билгесе, дип бәялиләр.

Яхшы сүз, китап сүзе һәрчак һәркемне үзенә тарта. Океаннарны, бик күп илләрне кичеп йөрүче Миргазиян Юныс Алжир һәм башка илләрдә Николай Бердяев, Георгий Федотов, Сергей Булгаков, Владимир Набоков һәм башкаларның китапларын сатып ала да каютасында кача-поса укып чыга. Ләкин совет заманы бу, идеологик, таләпләр бик кырыс. Кораб Одессага якынлаша башлагач, әлеге китапларны ул, бәрәңге капчыгына бушатып, тиз батсын өчен эченә тимер әйбер салып, иллюминатор аша диңгезгә ташлый. М. Юныс әйтә: бу—минем тарафтан вандализм, мине манкортлаштырудан коткаручы фикердәшләремне суга батырып үтерү белән бер дәрәҗәле хыянәтчел адым булган икән. Ләкин "дөрес эшләвем" бик тиз расланды: КГБ стукачлары бик тиз арада минем каютадагы барлык китапларымны карап, тентеп чыктылар.

**Миргазиян Юныс:** *"Менә шул халыктан яшертен китапларны укып чыкканнан соң гына мин социализм җәмгыятенең ни икәнен аңладым һәм оппозици-*

*онерга, милләтчегә әверелдем. Андый китаплар белән очрашу минем яшәеш кыйбласын бөтенләй икенче тарафка борып җибәрде"* дигән сорау ташлый:

—Менә сез, ярты гасырдан артык урыс арасында яшәп, чирек гасыр диңгез кичеп, урыс югары уку йортларын тәмамлап, урыс журналында эшләп тә татарлыктан ваз кичмәгән, кичү генә түгел, хәтта татар өчен җан атып яши торган иң мөхтәрәм шәхесләребезнең берсе. Әгәр урысча язган булсагыз, сезнең әсәрләрнең тиражлары дистәләгән мәртәбә күбрәк чыгып, данызыз тагын да еракка таралыр иде дип уйлыйм. Ә сез башка юлны—чын татар юлын сайладыгыз...

**Миргазиян Юныс** җавап бирә: —Син дөрес әйтәсең, әгәр урысча язсам, мин кимендә 30-40лап китап чыгара алган булыр идем. Эш менә нәрсәдә, энекәш. Урысча намаз укып була микән? Юктыр дип беләм...

М. Юныс белән кызыклы бер хәл була: "Шәмдәлләрдә генә утлар яна" дигән, миңа калса, иң милли һәм кызыклы әсәрен ул чистага яңадан күчерә һәм... каралама диеп, диңгезгә ташлый! Караламасы исә—кулында, каютасында торып кала. Фантазия белән чынбарлык арасында яшәгәндә әнә шундый гайре табигый хәлләрнең чыгуы иҗат әһелләре өчен бер дә чит нәрсә түгел. Моның кайбер мисалларын алдагы бүлектә дә әйтеп киткән идек.

Италияне гизә башлагач, ул итальян телен өйрәнә башлый һәм гаҗәпләнә: бездәге сабын—аларда "сабон", пыяла дигәнең "фиала" дип атала икән. Очраклы хәл түгел бу, әлбәттә. Атилла ярты Европа, Азияне яулап алган чакта, ирләр-хатыннар гына түгел, тел вә лөгать алмашу да көчле булган, күрәсең.

Әйе, кыйммәтле сүзләрнең фәһеме беркайчан да үзенең асылын югалтмый.

**Зөлфәт:** *"Шулкадәр дә хикмәтле, серле дөньяда ни бар, анда нинди гамәлләр кылына—шуларның һәммәсенә дә кеше дигән әкәмәт зат сүзләр уйлап тапкан. Һәм ничәмә-ничә телдә диген әле. Сүз белән дөнья бәйләнеше мине бәләкәй чагымнан ук таң калдыра иде. Серлерәк тоелган, миңа аңлашылып бетмәгән сүзләрнең мәгънәләрен белергә тырышып, өлкәннәрнең тәмам теңкәсенә тия идем мин. Ә инде сүзләрнең серен, хикмәтен ачкач, аларның чынбарлыкка никадәр туры килүенә исләрем китә иде."*

*Менә шундый малай сүзләрне үзе дә уйлап табарга ничек ашкынмасын инде? Һәм ул малай сүзләр янәшәлеген үзгәрткәч, бөтенләй яңа, кызыклы, матур үзгәреш пәйда булуын тоеп ихластан кинәнә иде. Әкиятләрне үзем уйлап табып, аларны дәфтәр-дәфтәр итеп язарга тотындым. Дәфтәрне үзем ясадым. Нинди ак кәгазь очраса, шуларны җыеп, калай кисәге белән төпләп (әткәй—тимерче!) гел әвәрә килә идем.*

*Кешелек тарихында атаклы яугирләр булды. Аларның сүзе һәм угы бердәй дәрәҗәдә кодрәтле булган. Ләкин туган телеңне тулаем яхшы белим дисәң, һәр сүзнең шул "Аллаһы сүзе" түгелме икәнен уйлап карарга кирәк..."*

Әсәрнең телен камилләштерү, шомарту бик күп әдипләргә хас. Шул ук Зөлфәтнең студент чакта, "Айлы соната"мы, әллә "Ай сонатасы"мы дип әйтү дөрес икән дип бәргәләнүе бик күпләребезнең хәтерендә әле.

Сүзләр—халыкның уена, акылына, тәҗрибәсенә, дөньяны ничек кабул итүенә бик тә бәйле нәрсә. Әйтик, руслар "снегирь" дигән кошны без "кызылтүш" дип атап йөртәбез. Урыслар бу тиктормас кошның кар өстендә бөтерелүен күздә тоткан, күрәсең. Ә безгә аның кышкы алмадай кызыл түшле булуы күбрәк ошаган, күрәсең. Минем бик тирәнгә батасым килми, теләүчеләр булса, сандугач (былбыл) сүзенең кайсы телдә ничек яңгыравын, ниләр аңлатуы хакында кызыксынсыннар.

Тел-стильне шомарту, камилләштерү—күп кенә язучылар өчен хезмәт, ихтыяҗ булган һәм булачак. Әйтик, Бальзак үзенең язмаларын төзәтү-үзгәртүе белән корректорларның тәмам теңкәләренә тия торган була...

Минем редакторлык тәҗрибәсендә дә гыйбрәтле мисаллар җитәрлек иде. Мәсәлән: "Аның колагы ишетүдән баш тартты", "Үзләре белән бергә, вертолетның тамагын ялгап чыктылар..." кебек җөмләләр...

Берзаманны, студент чакларда ук, мине әдәбиятның зурлыгы, җаваплылык

куркыта иде: иҗат эшен ике тапкыр ташлап карадым!.. Әмма булдыра алмадым, чөнки әйтер сүзем барлыгына, язачагыма ышандым. Толстой: "Не могу молчать!" дигән. Аның үзен дә, фикерләрен дә әле юньләп белмичә, мин дә әнә шулайрак фикер йөрткәнмен булса кирәк.

Әйе, әйтер сүзең булса, күрше кесәсенә йөгереп керәсе юк, алар үзләре синең йөрәгеңнән кайнап чыга.

## ЗАМАН КЕМГӘ ТЕКӘЛГӘН?

Дөресен әйткәндә, заман барыбызга да, ягъни үзенең "гражданнарына" текәлгән һәм ул бездән дөрес, әтрафлы җаваплар көтә. Ни уйлыйсыз, ни язасыз, ни өчен сугышасыз? Сугышлардан туймадыгызмени әле? Чечняда ун ел азапланасыз, ә Кавказ әле һаман корт иледәй гүләп-кайнап тора... Саный китсәң, сораулар исемлеген су буе дәвам итеп булыр иде.

Заман барыбер безгә—әдипләргә, шагыйрьләргә текәлгән. Чөнки ныклы, төпле сүзне нәкъ менә алар әйтә белә. Публицистика өлкәсенә дә мин күпме һәм нинди генә мәкаләләр язып карамадым, бөтенесе "суга" китте: мактадылар, җылы сүз әйттеләр дә шуның белән—вәссәләм! Мин моны аңлыйм, ләкин өмет, ышаныч исән: язган сүзләрең, фикерләрең барыбер кем күңелендәдер утырып кала бит, күпмедер йогынты ясый.

Заман һәркайсыбызга текәлгән. Ул бездән чынлап та җавап көтә, тик менә күбебез җавапны бирә алмыйбыз шикелле. Чөнки һәркем үз дөньясына баткан (бакча, акча, бәрәңге, колорадо коңгызы һ. б.).

Ләкин заман бездән җавап көтә.

Без аңа ни дип әйтә алабыз? Әйтер сүзләр бик күп, ләкин төптән каерып әйтүчеләр аз. Менә шуңа да җаваплылыкның зур өлеше әдипләр җилкәсенә төшә. Алар яза, сөйли, әйткәннәре Дәүләт Советындагы сүзләрдән бер дә ким түгел, хәтта усалрак та әле. Әмма эт өрер, бүре йөрер, ди. Без бит Россия уртасында.

Мине бервакыт шундый сорау биләп алган иде: инде ничә гасырлар буена том-том әсәрләр вә китаплар басылган, киләчәктә әдәби темаларга кытлык булмас микән? Озак кына уйландым да, ныклы шундый фикергә килдем: бераүләр—җәмгыять агачының очын, икенчеләр кәүсәсен, өченчеләр исә тамырын күрә. Ә тормыштагы кешеара мөнәсәбәтләр, мәхәббәт һәм нәфрәт, әдәп-әхлак мәсьәләләренең беркайчан да искерәсе юк, алар үзләре үк көн саен йөз кабат яңарып, өр-яңа проблемаларны калкытып кына торалар.

Язучы боларның берсеннән дә кача алмый, кача яисә ераклаша икән, ул инде чын каләм иясе дә, чын фикер иясе дә була алмый. Аның максаты, әйткәнебезчә, җәмгыять сафында, бер адым алданрак атлап бару, булачак хәлләрне җетерәк күрү һәм чаң сугудан гыйбарәт. Евтушенко: "Фикер—биографиянең мөһим бер кисәге",—дип юкка гына әйтмәгәндер.

Михаил Шолохов 1933 елда ук Сталинга хат язарга батырчылык итә: "Тов. .Сталин! Умирают колхозники и единоналичники, взрослые и дети пухнут и питаются всем, чем не положено человеку питаться, начиная падалью..."

Тормышта батырлык һәркемгә кирәк. Ләкин хакимияткә каршы бару һәркемнең кулыннан яисә йөрәгеннән килми. Аның шул ягы кызганыч. Авырлык кичергән аналарның, ятим яисә хәерче үскән балаларның бер тамчы күз яшенә дөньядагы күпме ачы язмышлар яшеренгәндер? Без боларны күрә беләбезме, хөкүмәтләр, парламентлар ишетерлек итеп чаң сугарга, сүзләрнең иң саллысын, кайнарын, йөрәкләргә үтеп керердәйләрен әйтергә әзерме?

XX гасыр бөек җиңүләргә дә, илкүләм яисә дөнья күләм фаҗигаләргә дә бай булды. XX1 гасыр бусагасына без һәммәбез, бөтен кешелек дөньясы зур өмет һәм ышанычлар белән аяк баскан иде. Әмма өч-дүрт елы да узарга өлгермәде, шул арада никадәр фаҗигаләр өстебезгә ишелеп төште! Илләр елый, халыклар сыкрый, тайфуннар котырына, цивилизация тетри... Йә Ходаем, нинди заман бу: кеше ялгансыз, ришвәтсез, битлексез яши алмый, икейөзле булудан туктамый.

Әдәбият элек-электән кыен чакларда кешегә ярдәмгә килгән, аның рухын, әхлагын саклаган, җәмгыятьнең тазалыгы өчен көрәшкән. Аның бу гуманистик миссиясе бүген дә, иртәгә дә искермәячәк. Матурлык дөньяны коткарачак, ди Достоевский. Кешелекнең һәм әдәбиятның карашы, тоткан юлы менә шушы тарафка төбәлгән булырга тиеш.

Батырлык һәм матурлык тойгысын югалтмаска иде, ватандашлар!

Бүген безгә, татарларга, "Ватан" сүзенең кадерен, авырлыгын, фаҗигасен ачык итеп аңларга һәм аңлатырга вакыт җитте. Бу урында язучы сүзе аеруча кыйммәтле, үтемле, кадерле—моны тәфсилләп тору кирәкмидер. Язучы исемен күтәреп тә, әгәр ул иҗат эшеннән читләшсә, халкына хезмәт итмәсә, андый кешенең, халык әйтмешли, поты бер тиен. Батулла дөрес яза: чын мәгънәсендә Әдип булыр өчен Тукай, Исхакый, Галәү, Еникиләр дәрәҗәсендә булу кирәктер ул. Милләт язмышы турында кайгыртучы, көрәшче каһарман булмыш кирәк.

Йомгаклап шуны әйтергә була—әдәби әсәр баш мие күзәнәкләренең "тырышлыгы" гына түгел, язучы яшәешеннән аерылгысыз булган социаль, рухи, физик, эмоциональ һәм психологик факторлар кушылмасының гаҗәеп бер чагылышы ул. Шәхес күңеленең киеренке хәле гап-гади сүзләрне очкынлатып, дөрләтеп җибәрергә сәләтле! Мәсәлән, без Пушкин яисә Тукайны исән вакытларында күреп белмибез. Иҗатлары белән якыннан танышу исә безгә аларның сөйгән халкы һәм Ватаны өчен өзгәләнеп яшәүләрен, берниндн хәлләргә дә битараф булмауларын, хисси көрәш уртасында яшәүләрен аңларга ифрат былышлык итә.

Әдәбиятка үз-үзен аямый эшләүче, дөньяның һәм, барыннан да бигрәк, милләт гаме белән яшәүче якты, көчле шәхесләр кирәк. Бөек әдипләрнең һәркайсы әнә шундый биеклектә тора. Әдипнең шәхесе никадәр зур булса, аның иҗаты да шулкадәр олы, масштаблы.

Табигать биргән талант орлыгың кечкенә, фәкыйрь, мескен, гарип икән, өстеңә гомер буе кояшлы яңгыр явып торса да, аның җимешләре барыбер кечкенә булачак...

Шактый күләмле бу эссе "Алдым каләм кулыма" дип юкка гына аталмады. Кулыңа каләм алгансың икән, син инде үз өстеңә зур җаваплылык алдың дигән сүз. Юлдагы киртәләрне, иҗади газапларны, үз-үзеңне җиңү җиңелләрдән булмас. Әмма сүз көче, сүз кодрәте, тәэсир куәте сезнең кулларда, каләм ияләре. Сезгә хәерле юл...

Сүзгә—хәерле юл!

*2003—2005 еллар.*
*Казан—Олы Мишә—Васильево.*

Хатыйп
Миңнегулов

*Клара Булатовага 70 яшь*

# ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ ХАДИМӘСЕ

*Башка авторлар, ничектер, анысын белмим: әмма минем өчен иң кыены язмага исем табу. Бу мәкалә дә аннан чыгарма түгел. Төрле исемнәр уйлап карадым да, шушы атамага тукталдым. Әлбәттә, ул да күңелне тәмам канәгатьләндереп җиткерми. Шулай да бу исем, минем карашымча, Клара Булатова эшчәнлегенең асылын шактый тулы чагылдыра. Мин инде аны ярты гасырга якын беләм. Шушы вакыт эчендә еллар агышы, җәмгыять белән бергә, бу затның да теге яки бу дәрәҗәдә үзгәреше, рухи һәм җисмани эволюциясе табигый. Әмма аңда татар шигъриятенә, газиз ана теленә, алар аркылы сөекле халкына тугрылык, хадимәлек, мөкиббәнлек һич тә үзгәрмәде, киресенчә, арта, көчәя генә барды. Мин бу мөхтәрәмә затны әдәбияттан, татар яшәешеннән башка күз алдына да китерә алмыйм. Әгәр дә ул йә җәннәттәй тормыш, йә газаплы шигърият дилеммасы /сайлау мөмкинчелеге/ алдында калса, (иманым камил!), һичшиксез, соңгысын сайлар иде. Аның һәрбер күзәнәге тумыштан ук шигъри рух белән сугарылган, шигърият—аның иманы, кыйбласы, яшәешенең асылы. Ул—могҗизалы сүз сәнгатенең чын мәгънәсендә хезмәтчесе, хадимәсе, фидакарь көрәшчесе.*



## I

Дөньяга килгән һәр адәм баласыныкы кебек, Клара Гариф кызы Булатова—Рафигуллинаның да үз гомер юлы, үзе салган тормыш сукмаклары бар. Ул тумышы белән җырларда көйләнгән, бик күп мәшһүр затларны, шул исәптән әдәбият һәм сәнгать әһелләрен биргән атаклы Сарман ягыннан, татар теленең, халык моңының табигый төбәгеннән. Әгәр дә шагыйрә ана теленең, сүз сәнгатенең бөтен нечкәлекләрен белеп, тел дәрьясында судагы балык кебек эш итә икән, монда, әлбәттә, Сарман ягының да роле зур.

Туган төбәк, аны сагыну хисләре, җирсү әдибәнең иҗатында да калку гәүдәләнеш тапкан:

*...Синдә—яшьлек язларым,*
*Синдә—башлап язганым.*
*Уйларымны гел тартасың,*
*Ахры тартып кайтартасың,*
*Читтә кала алмамын,*
*Сарманым!...*

* * *

*Сарман якларында сары чәчәк*
*Төшләремә керә сибелеп.*
*Кайта алмый йөргәнгәдер инде,*
*Сагышлардан үзәк өзелеп.*

Клара Булатова Сарман районының Карамалы авылында (аны кайвакыт Татар Карамалысы дип тә йөртәләр) 1936 елның 18 мартында дөньяга аваз сала.

Шагыйрәнең 2004 елда язылган бер истәлегендә мондый юллар бар: "Әни миңа, ачуы килгән чагында, еш кына: "Юньле булсаң, юлда тумас идең, житлекмичә туган нәрсәкәй!"—дип әйтә торган иде. Ул кадәресенә кем гаепле булгандыр, әмма, сөйләүләре буенча, юлда тууым хак. 18 мартта туганмын мин. Ул елны яз бик иртә килгән. Әни яткан чана юл читендәге... карлы-сазлы измәгә ауган. Әни аста калган. Шунда мин дә туа башлаганмын".

Клара Булатова — мөгаллимнәр гаиләсенән: әтисе—Гариф абзый (1906-1984. Шулай ук чыгышы белән Сарман төбәгеннән—Илексаз авылыннан)—математика укыта, бик озак еллар буе мәктәп директоры булып эшли, әнисе Ханисә апа (1906-1988. Тумышы белән атаклы Теләнче Тамактан)—тел-әдәбият укытучысы. Элек мөгаллимнәрне бер мәктәптән икенчесенә күчерү еш күзәтелә иде. Булачак шагыйрә дә әти-әниләре белән районның төрле авылларында яши, сугыш һәм аннан соңгы авыр елларның бөтен авырлыкларын, мәшәкатьләрен күрә. ("Татып үстек сугыш газапларын",—ди ул бер шигырендә). Әтисе фронтка киткәч, биш балалы гаиләдә әнисенең төп таянычларыннан берсенә әйләнә. Өченче-җиденче сыйныфларны Клара Ләке мәктәбендә укый. Ә инде урта мәктәпне ул 1954 елда Сарманда тәмамлый.

Шагыйрә иҗатында керәшен татарларының, гореф-гадәтләре, фольклоры, сөйләм элементлары, "Олы көн", "Питрау", "Торыйсун" кебек бәйрәмнәре, архетип кебек, еш телгә алына. Болар әдибә күңеленә балачактан, Ләкедә яшәү елларыннан ук кереп, сеңеп кала. Чөнки Ләке—керәшен авылы, шагыйрь Ямаш Игәнәйнең (1938-1997) туган төбәге. [Миңа заманында, дөресрәге 1964-1966" елларда Ләке тирәсендәге Чукмарлыда (Аяз Гыйләжев, Әзһәр Габидиләрнең туган авылы) мәктәп директоры булып эшләргә туры килгән иде. Шуңа күрә миңа да Ләке керәшеннәренең гадәт-йолалары шактый таныш. Шунысын да әйтим: Клара Булатова минем якташ та диярлек. Заманында минем туган авыл да Сарман районына кереп алган. Әнием дә Карамалы тирәсендәге Сарайлы авылыннан. Сарман районында мин Иске Кәшер урта мәктәбен тәмамладым. Бу төбәктә, университетны бетергәч, өч елдан артык эшләп тә алдым. Бертуган апам, туган-тумачаларым да хәзер Сарман районында яшәп ята].

Шагыйрәнең Ләкегә мөнәсәбәтле яисә аңа багышланган парчалары да бар. Шуларның берсе мондый юллар белән башлана:

*Җәйләр керсә гел алгысый күңел,*
*Гел үткәннәр искә төшәләр.*
*... Ләкеләргә ел да кайтыр идем,*
*Питрауларны бәйрәм итсәләр.*
*Ах, ул Питрау!*
*Билдән күмәр иде*
*Болыннарда чәчкә үләне,*
*Тирә-юньнән кунак килер иде!*
*Кыз-кырыны (кыркыны.—Х.М.), егет-җиләне.*

Өлгергәнлек аттестаты алгач, Клара Булатова берара Сарман райны Түбән Ләшәү башлангыч мәктәбендә балалар укыта. Аннан шагыйрәнең ярты гасырлык вакытны үз эченә алган Әлмәт чоры башлана. Биредә ул төзүче, көнкүреш комбинатында кассир, Төзүчеләр сараенда оештыручы һ.б. вазифаларны башкара. Шулай да аның төп шөгыле—укытучылык, әти-әнисенең профессиясенә тугрылык. Клара Булатова

инде менә 40 елга якын мөгаллимәлек йөген тарта: ул Колшәрип, Яна Кәшер, Түбән Мактама мәктәпләренә чирек гасыр буе шәһәрдән йөреп укыта, 10 ел буе Әлмәт татар гимназиясендә эшли. Инде хәзер, үзе килен булып төшкән Нәдер авылыннан йөреп, Әлмәт муниципаль институтында дистә еллап дәресләр алып бара. Бер шигырендә ул болай ди:

*Укытучы булып гомер иттем,*
*Укытучы идем!*
*Чын ихластан ул исемне йөрттем,*
*Шул эшемне сөйдем.*

Шунысын да әйтик: Клара Булатованың күркәм генә гаиләсе (ире Нәфис—офицер, улы Марс, оныклары) бар.

Үзе әдәби иҗат белән шөгыльләнгән укытучы, кагыйдә буларак, тел һәм әдәбиятның асылын, кыйммәтен, үзенчәлекләрен тирәнрәк тоя. Мөгаллимә Клара Булатова—шуның ачык бер мисалы.

Ул укыткан балалар арасыннан күпләгән педагогларның, журналистларның, әдипләрнең чыгуы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Аларның шактые (Камәрия Ямалетдинова, Атлас Гафиятов, Рәйханә Мирсияпова һ.б.) безнең университетта да белем алды. Клара Булатова шәкертләре тел-әдәбиятны, милләтне яратулары белән аерылып торалар иде. Димәк, шагыйрә үзендәге сыйфатларны укучыларына сеңдерә алган, милли дәвамчанлыкны тәэмин итүгә үзеннән сизелерлек өлеш тә керткән. Тикмәгә генә ана 1978 елда ук рәсми рәвештә “Укытучы-методист” исеме бирелмәгән.

Клара Булатова эшчәнлегенең янә бер мөһим тармагы бар: ул да булса Әлмәт телевидениесендә эшләү. Шагыйрә бу шөгылен мөгаллимәлектән аерылмыйча башкара. Ун ел эчендә ул “Җомга” программасында гына да халкыбызның рухы, гореф-гадәтләре, әдәбияты, сәнгате турында күпме тапшырулар оештырмады һәм тамашачыларны күпме күренекле, кызыклы затлар, мәдәният, мәгариф, фән әһелләре белән очраштырмады! (Алар арасында без фәкыйрегез дә бар иде). Аның халык теленә “Җомга апа” исеме белән кереп калуы да тирән, символик мәгънәгә ия. Әгәр дә шагыйрә:

*Һәр очраган үтә сәлам биреп,*
*Бар да таныш монда;*
*Очынып йөрим яшь чактагы кебек*
*Әлмәт урамында,*

—дип яза икән, бу сүзләрдә һичнинди дә арттыру юк,—бар да хак, раст.

Узган гасырның урталары һәм икенче яртысы—Әлмәтнең шаулап үскән, нефть башкаласына, мөһим мәдәният үзәкләренең берсенә әйләнгән еллары. Монда татар кызы, шагыйрә, мөгаллимә, журналист Клара Булатованың да өлеше зур. Әгәр дә Әлмәт нефтьчеләренең “Хәзинә” гәҗитендә: “Данлы Әлмәт каласының һәрбер таш пулатына Исемеңне язып була Клара Булатова” дигән юлларны басканнар икән, бу да юкка гына түгел, ә шагыйрә эшчәнлеген хакыйкый бәяләү.

Казан университетында уку да шагыйрәнең гомер юлында мөһим урынны били. Әле дә хәтеремдә: 1959 елның август ае. Университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә имтиханнар биреп йөрибез. 130 дан артык кеше. Бер урынга алты гариза. Әмма беребездә дә көнчелек хисе юк. Сөйләшәбез, аралашабыз, бер-беребез белән кызыксынабыз. Кечерәк кенә гәүдәле, куе бөдрә чәчле, бик хәрәкәтчән бер кыз аеруча игътибар үзәгендә. Оста сөйләшә, авызына каратып тота, арага шигъри юллар да катнаштырып җибәрә. Бу моңа кадәр матбугатта исеме еш ишетелгән Клара Булатова булып чыкты. Мин аны тәүге мәртәбә шунда күрдем. Аннан без ике еллап бер группада укыдык. Клара бик зиһенле, тырыш студент булып чыкты. Дәресләргә дә йөри. Күп кенә шагыйрьләрнең әсәрләрен яттан да сөйләп җибәрә. Ул аеруча үзенең чичәнлеге белән игътибарны җәлеп итә иде. (Бу сыйфаты, ягъни экспромт белән шигырь әйтүе аның хәзергәчә сакланган). КПСС тарихыннан беренче курста

безгә өлкән яшьтәге Шакир ага Еналиев керә иде. Тәүге дәрестә үк Клара аңа атап шигырь чыгарды. Тәнәфестә укытучыны култыклап алды да, шигырен укыды. Шул чак Шакир аганың нишләргә белмичә аптырап калуы хәзер дә күз алдында тора.

Бу елларда университетта иҗади вазгыять шактый көчле иде. "Әллүки" әдәби берләшмәсе гөрләп эшләде. Төрле кичәләр, күренекле әдипләр (Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нәкый Исәнбәт һ.б.) белән очрашулар еш була иде. Язучылар оешмасы да төрле кызыклы чаралар оештырып торды. Клара боларның һәммәсенең үзәгендә кайнады. Көндәлек матбугат битләрендә шигырьләре еш басылды. Әмма аерым сәбәпләр аркасында ул, ике еллап укыгач, университеттан китеп торды һәм кабат кайтып 1965-1969 елларда янә студент булды һәм уңышлы гына бу уку йортын тәгәлләде. Аның шигырь белән язылып, шигъри шәкелдә языланган шигърият турындагы диплом эше (аны русчалатып "Трактат о поэзии" дип әйтергә мөмкин) хәзергәчә кабатланмас (уникаль) күренеш буларак искә алынып килә. "Шигърият" дип исемләнгән шул күләмле хезмәттән аерым үрнәкләр:

*Шигърият ул—*
*Тереклекнең чиста елмаюы,*
*Ул—гөнаһсыз сабый көлүе,*
*Ул сабыйның якты күз карашы,*
*Аның көнгә якты сибүе...*
*Чибәр кызның бите аллану ул.*
*Балкуы ул,*
*тирән диңгез кебек,*
*Күкләр кебек зәңгәр күзләрнең;*
*Яки кара күзләр очкыны ул,*
*Яки бөдрә чәчләр дулкыны ул,*
*Мәрмәр сыны яки гүзәлнең,*
*Тибрәнүе иркә күкрәкләрнең,*
*Көмеш чыңы сихри тавышының,*
*Якты эзе олы шатлыкның ул,*
*Күләгәсе олы сагышның...*

*—...Шигърият ул*
*безгә Тукайларның*
*Биреп киткән җанлы мирасы.*
*Туган халкыбызның мәңге яшәр,*
*Мәңге сүнмәс олы иҗаты...*

## II

Клара Булатова, кайда гына укыса да, эшләсә дә, нинди генә вазифалар башкарса да, ул, иң беренче чиратта, шагыйрә. Бу аңа Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән сәләт, талант. Ул аның бөтен тотышында, холкында, сөйләмендә, эш-гамәлендә сизелеп тора. Үзенең "Тәрҗемәи хәлем"ендә К. Булатова болай дип яза: "Тормыш һәм иҗат юлым икесе бергә башлагандыр дип беләм: шигырьләрне үзем белә башлаганнан бирле чыгарам, нәкъ шулай "чыгарам", ә язам түгел. 1943 елның ачлыктан шешенеп-интегеп утырган кышында инде хәреф танысам да, кулыма каләм алып язмый идем әле. Әмма әллә күпме такмак туглаган телем инде...

*Мәрхәбәне урыныннан*
*Алып кына ташласы;*
*Паек та кайтмый, ичмасам,—*
*Кич әллә ни ашасы,*

—дигән... юлларны чыгаруга, әни мина шагыйрьлек язмышын юрап куйган иде... Сарман урта мәктәбендә укыганда минем байтак кына шигырьләрем район

газетасында гына түгел, республика матбугатында да басылып чыкты. Казанда ин беренче күренүем 1953 елда "Чаян" журналында булды".

Әлмәткә күчеп килгәч, К.Булатованың иҗади активлыгы тагын да арта. Бирелә ул әдәби түгәрәккә йөри, әдипләр белән очрашып тора, кинәш-консультацияләр ала. Республиканың гәҗит-журналларында, күмәк җыентыкларда аның шигырьләре бер-бер артлы басылып тора. Шагыйрәнең тәүге китабы — "Язлар алда" исемле шигъри җыентыгы 1967 елда нәшер ителә. Янадан ике елдан "Һәрвакыт янымда" китабы басыла. Гомумән, К Булатованың ике дистәгә якын китабы дөнья күргән. Арада чәчмә әсәрләр дә, балаларга атап чыгарылганнары да бар.

Күрәсез: шагыйрәнең дөнья күргән иҗат мирасы шактый күләмле. Ә бит әле аның басылмый калган язмалары да бар.

Һәр иҗат әһеле сәнгати яктан камил әсәрләр генә тудырырга омтыла. Әмма моңа һәрчак ирешеп булмый. Клара Булатова әсәрләре арасында да, аеруча башлангыч чорда, әдәби яктан йомшаграк парчалар, тезмәгә салынган гадәти юллар, конкрет факт-вакыйга белән мавыгулар, шигъри кабатланулар очрап куя. Әмма бу төр күренешләр аның иҗатында азчылык урынны алып тора.



*КДУның I курс студентлары-группадашлар. Сулдан уңга: Хатыйп Миңнегулов, Клара Булатова, Лена Таҗиева (Яруллина) һ. б. 1960 ел.*

Мин К. Булатованың язганнары белән азмы-күпме хәбәрдар кеше. Бу мәкаләне әзерләгән вакытта да янә бер мәртәбә шагыйрәнең китаплары белән танышып чыктым һәм шундый бер нәтиҗәгә килдем: Клара Булатова чын мәгънәсендә олы, талантлы әдибә. Ул күләм ягыннан гына түгел, ә мәгънәви, эстетик җәһәттән дә бай мирас, рухи хәзинә тудырган. Аның иҗатыннан башка соңгы ярты гасыр татар шигъриятен күз алдына да китереп булмый. Шагыйрәнең татар сүз сәнгатендә үзенә лаеклы мөхтәрәм урыны бар. (Юкка гына аның шәхесе һәм иҗаты 50-60 елларда ук Хәсән ага Туфан кебек бөек шагыйрьне дә илһамландырмаган икән шул!).

К.Булатова иҗаты хакында Н.Исәнбәт, С.Хәким, Ш.Маннур, Г.Афзал, Р.Гаташ, Т.Галиуллин, Р.Рахмани, Мансур Вәлиев, Л.Кәшфиева кебек әдипләрнең, тәнкыйтьчеләрнең дә унай, кызыклы фикерләре бар. "Аның шигырьләре,—ди, мәсәлән, Н.Исәнбәт,—чынлап та шигырь. Анарда бай хиссиятләр теле, тоткарсыз тойгы, табигый агым бар". Г.Афзал фикеренчә, "Клара Булатова шагыйрь булып туган кеше, шигырь җанлы, шигырь җенле, фанатик шагыйрә, талантлы, бик популяр шагыйрә ул".

Кабатланмас шәхесләр генә иҗатка сәләтле. К.Булатова да әнә шундый затларның берсе. Аны беркем белән дә бутап булмый: аның үз йөзе, үз холкы, үз карашы, үз гомер юлы бар. Нәкъ әнә шул үзенчәлекләр шагыйрә иҗатының асылын, төп эчтәлеген билгели, бөтенләеген тәэмин итә. Аның чичәнлеге хакында инде алдарак сүз булган иде. Бу сыйфат әдибәнең күп кенә әсәрләрендә нык сиздерә. Ул еш кына, ничектер, язучыдан бигрәк, сөйләүчене хәтерләтә. Әйтерсен, автор үзенең шигъри юлларын, укучыдан бигрәк, тынлаучыга, аудиториягә сөйләп тора: аңа дәшә, мөрәҗәгать итә, ике арада диалог-әңгәмә кора. Аның теленнән, табадан төшкән коймак кебек, хикмәтле, йомры сүзләр чыгып кына тора.

К.Булатова һәм язма әдәби мирасны, һәм мифология, фольклорны камил белә, дөресрәге, болар аның күнеленә сеңгән, зиһени хәзинәсенә әйләнгән. Шуна күрә ул татарның образлы фикерләү үзенчәлекләрен, сурәтле код-детальләрен,

архетипларны яхшы тоемлый, тыңлаучы белән автор мөнәсәбәтләрен уртак бер дулкынга көйли белә. Аның иҗатындагы мәкаль-әйтемнәр, алынма поэтик юллар, традицион сурәтләр, мифологик элементлар тырпаеп, күзгә ташланып тормый, ә әсәрнең гомуми аһәңе, төп текст тукымасы белән табигый керешеп китә. Мәсәлән, бер шигырендә автор фольклордагы бер җырның юлларын ала да, аларны үз фикер-тойгыларына туры килешле тезмәләр белән яраклаштыра.

*Җырлаучыга көй кирәк,*
*Җанга җылы сүз кирәк.*
*Җырласаң да, еласаң да,*
*Уйласаң да түз, йөрәк*
*"... Җырлаганда, ят та ярый,*
*Елаганда, үз кирәк".*

Хәзерге әдәбият фәнендә "интертекстуаль алым" дип йөртелгән бу күренеш шагыйрә иҗатында еш һәм уңышлы гына кулланыла.

К.Булатованың күпчелек шигырьләре традицион, классик форма-шәкелләрдә, җыр, такмак, мөнәҗәт үлчәмнәрендә язылган. Хәтта ул бер шигырен мишәр татарларының табын җыры формасында, ягъни өч юллык строфа рәвешендә дә иҗат иткән:

*Хәсрәтләрем карадыр...*
*Хәсрәтләрем каралыктан*
*Чәчләрем агарадыр.*

Шуның белән бергә К.Булатованың шигъри техника, форма өлкәсендә эзләнү-тәҗрибәсе дә кызыклы гына. Ул урыны белән аерым сүзләрне, юлларны кабатларга, үлчәм-вәзеннең, рифма-кафиянең, строфаның төрле шәкелләрен, вариантларын кулланырга да ярата.

*... Бу җырларда бернинди дә яңалык юк,*
*Көйләр шул ук, сүзләр шул ук кала әле,*
*Ә шулай да,*
*Ә шулай да*
*Син аларга колак салып кара әле.*

* * *

*Бүтән килмә минем яныма син,*
*Куркыныч ут минем йөрәктә.*
*Сүнеп барган утка кагылма син,*
*Син яңадан аны көйрәтмә,*
*Син яңадан аны дөрләтмә...*

К.Булатованың аерым шигырьләре моноспектакльне хәтерләтә. Аларда автор үз-үзе белән сөйләшә, бәхәс кора.

*Булмаганны!*
*"Сөйми башлады",—дип,*
*Ник сөйлисең юкны?*
*Кит әле!*
*Сөйми башлар өчен, башта сине*
*Яратырга кирәк бит әле...*

* * *

*... Кояш көлеп торган җәйге көндә*
*Көтмәгәндә аяз ил күген*

*Кара болыт килеп каплаганны*
*Күрдеңме син? –*
*Ә мин, мин күрдем...*

Гомумән, автор шигъри янгырашка, аһәңлелеккә нык игътибар итә. Мөгаен, шунадыр да аның күп кенә парчаларына композиторлар тарафыннан көйләр дә язылган ("Су буенда кыяк үлән", "Шушы яктан, шушы туфрактан без", "Кыңгырау чәчәкләре", "Асылмалы күпер", "Якын дустың барын онытма" һ.б.).

Шагыйрә иҗатында кызыклы шигъри табышлар, отышлы сурәт-детальләр еш очрап тора.

*Өндәү билгеседәй туры*
*Калырга күпме тырыш -*
*Сорау билгесе шикелле*
*Бөгә дә куя тормыш...*

* * *

*...Миңа һәрвакыт бары егерме,*
*Тик... ике ярым егерме генә.*

* * *

*... Каеннардан сары яфрак төште,*
*Өзгәләнә күңел...*
*Җан яраткан, күңел тарткан кешем*
*Үземнеке түгел,*
*Үземнеке түгел.*
*Ах, минеке түгел,*
*Үземнеке түгел.*

* * *

*Каеннар саргайган, чигәләр агарган.*
*Күңелләр, әйтерсең, яшь-яшьләр.*
*Һаман да сөяләр, һаман да көтәләр*
*Ярлары кайтмаган кәләшләр.*

Антитезалы, контрастлы фикерләү татар шигъриятендә элек-электән күзәтелә. К.Булатова да бу алымга еш мөрәҗәгать итә. Әмма ул капма-каршылыкларның диалектик берлеген, гармониясен дә тудырырга омтыла.

*... Яшь аралаш көлеп гомер итәм,*
*Елап яшим көлке аралаш...*

* * *

*Ерак ярларны чорный һәр төнне*
*Томан да сыман, төтен дә сыман.*
*Кайтыр көнеңне сагынып көтүе*
*Рәхәт тә сыман, читен дә сыман.*

К.Булатова—лирик, лиро-эпик, эпик әсәрләр авторы. Алар җыр, багышлау, робагый, поэма, хикәя, повесть, кыйсса, истәлек һәм башка жанрларда.

Аның шигъриятендә лирик башлангыч өстенлек итә. Уй-кичерешләр, хис-тойгылар, тәэссорат-эмоцияләр әдибә әсәрләренең төп эчтәлеген билгели. Лирик каһарман һәм автор образы аның иҗатында шактый якын һәм еш кына үзара керешеп тә китә. Алар өчен ихласлылык, тормышчанлык хас. Романтик күтәрелеш, тойгылар да тәмам чынбарлыктан аерылып китми. Бу хакта кайвакыт автор үзе дә искәртә:

*Еракларда зәңгәр һава төсе...*
*Хыялларда йөзеп чыгарлык.*
*"Берни дә юк анда",—дигән төсле—*
*Итәгемнән тота чынбарлык.*

Лирик герой, авторның үзе кебек үк, актив табигатьле, хәрәкәтчән. Бер шигырен ул юкка гына "Терекөмеш булу кирәк миңа, Болай яшәү өчен" (ягъни"барлык жиргә, бөтен эшләргә" өлгерү өчен), — дип тәгәлләми.

Еш кына "Сүз сәнгате бер, аны ир-ат, хатын-кыз әдәбиятына бүләргә ярамый",—дип әйтергә яраталар. Гомумән, бу фикер дөрес. Әмма хосусый планда ул бәхәсле. Чөнки хатын-кыз физиологик җәһәттән генә түгел, ә психологик, тоемлау, фикеркичерү ягыннан да ир-атлардан билгеле бер дәрәҗәдә аерылып тора. Бу сүз сәнгатендә дә ачык чагыла. Күп кенә җыр-бәетләрнең, мөнәҗәтләрнең, гәрчә авторлары күрсәтелмәсә дә, хатын-кызлар тарафыннан иҗат ителүе бәхәс тудырмый. Газизә Сәмитова, Заһидә һәм Сания Гыйффәтләр, Сажидә Сөләйманова язган шигырьләрдә дә хатын-кызларга хас лиризм, эмоциональлек сизелеп тора. Клара Булатованың "Бала тудыру йортында" шигыре мондый юллар белән башлана:

*Ир-хатынга дөнья уртак, диләр,*
*Монда түгел ләкин уртагы...*
*Бу дөньяның ирләр белми торган,*
*Белә алмый торган почмагы.*

Шагыйрәнең лирик каһарманы—бай табигатьле, сизгер, тәэсирләнүчән хатынкыз. Ул мәңгелек мәхәббәт утында да яна, баласы, гаиләсе өчен шатлана һәм борчыла да; замана болгавырлыгы аның җанын да кимерә. Иң мөһиме: бу героиня битараф, ваемсыз, гамьсез түгел. Ул бөтен күңеле белән кешеләрне гафләт йокысыннан уятырга, рухи яктан пакьләргә, җәмгыятьтә инсани мөнәсәбәтләр урнаштырырга омтыла, шушы изге юлда яна, көя. Шунысы кызыклы: шагыйрәнең лирик каһарманы (һәм автор үзе дә) үз-үзенә тәнкыйди караш та ташлый: "... Без акылдан чынлап яздык бугай,—Акыл керер чакта", "Иске-москы киеп, мин бичара, Экраннарга чыгып утырам. "Туган телем", "Иман, денем" диеп, Нишләп йөргән булам, котырган. Шигырьләрең, жырың кемгә кирәк? Кемгә кирәк үзен, ниһаять?..."

Туган жир, туган туфрак һәркемгә якын, үз. Нәкъ шуңа күрә дә бу хакта күпләгән әсәрләр иҗат ителгән. Болар арасында К.Булатованың да матур-матур парчалары бар. Аның "Шушы яктан, шушы туфрактан без" шигыре үзе генә дә ни тора!

*... Шушы яктан, шушы туфрактан без,*
*Читтә йөрсәк, шуңа күрәдер,*
*Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,*
*Таллар җырлап төшкә керәдер...*

Шагыйрә еш кына туган табигать белән керешеп китә: әйтерсең, елга-сулар, тал-өянкеләр, былбыл-сандугачлар аның ишләре, сердәшләре. Әмма туган жир өчен ул үзен җаваплы да саный:

*... Елгаларга төшеп сулар алам,*
*Йолдызларга карап уйланам.*
*Туган җирем, мин бит бар гамеңне*
*Йөрәгенә җыйган бер балаң...*

Шагыйрә өчен туган жир, табигать, әби-бабай, ата-ана аерылгысыз төшенчәләр.

*... Әткәм печән чапкан аланнарны,*
*Әнкәм җиләк җыйган аланны.*
*Шул чактагы бөтенлеге белән*
*Хәтер генә саклый аларны.*

К.Булатовада вакыт, гомер агышын тою көчле. Ул аны яз, җәй, көз, кыш фасыллары, аккан сулар, искән җилләр, яна ел тематикасы аркылы сурәтләргә ярата. Шагыйрә аларны рухи халәт белән янәшә дә, капма-каршы да куя, ике арада гармоник мөнәсәбәтләр дә урнаштырырга тырыша.

*Безнең дә бит яшьлек бар иде:*
*Дүрт фасылы елның яз иде...*

* * *

*Кырык яз,*
*Кырык җәй,*
*Кырык көз,*
*Кырык кыш.*
*Ах, кайчан үткән бу?!*
*Кырык яшь—картлыкның яшьлеге,*
*Яшьлекнең картлыгы икән бу..*

К.Булатованың озын-озак иҗат юлында эчке бер эволюция дә күзәтелә: нечкә лиризм арта, уй-кичерешләрдә табигыйлек, фәлсәфи яңгыраш көчәя. Шагыйрәне гомер узу, рухи кыйммәтләрнең югала баруы борчый. Аның иҗатында сызлану, сыкрау кебек экзистенциаль мотивлар арта бара. Юкка гына ул соңгы китапларының берсен *(Казан, 2003.—148 б.)* "Әрнү" дип исемләмәгәндер.



*Рәдиф Гаташ, Клара Булатова һәм Разил Вәлиев. 1982 ел.*

Клара Булатова шагыйрә генә түгел, чәчмә әсәрләр авторы да. "Яшел каләм" китабына *(Казан: Рухият, 2003. 160 б.)* аның хикәя-повестьлары, истәлекләре тупланган. Дөрес, әле аларның кайберләренә әдәби гомумиләштерү, психологик дәлилләү җитеп бетми. Шулай да гыйбрәтле хәлләрне, аянычлы язмышларны гәүдәләндерүләре белән бу язмалар игътибарга лаек. "Кара кыйсса" хикәясе—спектакль өчен менә дигән материал. "Яшел яфрак—яшәү төсе" повесте да драматик табигатьле. Анда Анна исемле керәшен кызы белән Миңлегали арасындагы мәхәббәт күнелләрне тетрәндерерлек итеп тасвирлана. Повестьның шигъри юллар белән тәмамланган ахыры да мәгънәле, ямансу:

*Яшел яфрак яшел Торыйсын*
*"Ни хәлләр?" дип никләр сорыйсың?*
*Яшел яфрак—яшәү төседер,*
*Торыйсыннар яшьлек өчендер.*

"Яшел каләм" китабына өлешчә автобиографизм да хас. Андагы вакыйга-хәлләр, "Ләрия" һәм "мин"нәр аркылы без авторның да тормыш юлын, рухи халәтен шактый дәрәҗәдә күзаллыйбыз. Шунысы кызыклы: К.Булатова үзенең чәчмә әсәрләрендә дә, ничектер, шагыйрә булып кала. Аларда субъектив башлангыч, эмоциональ мөнәсәбәт көчле, шигъри юллар да очрап куя.

Автобиографизм, шигъриятлек аеручa эпистоляр төзелешле "Искәндәр кыйссасы"на хас. Ул, Урта гасыр әдәби традицияләрен дәвам иттереп, чәчмә һәм тезмә юлларны катнаштырып язылган. Бу әсәр Хәсән Туфан һәм Клара Булатова шәхесләрен, иҗатларын аңлау, танып-белү ягыннан бигрәк тә мөһим. Әмма бередәге Тәнәкә һәм Искәндәр реаль шәхесләр генә түгел, ә билгеле бер әдәби гомумиләштерүләргә, романтик яңгырашка ия булган сәнгати образлар да.

* * *

Клара Булатова инде менә 50 елдан артык шигъри бәйгедә, туган теле өчен изге көрәштә. Бу чорда аңа юлларның тигезен һәм чокырлысын үтәргә дә, көннәрнең аязын һәм болытлысын күрергә дә, хисләрнең татлысын һәм ачысын кичерергә дә туры килгәндер. Әмма кечерәк кенә гәүдәле, шашкын күңелле бу зат һич тә туктап калмый, һаман алга бара, яшәү мәгънәсен, гомер фасылларының асылын аңларга омтыла. Аның хис-кичерешләргә бай, халыкчан рухлы, афористик яңгырашлы шигырьләре уйландыра, дулкынландыра һәм — иң мөһиме—яшәүнең кадерен белергә, хәтер дәвамчанлыгын тояpга ярдәм итә. Шагыйрәнең бер парчасында бөтен кайгы-газапларны, тетрәнүләрне, йөрәгең түзсә, үткәрергә, кичерергә була диелә.

*...Кайнар яшьләреңне йотып була,*
*Вакытсыз, дип, агып бетмәсен.*
*Хисләреңне тыеп тотып була, —*
*Ә йөрәк соң, йөрәк нишләсен?*

Бу сорауга, мөгаен, "янсын" дип кенә җавап бирергә кирәктер. Чөнки шагыйрьгә йөрәк яну-көю өчен бирелгән. Моңа кадәр, Клара ханым, янып-көеп яшәдегез, калган гомерегез дә шигърият, туган тел, милләт, табигать, инсаният өчен янып-көеп үтсен!

*... Гомернең, шушы гомернең*
*Минеке калганнары—*
*Үтмәгән, китмәгәне дә,*
*Бетмәгән, җитмәгәне дә*
*Бар әле, алда әле.*

Амин, шулай булсын!

*январь, 2006.*

Зиннур
МАНСУРОВ

*Әхмәт Рәшиткә 70 яшь*

# "МӨМКИН" БЕЛӘН "ТҮГЕЛ" АРАСЫ

Мәңгелек Илаһи затның илчесе итеп җибәрелгән пәйгамбәрләр дә чынбарлыкта аерым заманнарның адәми яшәеше җирлегендә күзаллана. Фани дөнья гамьнәре белән янып яшәүче шагыйрьләргә исә баштанаяк үз чорының улы булып калырга язган. Гомумән, заман рухына буйсынмаган иҗатчы асылда бөтенләй туа алмыйдыр. Мондый хәл бик табигый, чөнки теге яки бу дәвернең жете мөһере сугылган әсәрләр генә чорлар алышынган вакытта үзләренең рухи кыйммәтләрен югалтуга дучар ителмәскә мөмкин. Ә яшәү мәгънәсен чагылдырган иҗатының киләчәк язмышы кайсы каләм әһелен генә бимазалап тормый икән?!



Үзеннән-үзе аңлашыла торган мондый гадәти зарурият югарылыгыннан караган чакта, шагыйрь Әхмәт Рәшит артыгы белән замана баласы буларак күзаллана. Әйе, артыгы белән замана баласы, чөнки шулай әйтергә җирлек бар. Үзебез шаһит, үтеп киткән гасыр гаять каршылыклы иде: иҗтимагый, социаль, идеологик яктан гына түгел, шуларга бәйле рәвештә, кешелек асылын билгели торган рухият җәһәтеннән дә. Әлбәттә, мондый җирлектәге яшәеш кысаларында замандашлар төрлечә халәт кичергәннәр. Әле бит тәкъдирнең үзенчәлекләре дә була. Әйтик, Тукайны кыска гомере буена эзәрлекләгән "печать проклятия"ләр, үзебезчә гадиләштереп әйткәндә, "кара сакал"ларның язмышка әрнеткеч "төзәтмә"ләр кертеп торуы. Тоташ драматизмнан гына торган егерменче гасыр исәбендә мәхәббәт сакчысы тарафыннан үгисетелгән затлар бихисап исәпләнәдер. Кемнәргәдер тиңләштерергә теләмим, әмма тугыз яшеннән (!) бөтенләй ятим калган Әхмәт Рәшитне дә күпмедер дәрәҗәдә "ят яратылган" иҗатчылар җөмләсенә кертмичә булмый.

Шагыйрь биографиясендәге ошбу хәл-халәткә басым ясап үтүем йомшак күңелле укучыларымны хискә бирелдерергә теләүдән түгел. Хикмәт шунда, гомер юлының шулай аянычлы башлануы булачак иҗатчыда тирән эз калдыра. Нәкъ менә шушы фаҗигаи гаҗизлек аның яшәү рәвешенә үҗәтлек белән катгый искәрмәләр кертә, шәхеснең холык-фигыленә дә үз хасиятләрен өсти, хәтта язу алымын барлыкка китерүдә дә драматик асылын әледән-әле сиздереп торырлык йогынтысын ясый. Ун яшьлек малайның шигырьләр яза башлавы да газиз әти-әнисен югалту тетрәнүләренә турыдан-туры бәйле. Хәер, истәлек рәвешендә язылган бер мәкаләсендә ул әлеге бәйләнешне үзе дә искәртә. "...Гаҗәп матур иде дөнья ул көнне,—дип искә ала шагыйрь.—Язны мактап шигырь язмасаң, гөнаһ булыр төсле иде. Сугыштан соңгы авыр елларда алдагы көнгә фәкать өмет белән караган,

күгәрчен гөрләсә дә, күзләренә мөлдерәмә яшь тулырга торган, йөрәгенә әрнүле моңнар оялаган миндәй ятим бала өчен бигрәк тә шулай".

Шигърият сәнгатьнең иң мәһабәт төре булып саналса да, шигырь кешеләргә ләззәт бирер өчен генә язылмый. Бигрәк тә татарда. Юк, шигърияттә "тормыш елмаюы" гына чагыла алмый, чөнки яшәешебез сөенечле мизгелләрдән генә тормаган. Халыкның уй-гамен аһәңле сүз белән аңлатып биргән бердәнбер сәнгать төре буларак, шигърият инде күптән татарның туктаусыз сызлануючы җан авазын яңгырату чарасына әверелгән. Кулына каләмне бик яшьли алган Әхмәт Рәшит тә безнең шигърияттәге үтәли мотивны баштук дөрес тойган.

*Без халыкка хак сүз әйтү өчен,*
*Өзелгәнбез аның бәгыреннән.*
("Антидөньялардан атыла тора...")

*Малайлыктан чыгар-чыкмас борын*
*Чырайларга кунды кырыслык...*
("Идеаллар искә төшкәндә")

Чыннан да, йөрәгенә кече яшьтә үк салынган җөй аны күзгә күренеп өлкәнәергә мәҗбүр итә. Балачакта язмыш сынавын кичергәннәр өчен, гадәттә, тормыш чынлыгы чагыштырмача кырысрак булучан. Шуңа күрәдер, Әхмәт Рәшит ирексездән газиз халкына ныграк елыша һәм үзен яшьли халык улы итеп тоя башлый. Иҗатының башлангыч чорында язылган "Минем шәҗәрәм", "Автопортретка штрихлар", "Варислар" кебек поэмаларында аеруча анык сиздергәнчә, шагыйрь үзенең яшәве белән әти-әнисен генә түгел, ә туган кавеме элгәрләрен дә дәвам итә. "Ә аталар узган данлы юллар Бүгенгегә килеп тоташкан,—дип искәртә ул "Минем шәҗәрәм" исемле поэмасында.—Алар каны хәзер безгә күчкән, Җир нур җыйган кебек кояштан...". Гомумән алганда, аның авыр югалтулардан башланган язмышы халык язмышының бер өлеше буларак күзаллана.

*Гасырларны иңләп атлап киләм,*
*Үлми,*
*сүнми,*
*армый,*
*ялыкмый.*
*Бабамнарны барлыйм.*
*Мин—бер улы*
*Татар дигән батыр халыкның.*
("Гасырларны иңләп...")

Сизеләдер, Әхмәт Рәшит иҗатында аллы-гөлле күбәләкләргә мөкиббән китү кебек сентиментальлек бөтенләй диярлек очрамый. Аның инануынча, фидаилар башын Себер җибәргән татар шигыре татлы десерт вазифасын үтәүдән ерак тора. Шигъриятькә педантлык килешми. Бу җәһәттән моңлы җилкенчәк кулына иядәшкән пегас төпкә җигелеп тартучы ат хезмәтен дә үти. Башкача әйткәндә, Әхмәт Рәшит әсәрләре нигезендә яткан халык гаме риторик алым нәтиҗәсе рәвешендә түгел, ә җан-рух биографиясе җирлегендә яңгыраш алган йөрәк авазы буларак кабул ителә. Моң сирпеп торган менә шушы якты гамь аңа әдәби иҗатта да, иҗтимагый эшчәнлектә дә талант көчен бер олуг максатка тупларга ярдәм итә. Ә шагыйрьнең тулы ачылган таланты күпкырлы булуы белән аерылып тора. Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов билгеләп үткәнчә, "Әхмәт Рәшит иҗаты идея-тематик һәм жанр ягыннан шактый төрле. Ул иҗтимагый-социаль, мәхәббәт, фәлсәфи мәсьәләләр хакында уйлана, үзенең уй-хисләрен лирик шигырь, поэма, мәдхия, мәсәл, җыр, робагый жанрларында шәкелләштерә, балалар өчен дә самими, үтемле шигырьләр иҗат итә".

Табигате белән тыныч кешеләр язучы вазифасын күтәрә алмыйдыр. Каләм әһеле тыштан сабыр күренсә дә, ул асылда "эчке янулы" булырга тиеш. Аны намус

тынгысызлыгы һәрдаим уяу тота. Битарафлык иҗатчы холкына салынмаган. Дөрес, сабырлык белән тәвәккәллек арасындагы чикне күпләр атлап чыгарга җөрьәт итми. Илдә хөкем сөргән кануннар да баш калкытырга теләүчене тыеп тота. Ә менә Әхмәт Рәшит әле 8 нче сыйныфта укыганда ук бу куркыныч чикне бозар өчен үзендә азмы-күпме батырлык таба. Әлеге вакыйга болайрак була. Элекке Олы Тархан районы үзәгендәге мәктәпкә күчкәч, әти-әнисез калган малайга фатирда торырга туры килә. Фәкыйрьлек үксез җанны кыен хәлдә калдыра. Киеме сәләмә. Кеше почмагында ачлы-туклы яшәүдән анын тәкате тәмам корый. Өмет чаткысын да күрсәтмәгән шундый кара көннәрнен берсендә ул, төбәктәге ятим балаларга ярдәм сорап, Иосиф Сталиннның үзенә мөрәҗәгать итәргә карар кыла. "Письмо на татарском языке..." Гап-гади дәфтәр битенен өске өлешенә әүвәл шундый сүзләр язып куела. Гәрчә хатны кемнендер ярдәме белән урысча яза алыр булса да, ул үзенен үтенечен "халыклар атасы"на саф ана телендә бәян итә. Мөгаен, әлеге балаларча үҗәтлек гамәле шагыйрьнен милләтпәрвәрлек сыйфатларын көчәйтүгә китергән беренче җитди адымы булгандыр. Мөрәҗәгать эзсез югалмый: юлбашчыдан ТАССР Югары Советы аша килеп төшкән җавап хаты яшь буынга кайгыртучанлык күрсәтергә бурычлы эреле-ваклы түрәләрне аякка бастыра...

Каләм әһеленен "общественный кеше" булырга тиешлеген әлегә тирәнтен аңлап бетермәсә дә, ул үзеннән-үзе тормышта рөхсәт ителгәннен чикләрен киңәйтү омтылышы белән яши башлый. Өметсезлеккә бирелми, чөнки ышана: "Мөмкин" белән "түгел" арасында Күзгә күренмәстәй күперләр бар...". Казан дәүләт университетынын өченче курсында укыган чакта Әхмәт Рәшитнен мәктәп елларындагы тәвәккәллеге янә кабатлана. СССР җитәкчесенә хат юллаунын җаен белгән студент инде Никита Хрущевка мөрәҗәгать оештырырга ният кыла. Максаты—Татарстан радиосынын татарча тапшырулар вакытын арттыру. Биш йөзләп имза белән җибәрелгән хатка Мәскәү Кремле хуҗасыннан унай җавап килә.

Билгеле, каршылыксыз тормыш булмаган кебек, каршылыкларга кермичә, әдәби әсәрләр дә тудыра алмыйсын. Яшәешнен әлеге хасияте шагыйрьләргә аеруча кагыла. Чорнын һәртөрле киеренкелеген йөрәге аша үткәргән иҗатчы ничек инде шәхси кичерешләрендә генә казынып ятсын?! Иҗтимагый күренешләрнен күзенә туры карый белергә өйрәнгән һәм үзе дә драматик "массовка"ларда катнашкан шагыйрь буларак, Әхмәт Рәшитнен язганнарында заманнын кискен каршылыклары, кешенен җан-рух сызланулары шактый тулы чагыла. Бу табигый, чөнки авторнын һәрбер әсәре нигезендә уйлап чыгарылмаган кырыс чынбарлык ята, һәм әлеге дә баягы эмоциональ мәгълүмат анын халәте рухиясендә һәрвакыт мөлдерәп тора. Иҗатташым үзе үк искәртеп үткәнчә, "Җан тетрәткеч ачы хакыйкатьләр Кереп поскан безнен күзләргә...". Өстәвенә, яшьли кителгән күнел үзенә күпне сендерүчән. Шул ук вакытта шагыйрьнен башы өстендә әти-әнисе генә түгел, ерак гасырларда яшәп киткән аксакаллар да тукып тора кебек.

*Ә сезгә әле яшисе—*
*Җир сөреп, ашлык чәчеп*
*Һәм үзсүзле дөнья белән*
*Көн саен бәхәсләшеп.*

("Васыять")

*Татар булып яшәүләре*
*Бу дөньяда, ай-һай, авыр!..*

("Зар")

Һәм Әхмәт Рәшит яшь варисларын барлап торучы элгәрләргә гомеренен аерым бер биеклегеннән үзенчә җавап та бирә:

*Урадым тузанлы юлларны—*
*Еракта калдылар эзләрем;*
*Дөньянын бүгенге хәленнән*
*Олы бер хакыйкать эзләдем.*

("Урадым")

*Безнең әле килер заманнарда*
*Әллә нинди эшләр кыласы бар;*
*Үз иманын, үз йоласын тотып,*
*Татарның чын татар буласы бар.*
("Без—бар!")

Әлбәттә, хакыйкать биеклегенә күтәрелү җинел генә бирелми. Мондый максатка йөз төбәп барган чакта, гадәттә, урау юллар аша үтәргә туры килә. Читкә тайпылулар да булгалап тора. Һәм алданулар да... Бу уңайдан әдәбият белеме классикларының "Барыннан да элек—идея!" дигән уртак кагыйдәне алга сөрүләре искә төшә. Анысы шулайдыр, әмма каныңа сеңдерелгән идея аерым төзәтмәләргә мохтаҗ булса?! Ерактагы балачакта Сталин белән хат алышкан Әхмәт Рәшиткә тора-бара нинди генә идеологияләр мәктәбен үтәргә туры килмәгән. Диссидент каләм әһелләре берсен-берсе кабатлап әйткәнчә, язучы өчен хакимият тарафыннан эзәрлекләнү түгел, ә кешелексез идеологиянең әгъвалавы күпкә куркынычрак. Совет чорындагы тоталитар сәяси системаның котылгысыз көчле басымы Хәсән Туфан кебек классик дәрәҗәдәге әдипләрнең дә башын бутады. Анларга тырышып карагыз: уналты ел дәвамында сөрген михнәтләрен кичергән тәҗрибәле шагыйрь илнең халкын эзәрлекләүче юлбашчыларга мәдхия укуын барыбер туктатмады (?!). Төгәлрәк әйткәндә, татар шигъриятенең алтын хәзинәсенә керәчәк кабатланмас иҗат мирасында аның күпмедер дәрәҗәдә "кызыллык" йөгертелгән әсәрләре, ягъни үзенең җинаятьчел асылын әледән-әле күрсәткәләп торган режимга карата лояль мөнәсәбәтен белдергән шигырьләре дә байтак. Яудан соң батырлар күбәя, дигәндәй, хәзер мондый четерекле мәсьәлә уңаеннан акыл сату әхлакый яктан бик үк урынлы да түгелдер. Әле туксанынчы елларга кадәр күп кенә шигъри китаплар Ленин бабабызга багышланган әсәрләр белән ачылып китә иде. Монысы инде әлеге дә баягы вөҗүдкә үтеп кергән коммунистик тәрбиядән, намуслы шәхеснең иман рәвешендә сеңдерелгән сәяси тәгълиматка үзенчә бирелгәнлегеннән киләдер. Боларның бөтенесе дә инануга бәйләнгән. Андыйларны гаепләүдән Аллам сакласын!..

Совет идеологиясе сынавын һәркем үзенчә кичте. Һәм шагыйрь Әхмәт Рәшит тә. Әйе, ил күләмендәге бу шаукым аңа да кагылып үтте. Гәрчә үзе балачакта иҗтимагый көнкүреш шартларына карата тискәре мөнәсәбәтен белдергән "гыйсьянчылык" гамәлен кылса да, шагыйрь булып өлгергәч, ул шушы җәмгыятьнең башбаштак хакимнәренә өлешчә дан җырлауга корылган "Иптәш коммунист" исемле поэмасын язды. Үзе әлеге фиркадә торган булса, аның хәлен анларга да мөмкин. Юк, бу ялкынлы тарафдарның патриотик бурычын үтәве булмады, сәяси вәзгыять йогынтысына ихтыярсыз бирелүнең бер нәтиҗәсе иде. Дөресен генә әйткәндә, мәҗбүри вазифалар өстенлек алган совет хакимияте чорында кысу алымнары иҗатчыларга карата да киң кулланылды. Әйтик, Язучылар берлегендә эшләп килгән шигърият секциясенең 1961 елда үткәрелгән бер утырышында шагыйрь Әхмәт Рәшитне "иҗтимагый әһәмияткә ия булган темаларны күтәрмәүдә" гаепләп чыгалар. Бу очракта нинди темаларга өстенлек бирелергә тиешлеге беркетмәдәге фикер сөрешеннән һәркемгә яхшы анлашылса кирәк. Мәҗбүрилек төсмерендәге тәкъдим үзенең эшен башкара: Нурсолтан, Гәүһәршат, Сөембикә кебек "иҗтимагый" кызларыбыз "табу" тузанында күмелеп ятканда, ерактагы Америка коммунисты Анджела Дэвислар татар шигырендә үрнәк итеп куела... Шунысы бик тә сөендерә, Әхмәт Рәшит "Шигырьләремнән танырсыз..." исемле мәкаләсендә "урра-патриотлык" ягына авышып алуын үзе дә таныды; "гөнаһлы" саналган әсәрләрен сайланма җыентыкларына кертмәде һәм замана чиренә бирешүне шигырендә дә гаепләде:

*Көндәмлеккә шундый күнегелгән—*
*"Ур-ра!" дидек хәтта ялгышка;*

*Үз-үзенә үлем карарын да*
*Каршылады кемдер алкышлап.*
("Заманалар...")

Форсат чыкканда әйтеп үтим, үз иҗатына тәнкыйди карый алган затларны шәхсән үзем ихлас хөрмәт итәм. Хәйләкәрлек катыш зирәклеге белән беренче очрашуымда ук үзенә җәлеп иткән олпат шагыйребез Сибгат ага Хәкимнең, сөйләшеп утырган чакта, башлангыч иҗат чорының берничә елын бөтенләй сызып атарга теләге барлыгын көрсенеп әйткәне әле дә хәтеремдә. Өлкәнәя барганда кетелмәстән классик югарылыкта яза башлаган Нури Арслановның да элеккерәк шигырьләренә беркадәр оялыбрак каравы шагыйрьнең дусларына яхшы мәгълүмдер. Нибары сигез елда биниһая зур иҗат мирасы калдыруга ирешкән бөек Тукаебызга да, "Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылган чүпләрем", дип, киләчәк буыннардан үзенә карата бераз мәрхәмәтлерәк булуларын сорарга иксез-чиксез горурлыгы комачау итмәгән. Үзенә үзең ревизор булу, һичшиксез, һәркем өчен зирәклек билгесе. Кызганыч, бездә хәзер "конвейерга салып" язылган бихисап әсәрләренең һәркайсын да яхшыга санаучылар артык күбәйде, андыйларны исә үзләре исән-сау чагында иҗатларын җиз иләк аша үткәрү мәсьәләсе бөтенләй борчымый.



*Гариф Ахунов белән Әхмәт Рәшит*
*Әхмәт Исхакка (уртада) 80 яшь тулган көн.*
*Май, 1985 ел.*

Кайбер ялгыш адымнарны кичекмичә тану зарурлыгы турында фикер йөрткәндә, каләмдәшем Әхмәт Рәшит белән Украинага сәфәр кылуым искә төшә. Донецк шәһәрендә яшәүче милләттәшләребез өчен махсус оештырылган әдәби очрашулар барышында безне татар җырларына кергән атаклы Донбасс шахталарының берсенә алып төштеләр. Нәкъ шахтерларча киенеп алдык. Тау эшләре коткаручылары төркеме җитәкчесе кунакларны үзе озатып йөрергә булды. Тирәнлек ярты чакрым чамасы. Күмер төялгән вагончыклар янәшәсеннән забойчылар "мич"енә таба үтәбез. Аяк асты юеш, кысанлык, дымлы бөркү һава. Күмер чыгаручылар юлы шулкадәр тарайды ки, без инде шуышып барырга мәҗбүр булдык. Җитмәсә, яктылык та чамалы. Мүкәләү озакка сузылды. Шулчак "гид"ка әйтеп куйдым: "Барысына да түзәрбез, чөнки изге Казаныбызга якынаеп барабыз бит!" Коткаручылар башлыгы көлеп җибәрде... Серле көлүнең сәбәбен шахта идарәсе бинасында эленеп торган карталарга баккач кына аңладык: сәфәрдәшем Әхмәт абый Рәшит белән бөтенләй капма-каршы якка таба шуышып барганбыз икән! Мондый ук үкенечле хәлләтне күптән кичергәнем юк иде...

Җир өстендәге юлларның катлаулырак булуы мәгълүм. Иҗтимагый тормыштагы юнәлешләр дә һәрдаим үзгәреп торучан. Кешеләр арасында аумакайлык көчәйде. Сәясәттә "пычраклык микъдары"ның артуы да дәүләти зирәклекнең тоныклануына китерде. Ике төрле хакыйкать хокукый яшәеш алды. Хәтта руханилар да сәясәткә ныклап кергән заманда, әлбәттә, халык язмышыннан аерылгысыз шагыйрь читтә кала алмый. Әмма мондый һәртөрле ыгы-зыгыдан ул күпмедер өстенрәк булырга бурычлы. Һәрхәлдә, шушы максатка омтылырга тиештер.

Үзенең иҗатында кискен сыйфат үзгәреше ясарга ният кылган Әхмәт Рәшит сиксәненче еллар башында тарихи әсәрләр язуга ныграк игътибар итә башлый. Күңеленә яшьли кереп урнашкан милләт гаме аны бай тематик катламнарга китереп

чыгара. Зур максатка муафыйк адым эчке сиземләү нәтиҗәсе дә, чөнки туган халкына чынлап хезмәт итәргә алынган шагыйрь күпмедер дәрәҗәдә тарихчы чалымнарына да ия булырга тиеш. Югыйсә мәдәни хәтергә нигезләнмәгән әсәрләр эшләнеш ягыннан көпшәк килеп чыгучан. Өстәвенә, совет чоры мәктәбендә үтелгән тарих курсы татар балалары өчен үтә кыска булып чыкты, хәтта иң фаҗигале 1552 елыбыз да күпчелек укучыларның күңелендә тирән уелып кала алмады. Бу җәһәттән шагыйрь Әхмәт Рәшит хөр фикерләүгә юл ачкан яңа хәбәрдарлык шартларында нәкъ менә шушы һәлакәтле еллар тирәнлегенә беренчеләрдән булып төште һәм Сөембикә ханбикәбез образы аша татар халкы кичергән гаять авыр сынау чорының социаль-драматик асылын мөмкин кадәр тулы чагылдырган поэма иҗат итүгә ирешә.

Дөнья әдәбияты мирасыннан күренгәнчә, элекке заманнарда тарихи поэмалар ничектер риваять кылу рәвешендәрәк язылган. Мифлар шигъриятенең булуы да безгә яхшы мәгълүм. Әлбәттә, мондый тенденцияләр татар әдәбиятында да тамыр җибәрерлек җирлек тапкан. Ә халык иҗатында чагыштырмача күбрәк тә. Безнең заманның нәкъ менә сиксәненче еллары башында, искәртеп үткәнемчә, шигърияттә тарихилыкка ирешү өчен яңа мөмкинлекләр ачылды. Чын тарихи вакыйгаларга нигезләнгән шигъри әсәрләргә татар халкында ихтыяҗ аеруча зур иде. Аңлашыла ки, кырыс чынбарлыкта тәрбияләнгән Әхмәт Рәшит әлеге мөмкинлектән бик вакытлы файдаланды. Югарыда телгә алынган “Сөембикә” поэмасын кабул итәргә киң җәмәгатьчелек, аеруча гаммәви мәгълүмат чаралары хәтта әзерләнеп тә җитмәгән булып чыкты. Тыю мөһере сугылган тарихи чынбарлык сәхифәләренең кинәт ачылып китүе күпләрне инде күнегелгән иске гадәт буенча өркетеп җибәрде бугай: шагыйрь үзенең каләмен кыю рәвештә иркен җибәреп язылган тарихи әсәрен башта аерым өзекләр хәлендә генә шигырь сөючеләр игътибарына тәкъдим итә алды.

Тарихка авышкан Әхмәт Рәшит теманы үзләштерүдә эзлеклелек күрсәтте. “Сөембикә” поэмасыннан соң “Колшәриф” язылды. Аннары “Мөхәммәдъяр”... Тарихи затларыбызга багышланган әлеге әсәрләр әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде. Чыннан да, шигъри трилогияне хәтерләткән бу поэмалар бер-берсен тулыландырып кына калмыйча, халкыбызның күптән көтелгән тарихи сурәтенә җете шәрехләр дә өстәде. Шагыйрьнең сонрак дөнья күргән “Казан” поэмасы исә үзенчәлекле хатимә, шушы мөкатдәс теманы беркадәр гомумиләштергән эпилог буларак кабул ителә. Гүяки халкыбызның мәдәни-тарихи хәтере белән ашланган иҗатчы хәтере гасырлар өстеннән очып бара, бер-берсеннән аз-маз үзгәрәк язмышлы буыннарны вакытның бәлзәмле җебе белән үзара бәйләргә омтыла, бүгенге иректе кысуга китергән кичәге иҗтимагый тәртипсезлекләрнең киләчәккә сабак булырлык сәбәпләрен эзли. Гомумән, Әхмәт Рәшитнең дәрсе гыйбрәт алырлык тарихи әсәрләре безгә үткәннән киләчәккә барырга үзенчә ярдәм итә.

Мантыйкчылар искәрткәнчә, акылның берьяклы эшчәнлеге иҗатта бертөрлелеккә китерә. Бу уңайдан Әхмәт Рәшиткә хафага төшәрлек сәбәп юк—ул шигъриятнең һәммә юнәлешендә дә үзен бердәй иркен тоя. Күргәнебезчә, зур иҗат потенциалына ия булуны таләп иткән поэма жанрында да шагыйрь кыйсса-дастаннары белән данлыклы әдәбиятыбыз хәзинәсенә саллы өлешен кертә. Хәзер инде аның әлеге шигъри төргә караган унбишләп әсәре бар. Алар эчтәлекләре ягыннан да, шәкелләре җәһәтеннән дә төрле. Шулар арасыннан “Йолдыз вакыты белән” исемле поэмада, минем карашымча, авторның эзләнүчән холкы аеруча калку чагылыш тапкан.

*Мин камиллек эзлим тереклеккә,*
*Камил акыл эзлим заманнарга;*
*Мин яхшыны телим дәвамнарга,*
*Мин яманны телим тәмамларга...*

Бу юлы шагыйрь гасырлар өстеннән генә очып калмый, җанын һәрдаим ымсындырып торган очсыз-кырыйсыз галәм киңлекләренә чыга. Табигый ки, киңрәк орбитага чыга барган саен шигъри гомумиләштерүләр дә зурая бара. Бу гөнаһлы җирдә үзе ачкан хакыйкатькә ул шул рәвешле еракка китеп карарга җөрьәт итә. Хәер, ниндидер илаһият белән өртелгән шигырь үзе дә безгә шушы тарафлардан

инәдер кебек тоела. Нәкъ менә шундый биеклектән автор үзен дә эченә алган инсаниятнең асыл йөзен, дөнья халыклары язмышында газиз кавеменең насыйп кылынган вазифаи урынын ачыграк күрергә тели. Ә илаһи биеклектән барысы да уч төбендәге кебек күренә икән бит. Кешелек кырмыска оясын хәтерләтә. (Хәер, Коръәнгә кертелгән әлеге сөйкемле җан ияләрен гайре камиллектә һич тә гаепләргә теләмим). Зурдан кубып кылынган кайбер гамәлләр шулкадәр дә беркатлы булып тоела. Кайчак көләсе дә килеп китә. Аерым мәхлукларның үзләре турында ныграк кайгыртулары аркасында халык кадәр халык әледән-әле фаҗигага дучар ителә. Мондый чакта йөрәк өзгәләнә. Адәм пәйгамбәрнең шундый балалары өчен, валлаһи, еш кына оятка көч килә...

Кояш сукмагыннан шагыйрь бара. Аның үзенчә инануы бар: "Бу дөньяны үлчәп булмый өч яссылык белән...". Хәтта ел фасылларының да бишенчесе булырга тиеш. Исбат ителмичә нигез итеп алынган кадими постулатлар нилектән әле икейөзле янусларның фикерләвен аклап килә? Сорау арты сорау туа. Атомнар әллә ничә кисәкчеккә бүлгәләнеп беткән заманда шагыйрь кайбер шиклерәк аксиомаларны да ватарга омтыла. Шул ук вакытта әсәр герое үзенең "анти-мин"е белән каршылыкка керә. Гадиләштереп әйткәндә, берсе югарыга омтылган саен тегесе аның чабуыннан тарта. (Хәтта күкнең үзендә дә татарлык кабатлана икән).

*Анти-минем иске фәлсәфәсен*
*Адым саен төшереп тора искә;*
*Юк, барыбер туктап кала алмыйм—*
*Мин камиллек эзлим яшәешкә...*

Бер уйлаганда, үткәннәрне инде кайтара алмыйсың, киләчәкнең ничек булачагы билгесез. Димәк, алар—юк (?!). Менә шуларны бүгенгедә ничек үзара бәйләргә? Әлбәттә, әлмисактан килгән тамырлар үткәннәрне киләчәккә тоташтыра. Без маргиналлар түгел. Әгәр дә бүгенге дөнья йөзендә җиде миллионлап татар яши икән, милләт шәҗәрәсен тәшкил иткән кардәшләрне исәпләргә саннар җитмәс иде. Теләсә нинди халыкны шундый тамырлар яшәтә. "Үткәнемнән барам иртәгемә—Барам шулай мәңгелеккә табан", дип белдергән шагыйрь, һичшиксез, Аллаһ тарафыннан яралтылган газиз кавеменең озын гомерле булуына тирәнтен ышана. Алай гына түгел, язмыш юлын йолдыз вакыты белән үлчәп, аңа ерак киләчәктән лаеклы урын барлый.

Күренә ки, Әхмәт Рәшитнең фикерләргә сәләтле кешене иксез-чиксез уйлануларга чакырган әлеге поэмасында, аеруча "Пәйгамбәрләр канлы байрак тотып..." кебек юлларында, Һади Такташ иҗатының беренче "гыйсъянчылык чоры" аһәңнәре дә яңгырап куя. Ә инде әсәрдәге "Мин—Кеше!" рефрены Литва шагыйре Эдуардас Межелайтисны искә төшерә. Юк, әлеге охшашлык чалымнары кемнедер кабатлау юлына кучүдән түгел, зур гомумиләштерүләрдә башка олуглар белән фикердәш булудан килә. Ышанып әйтергә мөмкин, Әхмәт Рәшитнең "Йолдыз вакыты белән" исемле лирик-фәлсәфи поэмасы татар шигъриятенең югарылыгын күрсәтүче әсәрләр рәтенә керергә хаклы. Кызганыч, менә шундый үзенчәлекле иҗат уңышына үз вакытында тәпле бәя бирүче табылмады. Нишләмәк кирәк, куанычлы хәбәр ирештерүче кәрваннар да бездәрдә элек-электән соңарып килгән.

Инде җиргә төшеп, шуны искәртәсе килә: Әхмәт Рәшитнең күпкырлы иҗаты белән тулаем танышкан чакта аның рухиятен ачып бирүче хасиятләр җитерәк булып күренә—замана мәдәнияте белән баетылган фәһемлелек, дөньяга караш киңлеге, чынбарлыкны аңлау тирәнлеге, фикерләү ачыклыгы, онытыла башлаган төп идеалларга күзләрне зуррак итеп ачтыру... Гадәттә, теге яки бу әсәрдә әлеге сыйфатларның чикләнгәнлеге сизелсә, сүзнең очы үзеннән-үзе каләм әһеленең тәрҗемәи хәленә барып тоташа. Иҗатка шушы яктан караганда, Әхмәт Рәшитнең күпчелек әсәрләре нәкъ менә тормыш белеменә, шәхси тәҗрибәгә таянган булулары белән аерылып тора. Балачакта ук гамьле ир-егет кыяфәтенә кергән шагыйрь, яклаучысыз калуы аркасында, чынбарлыкның сынауга тиң сабакларын артыгы белән алган. Гомер юлының һәрбер борылышы аңа үзенчә тәҗрибә өстәгәндер: Казан

дәүләт университетында белем алуын вакытлыча өзәргә мәҗбүр булып, ерак Төркестан тимер юлында тауар поездларын озатучы вазифасын башкару да, югары уку йортын тәмам иткәннән соң төрле җаваплы урыннарда эшләү дә, элекке СССР буйлап иҗат сәфәрләренә йөрү дә, шулай ук Һиндстан, Япония, Төркия, Кипр, Греция, Сингапур, Малайзия кебек илләргә чыгып гыйбрәт алулар да... Менә шуңа күрә, анарда тормыш матурлыгын яисә ямьсезлеген уйлап чыгару ихтыяҗы юк. Тоник анда йокымсыраган мәгънәсез хикмәтләр шагыйрьнең табигате өчен бөтенләй ят.

Рухи маяга ия булган шагыйрь, билгеле, иҗатта үзен чагыштырмача иреклe тота. Чынбарлык күренешләрен бөтен киңлегендә колачлый алган Әхмәт Рәшит әсәрләрендә дә аерым тормыш деталенең шигъри образга иркен күчешен тоемларга мөмкиндер. Аның сәнгати күзаллавы, гадәттә, мантыйк кысаларыннан чыкмый. Һәм шигъри сурәтләү алымнары ягыннан ул аңлы төстә реалист булып кала. Язу өслүбе тотнаклы—сабырлык сизелеп тора. Шул рәвешле ачык итеп фикерләргә омтылу шагыйрьне үзеннән-үзе сурәтләү ачыклыгына алып килә. Гомумән, татар классик шигыренең гасырлардан күчкән реальлеге Әхмәт Рәшитнең күңеленә шактый иртә кергән. Шагыйрьнең тотрыклы тезмә шәкелгә өстенлек бирүе дә аның әлеге традицион мәктәпкә тугрылыгын күрсәтә. Алда китерелгән шигъри өзекләр дә моның шулай булуын раслый. Барысы да табигый. Пыяла өргәндәге кебек: эчтән чыккан тынның нинди уй-гамьнәр белән корылган булса, үзен күрергә теләгән бәллүр дә шундый рәвешне ала. Сере бик гади. Шул ук классиклар искәрткәнчә, чынбарлык формасы ягыннан түгел, үзенең асылы белән матур.

Галиҗәнап каләм шуңа төшендерә: камил дәрәҗәдәге язу рәвешенә ирешү барыбер телне өйрәнүгә кайтып кала. Сүз белән эш итә белү, әйе, иҗатта мөһим роль уйный. Менә бу яктан Әхмәт Рәшит үзен бәхетле итеп саный ала—тел-өслүб осталыгының беренчел нигезе аңа шагыйрьлек таланты белән бергә бирелгән: җөмләләре төзек, сүзләре үз урынында, теле сыгылмалы... Тел җәһәтеннән ул тезмәдә дә, чәчмәдә дә һөнәрмәндләрчә эш итә. Язганын мөкәммәл дәрәҗәгә җиткерүдә, кемнәрдер шикелле, читләрнең ярдәменә мохтаҗ түгел. Киресенчә, телнең нечкәлекләрен яхшы белгән мөхәррир буларак, мондый хезмәтне башкаларга үзе күрсәтергә мөмкин. Сүз байлыгы зур. Дөрес, дөньяга киң итеп ачылган күзләр белән караучы шагыйрь кайвакыт алынма сүзләр куллануда үтә интернациональлек күрсәтә шикелле. Нәзберэклеге белән аерылып торган татар шигыре тукымасына ул нинди генә кәлимә яисә сүзтезмә кертеп җибәрми! Менә аларның кайберләре: ноосфера, апокалипсис, инфузория, $\Sigma=mc^2$ , гипоталамус, квадратура, дилемма, генетик код, хеви металл, homo sapiens... Дөрес, боларның уй-хис агышына күпмедер ятыш булганнарын авырлык белән "йотып" та җибәрергә мөмкин, вәләкин сүзләр сайлаудагы мондый чамасызлык шагыйрь иҗатының миллилек нисбәтен саклауга хезмәт итмидер. Тезмә әсәрләрдә искәрмә рәвешендә бирелгән астөшермәләрнең артык күбәеп китүе дә шигъри дулкынга корылган күңелне ничектер җайсызлык халәтенә өстерәп кертә. Тарихка мөрәҗәгать иткәндә, әлбәттә, аларның булуы зарурдыр. Әммa лирик кимәлдә язылган әсәрләрдәге сәнгати чынлык күпчелек очракта үзе турында үзе сөйләргә тиеш. Телебез мөмкинлекләре чиксез. Бары тик иҗтиһат итәргә генә кирәк. Хәер, иң кирәкле алыштыргысыз сүзне сайлап алуның кыенлыгын, иҗатның җаваплылыгын шагыйребез үзе дә искәртеп үтә:

*Туксан тугыз мәгънәсез сүзгә каршы*
*Бердәнбер мәгънәле сүз табып кара!..*

("Баш шәрифләренә акыл кирәк тә...")

*Шигырьләр олау-олау да,*
*Илаһи сүз сирәк.*
*Дөньяга юл күрсәтердәй*
*Пәйгамбәрләр кирәк.*

("Шигърият")

Әдәби әсәрләрне ачы балан кабып укучы кайбер нәзберэк затлар өчен Әхмәт Рәшитнең реаль җирлектәге шигъри дөньясы ап-ачык булып тоелырга мөмкин.

Алар да хаклы. Зәвыгы булган кеше шуны сизмичә калмас: бу шагыйрьнең язганнарында җинел генә аңлатып бирә алмаслык ниндидер эстетик мөлаемлык бар. Әлеге мөлаемлык нигезендә, минемчә, күңелнең ихласлыгы ятадыр. Чыннан да, ихласлык сәнгать әһеленең иң кирәкле сыйфатларыннан берсе булып санала, гомумән, һәртөрле иҗатны үтәли сафландырып торучы бәрәкәтле чыганак рәвешендә күзаллана. Табигый ки, әгәр авторның күңеле мондый башлангычтан мәхрүм икән, аның әсәрендә әлеге нигъмәт чагылыш таба алмый. Димәк, язучы булу таланты гына җитми, кеше булу таланты да кирәк. Безнең Әхмәт Рәшитебез дә "Бу юлы мин тудым Кеше булып, Бу тууым—шигырь язар өчен", дип тикмәгә генә әйтмәгән. Шагыйрь өчен аеруча мөһим зирәклеккә дә ихласлык аша гына ирешеп буладыр. Шундый югарылыкка күтәрелгән акыл ияләре әлеге зарурият турында кат-кат искәрткән.

Хәтта сокланырга мөмкин, ихласлык Әхмәт Рәшит күңеленә мөлдерәп торырлык итеп салынган. Юмартлык белән мулдан бирелгән самимилек, күрәсең, үксез җанда ундырышлы җирлек тапкан. Кайчак аның тормыштагы аерым гамәлләренә карап, "И, сабый күңелле шагыйрь!" дип тә әйтәсе килә. Риячылар белән тулы безнең чуардан-чуар дөньяда, әйе, артык эчкерсез затларга җиңел дә түгелдер. Әмма ана сөте аша ингән шушы бәһаләп бетергесез сыйфат каләм иясенә укучы белән ихлас әңгәмә корырга ярдәм итә. Бу яктан шагыйрь Әхмәт Рәшитнең күпчелек әсәрләре, минем карашымча, үзара ышанычка корылган булулары белән аерылып тора. Җырларын гына алыйк. (Ә мондый нәзакәтле жанрга садәлек аеруча мөһим шарт). Менә аларның кайберләре: "Беренче мәхәббәт", "Зәңгәр күлмәк", "Язгы гөлем", "Тәрәзәләр язга елмая"... Күпләребез раслар, бу җырлар белән инде берничә буын үсте. Аларны белмәгән татар юктыр. Шагыйрь өчен бу бәхет түгелмени?! Әлеге җырларның инде дистәләрчә еллар дәвамында онытылмыйча яшәве, барыннан да элек, авторның ихласлык белән баетылган лириклык талантына килеп тоташадыр. Юк, җырда алдап булмый. Кеше җанының тирәнлекләрен яктыртып күрсәтү өчен үз җанының эчтән балкып торуы зарур. Әмма дөнья бу, каләм ияләренең дә төрлеләре бар: күңелендә сумала кайнатып, үзләрен фәрештәгә санаучылар да, тормышта монафикъларча уйнап, ихлас булып кыланучылар да... Тик әдәптән аерылгысыз әдәбият ясалмалыкны кабул итә алмый: холыктагы мондый сыйфатларның һәммәсе дә ак кәгазьгә барыбер саркып чыга.

Каләмдәшем Әхмәт Рәшитнең иҗатын тулаем күздән кичерү мине аның үзе хакында гына түгел, гомумән, бүгенге шигърият һәм заман турында бер-берсенә тыгыз бәйләнгән менә шундый табигый уйлануларга этәрде. Моның өчен җирлек бар, чөнки шагыйрьнең авыр сынаулардан торган гомер юлында чорның каршылыклы агышы шактый тулы чагылыш тапкан. Ничек кенә булмасын, үзенә тиешле "чирәм җир"не ул сабыр рәвештә сөрә бирә. Исеме тирәсендә ниндидер шау-шу куптарып эшләүне бөтенләй яратмый, шунадыр без ана кайчак игътибар да итмибез бугай. Хәер, бериш мәгълүм исемнәрне эченә алган "обойма"ларга сыймаучы Әхмәт Рәшит үзе дә әдәбият мәйданында Роберт Әхмәтҗан, Рәшит Әхмәтҗан сыман беркадәр аерымрак тора кебек. Дан-дәрәҗә белән бозылмаган. Тәүге шигъри юллары белән танылу алып килгән әсәрләре арасында байтак еллар ятса да, ул үзенә күктән бирелгән әлеге дә баягы эстетик мөлаемлыкка һәрвакыт тугры булып кала. Сүз дә юк, аның шагыйрьлек холкы күпмедер үзгәрмичә калмагандыр, әмма иҗатының саф-чиста үзәге метаморфозалар кичермәгән. Һәм әлеге асыл сыйфатлар авторның бер-берсен тулыландыручы барлык әсәрләрен тоташ картинага берләштергән чакта, ягъни төрле елларда язганнарын күңелдән тулаем үткәргән мәлдә бөтен төсләре белән ачылып китә. Үзеннән-үзе шундый нәтиҗәгә киленә: туган халкына тугры хезмәт итүче Әхмәт Рәшитнең иҗаты, чыннан да, татар шигъриятенең мөһим бер буыны булып күзаллана икән.

♣

## Александр Филиппов

# ГӨРГӨРИ

**Гөргөри... Григорий Родионов... Ул ук—Гәрәй Рәхим, татар шагыйре, җәмәгать эшлеклесе... Шул ук вакытта менә дигән керәшен дә**

Григорий Васильевич Родионов—минем университет сабакташым. Шуңа күрә аның турында мин күп белергә тиеш. Биш ел буе бер тулай торакта яшәдек, бер үк суны эчтек, стипендия алган атналарда күрше тулай торак ашханәсендә тукланып йөрдек, ә күбрәк гомуми кухняда үзебез пешереп ашый идек... Азык-төлек әйберләре арзан иде ул чакта, ипи-чәйгә генә калган вакытларда бер тәңкәгә бер атна яшәп була иде. Гриша итне пешәр-пешмәс, ягъни чиле-пешле килеш ашарга ярата.



—Алай файдалырак, витаминнары яхшы саклана,—дия торган иде.

Ул Рөстәм Мингалимов белән бер бүлмәдә яшәде. Алар аерылмас дуслар иделәр һәм шулай булып калдылар да. Аларны язучы Шамил Бикчурин шагыйрь Әнвәр Давыдов кулына тапшырган. Ә Әнвәр абый исә, көн аралаш диярлек, тулай торактагы ике дус яши торган бүлмәгә килеп, аларның хәл-әхвәлләрен белеп китә иде. Гриша белән Рөстәмнең тулай торакта кер үтүкләү бүлмәсе янында нәкъ ике кеше кереп утырышлы үз иҗат "лаборатория"ләре бар иде. Өченче кеше аңа утырып та, басып та—берничек тә сыя алмый. Бүлмәдәге ыгы-зыгыдан качып, шунда кереп бикләнәләр дә, тәмәке пыскыта-пыскыта көне-төне шигырь язалар, имтиханнарга әзерләнәләр...

Мин аларның икесе белән дә дустанә мөнәсәбәттә булдым. Хәтта Гриша белән икебез бер үк төрле авыру белән җәфаланып та йөрдек әле. Бер михнәтнең бер рәхәте, дигәндәй, ел саен бер ай буена ашату-эчертүне дәүләт үз өстенә ала иде. Бу яман чирдән мине язучы Гадел Кутуйның сеңлесе, танылган журналист һәм язучы Диас Вәлиевнең әнисе, Татарстан һәм Россиянең атказанган табибәсе, Ленин ордены кавалеры, күп кенә фәнни хезмәтләр авторы, фтизиатр Зәйнәл Мөхәммәт кызы Кутуева җолып калды. Бу урында Зәйнәл апаның дөньякүләм танылу тапкан "Тапшырылмаган хатлар" әсәрендәге төп героиня Галиянең прототибы булуын да әйтеп үтү урынлы булыр. Бу асыл затның якты истәлеге безнең хәтерләрдә мәңге саклана.Безгә тормыш бүләк иткән өчен мең-мең рәхмәт аңа!

Григорий Родионов исә дәвалануын университетны тәмамлаганнан соң хастаханәдә дәвам итте. Монда үлем белән якалашып ятканда ул әнисе Фекла Григорьевна һәм әтисе Василий Семенович Родионовларга багышланган "Көннәр язга авышкач" дигән повестен тәмамлады.

Бу әсәрендә аның башка берни белән дә чагыштырып булмый торган туган ягына, аны дөньяга китергән, күп кыенлыклар аша тормыш кичкән әти-әнисенә, якын туганнарына, авылдашларына, дус-ишләренә, таныш-белешләренә, романтик хисләр белән сугарылган яшьлегендәге беренче мәхәббәтенә, аны дәвалаучы табибларга дустанә, эчкерсез мөнәсәбәте чагыла. Сагыш, үлем кебек авыр кичерешле төшенчәләр турында язганда да Григорий Родионов җор теллелегеннән читкә китми. Ул шуның белән күнелгә әллә нинди авырлык китерердәй

вакыйгаларны да жинел укылышлы итеп бирә. "Көннәр язга авышкач" повесте— үзенең тукымасы ягыннан алганда документаль әсәр. Андагы һәрбер персонажга тормыштагы исемнәрен куеп чыгарга мөмкин. Һәркайсының характеры шулкадәр оста итеп бирелгән ки, чын исемнәрен куй да укы гына! Язучы үзенең тумыштан бирелгән шаянлыгын, җорлыгын кушып, документаль җирлектә чын нәфис әсәр тудыруга ирешкән.

Григорий Родионов—Габдулла Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе шагыйрь һәм прозаик Гәрәй Рәхим—1941 елның 15 июлендә Татарстан Республикасының Шөгер (хәзерге Лениногорск) районы Федотовка (Аналык) авылында колхозчы гаиләсендә туган. Туган ягы турында сүз чыккач ул:

—Районның Шөгер булган чакларын сагынып яшибез,—ди. —Шөгер, дигәч, ничектер аның табигате күз алдына килә, аның турындагы җырлары искә төшә. Шуңа күрә районның элекке исемен кире кайтаруны күтәп йөргән якташларым бик күп.

Григорий Васильевич миңа үзенең туган авылы турында сөйли. Ә мин ул сөйләгәннәрне үземнең Зичәбашым белән чагыштырып барам. Гүя ул минем авылда туган да, минем күршедә торган. Авыл шулкадәр матур! Кемнең туган авылы матур түгел инде... Тауның буеннан-буена көмеш сулы чишмәләр челтерәп агып тора. Әнә, авылдашым Ксенофонтий агай Антонов махсус санап чыккан. Чакырым ярымга сузылган авылга 43 чишмә туры килә. Утыз биш метр саен бер чишмә! Авылның уртасыннан су ага, Аналык инеше. Безнекен дә Зичә елгасы ярып уза. Тау. Тау битеннән урман башлана. Мондый чакта бер әйбернең икенчесенә охшашлыгын керәшеннәрдә "суйган да каплаган", диләр. Монда да шул! Әле повестьны укыгач искә төште—кызыл балчыклы тау битендә сикергәләп йөри торган кызыл канатлы чикерткәләренә кадәр шул ук бит!

—Безнең яшьлек табигать белән бик нык бәйләнгән,—дип сөйли Григорий Васильевич. —Су буенда балык тотулар, урманда кышка житәрлек гөмбә, җиләк, чикләвек җыюлар дисеңме... Урман кисүләр, печән чабуларны әйткән дә юк инде. Ул вакытларда көндез бернәрсә дә эшләп булмый иде. Төшке якта әзерләгән печән яки утынынны ат белән төнлә генә алып кайта аласың...

Ә көндезләрен—колхоз эше. Бәйрәмгә барган кебек йөри халык колхоз эшенә. Озын арбаларга төялеп эшкә барганда да, аннан кайтканда да моңлы керәшен җырлары яңгырый. Авылдан тугыз чакырым ераклыктагы Колмаксар басуына кунатөнә эшкә китүләр үзенә күрә бер бәйрәм төсен ала. Алар арасында үзенең шаян шигырьләре белән авылдашлары арасында танылып өлгергән Григорий Родионов та була. Ул вакытта урта мәктәпне тәмамлаучылар үз теләкләре белән беркая да чыгып китә алмыйлар иде. Ил башлыгы Никита Хрущевның чакыруы нигезендә һәр яшь кеше институтка керер алдыннан ике-өч ел житештерү сферасында эшләргә тиеш сыман куелган иде. Гриша да башта колхозда, аннары авыл китапханәсендә ике ел эшләп ала. Бу эш аның холкына да килеп тора, чөнки яшьләр арасында оештыру эшен ана куш инде! Әле жиденчеләрдә укыганда ук үз очындагы яшьтәшләре арасында лидерлыкны үз кулына алып, 14 малайдан торган исемсезнисез генә яшерен оешма төзеп куя. Мондый фикер аңа Александр Фадеевнын "Яшь гвардия" романын укып чыкканнан соң килә. Бу оешма әгъзаларының һәркайсына үз араларындагы бер рәссам малай паспорт ясап тапшыра. Монысы ук инде ул вакытта Россиядә урнашкан тәртипкә, хокуксызлыкка каршы чыгу буларак бәяләнергә тиеш була. Әгәр сизгән булсалар, әлбәттә. Дөрес, бу оешманың эшчәнлеге тау башына менеп шигырь укудан, кичләрен жылы мунчада әкият сөйләп утырудан, "паспорт"ларны фуфайка мамыгы арасына яшереп тегеп куюдан узмый. Монда әле ул шигырь язуга, аны тау башындагы таш "трибуна" артыннан иптәшләренә кычкырып укуга да уен эш итеп кенә карый торган була. Шуңа күрә беренче шигырьләрен дә беркая да җибәрми. Шулай да әдәбият укытучысы класс саен кульязма журнал чыгара башлагач, беренче шигырьләрен шунда тәкъдим итә. "Яшь каләм" дип аталучы бу журналларның бер нөсхәсе хәзер дә әле Григорий Родионовта иң кадерле ядкарь буларак саклана.

Жыр-биюгә хирыс керәшен авылларында, гадәттә, үзешчән сәнгать түгәрәкләре көчле була. Аналыкта да көчле була ул. Халык телендә аның рәсми исеме бик сирәк кулланыла. Жырларда да гел шушы исеме янгырый. Кышын-җәен спектакльләр әзерләп, күрше авылларга гастрольләргә чыгып китәләр. Шулай итеп, авыл клубына бәрхет пәрдә алып эләләр, баян сатып алалар. Концертларны, гадәттә, Гөргөри алып бара торган була. Гомумән, концертлар оештыруның төп өлеше аның өстенә төшә. Аның бик тә артист буласы килә. Аның бу хыялын күреп торган авылдашлары, классташлары, укытучылар да канат куеп тора.

—Синнән менә дигән артист чыга, Казанга театр училищесына бар,—дип, аны мәктәпне тәмамлау белән үк шул елны гына яңадан эшли башлаган училищега озаталар.

Ул вакытта театр училищесы Күчмә театр белән бергә Кремльнең Спас манарасында урнашып, аның директоры драматург Риза Ишморат була. Авыл малае, Казанга килеп, ял көне булганлыктан, директорны өенә барып таба. Иртәгәсен аңа имтихан оештыралар. Шигырь сөйләтәләр, эпизод уйнатып карыйлар... Барысы да яхшы бара кебек тоела Гөргөригә. Бер шарт куялар:

—Барысы да килә... Тик чыжылдаучы тартык авазларың чыкмый, шуны ике көн эчендә төзәтәсең, син безнеке...

Шатлыктан авыз колакка җитә. Анысы гына "чепуха" дип уйлый ул. Казан урамыннан "с", "ч", "ш" авазлары кергән сүзләрне кычкырып барганда аңа барысы да гаҗәпләнеп карап кала. Әмма бер урнашкан артикуляцияне тиз генә төзәтеп булмый икән шул. Хәзер дә ул бу дефектыннан котыла алмаган, аның юморга бай шигырьләре үз укуында "классно" яңгырый. Шулай итеп, татар театр сәнгате характерлы рольләрне уйный алырлык менә дигән бер артистын югалткан, дигән фикер туа. Аның артист булу хыялы университетка укырга кергәч тә сүнмәде бугай. Мин университетның татар театр студиясендә аның белән өчме-дүртме спектакльдә бергә уйнавыбызны хәтерлим. Безнең режиссерларыбыз төрле елларда Татарстанның халык артисты Ибраһим Гафуров, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Гали Хөсәенов, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы Гәүһәр Камалова булдылар. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты режиссер Равил Тумашев та, безнең уенны карап, үзенең киңәшләрен бирә торган иде.

Артист була алмагач, Гөргөри, биштәрен асып, яңадан туган авылына кайтып китә дә китапханәдә ялгыз калган вакытларында шигырь язу хәстәренә керешә. Бер дәфтәр шигырьләрен районның "Ильич васыятьләре" газетасына юллый. Шуннан сайлап алып, аның "Язгы җыр" дигән бер шигырен бастырып чыгаралар. Бу 1960 ел була.

—Ул газета килгән көн минем өчен искиткеч шатлыклы булды,—дип искә төшерә хәзер Григорий Васильевич. —Авыл буйлап күтәреп йөрдем. Әллә ниләр булган кебек инде менә! Әгәр дә миннән, бәхет нәрсә ул, дип сорасалар, шушы мизгел белән үземне олы бәхет кичергән кеше дип саныйм. Шуннан соң мин тиз арада тагын бер дәфтәр тутырып җибәрдем. Бер мәлне редакциядән миңа чакыру килеп төште. Бардым. Шамил абый Бикчурин утыра тегендә. Тетмәмне тетеп ташламасыннармы болар! Бер шигыремне дә алмадылар. Ашыккансың, егет, дип кайтарып җибәрделәр. Шигырь язуның никадәр җитди эш икәнлеген шунда төшендерделәр...

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге беренче чыныгуны район газетасының әдәби иҗат берләшмәсендә алган Григорий Родионовка чын-чынлап язучылык эшенә керешергә киң юл ача. Андагы мохит шуны таләп итә. Университет студентлары янына татар әдәбиятының аксакаллары килеп йөри, лекцияләрне танылган әдәбият һәм тел галимнәре Хатыйп Госман, Нил Юзеев, Ибраһим Нуруллин, Зәет Мәҗитов, Мостафа Ногман, Диләрә Тумашева, Вахит Хаков, Альберт Фәтхи һ. б. укый. Хәзер боларның һәркайсы легендар шәхесләр бит. Өйрәтәләр дә, таләп тә итә беләләр. Бирелә укыган елларда Григорий Родионовның чын иҗат җимешләре Гәрәй Рәхим имзасы астында вакытлы матбугатта еш күренә башлый. Студент елларында ул университет каршындагы

әдәби-иҗат түгәрәге эшендә иң актив катнашучыларның берсе була. Сонрак бу түгәрәкнең җитәкчесе итеп тә сайлана. Аның "Вәгъдә" дигән беренче шигырьләр җыентыгы университетны тәмамлаган елны басылып чыга. Аннан соң озакламый "Чәчәк сатучы малай" дигән хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. 1968 елда аны СССР Язучылар союзы әгъзалыгына кабул итәләр.

"Татарстан яшьләре" газетасында эшләү еллары ана яңа иҗат баскычлары буйлап өскә күтәрелергә ярдәм итә. Анда килүгә үк ул яшь язучылар, артистлар, композиторлар, рәссамнарны үз тирәсенә туплаган "Лира" клубы ачып җибәрә. Ул вакытта яшь талантларның иҗатларын чагылдыручы бер генә басма да булмый. Ә бу—айга бер мәртәбә даими чыгып килүче кушбит—тиз арада иҗади яшьләрне үз тирәсенә туплый.

Григорий Родионов бераздан яңа вазифада. Аны Татарстан китап нәшриятына яшьләр-балалар редакциясенә мөхәррир итеп чакырып алалар. Анда эшләгән дәвердә ул татар язучыларының җитмешкә якын китабын редакцияләп чыгара. Үзе дә, эштән соң вакыт табып, яңа әсәрләр өстендә эшли, китаплар бастыра. Аннары инде язучылар белән эшләүдә шактый тәҗрибә туплаган, берничә китап авторы Гәрәй Рәхимне Татарстан Язучылар союзына әдәби консультант итеп чакырып алалар. Монда килгәндә инде ул "Омтылыш", "Хәтер", "Мин урамда йөрим", "Шатлык елы" дигән төрле жанрдагы әсәрләрен туплаган китапларын чыгарып өлгергән, әдәбият мәйданына атлыгучы яшьләргә үзенең төпле киңәшләрен бирә, юл күрсәтә алырдай җитлеккән язучы була. 1978-1979 елларда ул "Казан утлары" журналы редакциясендә проза бүлеге мөдире булып эшләп ала. Монда да ана татар әдәбияты классиклары булып киткән күп кенә язучыларның әсәрләрен редакцияләргә туры килә. Бирелә шулай ук күп эш башкарылган, әмма шуларның берсе аның хәтеренә нык уелып калган.

—Соңгы мәртәбә миңа Нурихан Фәттахның "Узган елларга карап" (бу китапның беренче исеме) дигән повестен редакцияләргә туры килде,—дип искә ала ул. —Ул анда сугыш елларында авылдагы авыр тормышны бик дөрес итеп тасвирлаган иде. Әсәр шулкадәр кыю язылган, тирән фикерле, тәнкыйтьле повесть иде. Шул әсәрне обком карап чыгып, бастыртмады. Ул аннары язучының бер җыентыгында "Артта калган еллар" исеме белән дөнья күрде. Менә шундый вакытлар да бар иде.

Шуннан соң Гәрәй Рәхимнең сукмагы Мәскәү ягына таба каера. Ул ике ел СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укый, монда драматургия секциясендә шөгыльләнүне кирәк дип саный. Бу вакытта секция җитәкчесе дөнья күләмендә танылган рус драматургы Виктор Розов була.

—Турыдан-туры Виктор Сергеевич кул астында шөгыльләнү ул минем өстемә бәхет тавы ишелеп төшкәндәй булды инде,— ди язучы үзе бу турыда. —Ул бик тәмләп сөйли, белемне чын-чынлап арттыра белә торган чын укытучы иде.

Талант беркайда да югалмый. Курсларда укып йөргәндә үк ана тагын бер бәхет елмая. Аны Россия Язучылар союзы идарәсе рәисе Сергей Михалков үз янына чакыртып ала да эш тәкъдим итә. Менә шуннан—1980 елдан башлап—җиде ел буена, Мәскәү язучылары белән иңгә-иң торып, Россия Язучылар союзы идарәсенең Татарстан, Башкортстан һәм Чувашстан республикалары буенча өлкән консультанты һәм союз каршындагы тәрҗемә советының җаваплы секретаре булып эшли. Эшләгәнгә эш язган, дигәндәй, аны шунда ук Язучылар берлеге аппаратының профком рәисе итеп тә сайлап куялар. Бу инде сиңа язучылар кухнясында кайнашу гына түгел, ә аларның һәркайсының тормыш-көнкүреше, борчу-шатлыклары, кайгы-хәсрәтләре эчендә кайнау да була. Кемгә квартира, кемгә иҗат йортына юллама, тагын әллә нәмәрсәләр кирәк! Бу эш эченә кереп чумсаң, сиңа ышанып тапшырылган өч тугандаш республиканың бер читтә калырга да мөмкин. Аның яңа эшендә беренче киңәшчеләре Сергей Михалков, Николай Доризо, Анатолий Алексин була. Бу чорда өч республиканың дистәләрчә язучылары үзләренең китапларын Мәскәү нәшриятларында чыгарып калалар.

Григорий Родионов Россия Язучылар союзында эшләгән вакытта татар әдәбиятын дөньяга таныту буенча да күп шөгыльләнә. Бу елларда Кол Галинең тууына 800 еллык юбилейны халыкара ЮНЕСКО календарена кертүдә ул куйган хезмәт тә

аз булмый. Парижга ЮНЕСКО штабына җибәрелгән бөтен материаллар да аның җылы кулы, кайнар йөрәге аша уза. Габдулла Тукайның 100 еллык юбилее да ЮНЕСКО календарена шул рәвешле кертелә. Ул вакытта әле суверенитет дигән нәрсә юк бит. Шуңа күрә татар әдәбиятын халыкара аренага чыгару коточкыч мәшәкатьле эш була? Ә Кол Галинең 800 еллыгын 14 илдә зурлап билгеләп үтәләр. Монысы—реаль чынбарлык. Татар әдәбияты тарихында беренче мәртәбә Мәскәүдәге Лужники стадионының зур залында татар әдәбиятына багышланган шигырь кичәсе үткәрелә. Ул да татар сүзенә сусаган мәскәүлеләр белән тулы була. Ул башкаланың мактанычы булган Колонналы залда татар әдәбиятының йөзек кашлары Кол Гали, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Акмулла юбилейларын Бөтенсоюз югарылыгында үткәрүгә ирешә.

Сиксәненче еллар азакларындагы илдә барган үзгәртеп корулар язучылар оешмаларын да читләтеп үтми. Күп кенә республикаларда язучылар оешмалары таркала башлый. Мондый шартларда Григорий Родионов үзенең укучысына якынрак булу теләге белән яңадан Казанга әйләнеп кайта. Ул вакытта Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе Туфан Миңнуллин аны үзенең уң кулы—рәис урынбасары итеп кабул итә. Мөстәкыйльлек даулап йөргән еллар була бу. Һәр вакыйганың уртасында булырга ярата торган Григорий Васильевич, язучылар идарәсендәге эшен ташлап, яңа гына оешып килә торган "Шәһри Казан" газетасында эшли башлый. Газетаның беренче саны чыгар алдыннан Борис Ельцин да Казанда йөри. Григорий Родионов аның белән очрашып, аңардан яңа газетаны котлау сүзләре яздырып ала. Шундый ук котлауны Минтимер Шәймиевтән дә яздыра. Ул котлаулар икенче көнне үк беренче санның беренче битендә басылып та чыга.

—"Шәһри Казан"да эшләгән елларымны бик яратам,—дип искә ала ул хәзер. —Нәкъ шул вакытта килеп чыкты бит инде милли мәсьәләләр турында авыз тутырып сөйләүләр...

1992 ел. Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында республика керәшеннәре үзешчәннәренең концерты бара. Керәшеннең дә борынына мөстәкыйльлек исе керә башлаган чак бу. Шушы кадәр керәшенне бөтен республикадан бер залга тагын кайчан җыясың әле?! Концерттан соң тиз генә конференция үткәреп алырга булалар. Григорий Родионов сәхнә артында туган бу фикерне халыкка җиткерә:

—Без сәясәт белән шөгыльләнергә теләмибез,—ди ул. —Әмма безгә үзебезнең гореф-гадәтләрне, культураны, җырларыбызны, телебездәге үзенчәлекләрне саклап калу, гомумән сәнгатебезне күтәрү өчен культура-агарту оешмасы төзергә кирәк.

Зал гөрләтеп кул чаба. Өч кешедән—Григорий Родионов, Галина Казанцева, Аркадий Фокин—оештыру комитеты төзелә. Республика керәшен оешмасы үз эшен әнә шулай башлап җибәрә. Аннары Чаллы яклары активлашып, күтәрелеп китә...

—Григорий Васильевич, сезнең иҗатыгызда керәшен темасы нинди урын алып тора?

—Дөресен әйткәндә, бу мәсьәләдә минем үкенечләрем зур. Яшь вакытта мин керәшен темасына игътибар итә алмадым. Ни өчен икәнлеге билгеле, ул вакытта бу темага язсаң да бастырмыйлар иде. Ул вакытта язган булсам, хәзер файдасы тигән булыр иде. Ләкин эш шунда ки, ул чордагы тәрбиям белән керәшен темасы минем каныма, җелегемә үтмәгән иде әле. Аны язу өчен иң башта керәшен патриоты булырга кирәк бит. Бу әйбер миңа соңрак—керәшен оешмалары төзеп йөргән вакытларда гына килде. Минем бөтен әйләнә-тирәм гел татарлардан гына тора иде. Араларында керәшеннәр юк диярлек. Мәктәптә дә, гүя ул керәшен авылында булса да, керәшен темасы юк иде. Бу теманың тәме миңа үзем өлгереп җитмичә кермәде. Шулай да соңгы вакытларда керәшеннәр турында аерым хикәяләрдән торган "Җәгүр дәдәй дәмәкләре" дигән повестем чыкты. Бу әсәр бары тик чынбарлыктан тора һәм анда шушы чынбарлыкка карата минем мөнәсәбәтем һәм бәям чагыла. Минем әнинең Җәгүр исемле абыйсы бар. 1911 елгы. Әле дә исән-сау. Сугыш кичкән. Төрмәдә дә утырып алган. Бик оста тегүче, умартачы, балта остасы. Бөтен эшне коеп куя. Үзе шулкадәр шаян, оста җырчы. Аның хатыны Үли җиңги дә туксан яшькә якынлашып килә. Мин аларга кайткалап йөрим.

—Барлык әсәрләрен дә шулай чынбарлыктан алынганмы?

—Шагыйрь буларак, язган әйберләремнең барысы да чынбарлыктан алынган. Ләкин аларны, әлбәттә, романтик биеклеккә менгереп язарга тырыштым. Өч повестем чыкты. Алар да, нигездә, чынбарлык. Берсе әниемә, аның фаҗигале үлеменә, икенчесе минем яшьлек мәхәббәтемә багышланган. Әлбәттә, әдәби әсәр гел чынбарлыктан гына тормый инде ул. Шулай да төп геройларның күңеле һәм барлыгы чынбарлыкка туры килә.

—Синең малайларыңның беренчесенең исеме Дауыт, икенчесенеке—Кубрат. Аларга исем кушканда нәрсәдән чыгып эш иттең?

—Беренчесенә исемне озак эзләдем. Ә менә икенчесенә тиз табылды. Монысы да язучылык эше белән бәйле. Мин бит "Борынгы Болгарны сагыну" дигән киносценарий яздым. Анда төп геройларның берсе—борынгы Болгар ханы Кубрат. Икенче улым шушы сценарий буенча беренче татар киносы төшереп йөргән вакытка туры килде. Кинорежиссер Булат Мансуров шунда ук әлеге исемне кушарга тәкъдим итте. Кубрат дип кушу, бер яктан, тарихны эченә алса, икенче яктан, ул минем әдәби героем, өченче яктан, христиан динен кабул иткән хан. Әмма, шулай да, византиялеләргә мөрәҗәгатендә, мона кадәр халкым нинди дин тоткан булса, шул диндә калсын, ди. Ул вакытта мәҗүсилек дине була. Хан болгарларны башка дингә күчерү белән шөгыльләнми.

—Киносценарий язу уе ничек туды? Беренче татар киносының язмышы ничегрәк?

—Әлбәттә, киносценарий язуым әле, дип утырып кына язып булмый. Аның нигезе һәм киләчәге булырга тиеш. Беренче Бөтендөнья татар конгрессында татар халкының кино сәнгатен тудыру турында сүз булган иде бит. Режиссер итеп Мәскәүдән Булат Мансуровны чакырдылар. Ә сценарий юк. Ул вакытта инде Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында минем сценарий буенча "Каһәрләнгән мәхәббәт" операсы куелган иде. Аннан соң шулай ук опера өчен борынгы Болгар темасына сценарием бар иде. Шулай итеп, мин Булат Мансуров белән очрашып, беренче татар фильмы өчен сценарийны икәү язарга булдык. Фильм тулысынча тасмага төшереп бетерелгән килеш "Мосфильм" студиясендә шушы көнгә кадәр монтажлап бетерүне көтеп ята. Вакытында акча булмыйча, сузылды да сузылды. Ләкин кино бар һәм ул экраннарга чыгачак. Ул һәркайсы икешәр серияле "Атилла", "Кубрат" һәм "Идел буе болгарлары" дигән мөстәкыйль фильмнан тора.

—"Каһәрләнгән мәхәббәт" операсы турында берничә сүз әйтмәсәк, әңгәмәбез китек калыр кебек. Бу әсәр сиңа һәм тагын дүрт артистка мактаулы исемнәр китерде бит...

—Бу теманы миңа композитор Бату Мулюков тәкъдим иткән иде. Бераз уйланып йөрдем дә риза булдым. Авыр тема иде бу, чөнки Мәҗит Гафури үзенең "Кара йөзләр"ендә вульгар социологизм чорындагыча муллаларны бик нык мыскыл иткән бит. Аннан соң авылны бик ярлы итеп күрсәткән. Мине бер идея биләп алды. Боларын йомшартып та була. Мин лидерның көчен күрсәтүне максат итеп куйдым. Анда халык сарык шикелле лидерга иярә. Шулай итеп, нинди матур башланган мәхәббәтне юкка чыгаралар, фаҗига ясыйлар. Аннары үзләре үк, шушы фаҗигадән соң Заһир артыннан ияреп, муллаларны каһәрлиләр, кызны кызганалар. Опера артистлары бу әсәрне Мәскәүдә Кремльнең съездлар сараенда да уйнадылар. Ә анда кадәр барып җитү бик җиңел түгел.

—Шагыйрь һәм язучы буларак заяга үткән вакытларың булды дип саныйсыңмы?

—Хәзер инде артка борылып карап, кайбер әйберләрне барлап карасаң да ярый. Мин үзем гомерем буе эшләдем дә эшләдем. Мин бит авылдан чыккан кеше. Әгәр бөкеремне чыгарып эшләмәсәм, миңа читтән бер тиен акча да керми. Ләкин яшь вакытта иҗатта заяга узган вакытлар күп булды, дип саныйм. Ә хәзер инде, рәсми органның бер чиновнигы буларак, иҗатка бөтенләй вакыт калмый. Ләкин мин моны заяга узган вакыт дип әйтә алмыйм. Менә унике ел инде Татарстан Дәүләт Советында өлкән референт булып эшлим. Ике яшь балам хакына эшлим. Элеккерәк елларда бер китап бастырып чыгарсаң, аның гонорар акчасына гаилә белән бер ел

яшәп була иде. Хәзер китап чыгара башласаң да үзең түләп бастырырга кирәк. Мина, бәлки, ул газеталарда, журналларда эшләп йөрергә дә кирәк булмагандыр. Ул чагында иҗат җимешләре күбрәк булыр иде.

—Киләчәкне ничегрәк күз алдына китерәсең? Без кая таба барабыз?

—Иң беренче илдән башлыйк. Моннан ун еллар элек киләчәк начараюдан-начараюга таба бара дип, бөтенләй кәефем төшкән иде. Дөрес, ул хәзер дә яхшыга таба бармый. Шул ук вакытта артка таба тәгәрәү дә акрынайды. Хәзер аз гына тотрыклылык бар шикелле. Авыр яшәүчеләр күп, әлбәттә. Илнең киләчәге алай ук начар булмастыр дип уйлыйм. Балаларымның киләчәге эш белән бәйле булыр инде. Мин аларның икесен дә татар мәктәпләрендә укытам. Татар милләтенең киләчәге турында шулай кайгыртам. Үземнең киләчәк турында әйткәндә, матур картлык килсен дип телим. Балаларым бераз үсә төшкәч, пенсиягә чыгып, гел язучылык эшенә генә чумарга исәплим. Аллаһы Тәгаләнең зиһен бирүен телим.

Григорий Родионов—утыздан артык китап авторы. Чыннан да, алар күбрәк тә була алыр иде. Ул унбиш ел гомерен ике томлык “Татар поэзиясе антологиясе”н төзүгә багышлый. Әдип Алмыш хан чорындагы көмеш акчага сугылган икеюллыктан алып (930 нчы ел) 1992 елга кадәрле вакыт аралыгындагы барлык шагыйрьләрне барлап, алар иҗатындагы иң яхшы үрнәкләрне татар укучысына тәкъдим итә. Моңа кадәр әле аның кулы аша “Татар балалар поэзиясе антологиясе” үткән була.

Григорий Родионов—Гәрәй Рәхим—кырык елга якын татар әдәбияты байрагын югары тоткан хәлдә төпкә җигелеп тартып барды. Әдәби тәнкыйть аның иҗатын һәрвакыт уңай бәяләде. Татарстанның халык шагыйрьләре Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Калмыкстанның халык шагыйре Давыт Көгелтинов, Башкортстанның халык шагыйре Равил Бикбаев, Ленин премиясе лауреаты, рус шагыйре Егор Исаев һәм башкалар аның иҗатына югары бәя биреп, аны зур хәрефтән Шагыйрь дип атадылар.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ПӘЙГАМБӘР*** *ф. – Пәйгам*-хәбәр, вәхи(й) һәм *бар*-китерүче сүзләреннән тора. Аллаһы Тәгаләнең Рәсүле (илчесе, мөрсәле, хәбәрчесе), нәби, сәүчи.

Коръәндә дөньяга кешеләрне Хак дингә вә изге гамәлләргә өйрәтү өчен килеп киткән 25 пәйгамбәрнең исемнәре телгә алына. Бу исемнәргә хәдисләрдә бәян кылынган яки пәйгамбәрлекләре ачык мәгълүм булмаган тагы 11 шәхесне өстәргә мөмкин:

1.Адәм пәйгамбәр.
2.Ашгия (Шәгыя, хәдисләрдән билгеле).
3.Әльясәг пәйгамбәр (Әльясагъ язылышы да очрый).
4.Әрмия (хәдисләрдән билгеле).
5.Әюб пәйгамбәр (Әйүб, Әйүп язылышлары да очрый).
6.Бишер пәйгамбәр (хәдисләрдән билгеле).
7.Гайсә пәйгамбәр.
8.Гозәир (Гөзәер дип язу да очрый, аның пәйгамбәрлеге ачык түгел, ләкин Коръәндә искә алына).
9.Даниял пәйгамбәр (хәдисләрдән билгеле).
10.Дауд пәйгамбәр (чыганакларда Давыт дип язу да очрый).
11.Зөлкарнәйн (Зөлкәрнәен язылышы да очрый, пәйгамбәрлеге ачык түгел, ләкин Коръәндә искә алына).
12.Зөлкифел пәйгамбәр.
13.Зәкәрия пәйгамбәр.
14.Ибраһим пәйгамбәр.
15.Идрис пәйгамбәр.
16.Ильяс пәйгамбәр.
17.Исмәгыйль пәйгамбәр.
18.Исхак пәйгамбәр.
19.Йосыф пәйгамбәр.
20.Локман (пәйгамбәрлеге ачык түгел, ләкин Коръәндә искә алына).
21.Лут пәйгамбәр.
22.Муса пәйгамбәр.
23.Нух пәйгамбәр.
24.Салих пәйгамбәр.
25.Сөләйман пәйгамбәр.
26.Хозыр (Хөдер, Хызыр; хәдисләрдән билгеле).
27.Һарун пәйгамбәр.
28.Һуд пәйгамбәр.
29.Шис (хәдисләрдән билгеле).
30.Шөгаиб пәйгамбәр.
31.Ышмуил (хәдисләрдән билгеле).
32.Юныс пәйгамбәр.
33.Юшагъ (хәдисләрдән билгеле).
34.Ягъкуб (Йагкуб) пәйгамбәр.
35.Яхъя пәйгамбәр.

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче саныннан басылып килә.*

36. *Мөхәммәд галәйһимус-саләту вәссәлам*—иң соңгы Пәйгамбәр.

Бер риваятькә караганда, Адәм галәйһиссәламнән соң Мөхәммәд Пәйгамбәргә кадәр 124 мең пәйгамбәр килгән. Икенче риваяттә 224 мең саны күрсәтелә.

XVI гасырда яшәгән төрек галиме Фуратиның "Кырык сөаль" дигән китабында йәһүд галимнәренең Мөхәммәд Пәйгамбәрдән: "Дөньяга ничә нәби һәм ничә мөрсәл җибәрелгән, алардан безгә ничә китап һәм сәхифә килеп ирешкән?" дип сораулары турында сөйләнә. Мөхәммәд галәйһиссәлам аларга түбәндәгечә җавап биргән. Аллаһы Тәгалә җиргә 124 мең пәйгамбәр җибәргән, шуларның 313 е Рәсүлләр, ә калганнары нәби дип атала. Җәбраил фәрештә алдан күрү сәләте биргән пәйгамбәрләр генә Рәсүлләр, аларның саны 313. Шушы 313 пәйгамбәрнең 25 е Коръән-кәримдә зикер кылына. Аллаһ тарафыннан иңдерелгән язмалар саны-104, 100 сәхифә (төргәкнамә) һәм 4 китап. Алар җиде пәйгамбәргә җибәрелгәннәр. Барлык китаплар да Рамазан аенда иңдерелгән: Тәүрат-Рамазанның беренче көнендә, Инҗил-13 нче көнендә, ә Коръән-кәрим Рамазанның 27 нче көнендә иңгән.

Иң әүвәлге пәйгамбәр—*хәзрәти Адәм*, иң соңгы пәйгамбәр—*Мөхәммәд галәйһиссәлам*. Ул ахырзаман Пәйгамбәредер, аңардан соң дөньяга пәйгамбәрләр киләчәк түгелдер (Әхмәтһади Максуди). Барча мөселманнар аның өммәтеннәндер. Ул барча галәмнәргә һәм шулай ук җеннәргә дә пәйгамбәр итеп җибәрелгән.

Шулай да: "Аллаһы Тәгалә бу Ислам өммәте өчен һәр йөз сәнә башында (һиҗри исәп белән) яңартучылар булдырып торыр" дигән хәдис бар. Аларны *мөҗәддиләр* дип атыйлар.

Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәрләре түбәндәге сыйфатларга ия:

1.Пәйгамбәрләр тугрылыклы (Сыйддикъ),

2.Алар һәрнәрсәдә иминлеккә баралар (Әманәт),

3.Алар Аллаһы Тәгалә әйткәннәрне һич кимчелексез кешеләргә тапшыралар (Тәблигъ),

4.Алар зирәк (Фәтәхәт),

5.Алар гөнаһ эшләрдән тәмам сакланганнар (Гыйсмәт).

Пәйгамбәрләр могҗиза кылу сәләтенә ия.

Ризаэддин Фәхреддин Рәсүлләрнең кешелек сыйфатларына карата түбәндәгеләрне язган: "Бу Рәсүлләр үзләре кешеләр җөмләсеннән булып, инсаннарның тормышлары өчен лязим вә табигый эшләр аларга да хас. Бөтен кешеләр кебек Шәригать хөкемнәре белән куәтләнгән булсалар да, пәйгамбәрләрнең һәммәсе тугрылык вә зирәклек белән сыйфатланган. Алар үзләренең вазифалары булган Шәригатькә өндәүне тырышып башкардылар. Рәсүлләрнең һәрберсе хыянәт вә сер итеп саклау кебек әхлаклардан да, гомумән, гөнаһлы эшләрдән арынган. Бәгъзе вакытларда дөнья эшләрендә онытулары вә ялгышулары булса да, динне ирештерүдә бу сыйфатлардан сәламәтләр".

"Ягъкуб балалары" сүрәсенең 55 нче аятендә: "Тәхкыйк, пәйгамбәрләрнең кайберләрен кайберләреннән артык кылдык, вә Дауд пәйгамбәргә "Зәбур" исемле китап бирдек" диелә. Моннан үзләренә китап иңдерелгән пәйгамбәрләрнең дәрәҗәлерәк булуы аңлашыла (Адәм галәйһиссәлам, Ибраһим пәйгамбәр, Шис пәйгамбәр, Идрис пәйгамбәр, Муса пәйгамбәр, Гайсә пәйгамбәр һәм Мөхәммәд Пәйгамбәр). Риваятьләргә караганда, Адәм галәйһиссәламгә дә 10 кәгазь (китап) иңгән. Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә 10 кәгазьдә (сәхифә) вәхийләр иңдергән, Идрис галәйһиссәламгә 30 кәгазь, ә Шис галәйһиссәламгә 50 кәгазь җибәргән, Муса пәйгамбәргә "Тәүрат" (Китаб, Сухуф, Фуркан), Гайсә пәйгамбәргә "Инҗил" иңдергән дип карала. Мөхәммәд Пәйгамбәргә иңдерелгән "Коръән"не дә "Фуркан" дип атау очрый. Коръән- кәримнең Зәйд ибне Сабит тарафыннан 632 елда төзелгән беренче мәтенен дә Сухуф дип атыйлар. Коръәндә әйтелгәнчә, Һарун пәйгамбәргә дә вәхий иңгән (4:163, 5:84, 10:75, 19:53, 21:28, 23:45, 25:35).

Исламияттә аеруча түземле тугыз пәйгамбәр аерып күрсәтелә, болар (*улү-л-газми*): Нух, Ибраһим, Дауд, Йагкуб, Йосыф, Әйүб, Муса, Гайсә пәйгамбәрләр һәм Мөхәммәд Пәйгамбәр ("Коръән тәфсире"ндә алар "каты чыдамлылар" дип телгә алына, 46: 35/34). Шуны да әйтеп китик, В.Порохова тәрҗемәсендә (комментарийлар өлешендә) *улү-л-газми* пәйгамбәрләр рәтенә кеше каумен һәм диннәрне нигезләүче Нух, Ибраһим, Муса, Гайсә һәм Мөхәммәд Пәйгамбәр генә (бишәү) кертелгән.

"Рисаләи Газизә" китабында Зәкәрия һәм Шәмгун кебек пәйгамбәрләр *йәлавычлар* (*хәварийуннар*, апостоллар) исәбенә кертелә, ә Идрис, Шис һәм Муса пәйгамбәрләр-кәбирләр, ягъни зурлар, алар *сәүчи* дип аталган. Хәер "Древнетюркский словарь"да китерелгән мисал-иллюстрациядә Мөхәммәд Пәйгамбәр дә йәлавыч дип аталган: *"Муһаммәд йәлавач халаек башы"* (Мөхәммәд йәлавыч—халык җитәкчесе).

Халык арасында аеруча күренекле зат исәпләнгән Йосыф пәйгамбәргә дә вәхий назил булмый, ләкин ул төш юрау сәләтенә ия булган.

Гадәттә *пәйгамбәр, рәсүл* һәм *нәби* сүзләре синонимнар дип карала. Ләкин, күрәбез ки, исламияттә алар аерыла. Мәс., шул ук "Рисаләи Газизә"дә: "Нәбидер һәр рәсүл, аңлагучы бул, Вәләкин һәр нәби ирмәс Рәсүл ул" диелә. Ягъни рәсүлнең дәрәҗәсе нәбинекеннән артыграк. Нәбинең Алладан иңгән китабы юк диләр. Шушы ук әсәрдә Җәбраил галәйһиссәламнең нәбиләргә йокыда хәбәр бирүе, ә рәсүлләргә уяу вакытларында килүе ачык әйтелгән.

Ризаэддин Фәхреддин "Хозыр вә Ильяс—дүрт үлемсез пәйгамбәрнең икесе. Аларга мәңгелек гомер бүләк ителгән һәм алар кешеләрдә Аллаһы Тәгаләгә ышану көчен арттырырга җибәрелгәннәр. Алардан соң тагын Гайсә һәм Идрис пәйгамбәрләрнең дә шул ук вазифаны башкарулары риваять ителә",-дип яза.

"Сыер" сүрәсенең (2) 285 аятендә: "Барысы да Аллаһка, Аның фәрештәләренә, китапларына, Рәсүлләренә иман китереп инандылар. Аның Рәсүлләренең берсе арасында да фәрекъ-аерма кылмыйбыз",—диелгән (Сәлман хәзрәт тәрҗемәсе буенча). "Тәфсир Ногмани"да бу урын түбәндәгечә: "(мөэминнәр): Рәсүлләрнең берсен икенчесеннән аермыйбыз, барчасына да бертигез ышанабыз",—диделәр." Монда югарыда әйтелгәннәр белән капма-каршылык юкмы соң? Безнеңчә, бу очракта мөэминнәрнең Рәсүлләргә бертигез таянуы турында сүз бара.

Төрек галиме Фурати да үзенең "Кырык сөаль" дигән хезмәтендә йәһүд галимнәре биргән сорауга Мөхәммәд Пәйгамбәрнең: "Хәзерге вакытта тагын дүрт пәйгамбәр исән. Икесе-җирдә, ә икесе-күктә. Күктәгеләре—Идрис белән Иисус, җирдәгеләре-Хызыр белән Ильяс пәйгамбәрләр",—дип җавап бирүе турында хәбәр итә.

Кайбер чыганакларда *әсхаб әр-расс*—коега табынучылар каумена Аллаһының илчесе итеп җибәрелгән *Ханзала пәйгамбәр* телгә алына.

Югарыдагы ачык күрсәтмәләр булуга да карамастан, исламияттә хатын-кызлардан Муса галәйһиссәламнең анасы кебек, Фиргавеннең хатыны Асия кебек, Сара, Һаҗәр, Һәва һәм Мәрьям-ана кебек хатыннарның пәйгамбәр булу-булмавы турында фикер алышулар билгеле. Ахырда алар пәйгамбәр булмаганнар, бәлки ситдикалар, изгеләр булганнар дигән фикергә киленгән.

Пәйгамбәр сүзе чуаш һәм мари телләренә дә кергән, ләкин ул аларда мәҗүси мәгънәләрне белдерә: чуаш телендә—илаһ, бүреләр иясе; мари телендә—илаһ, пәйгамбәр, ярдәмче. Керәшеннәр *пигамбәр* сүзен кулланалар.

Аннары исламияттә *бәшәр пәйгамбәре* (адәми заттан булган пәйгамбәр) һәм *мәләк пәйгамбәре* (фәрештә затыннан булган пәйгамбәр) аерып карала. Рәсүл *Җәбраил, Исрафил* һәм *Микаил*, шулай ук күктәге мәлаикләр-фәрештә пәйгамбәрләрдер. Таҗетдин Ялчыгол үзенең "Рисаләи Газизә" китабында адәми пәйгамбәрләрнең фәрештәләр пәйгамбәреннән өстенлегенә биш дәлил китерә, ул дәлилләрнең иң беренчесе—Аллаһы Тәгалә кушуы буенча фәрештәләрнең Адәм пәйгамбәргә сәҗдә кылулары. Бу мәсьәләдә киресенчә уйлаучы фәлсәфәләр дә булган.

Тагын шуны да әйтеп китик, шигыйләрдә Гали хәзрәтнең варисларын барлык пәйгамбәрләрдән дә өстен куйганнар.

Инҗилдә пәйгамбәрләр турында тагын бер хакыйкать әйтелгән: "Чынлап әйтәмен сезгә: үскән җирендә бер генә пәйгамбәрне дә кабул күрмиләр" (Матфей, 4:24). Рустагы "Нет пророка в своем отечестве" сүзе Инҗилдән алынган.

Билгеле булганча, иудаизмдагы һәм христианлыктагы күп кенә пәйгамбәрләр Исламдагылар белән уртак. Ләкин, әйтик, Библиядә телгә алынган Кәнган пәйгамбәрләренең байтагы үзләренең эшчәнлекләре буенча шаманнарга якын тора. Аларның берләре сәйяр тормыш алып барганнар, халык исәбенә тукланып яшәгәннәр, ә икенчеләре патшаларга хезмәт иткән. Иске Гаһеднамәдә (Васыятьтә) Самуил пәйгамбәр, Гад, Нафан, Илия, Елисей пәйгамбәрләр еш телгә алына. Бу пәйгамбәрләрнең

кайберләре вәгазьләрен язып барганнар һәм ул вәгазьләр соңыннан Иске Гаһеднамәгә теркәлгән. Боларының 4 есе: Исаия, Иеремия, Иезекииль, Даниил "бөек" пәйгамбәрләр исәбенә кертелә, ә 12 се (Осия, Иоиль, Амос, Авдий, Иона, Михей, Наум, Аввакум, Софония, Аггей, Захария, Малахия) "кече" пәйгамбәрләр булып исәпләнә.

Әдәбиятта *Дин пәйгамбәре* һәм *Мәдәният пәйгамбәре* дигән гыйбарәләр очрый. Ә талчук базарында иске малларның чын бәясен яхшы белүче, сынамышлы антиквар картларны электә *талчук пәйгамбәре* дип атаганнар.

Терлекчелек белән көн күргән халыкларда, шул исәптән татарларда да, "хайваннар (терлек) пәйгамбәре" төшенчәсе булган (кайбер якларда Зәңки бабай—куй көтүчесе, Чулпан бабай—ат көтүчесе, Искәндәр бабай—сыер көтүчесе).

Тагын кара: ***ЯЛГАН ПӘЙГАМБӘРЛӘР.***

***РӘСҮЛ, РАСУЛ*** *г.*—Илче мәгънәсендә. *//Алланың рәсүле*-Алланың илчесе. Исламда Мөхәммәд галәйһиссәламгә карата кулланыла торган термин. *Нәби* термины Мөхәммәднең Аллаһы белән туры бәйләнешен, ә *рәсүл* термины аның илаһи миссияне башкарып, адәмнәрне хак дингә күндерүче булуын күздә тота. Ризаэддин Фәхреддин Рәсүл-пәйгамбәр терминын нәби-пәйгамбәрләр терминыннан аерып күрсәтә. Таҗетдин Ялчыголның "Рисаләи Газизә" әсәрендә Җәбраил галәйһиссәламнең нәбиләргә йокыда хәбәр бирүе, ә рәсүлләргә уяу вакытларында килүе әйтелгән. Шунда ук нәбинең Алладан иңгән китабы булмавы турында искәртелә.

*Рәсүл*-нең күплек саны шәкеле-*рөсел.*

***РӘУШАН, РУШАН*** *ф.*—Яктыртучы, нурлы. Татарда кеше (ир-ат һәм хатын-кыз) исеме булып та йөри торган сүз. Башта грек теленә, аннары борынгы рус теленә дә үтеп кереп, Рәушан сүзе "Роксана"га (хатын-кыз исеме) әйләнгән (Арслан яки Рөстәм исеме "Руслан"га әйләнгән шикелле). Тарихтан билгеле булганча, Искәндәр Зөлкарнәин (Александр Македонский) үзе буйсындырган Бактрия патшасы кызы Рәушан-Роксанага өйләнә. Роксананың язмышы фаҗигале була. Ире вафат булганнан соң ул ун елдан артык гаять зур империяне идарә итә, ләкин яңа эрага кадәр 311 елда үзенең кечкенә угылы белән бергә үтерелә. Бу вакыйгалардан соң ике мең еллап вакыт узгач, Төркия солтаны Сөләйман Кануниның (1495/94-1566) *Роксалана* исемле славян кызына өйләнгәнлеге билгеле. Ихтимал, Роксалана исеменең килеп чыгышы Роксана исеме һәм, димәк, шәркый Рәушан исеме белән бәйледер.

*//Дәхи җирне киң кылдык, вә анда таулар салдык, вә җирдә үстердек һәр үсемлекне аталы-аналы итеп, ул үсемлекләр күңелләрне рәушан кыладыр.* "Коръән тәфсире", "Каф" сүрәсе (50):7.

***РУН ЯЗУЫ*** *тар.*—Рун язулы истәлекләрдән Орхон елгасы буендагы ташка тырнап язган истәлекләр төрки каһанлыкның соңгы чорына-VIII гасырга карыйлар. Енисей буендагы язмалар исә VII-VIII гасырларга нисбәт ителә. Рун язуы борынгы Идел буе болгарларында да кулланылган.

*"Руник язулар"* варианты да очрый.

***РУХ*** *г.*—Җан, рух. Бу сүз борынгы гыйбрани *руах* сүзенә барып тоташа. *//Рух әл-илаһ*-илаһи рух. *Галәви рух*-югары (дәрәҗәдәге) рух (фәрештәләр һәм кешеләрнең рухлары күздә тотыла). *Сәфли рух*-түбән җан (җеннәр һәм шайтан затыннан булганнарның җаннары күздә тотыла). *Рух рахәт*-җан рәхәте. *Рух рәван*—китүче җан, рух. *Рух әл-коддус*—Изге рух (христианнарда—Святой дух; Святой тын—керәшеннәрдә; ләкин Исламда ул Җәбраил фәрештә белән тәңгәлләштерелә. Р.Батулла тәрҗемә иткән "Коръән"дәге сүзлекчәдә *"Рух—ел Кодус"* "изге рух, Җәбраил фәрештә, Аллаһтан килгән сүз" дип аңлатыла).

*Рух*-ның күплек саны шәкеле: *әрвах* (гадәттә үлгән кешеләрне атаганда кулланыла).

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ТАНЫШ ТАВЫШЛЫ МИЛЛӘТТӘШ

"Тынлагыз, тынлагыз! "Азатлык радиосы сөйли... Дөнья буйлап сибелгән татарлар турында... Сембер яналыклары белән Айрат Ибраһим..."

Айрат Ибраһим—"Азатлык" дулкыннары аша меңнәрнең йорт вә күнелләренә керүче милләттәшебез. Татарстаннан читтә яшәп яткан туганнарыбыз язмышы белән таныштырып, яшәеш турында уйландырып, кешелек дөньясындагы ялгышларны фаш итеп, күнелләрне сафландырып тора ул.

Айрат Исмәгыйль улы Ибраһимов 1936 елның 10 февралендә Башкортстанның Бәләбәй районы, Мәтәубаш авылында туган. Мәктәпнең 7 сыйныфыннан соң Бәләбәй педучилищесын тәмамлый. Ләкин мәктәптә укытырга туры килми: армиягә алалар, аннан хәрби училищега җибәрәләр. Озак кына армия хезмәтеннән сон—шоферлар укыту. Горбачев җепшеклеге аркасында Ульяновскида яшәүче милләттәшләребез "Өмет" дигән татарча гәзит һәм "Чишмә" атлы телевизион тапшыру ачуга ирешәләр һәм Татарстан белән Башкортстаннан тыш беренче өлкәкүләм мәгълүмат чарасына тиенәләр. Моны татар милли "Туган тел" оешмасының иң мөһим казанышы дип тә әйтеп буладыр. "Туган тел"нең үзенең дә, аның "балалары" "Өмет" белән "Чишмә"нең дә дөньяга килүендә Айрат абыйның хезмәте зур. Ул—"Туган тел"нең беренче рәисе, "Чишмә" телетапшыруын башлап җибәреп, белгеч килгәнче, дүрт ай буе алып баручы да, күп еллар "Өмет" гәзитендә эшләп, гәзит укучыларының мәхәббәтен яулаган журналист та. Шул ук тынгысыз җан—1988 елдан бирле Шәһри Болгарга сәяхәтләр оештыручы, Ульяновскида беренче булып "Нардуган", "Нәүрүз" бәйрәмнәрен, "Сембер җыры" конкурсларын оештыручы, өлкә үзәгендә ана теле буенча беренче факультатив дәресләр ачып җибәрүче.



Айрат абый белән танышуыбыз 1995 елда, Хәтер көнендә булды. Һәм таныштык кына түгел, дуслаштык та дип әйтә алам. Күптән түгел аның белән иркенләп сөйләшергә туры килгән иде. Шул әңгәмәнең кайбер өлешләре башка милләттәшләребездә дә кызыксыну тудырыр дип уйлыйм.

**—Айрат абый, Ульянда милли хәрәкәт ничек башланып китте?**

—Туганкай, милли хәрәкәт, минемчә, беркайчан да сүнмәгән ул: йә дөрләгән, йә пыскып кына булса да дәвам иткән. Мәсәлән, Владивостокта яшәгәндә дә без, уңлап гаилә, барлык бәйрәмнәрне, табигатькә чыгып ял итүләрне бергә оештыра идек. Хәтта Мәскәүдән Сәяр Хәбибуллинның "Хыял" ансамблен чакырып, анда яшәүче милләттәшләребезне татар моңы белән сыйлаган да булды. Күп-күп татарлар белән очрашып танышырга Илһам Шакиров концерты да ярдәм итте. Әлбәттә, "больше трех не собираться" шартларында сәяси мәсьәләләрне күтәрү мөмкин түгел иде, анысы булмады. Шулай ук махсус оешма турында да хыяллар юк иде.

**—Мин нәкъ менә оешма турында сорарга теләгән идем. Сезнең "Туган тел" бөтен СССР буенча беренче татар оешмасы булды бугай.**

—Белмим инде. Һәрхәлдә, минем андый оешмалар турында ишеткән юк иде. Без 1998 елның мартында "Туган тел"нең ун еллык юбилеен зурлап бәйрәм иттек. Мәскәү, Оренбург, Богырыслан, Самара, Свердловск кебек шәһәрләрдә милли оешмаларның нәкъ шул исем белән аталуы чыннан да беренче булганбыз дип уйларга нигез бирә кебек.

**—Ә башка шәһәрләрдә сезнең "Туган тел" турында каян белгәннәр дип уйлыйсың?**

—Анысы турында уйлап тормаска да була. 1988 елның августында "Социалистик Татарстан"да "Туган тел" исемле мәкалә чыкты. Шуннан соң әлеге газетның журналисты Заһидулла абый Шәфигуллин белән "Казан утлары"нда эшләгән Тәуфикъ Әйдидән төрле төбәкләрдән килгән хат авторларының адресларын алган идем. Шулар белән элемтәгә кердек, кайберләре белән дуслашып та киттек әле.

**—Ничек кеше җыеп, оешма булдырырга җөрьәт иттегез?**

—Мин җыймадым, киңәш кенә бирдем. Наил Микеев төрле инстанцияләргә хатлар язып, имзалар җыеп йөри иде. Мин дә күп язган идем андый хатларны, тик файдасы гына булмады. Шунда Наилгә әйттем, әгәр берәр оешма исеменнән мөрәҗәгать итсәк, бәлки файдасы булыр иде, дидем. Оешма төзелсә, аның башка файдалы яклары булачагын да әйттем. Ул үз танышларын җыйды.

**—Ә рәис итеп сине сайлаганнар.**

—Мин программа һәм устав проектлары төзеп килгән идем. Үзең төзегәнсең, әйдә, җигел, без ярдәм итәрбез, диделәр. Ризалаштым инде...

—Куркытмадымы?

—Куркучылар да булды анысы. Наил Микеев әйтүенчә, бик тә мөхтәрәм бер агай: "Мин оешмага кермим, барыгызны да җыеп алып китсәләр, ичмаса, бер белемле фидакарь татар кешесе калсын инде шәһәрдә",—дигән. Ә миңа килсәк... Тулы сүз ирегә ачылган вакытта куркырга сәбәп тә юк иде, минемчә. Аннан, мин болай да яхшы ук каты заманнарда—20 ел элек үк "куркытылган" кеше.

—Анысы ничегрәк булды?

—Гаеп үземдә инде. Бар уйларыңны да кешегә ачып салуны яхшы сыйфат дип әйтеп булмый. Мәсәлән, "КПСС тарихы фән түгел, тарихны илнең чираттагы лидерына җайлаштыру гына ул", дигән сүзне минем авыздан беркем дә тартып алмады бит. Бигрәк тә Брежневның мәгълүм "Малая земля" дигән "шедеврын" өйрәнгән дәрестә. Мин ул чакта сәүдә флотына кадрлар әзерләгән уку йортында эшли идем...

Безгә көчләп тагылган кириллицаның корткычлыгы, рус булмаган халыкларның телләрен бетерү ысуллары турында "Комсомольская правда"га зур гына хат җибәрдем. Шуннан соң беренче мәртәбә "компетентлы иптәш" белән сөйләшергә туры килде. Университетта бер кыз "Рус халкының татар-монгол золымына каршы көрәше" дигән темага диплом яклый иде. Ә мин бу теманың халыклар дуслыгына зарары турында, золымның да, көрәшнең дә бөтенләй булмавы, Алтын Урданың Россия тарихына унай тәэсире турында сөйләдем. Ә үз дипломымда, 19 нчы гасыр азагында Кытайны бүлгәләүдә Россия аеруча зур комсызлык күрсәткән, дигән нәтиҗә ясадым. Оппонент профессор Бродянский бик кискен тәнкыйть белән чыкты. Шөкер әле, җитәкчем Людмила Черных, Ленинның 55 томын да яттан белгән галим, минем үз фикерләремне Ленин ярдәмендә исбат итүемне бик тә ошатты. Шундый чыгышлар аркасында минем эш кабинетыма теге, ничек диләр әле, "кнопка" куйганнар.

**—Ә моны каян белдең?**

—Бик соң белдем шул: киткәндә бер КГБ майоры әйтте һәм миңа тагын бер яңалык ачты: Син училище башлыгына рәхмәт укы—"Җибәрегез инде шулай гына, яхшы эшли, училищеның 14 уку ротасы арасында аныкы иң яхшысы, зарары тимәде",—диде. Шуны да бел: без синең арттан өч ел күзәттек: йә листовка элүеңне, йә кабинетыңдагы ләчтитеңне курсантлар алдында сөйләвеңне көттек. Молодец, анысы булмады, димәк, үзеңә дә рәхмәт әйт",—диде. Саубуллашканда, "Миңа артабан ничек яшәргә соң?"—дип сорадым. "Гади кешечә яшә. Чит илләр турында хыялланма, режимлы, серле заводларда эшләргә алмаслар—анда эшең калмаган, җитәкче урыннарга омтылма. Калганы мөмкин сиңа",—диде.

**—Ә аннан соң бу “компетентлы иптәшләр” белән аралашырга туры килмәдеме?**

—Юк дияргә була. “Азатлык” радиосы белән хезмәттәшлеккә кергәнче. Хәзер кызыксыналар. Тынлыйлар. Мәсәлән, Шамановның урынбасары Ковель бервакыт сорый: “Чынлы районы башлыгы Рамазановның мөфти булуын каян уйлап чыгардың?”—ди. Мин әйтәм, андый уйлап чыгаруымны син үзең каян уйлап чыгардың? Мин аны МӘШҺҮР дип атадым. Тәржемәчеләрегезгә әйтегез, “мөфти” белән “мәшһүр” сүзләре арасында аерма бар, радионы игътибарлырак тыңласыннар һәм ана телен ныграк өйрәнсеннәр”. Тагын бер очрак. Телефон аша “Азатлык” радиосына хакимияткә ошамаслык мәгълүмат биргән идем. Бер танышым шылтырата: “Айрат абый, син шулай-шулай дип әйткәнсең икән”,—ди. “Каян беләсең, әле бу сүзләр эфирда яңгырамады бит”,— дигәч, егетебез аптырады. Шундый очраклардан чыгып, мин әле алар өчен һаман кызыксынырлык кеше булып калам, ахрысы, дип уйлыйм инде.

**—Дүрт дипломым бар, дидең. Сине яхшы журналист дип санаучылар күп. Ә журналистлыкка дипломың юк.**

—Эш дипломда түгел. Иң зур байлыгым дип ана телен педучилище таләпләре күләмендә белүемне саныйм. Һәм нәкъ шул миңа журналист булып йөрергә ярдәм итә дә инде.

**—Синең бит русча да шәп-шәп язмаларың чыккалый.**

—Син мәгълүм бер фикерне әйттермәкче буласың, ахрысы. Әйе, бала бары тик ана теле нигезендә генә тиешле үсеш ала. Шул исәптән, чит телләрне дә камил үзләштерә. Табигать шулай кушкан. Ходай биргән сәләт барыбер үзенә юл яра, калкып чыга ул. Совет чорында “балам кеше булсын, урысча укысын” дигән сафсата ата-аналар башына дөмбәсләп тутырылды, хәзер аңгыралатылган, куркытылган, урыслатылган балалар үзләре әти-әни булып җиттеләр. Менә кайда ул безнең өчен иң зур фаҗига!..

* * *

Айрат абый элеккеге Советлар Союзы җирлегендәге татар дөньясын аркылыга-буйга гизгән кеше. Аның юл географиясе Германиядән алып Ерак Көнчыгышкача сузылган. Мордовия, Нижгар, Пенза, Тамбов, Волгоград, Самара, Сарытау кебек күп кенә өлкәләрне үтеп, милләттәшләребез тормышын өйрәнә ул, үгет-нәсыйхәт биреп, аларга үз акчасына сатып алган китапларын тарата, татар мәктәпләренә милли гәзит-журналларыбызны яздырта. Айрат абый меценатлык эшчәнлеге дә алып бара. Ул ел саен өлкәдә билгеләнүче “Мәшһүр татар”ларны бүләкләүне үз өстендә тота, төзелүче мәчет-мәдрәсәләргә дә матди яктан ярдәм итә, үз акчасына китаплар бастырып тарата. Ягъни татар дөньясын рухи яктан баета...

Кеше берьялгызы гына шулкадәр зур эшчәнлек алып бара алырмы идеме икән? Юктыр. Айрат абыйның янында фикердәшләре-дуслары бар. Хатыны Әминә апа, кызлары-оныклары—көч-дәрт бирүчеләре, ныклы рухи тыллары аның.

**Нурулла ГАРИФ**

# Б

**БАТТАЛ** (Сәитбатталов) Фәнзаман Сәитбаттал улы (16.2.1939, Минзәлә р-ны Урсу а.), язучы, публицист. Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1972-75 елларда халык депутатларының Түбән Кама шәһәр Советы башкарма комитетында бүлек мөдире, 1984-93 тә «Татарстан» Дәүләт теле-радиотапшырулар к-ты хәбәрчесе, 1993-97 дә Татарстан китап нәшрияты мөхәррире. Язмалары 1950 еллар урталарыннан басыла башлый. Әсәрләре сатирик эчтәлекле, үткен, образлы теле б-н аерылып тора. Аларда байлыкка кызыгу, комсызлык, саранлык көлке объектына алына. 1980 елларга кадәр Б. әсәрләре, бигрәк тә публицистикасы, басылмады диярлек. 1990 елларда юмористик хикәяләре тупланган «Сакалыңа ут капса» (1990), «Безнең сурәт» (1993), «Гөнаһ шомлыгы» (1993), «Бака да бата» (1995), «Сигезенче оҗмах» (1999), «Соңарган яз» (2001) җыентыклары, «Юлын белгән адашмас» (2000) дип аталган публицистика китабы укучылар арасында популярлык казанды.

Әд.: Әхмәтҗанов И. Ахыргача барам, ахыргача! // Татарстан хәбәрләре. 1992. 1 апр.; Шәрәфи Р. Бер фикер // Шәһри Казан. 1995. 28 февр.; Әхмәтҗанов М. Фәнзаманнар заманы // Килер бер көн. К., 1998.

**БАТУЛЛА** (Батуллин) Рабит (Роберт) Мөхлис улы (26.3.1938, Зәй р-ны Түбән Олыҗы а.), язучы, актёр, режиссёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1985). М.И.Щепкин исем. театр уч-щесен (1961), ГИТИС каршындагы Югары режиссёрлык курсын (1966) һәм М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курс (Мәскәү, 1979) тәмамлый. 1961-63 елларда Татар. академ. театры артисты, шул ук вакытта режиссура б-н дә шөгыльләнә. 1963-65 тә Курчак театры һәм Казан телевидение студиясендә балалар өчен тапшырулар редакциясе режиссёры. 1970-75 тә театр уч-щесендә һәм мәдәният ин-тында укыта. Әдәби иҗат эше б-н 1960 елларда шөгыльләнә башлый. 1966 да Б.ның балалар өчен язылган «Исемем минем Дүрткүз» дип аталган беренче китабы басыла. «Төш вакытында могҗиза» (1966), «Курай уйный бер малай» (1970) пьесалары Казан, Луцк, Омск, Донецк, Саратов, Кемерово, Салават, Махачкала шәһәрләре сәхнәләрендә куела. «Уйларымны кеше белсен» (1969), «Ташламам, җанкисәгем» (1980) җыентыкларына кергән хикәяләре юморга корылган, катлаулы сюжетлы булулары б-н аерылып торалар. Б.ның әсәрләренә тормышны фәлсәфи аңлату хас. Б. 1970 еллар башыннан проф. сәхнә өчен драма әсәрләре яза. Яшьләрнең мөстәкыйльлеккә, тормыш авырлыкларын җиңүгә омтылышларын романтик күтәренкелек б-н тасвирлаган «Туйлар узгач» (1973) муз. комедиясе, «Өчәү юлга чыктык» (1974) драмасы һ.б. тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителде. «Кичер мине, әнкәй!» (1979) пьесасы татар драматургиясендә зур уңышка иреште. Ул 1980 елларда башка милләт театрлары сәхнәләрендә дә уйнала. 1986 елда Г.Тукай турында «Сират күпере» исемле тарихи драмасын яза. Б. үзен эпик масштабтагы язучы буларак та танытты. «Юл буенда зәңгәр чәчәк» повестында (1990) замана яшьләре проблемаларын күтәрә. «Сөембикә—царица казанская» романы (1992; рус теленә тәрҗемәсе «Сюмбике», 2001) Казан ханлыгы патшабикәсенең фаҗигале язмышы турында. Коръән аятьләренең татарча мәгънәләрен аңлаткан җыентык чыгарды (2000). Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге бүләге иясе (1991).

Әсәр.: Прости меня, мама! М., 1981; Серле сандык. К., 1983; Елантау. К., 2005.

Әд.: Фәттах Н. Беренче китап һәм балалар әдәбияты // Казан утлары. 1967. N9; Шәрәфи Р., Мингалим Р. Эзләнүләр юлыннан: Батулла иҗаты турында уйланулар // Казан утлары. 1980. N8; Әхмәдуллин А. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**БАТЫРМОРЗАЕВ** Зәйнелгабид Нухай угылы (1897, хәзерге Дагъстан Респ-касы Аксай а. - 8.10.1919, Батайорт а., шунда ук), кумык язучысы, публицист.

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2005 ел, 4 санынан басылып килә.*

Язучы Нухай Батырморзаевның улы. Б.ның шәхес булып формалашуына татар кешесе – Исхак исемле университет белемле мөгаллим көчле йогынты ясый, аның киңәше б-н Б. Әстерхан һәм Казан мәдрәсәләрендә укый. Б.ның 1916-17 елларда язылган «Мәдрәсәгә мулла килде», «Муллаларга үч итеп», «Шамхал нүкәре» пьесаларында, «Даниялбәк» драмасында иске карашларга каршылык мотивлары өстенлек итә, тау халыкларында яшәп килгән кан үче, байлыгына карап кыз ярәшү кебек гадәтләр, социаль гаделсезлек тәнкыйтьләнә. Драматург буларак, Г.Камал иҗаты тәэсирендә формалаша. Туган авылында һәм Әстерханда укыган елларында аның «Бәхетсез егет», «Беренче театр» пьесалары буенча куелган спектакльләрдә уйнавы, соңрак драматургның «Гашыйк», «Безнең шәһәрнең серләре» пьесаларын кумык теленә тәрҗемә итүе мәгълүм. Б. инициативасы б-н «Безнең шәһәрнең серләре» тәрҗемәсе 1918 дә Тимер Хан-Шура шәһәре (хәзерге Дагъстан Респ-касындагы Буйнак ш.) театры сәхнәсендә уйнала. Шигъри иҗатында («Халыкка», «Халык мәнфәгатен яклаучыга» h.б. шигырьләр) Г.Тукай поэзиясенең тәэсире сизелә. Б.ның татар шагыйре С.Сүнчәләй шигырьләре турында язган кулъязма рецензиясе саклана.

Әд.: Алиев С. Дорога в современность. Махачкала, 1977; Акбиев С.-М.Х. Связи времен и дружба литератур. Махачкала, 1985.

*Р.К.Ганиева.*

**БАТЫРМОРЗАЕВ** Нухай (1869, хәзерге Дагъстан Респ-касы Аксай а.-8.10.1919, Батайорт а., шунда ук), кумык язучысы, мәгърифәтче, кумык реалистик прозасына нигез салучы, җәмәгать эшлеклесе. Гарәпчә, татарча башлангыч белемне атасыннан ала. Мәдрәсә тәмамлагач мөгаллимлек итә, аннары зәркәнче булып эшли. 1905-07 елларда Әстерхан, Оренбург, Казан шәһәрләрендә яши. Оренбургта «Вакыт» г-тасы редакциясендә, Казанда Кәримевләр матбагасында эшли, «Казан мөхбире» г-тасында языша. 1916-17 дә улы Зәйнелгабид б-н бергә Хәсәүйорты авылында «Таңчулпан» дигән әдәбидраматик түгәрәк оештыра һәм шул исемдәге журнал чыгара. «Язык Гъабибатъ» («Бәхетсез Хәбибәт», 1910), «Ръарун булан Зубайдат, яда Насипсиз Жанбике» («Һарун белән Зөбәйдә, яки Бәхетсез Җанбикә», 1912), «Давут булан Лайла» («Даут белән Ләйлә», 1914) исемле повестьлар авторы. Алар татар мәгърифәтчеләре М.Акъегетзадә, З.Бигиев, Р.Фәхретдин, З.Һади әсәрләре йогынтысында языла. «Кавказ һәм бөтен Русиядәге хәлләр» исемле поэмасында Г.Тукай поэзиясенең тәэсире нык сизелә. Б. әсәрләрендә татар язучыларын да тирән борчыган милли мәгариф, мөселман хатын-кызларның хокукый хәле мәсьәләләре күтәрелә. Большевиклар б-н элемтәләре өчен Б. улы Зәйнелгабид б-н бергә деникинчылар тарафыннан атып үтерелә.

Әсәр.: Батырмурзаев Н. Давут булан Лайла. Махачкала, 1965.

Әд.: Ганиева Р. Уртак кояшыбыз // Казан утлары. 1966, N 4; Дациев А. Нухай Батырмурзаев. Махачкала, 1968; Алиев С. Дорога в современность. Махачкала, 1977; Акбиев С.-М.Х. Нухай Батырмурзаев и татарские прозаики-просветители // Связь времен и дружба литератур. Махачкала, 1985.

*Р.К.Ганиева.*

**БАҺАВИ** (19 йөзнең 1 нче яртысы), шагыйрь, «Бүз егет» дастанының авторы. Шагыйрь турында кайбер мәгълүматлар дастанның үзендә очрый. Берничә урында ул үзен «бичара Баһави» дип атый. Проза б-н язылган кереш өлештә әсәрнең язылу тарихына да туктала: «Бүз егет» китабыны бер катар күреп идем, фарсы теле берлә язылмыш иде... Үземезнең күңелемез кайгылы көндә «Бүз егет» китабына кайгымыз түкеп... мең дә сикез йөз кырык икенче елында язып ирдек, Уфа илендә...» Шуннан башка автор биографиясенә кагылышлы бүтән мәгълүмат юк. Бер-берсенә гашыйк ике яшь кешенең фаҗигале язмышын романтик буяуларда сурәтләгән бу дастанның кульязма нөсхәсен Семипулат өязендә (Казакъстан) В.В.Радлов таба һәм үзенең «Көньяк Себер һәм Җөнгәр далаларында яшәүче төрки кабиләләрнең халык иҗаты үрнәкләре» («Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи», 1870) исемле хезмәтенең 3 нче томында бастырып чыгара. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан «Бүз егет» дастаны татар халкы арасында, ш.у. казакъ, нугай h.б. төрки телле халыкларда иң яратып укыла яки телдән сөйләнә торган әсәрләрнең берсенә әйләнә. Иң тулы дип исәпләнгән басмасы (К., 1984) РФА Көнчыгыш ин-тының С.-Петербург бүлеге фондында саклана торган кульязма нөсхәсе нигезендә әзерләнгән.

Чыган: Татар халык иҗаты. Дастаннар. К., 1984; Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Ч. 3. СПб.б 1870.

Әд.: Гайнетдинев М.В. XIX йөз татар әдәбияты тарихына яңа материаллар // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992.

*М.В.Гайнетдинев.*

**БАШКУРОВ** Рөстәм Шакир улы (16.5.1927, Горький өлкәсе, Сергач р-ны Камкино а. - 5.4.1967, Казан), әдәбият белгече, филол. фән. канд. (1958). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1950), 1950-60 нчы елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих интында фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре башлыча Г.Тукай тормышына һәм иҗатына, татар һәм рус әдәбиятларының багланышларына карый.

Хезм.: Тукай һәм рус әдәбияты. К., 1958; История татарской советской литературы (автордаш). К., 1965; Навсегда в сердце народа. (Жизнь и творчество Габдуллы Тукая). (автордаш). К., 1966.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблигр. словарь. К., 1970.

**БАШМАКОВ** Ибраһим Йосыф улы (1893, Пенза губ., Инсар өязе Үрләдем а. - 5.10.1913, Оренбург ш.), шагыйрь. «Галия» мәдрәсәсендә (Уфа ш.) укый. «Вакыт» г-тасында, «Шура» ж-лында хезмәттәшлек итә, шунда ук беренче шигырьләрен һәм тәрҗемәләрен бастыра. Аерым шигырьләре «Яңа әдәбият» (1914, төз. Г.Ибраһимов һәм Г.Баттал), «Көрәш җырлары» (1923, төз. Ф.Бурнаш) җыентыкларына, «Татар поэзиясе антологиясе»нә (1956, 1992) керә.

Әд.: Бәкер К. Ибраһим Башмаков (вафат) // Вакыт, 1913. 10 окт.; Мәрхүм шагыйрь (Яшь шагыйрь Ибраһим Башмаковның үлүе турында) // Аң. 1913. N20; История татарской советской литературы. М., 1985.

**БАЯН** (Баянов) Әхсән Фәтхелбаян улы (8.12.1927, хәзерге Башкортостан Респкасы, Илеш р-ны Әшмән а.), язучы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1988), ТР ның халык шагыйре (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1956). 1962 елга кадәр «Социалистик Татарстан» г-тасында хәбәрче, әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, 1962-66 да «Казан утлары» ж-лының җаваплы сәркәтибе, 1977-81 дә баш мөхәррир урынбасары вазифаларын үти. Әсәрләре 1950 елларда басыла башлый. Аның «Диңгез шавы» (1959), «Мират» (1963), «Әйт сүзеңне, яшьлек!» (1965), «Сез аңларсыз мине» (1971) китапларында тупланган лирик һәм фәлсәфи шигырьләрендә, балладаларында заманның, яшәешнең проблемалары чагылыш таба, шагыйрь җәмгыятьтә кешенең роле турында фикер йөртә. «Җәй - яшел кош» (1976), «Елларга сәяхәт» (1977), «Ак канатлар» (1983), «Кызыл ут» (1999) исемле шигырь һәм поэма җыентыкларында Б.ның замандашларының кичерешләре, яшәү мәгънәсе һәм аның матурлыгы, Туган иле һәм халкы, милләтнең үзбилгеләнеше өчен көрәше, рухи яңарышы һәм бәйсезлеге турында уйланулары. Аның «Дүрт монолог» (1968), «Аязучан болытлы һава» (1978) повестьлары күңел җылылыгы, лиризм б-н сугарылган. «Яшьлегемне эзлим» (1966, рус теленә тәрҗемәсе «Ищу молодость», М., 1971), «Тау ягы повесте» (1972, рус теленә тәрҗемәсе «Повесть Горной стороны», 1978), «Төлке тоту кыен түгел» (1975) повестьларында тормышта үз урынын эзләүче, халык традицияләренә тугрылык сакларга омтылган яшь кеше образы чагылдырыла. «Ут һәм Су» (1971), «Таш китап» (1981) романнары Кама буендагы гигант төзелеш картиналарын гыйбрәтле язмышлар аша сурәтләүгә, төбәкнең экологик проблемаларына багышланган. «Урланган ай» повесте өчен Б. Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек булды (1999). Б.ның прозасы романтик шартлылыгы, метафораларга һәм символик образларга бай булуы б-н аерылып тора. Б.ның драматургиясе дә үзенчәлекле. «Күзләре нинди иде» (1965), «Зәңгәр кыңгыраулар» (1972) психологик драмаларында хәзерге заман кешесенең әдәпәхлак проблемалары үзәккә алына. «Һәйкәл» (1970), «Алтын кашбау» (1989) трагедияләре тарихи вакыйгаларга нигезләнеп язылган. «Почёт Билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Әсәр.:Сайланма әсәрләр. 2 томда. К., 1993. Сайланма әсәрләр: К., 2002. 5 томда.

Әд.: Галимуллин Ф. Шагыйрьнең прозасы // Казан утлары. 1994. N5; Әхмәтҗанов М. Җирдә Прометей бар // Мәдәни җомга. 2000. 4 февр.; Мустафин Р. Человек и его дело // Литературное обозрение. 1979. N6.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

# "БЕР-БЕРЕҢЕЗГӘ ГЫЙЗЗӘТ КЫЙЛЫҢЫЗ"

"Җир яңара, җир яшәрә... өзелмичә, тукталмыйча, бөек Чулман кебек, Әтил кебек көн-төн җирдә тормыш ага" дип яза Нурихан Фәттах "Әтил суы ака торур" әсәрендә. Өзелмичә дәвам иткән тормышның бер тармагы — әдәбият та — тукталмыйча, иҗатлары инде тарихта калганнарның казанышларыннан, игелекле яшәешләреннән көч алып үсә. Яңара. XX гасыр башында һәм уртасында әдәбиятның алтын баганалары булып калыккан Нәкый Исәнбәт, Һади Такташ, Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир, Гадел Кутуйлар кормасын Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗевләр буыны алыштырды. Инде менә алар да, безнең кордашлар да, бакыйга күчтеләр. Күбесе — көндәлек аралашып, якыннан белеш булып яшәгән затлар... Янәшәдә чакта аларның зурлыкларын чамаласак та, иҗатларының мәгънәсе бөтен мөкәммәле, бөтен тирәнлеге белән аңланылмаган, шәхесләренең куәте тулы күзалланмаган.


*Уңнан сулга: И. Нуруллин, Н. Фәттах, таҗик язучысы Б. Хаданкаев. 1988 ел.*

"Еракка китеп кара син, еракка китеп кара", дигән шагыйрь. Араларында исемнәре әдәбият тарихында мәңге калырлыклары да бар икән бит. Шундыйларның берсе — Нурихан Фәттах.

Нуриханны мин университеттан ук беләм, бер чорда укыдык. Алар төркеме бездән бер ел алда бара иде. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылганга нибары 4 ел. Бүлек мөдире Рабига Афзал кызы Хәкимова — штатта торучы бердәнбер укытучы. Латиф Җәләй, Мөхәммәт Гайнуллин, Зиннәт Ишмөхәммәтев, гарәп теле укытучысы Дәүләтшә Сафин кебек галимнәр сәгатьләп эшлиләр, лекция укырга гына килеп йөриләр. Шуңа күрә бүлекнең иҗтимагый тормышын өлкән курс студентлары алып бара, сугыш дәһшәтләрен үтеп кайтканнар яшьрәкләргә, турыдан-туры мәктәптән килүчеләргә, җитәкчелек итә. Алар татар телен, әдәбиятын, халкын чиксез яратып, милләтне үстерүгә, киләчәген рухи көчләр белән тәэмин итүгә гомерләрен багышлаган фидакарь затлар булган икән. Әхмәт Юныс, Әхәт Нигъмәтуллин, Рәшат Гайнанов, Фазыл Фасеев, Ибраһим Нуруллиннар газета-журналларда язмалары күренгән яшьләргә хатлар язып шушы бүлеккә чакырып китергәннәр, университетның кабул итү бүлмәсендә торып, гариза бирергә килгән милләттәшләрен татар бүлегенә керергә димләгәннәр. Чөнки бүлектәге төркемнәр тулы түгел, аны аз беләләр. Мәсәлән, 4 нче курста 8 кеше, безнең 1 нче курста 13 кеше булды. Фазыл Фасеев үзе дә математика бүлегенә кергән җиреннән татар бүлегенә күчкән. Шуңа күрәдер, мөгаен, егәрлерәкләрне сайлап

алгангадыр, татар бүлегеннән чыкканнардан бик күпләр әдәбият, мәдәният, ижтимагый-сәясәт мәйданында күренекле урыннарны алып тордылар һәм торалар.

Бүлектә ижтимагый тормыш бик җанлы бара. Әдәби түгәрәк гөрләп эшли, стена газетасы чыгып тора. Нуриханнар группасы белән әдәбият түгәрәге утырышларында очрашабыз, "Әдәби сүз" исемле стена газетасыннан "әсәр"ләрен укыйбыз. Студентлык елларында Нуриханның зур язучы, чын язучы, галим-язучы булып китәсен, әлбәттә, без (һәрхәлдә мин үзем) сизмәдек. Аның ниндиерәк кеше икәнен дә озын колактан гына, аның белән бер төркемдә укучылардан гына ишеткәләдем: көндәлек алып бара икән, көндәлегенең тышына "копейка рубль бережет" дип язып куйган икән! Бусы инде Нурихан турында һич тә яхшы уйлар тудырмый. Без бит акча турында, дөресрәге байлык турында, уйлаудан читләштерелгән, эшкә урнашканда "хезмәт хакы күпме булачак?" дип сорарга ояла торган буын. Акча юк инде ул, кирәк инде ул. Күпләр өеннән бер тиен ярдәм алмыйча стипендиягә яши, вокзалда йөк бушатып ипилек юнәтә (мин үзем тегү тектем, китапханәдә эшләдем). Укып бетергәч, яхшы хезмәт хакы алып мул яшәрбез дип ышанабыз. Шул көч бирә. Бер яктан акчага омтылу оят санала, икенче яктан киләчәктә яшәеш яхшы тәэмин ителер дип өметләнәбез. Менә шундый ике төрле, ике аермалы иде безнең дөньяга караш. Русча "раздвоение личности" диләр моны. Тик без моның шәхесебезнең икегә аерылуы икәнен анламаганбыз. Ә менә Нурихан икейөзлеләнмәгән. Сакчыл яшәргә кирәклеген ачыктан-ачык әйткән. Авылда калган ялгыз анасыннан әлләни ярдәм ала алмаган Нурихан да һәр тиенне санап яшәгәндер. Ә бәлки ул бу шигарьне кинрәк итеп, бер минутыңны да бушка әрәм итмә дигән фәлсәфи ноктаи назардан чыгып билгеләгәндер? Алдагы яшәве шулай уйларга нигез бирә. Хикмәти акыллы кеше булып чыкты бит ул.

Нурихан ул, ничектер, тыныч һәм басынкы иде кебек. Аның җыелышларда чәчрәп чыкканын, сәхнәдә концертларда катнашканын хәтерләмим. Шулай да ул күпләр кебек эченә сенеп, югалып торган зат түгел иде. Шуңа күрә, гомуми уртачалыкка сыймый торган булганга, аның кайбер гамәлләре безгә дә килеп ишетелгәндер.

Соңыннан, олы тормышка чыккач, ул үзенчә яшәве, курыкмыйча үзе теләгән адымнарны ясавы белән безне гел гаҗәпләндереп торды. Гадәти нормага сыймый торган кеше икәне торган саен тулырак ачыла барды.

Ул елларда университетның татар әдәбияты һәм теле бүлеген тәмамлаучыларның шактые китап нәшриятына эшкә билгеләнде. Нурихан да хезмәт юлын шунда башлады. Мин "Татарстан яшьләре"ндә эшлим, юлыбыз кисешә, исәнләшеп йөрибез.

Аннары ул югалып торды. Чистайга газетага эшкә күчкән икән. Фатирсызлык сәбәп булгандыр, күрәсең. Менә бер вакыт хәбәр таралды: Нурихан бик яхшы роман чыгарган! Шаккатып сөйләшәбез. Университетны тәмамлаучылардан беренче булып роман язган! "Сезненчә ничек" дип атала. Ябырылып әсәрне укыйбыз. Бу бит безнең студентлык еллары турында, прототипларын да шәйлибез.

Әдәбият даирәсе дә әсәрне бик яхшы кабул итте. Минем хәтеремдә шулай сакланган. Хәзер романны кире кайтып укыгач, күрдем — студентлар тормышы фон гына икән, анда сүз мәхәббәттә тугрылык, әхлаклылык, хезмәткә мөнәсәбәт, гомумән намус турында икән. Шул замандагы студентлар һәм авыл тормышын, сабыр һәм чая, ялкау һәм эшчән кешеләрен җанлы килеш саклый торган музей шикелле тоелды миңа бу әсәр. Әлбәттә, әдәби әсәр тормышның нәкъ үзе була алмый. Ул тормышның иң әһәмиятле якларын алып гомумиләштерә. Әмма нигезе — чынбарлык. Хәзерге яшәештә исә андый студентлар, андый колхозчылар тудырырлык җирлек юк инде.

Минем хәтеремдә калганча, Нурихан Фәттах һәрчак гадәти булмаган гамәлләре белән җәмәгатьчелекне сискәндереп яшәде. Менә "чирәм җирләренә киткән икән" дип ишеттек. Күп тә үтми казакъның сөрелми яткан далаларына чирәм күтәрергә килгән меңнәрчә яшьләр яшәешенең рәсми чыганакларда булмаган, газета-журналларда әйтелми торган якларын сурәтләгән әсәр килеп чыкты. "Бала күңеле далада" исемле ул роман төрле һәм капма-каршы фикерләр тудырды. Ибраһим

Нуруллин аны тәнкыйди реализм әсәре дип бәяләде. Социалистик реализм хөкем сөргән чакта мондый бәя, әлбәттә, унай бәя түгел иде. Нуриханның кәефе кырылып йөргәндер-йөрүен, әмма ул Ибраһимга ачу сакламады гына түгел, хәтта дустанә мөнәсәбәттә калды. "Әтил суы ака торур" романына язган автографы моның дәлиле булып тора. Ул Ибраһимга хөрмәт билгесе булу белән бергә Нуриханның язучылар һөнәрен ничек аңлавын, бәяләвен күрсәтә. Шуна күрә аны тулысынча күчерәм.

*"Ярты гасырлык гомереңең яртысын кайгырып, борчылып һәм тир түгеп уздырган кордашым Ибраһим Нуруллинга. (Болары һәм азакта Ибраһимга гына аталган сүзләре кызыл кара белән язылган. Ә гомумән язучылык хезмәтенә караган сүзләр зәңгәр кара белән бәян ителгән, аерып куелган). Без, каләмнән, карадан, кәгазьдән башка яши алмаучылар, һәммәбез дә кайгырабыз, борчылабыз һәм иң яхшы вакытыбызны тир түгеп уздырабыз. Безнең барлык тырышлыгыбыз, кайгы-хәсрәтләребез һәм шатлык-кайгыларыбыз бары бер генә максатка — туган халкыбызга, әдәбиятыбызга, телебезгә хезмәт итүгә юнәлгән.*

*Киләчәктә дә кайгыру, борчылу, шатлану һәм тир түгеп хезмәт итү бәхетеннән мәхрүм булмавыңны теләп, чын күңелдән хөрмәт вә ихтирам белән: Нурихан Фәттах.*

*19 апрель 1973 ел. Казан".*

Бу хәл, ягъни тәнкыйтькә мөнәсәбәте, Нуриханның горур һәм хикмәти акыллы кеше булганын раслый. Ул үзенең иҗади җегәрен ачу саклап үч алу кебек мәгънәсез һәм гаять зарарлы гамәлгә түкмәгән.

Менә бервакыт тагын безнең исебезне алган хәбәр таралды. Нурихан йорт салган! Хәзергеләр өчен бу гаҗәп эш булмас. Әмма ул чакта! Без бит фатирны хөкүмәттән көтәбез, иңәләбез, ялварабыз. Димәк ул фатир сорап чиновниклар бусагасын таптап, гарьләнеп, түбәнсенеп йөрүгә вакытын һәм көчен сарыф итмәгән. Соныннан Нуриханның үзе һәм аның хатыны Руфина белән аралашканда беленде: башта өйнең бер өлеше, начармы-яхшымы сыенып яшәрлек кадәре, житкезелгән. Аннары берничә ел буе акрынлап, акча булган саен, вакыт мөмкинлек биргән саен эшләнгән икән. Нуриханның 70 яше уңаеннан "Республика Татарстан" газетасына мәкалә язганда мин аларга барган идем. Аның кечкенә генә эш бүлмәсенең диварларына идәннән түшәмгә кадәр китап шүрлекләре эленгән. Өстәле тәрәзәгә каратып, шүрлеккә аркасы белән утырып язарлык итеп куелган. Миңа ул дивар, ничектер, Нуриханны кысып, өстән басып торган шикелле тоелды.

—Бу китаплар өстеңә авып төшәр дип курыкмыйсыңмы, — дип тә сораган идем. "Бала күңеле далада" әсәреннән соңмы, аннан алдарак булган хәлдерме, тәгаен генә хәтерләмим, Нурихан турында тагын яңалык ишетәбез: Нуриханны Табеев өлкә комитетына чакырган икән дә, ул бармаган, минем анда эшем юк, миндә эше булса, үзе килсен, дигән икән. Еллар үткәч, Күктүбәдә бергә ял иткәндә, бу турыда сорагач, аның кәефе кырылды, зур ризасызлык белән: юк инде, арттыралар, ниндидер бер инструкторына чакырганнар иде, диде һәм, гомумән, ул турыда сөйләшәсе килмәде. Берәү булса, әйе, дип күкрәк кагып, мактаныр иде. Ә ул рәсми кешегә мондый җавап бирү тәрбиясезлек, мәгънәсезлек булыр иде дип санады.

Мондый арттыруда, бу легендада язучыларның хөрлеккә, шул куркытып, кысып торган обком дигән нәрсәдән котылырга, аның борынына чиертергә теләүләре, шуны булдыра алмаганлыктан газапланулары, хет ичмасам Нурихан сүзләре итеп йөрәкләрен басулары гәүдәләнә дип уйлыйм. Нуриханның шундый сүзләр әйтергә куәте житә дип санау бик табигый. Аның үзен иркен тотуы, түрәләр тирәсендә чәбәләнеп йөрмәве, бөтен яшәеше һәм иҗатының мәгънәсе менә жирлек, нигез бирә.

Нурихан әдәби хезмәтне күңел, хис эше дип кенә карамады. Иҗаты шулай уйларга куша. Аның әсәрләре авторының рәсемләү, сурәтләү сәләтенең зур икәнен күрсәтәләр һәм шуның белән бергә аның гасырлар тузанына күмелгән тарихтан хакыйкатьне бөртекләп җыючы, аңлатучы киң колачлы акыл иясе, галим икәнен дә белдерәләр.

"Әтил суы ака торур" романы татар әдәбиятында тарихи жанрны җанландырып җибәрүе белән генә түгел, безне борынгыдан борынгы балаларыбызның яшәешенә

алып керүе белән игътибарыбызны биләп алды. Аның сюжет жепләре, композициясе әсәрне аерыла алмыйча укый торган итеп корылган.

"Сызгыра торган уклар" исә тагын да ераграк тарихыбызны гәүдәләндерә. Без аны да ләззәтләнеп, уйланып, аерыла алмый укыдык. Нуриханның әсәрләрен бер укый башласаң, укып бетермичә аннан ычкына алмыйсың, аннары да кайта-кайта кулга аласың. Фәттахның болай ерак тарихка китүенең сәбәбе турында без еш бәхәсләшә идек. Тарихыбызның өйрәнелмәгән булуы, аны белмәвебез, узганны белмичә хәзергене аңлап булмый дигән караш тирәсендә сүз куера иде. Ә бәлки ул иҗатын, яшәешен рәсмияттән, рәсмият колы булган идеологлардан саклау өчен фикерләрен, дөнья барышын ничек аңлавын борынгы вакыйгалар, характерлар аша әйтергә теләгәндер. Ул бит совет чынбарлыгына мөнәсәбәтен үз заманы вакыйгалары аша үткәрә алмый иде. "Кичү" романының һәм "Кырык дүртнең май аенда" хикәясенең 1995 елда гына китап булып чыгуы шул фикерне дәлилли булса кирәк. Нурихан кебек үз юлы белән бара торган кеше һәрвакыт шик астында, аеруча күзәтү астында яшәде. Хатыны Руфинаның узган ел "Казан утлары" журналында чыккан истәлегеннән күренгәнчә, хәтта тарихи әсәрләрен дөньяга чыгару да шома гына, каршылыксыз гына бармаган.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар: фән дигән нәрсә, эзләнү, яңа фактларны табу һәм аларны аңлату ул кешене әсир итә, Нуриханның үзе әйткәнчә, "тир түгеп" табылган фактлар әйтеп бетергесез ләззәт бирә, яңа эзләнүләргә дәртләндерә. Нуриханның тарихи романнары да — гаять зур эзләнү һәм хезмәт нәтиҗәсе. Ул төркиләр тарихына караган төрле телләрдә, төрле чорларда язылган хезмәтләрне өйрәнеп чыккан, Себер, монгол далаларын гизеп үзенең геройлары яшәгән тирәлекнең торышын күзәткән, җилләрен иснәгән, тарихның саклап калган эзләрен күзәткән.

Ник, ни өчен күргән ул бу җәфаларны? Юк, тарихны өйрәнеп ләззәтләнү өчен түгел икән. Татар теленең бүгенге хәленә җаны әрнеп, миендә кайнаган сорауларга җавап табу өчен мөрәҗәгать иткән икән ул тарихка. "Шулай итеп, чыннан да, бетәрбез микәнни? Нишләп минем телем гасырлар буена сөйләшү өчен яраклы булган да, нишләп хәзер генә... яраксызга әйләнгән?... Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә... Икенең берсе — йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә... Мин көрәшергә булдым...

Барыннан да элек минем үз телемне, тарихымны беләсем, аңлыйсым килде. Кем булганбыз, без нинди булганбыз? Каян башлаган, ничек ялган безнең телебез?", — дип яза ул үзе "Шәҗәрә" китабының кереш сүзендә. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, "Шәҗәрә" ул чын гыйльми китап, төркиләр тарихына яңача карау кирәклеген раслый торган саллы хезмәт.

Нурихан Фәттахның тарихи жанрга өстенлек бирүен ничек аңлавымны бәян итеп, бераз читкәрәк киттем ахыры. Нурихан әсәрләрендәге көрәш ялкыны, Ватан кайгысы белән сугарылганлык сыйфатлары "Кол Гали" пьесасында аеруча көчле.

Бу пьеса буенча куелган спектакль безнең һушыбызны алды. Ул безне тетрәндерде, тарихыбыз, халкыбыз өчен горурлык һәм соклану хисләре уятты, милләтебезне бер чокылдан чыгуга икенчесенә төшерә торган комсыз, явыз һәм әшәке җаннарга карата нәфрәтне көчәйтте. Андагы "шагыйрь кол булмас, кол шагыйрь булмас" дигән сүзләр безнең күңелләрдә яшәгән, ләкин ачыктан-ачык әйтелә алмаган протест һәм нәфрәт хисләренең гәүдәләнеше булды, девизыбызга әверелде. Нуриханның Табеевка һәм шул чактагы совет рәсмиятенә җавабы менә шушы сүзләр дип беләм.

Нинди юбилее уңаеннандыр, 50 яшьлеге микән, Төзүчеләр сараенда тантаналы җыелыш булды. Шул мәҗлестә Нурихан тагын инде моңарчы урнашкан гадәтләрне тотмады. Ул мәҗлесне оештыручыларга кыска гына рәхмәт сүзе әйткәннән соң татар теленең хәле турында ачынып сөйләде, аны саклау, күтәрү, аш бүлмәсеннән эш бүлмәсенә чыгару өчен кирәкле чаралар тәкъдим итте.

Менә шушылай гел үз юлы белән баруы, сүзләренең, гамәлләренең аның шәхсән үзе өчен зарарлы булуына карамастан инанган иманын саклавы, көрәшүе, гаять

талантлы зур язучы, хөр холыклы, рәсмияткә баш бирми торган батыр кеше булуы өчен мин аны чиксез хөрмәт иттем. Әмма якыннан аралашканга кадәр мин аны көндәлек яшәештә дә унайсызрак, чәнечкелерәк, кырысрак кешедер дип уйлый идем. Якыннанрак танышуыбыз исә Кара диңгез буенда, Кырымдагы Күк түбә илендә (Коктебель) булды. Без алар белән анда ике тапкыр бергә ял иттек. Шунда Нурихан мине тагын бер тапкыр аптырашка калдырды. Ул башка язучыларга бөтенләй охшамаган булып чыкты. Мактану, һавалану ише нәрсәләрне, үзенчә ничектер аерымланырга тырышунын аңарда чаткысы да юк. Киресенчә, син мактый башласаң, ул сине сүрелдерә, туктата.

Хатыны Руфина белән мөнәсәбәте дә мин уйлаганча түгел икән. Алар бик дуслар, Нурихан хатынына басым ясамый, үзен өстен куймый, үзе турында кайгыртуны, хезмәт күрсәтүне таләп итми, анын иреген кысмый, ана карата бик игътибарлы. Без Нуриханның беренче хатыны белән бергә эшләдек, аннан ишеткәннәр буенча бу бер дә болай булырга тиеш түгел иде кебек.

Журналистикада шундый гадәт бар: берәр кеше турында язарга алынсаң, очрашканчы ук анын сурәтен, сыйфатламасын күңелендә тудырасың. Шунын белән чагыштырганда чынбарлык тулырак һәм тирәнрәк ачыла кебек. Нуриханнын көндәлек яшәешенең мин уйлаганча булмауы да аны ачыграк күрергә, тулырак аңларга ярдәм итте. Нуриханнын бәхете зур талантында һәм шул талантны эшкә җигәргә шартлар тудыручы хатынында дип беләм.

Руфина — гаять чибәр, акыллы, тигез холыклы якты хатын. Чүпрәк-чапракка мөкиббән китми, әмма зәвык белән киенә, табигатьне сөя. Һәм минем күзәтүләрем буенча, Нурихан Руфинаны чынлап яратты. Анын тышкы кыяфәте дә Нуриханга ошаган тип дип беләм. Руфинада үзен өстен кую, башкаларга мыскыллап карау кебек сыйфатлар юк. Ул — сабыр, унган, житез хатын. Үз өлкәсендә, медицинада, зур уңышларга ирешү белән бергә әдәбиятны да ярата һәм белә. Нурихан үзе Язучылар берлегенең төрле җыелышларына, чараларына йөрергә яратмый, анда анын "вәкаләтле илчесе" Руфина булды, хәзер дә ул язучынын истәлеген саклау юлында.

Диңгез буенда без Руфина белән бик тиз үз булып киттек. Ул да ташлар жыярга һәм тирә-якны гизеп йөрүне ярата икән. 50-60 нчы елларда Күктүбә пляжында сердолик, хак, гагат кебек ярым кыйммәтле ташларны таба идек. 80 нче елларда диңгезнең табигый яры юк иде инде, аны диңгез юып алып киткән. Хәзер гади ташлы ярда асылларын таба алмыйсың. Шуңа күрә Иҗат йорты күршесендә яшәүчеләргә барып электән җыелган ташларга карап хозурланабыз.

Һәркөн иртәнге аштан сон өчәүләп кая булса да бер якка чыгып китәбез. Нурихан да йөрергә ярата икән. Шул сәяхәтләрдә ул гаять тыйнак булды, үз теләген безгә такмый иде. Үзен безнең белән бер рәткә куя, аерымланмый. Вакыты белән шаярулы, вакыты белән җитди сүзләр сөйләп вакыт үтә. Дөрес, ул чакта инде Күктүбә илендә карап йөрерлек матур урыннар нык кимегән иде. Кара тау өстендә 18 метрга калкып торган "шайтан бармагы" кыясына да менә алмадык. Чөнки Кара тауга якын китермиләр, хәрби пост куйганнар. Изге тау куенындагы чишмәнең дә серле илаһи матурлыгы югалган, улаклар куеп анын суын аска төшергәннәр. Ләкин яр буйлап барып Кара тау астында диңгез эчендә утырган Алтын капканы күрергә була. Ешрак Хамелеон тавына барабыз, анын өстенә менеп җырлашып утырганыбыз хәтеремдә. Шактый биек тау сыртындагы Волошин каберенә менәбез. Шагыйрьне зиярат итүче һәркем бер чуер таш алып менеп анын каберенә куя. Без дә алып мендек. Тирә-якта коры кылганнар үсә, алар әле һаман миндә бер кечкенә вазада истәлек булып сакланалар. Ибраһим безнең белән йөрми, ул, гадәтенчә, иртәнге якта эш өстәле янында. Нурихан эшләмәде, бөтен вакытын ялга бирде кебек. Бәлки миңа гына шулай тоелгандыр...

Ашханәнең верандасында бер өстәлдә тәгам җыябыз. Сөйләшүләр, фикер уртаклашулар шунда бара. Әлбәттә инде, сүз үзебезне гел борчып торган тел, милләт, тарихыбыз, аерым шәхесләр турында. Нуриханнарның кемне булса да гаепләп, усалланып сөйләгәннәрен хәтерләмим. Бу мине тагын гаҗәпләндерде. Талантлы зур язучы булып та исеме гел кабатланып торган "обоймага" кермәве,

әсәрләренең зур мәшәкатьләр белән генә дөньяга чыгуы аларда үпкә-ачу тудырырга тиеш иде кебек. Юк. Нурихан күбрәк төрки шәҗәрә, Урта диңгез буенда яшәгән борынгы бабаларыбыз турында сөйләргә ярата иде. Аннары кичен тагын җыелабыз, бәхәсләшәбез, карта уйныйбыз, төнге диңгездә ялангач коенып рәхәтләнәбез. Башка язучылар белән дә аралашыла. Күбрәк "милли" дип атала торган, рустан башка халык вәкилләре белән гәпләшәбез. Үзбәк галиме Иззәт Солтан, таҗик Бобо Ходжаев, чәчән Мөхәммәт Мусаев шундыйлар иде. Кичләрен мәҗлесләр дә корыла. Анысына Ибраһимның инвалидлык кенәгәсе ярдәмгә килә. Ул елларда эчемлек табу гаять кыен иде бит.

...1988 — 1989 нчы еллар. Үзгәртеп кору заманы, бәхәсләр кызган чак. Берсендә исеме безгә мәгълүм булмаган ниндидер рус шагыйре Ленинны мыскыл итә, юкка чыгара. Без, Ленинны пәйгамбәр санап яшәгән кешеләр, моны кабул итә алмыйбыз. Нурихан да теге шагыйрь яклы. Кичен аларда утырганда тагын Ленин турында сүз китте. Катгый рәвештә аның тәгълиматын кире кагучы Нурихан белән бәхәс шул дәрәҗәгә җитте ки, Ибраһим пыр тузынып мине алып чыгып китте. Борчулы төннән соң иртән шигәеп кенә ашханәгә киләбез: аралар бозылмасмы, тәмсезләнмәсме?! Безнең кыяр-кыймас кына елмаеп килгәнне күргәч, алар да җиңел сулап куйдылар. Алар да эшнең зурга китүеннән куркып торганнар икән. Шунда мин дусларыбыз Гыйльмановлар белән булган шундый ук хәлне сөйләп, төнге икедә кире әйләнеп кердек, дигәч Руфина: "безгә дә кире кергән булсагыз иде, төн буе борчылып чыктык бит", диде. Бу вакыйга Нурихан белән Руфинаның киң күңелле, дустанә мөнәсәбәтләрне сакларга омтылучы, аларга сакчыл булуларын дәлилли. Шунда мин обкомның Нуриханны өнәмәве җәмәгатьчелеккә мәгълүм булса да, ана хәерхаһ кешеләрнең ни өчен күп булуын аңладым: ул үзенең иҗади эшендә пөхтәлек һәм сафлык саклаган кебек, тормышында, кешеләргә мөнәсәбәтендә дә гаять игътибарлы һәм гади булган. Үз фикерендә нык тора белгән, әмма карашлар төрлелеген үзара дошманлыкка әверелдермәгән. Аның яшәеше бер-беренә "гыйззәт кыйлунын" (Шәмсетдин Зәки сүзләре), ягъни бер-береннең кадерен белүнең үрнәге икән... "Нурихан — киребеткән кеше" дигән фикерләр бар иде. Иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә бу сыйфат принципиальлек дип яхшылардан саналса да, көнкүрештә унайсызлыклар да тудыргандыр. Монысын инде балалары һәм Руфина гына белә.

Ә бит ул чагындагы хакимият аның тормышын катлауландыру чараларын байтак күргән. Бер сөйләшеп утырганда мин аңа Ибраһим тирәсендә бушлык урнашуы турында әйткән идем, ул, бу махсус оештырыла, диде, минем тирәмдә дә вакыт-вакыт әллә нинди хатын-кызлар чуала башлый, сәер кешеләр килеп чыга. Ул моны бер дә исе китмичә генә, гадәти хәл турында сөйләгән кебек итеп әйтте. Әнә шулай, булып тора торган сәер һәм шикле хәлләргә фәлсәфи тынычлык белән карап яшәгән икән ул.

70 яшьлеген билгеләгәндә тикмәгә генә аны "әдәбият ханы" дип сәхнәгә күтәреп меңгезмәделәр.

...Нуриханнар китте... Алардан соң да җирдә "тормыш ага". Ул агыш әдәбиятка яңа көчле талантлар китерер, алар халкыбызның миллилек хисенә куәт өстәп, аны дөньяга танытырга сәләтле гайяр егетләр булырлар, үзләреннән алда яшәгән буыннарның намуслы мирасына тугрылыклы калырлар дип өметләник.

**Розалина НУРУЛЛИНА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

*Бу сәхифә—балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләргә.*

Илшат СӘЙФУЛЛИН

## ҮСМЕРЛӘР ӨЧЕН ШАЯН ХИКӘЯЛӘР

### Киллер

—Кызый, Вахиттан котыласын киләме? Менә дигән жаен таптым, синнән шоколад!—диде Ландыш янына чабып килгән Шәмсия, мыш-мыш сулап.

—Ике шоколад, барып кына чыксын,—диде яна хәбәргә куанган Ландыш кулларын чәбәкләп.

—Алайса болай,—дип сүз башлаучы кыз як-ягына каранып алды да, Ландышны беләгеннән тотып, мәктәп янында чыр-быр килгән бала-чага яныннан кырыйгарак алып киткәч, шыпырт кына сүз башлады:

—Сина, дустым, киллер ялларга кирәк.

—Син нәрсә? Акылдан шаштыңмы әллә? Вахитны бинукльле мылтыктан атып үтерергәме?—дигәндә Ландышның чәчләре үрә торып, күзләре шакмак булган иде.

—Кем әйтә сина мылтык белән дип? Тотып, синең янга бүтән якын килмәү шарты белән тукмап алалар да, бетте китте!

—Ә-ә-ә,—диде Ландыш бераз тынычлана төшеп,—тик Вахитны кем генә тукмар? Чын киллерларның чемоданлап акча алганын кинода күргәнем бар. Ул хәтле акча мина каян килсен?

—Төшенкелеккә бирелмә, мин бүген генә ишеттем—тугызынчыдагы Каюм бер тартма "Кока-кола"га мондый эшләрне башкарып чыга икән. Өч еллык гарантия белән. Аннары күз күрер. Әгәр дә риза булсаң, озакка сузмаска кирәк, бәйрәмнәрдән соң киллерның бәяне күтәрүе бар.

Кичке энгер якынлаша башлагач, кызлар сөйләшенгән урында очрашып, киллерның "офисына"—элеккеге колхоз гаражының ташландык кәтильниенә юнәлделәр. Тырнак астын үткен пәке очы белән чистартып утырган Каюм кызларга усал карап алуга, Шәмсия аның каршына Вахитның сурәтен ташлады.

—Кем бу?—диде киллер өч көпчәкле велосипедта кыска чалбар белән майкадан гына утырган малайның сурәтенә карап.

—Вахит ич!—диде Шәмсия.

—Мәктәпкә керер алдыннан төшкән фотосы,—дип өстәп куйды Ландыш.

—Нинди начарлыгы тиде инде сезгә бу егетнең? Жиденчедә укый ул, шәп малай, беләм мин аны... Ярар, җавап бирмәсәгез дә була, тик кайсыгызга комачаулый бу малай?—дип киллер өстәл өстендә яткан сурәткә очлы пәкесен китереп калады.

Шәмсия Ландышка төртеп күрсәткәч, Каюм:

—Сиңа ике-өч көн мәктәптә күренмәскә кирәк, шуннан соң Вахитың сина якын да килмәс,—диде.

—Гомер буенамы?—диде Ландыш аптырап.

—Кименда өч ел!

Кызлар зур сумкаларын калдырып киллерның офисыннан чыгып та киттеләр. Сөйләшенгәнчә, Ландыш өч көн мәктәпкә килмәде. Шул вакыт эчендә чынлап та Вахит аның кереп хәлен дә белмәде, аннары мәктәптә дә, урамда да кызга якын килмәде. Баштарак Ландыш Вахиттан котылу бәхетеннән күкләрдә очып йөрсә дә, тора-бара ана бик монсу була башлады. Иртән өеннән чыгышлый аны беркем

каршыламады. Физкультурада чаңгысын кияргә, дәресләрдән соң авыр сумкасын күтәреп кайтырга беркем булышмады. Дәрес вакытларында озын толымнарына кагылучы табылмады, андыйлар табылса да, алар аның чәчләрен Вахит кебек йомшак итеп түгел, ә авырттырып тарталар иде. Тәрәзәсенә кар ыргытып та Вахит аны урамга чакырмады.

...Кыз тәмам авыруга сабышты.

Икенче көнне әти-әнисе эшкә киткәч Ландыш киллерга шалтыратып, аны өенә чакырды да, алар арасында җитди сөйләшү булды. Җитди сөйләшү кичен киллерның офисында, Каюм белән Вахит арасында да башланды:

—Карале Вахит, ялгышлык килеп чыкты бит, малай. Хәтерлисеңме, Ландышның йогышлы авыру белән авырый башлавын, ана чит кешеләрнең кимендә өч ел якын да килергә ярамаганлыгын әйткән идем?

—Хәтерлим...

—Врачлар ялгышкан бит, малай, Ландышның хәле терелүгә бара...

Каюм сүзен әйтеп бетермәде, Вахит офистан чыгып та йөгерде. Ул-бу булмагае дип киллер да артыннан чапты.

...Ландыш тәрәзәгә йомры кар килеп бәрелгәненә уянып китте. Тәрәзәгә дә карамый урамга ыргылды, чөнки болай йомшак, матур итеп карны Вахит кына ыргыта белә иде. Яланөс йөгереп чыккан кызның иңенә малай тунын салды да, алар кире кызның өенә юнәлделәр.

Ерактан карап торган Каюм исә:

—Мин булмасам нишләр иде икән болар!—дип төкереп куйды һәм кесә телефоны чылтырауга офисына юнәлде. Чылтыратучы—түбән очтан Алия, сыйныфташы Эрнесттан ничек котылырга белми икән...

## Үрнәк малай

Дүртенче "Б"да классны җыештыру чираты бу атнада Рөстәм белән Гөлфиягә килеп җитте. Дәресләр тәмамлану белән, сыйныфташлары таралуга, Рөстәм алдагы өстәлгә менеп утырды да, эскәмиягә аякларын салып класстәшына дәште:

—Закирова, болай эшлибез, мин хәзер спортзалга барып киләм, бишенчеләр белән решающий матч бүген. Ә классны аннары бергә җыештырып бетерербез.

—Беркая бармыйсың, беләм мин синең кайчан спортзалдан киләсеңне,—дип кыз чиләкне шалт иттереп сыйныфташының алдына китереп куйды.

—Ярый, синенчә булсын, син идәннәрне юа башла, мин такта сөртермен,—дип малай чүпрәккә ябышты.

—Оста икән, идәннең яртысын мин юам, яртысын син, тактаның да яртысын мин сөртәм, яртысын син!

—Усал син, Гөлфия, характерыңны үзгәртмәсәң, Мөхәммәт сиңа гомереңдә дә өйләнмәс,—дип малай сыйныфташының авырткан җиренә басты. Кызларның бөтенесе диярлек Мөхәммәт янында бөтерелә бит. Ләкин Гөлфиянең исе китмәде бугай:

—Һе, кирәге бар,—дип кенә куйды.

—Мин дә синең кебек кызга мәңге өйләнмәс идем. Сиңа өйләнсәң менә хәзерге кебек идәннең яртысын мин юам, яртысын син ю, чәйнекнең яртысын мин кайнатам, яртысын син кайнат, дип тигезгә тиеп бетәрсең,—дип мыгырдана-мыгырдана малай акбур белән башта идәнне, аннары тактаны уртага бүлде дә, сиңа башка сүзем юк дигәндәй чүпрәккә ябышты.

Сыйныфташының соңгы сүзләре кызда көтелмәгән кызыксыну уятты.

—Рөстәм,—диде ул мөмкин кадәр йомшак булырга тырышып,—син чынлап та спортзалга бар әле, спорт—егетләргә кирәкле эш, ә мин монда үзем карый торырмын, әллә ни кыенлыгы юк бит, көн дә өйдә эшләнелә торган эшләр,—диде Гөлфия. Ул соңгы сүзне әйтеп бетергәндә, малайдан җилләр исеп, швабра идәндә аунап калган иде.

Малай хәле бетеп, тирләп-пешеп, бишенчеләрне җиңеп класска килеп кергәндә бөтен җир ялт иткән иде.

—Кайда йөрисен, мин әллә кайчан эшне бетердем бит инде,—дип, Гөлфия кулларын ике якка җәеп җибәрде.

Класс чынлап та ямьләнеп, балкып тора иде. Моны чәчләрен ике атнага бер генә тараучы Рөстәм дә күреп алды:

—Молодец, Гөлфия, унган да икәнсен үзен, синен белән класс җыештырулары үзе бер рәхәт,—диде ул мангаендагы тирләрен сөртеп.

Ул арада сыйныф җитәкчесе Зифа Мөнировна да килеп керде. Чиста, җыештырылган классны һәм тирләп пешкән Рөстәмне күргәч ул аптырап:

—Гөлфия, әллә Рөстәмне дә идән юарга өйрәттенме?—дип сорады.

—Әйе, Зифа Мөнировна, Рөстәм менә диган итеп идән юа белә икән, мине чиләккә якын да китермәде.

—Алайса Рөстәм, башка малайларга үрнәк булып, иданне иртәгә үзен генә юарсын, яме, ә кызларга башка эш табарбыз,—дип укытучы сөйләшүгә нокта куйды да, бик канәгать калып класстан чыгып китте.

Чәчләре үрә торган малай, бер Гөлфиягә, бер Зифа апасы чыгып киткән ишеккә таба карап, сулы чиләккә арты белән килеп утырганын сизми дә калды.

## Ярата—яратмый...

—Ярата-яратмый, ярата-яратмый,—дип Инсаф ромашка төлгәшләрен йолкыды да, соңгы төлгәшне өзгәндә, күкрәген тутырып һава алгач, "ул мине я-ра-та!"—дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды. Аның тавышы кайтаваз булып, урамны озак кына яңгыратып торды.

—Нигә акырасың, кем сине ярата?—дип сорады әллә кайдан гына килеп чыккан Гадел, каушап калган Инсафка сәерсенеп карап.

Хыял күгендә берүзе генә очарга күнеккән үсмер, Гаделнең килеп чыгуын көтмәгән дә, теләмәгән дә иде. Ул якында гына яткан йолкыш көчекне күрсәтте дә:

—Кем яратсын, әнә, Файл мине ярата,—дип көчекнен колак артыннан кашып алды. Көчек тә, җавапсыз калмады, "әйе, мин аны яратам" дигәндәй башта Инсафның яна ботинкасын, аннан битен ялап куйды. Гадел чигә тирәсендә бармакларын боргалагач, кулын селтәп китеп бармакчы иде, шул вакытта роликлы тимераякта Руфинә килеп туктады.

—Кем кемне ярата?—диде ул мыш-мыш сулап. Аның еракган ашыга-ашыга, яшен тизлегендә очып килүе әллә кайдан күренеп тора иде.

—Әнә, Инсафны Файл ярата, бу шуна шатлана,—дип шаркылдап көлгәч, Гадел үз юлы белән китеп барды. Никтер Руфинә житди иде:

—Ә сиңа беркем дә яратам дип әйтмәдеме?—дип ул усал карашы белән Инсафның күзләренә текәлде.

—Ю-у-у-к.

—Кара аны!—дип кыз бармагы белән янады да, роликларында урамны чыжылдатып китеп тә барды.

Ни әйтергә теләде икән ул? Ә нигә Инсаф берни әйтмәде? Үзе бит тирә-яктагы бөтен ромашкаларны йолкып бетерә язды. Йә ярата килеп чыга, йә яратмый. Шуңа да егет, тагын бер тапкыр ромашка алып, язмышын сынап карарга булды. Ниһаять! Икенче тапкыр рәттән Руфинә Инсафны Инсаф Руфинәне яраткан кебек ярата булып чыкты. Соңгы төлгәшне өзгәндә Инсаф тагын куанычын тыя алмыйча кычкырып җибәрде.

"Ярата, ярата" дигән сүзләр тирә-якка таралып югала барган саен, урамның икенче башыннан роликлар чыжылдавы көчәеп, Инсафка якынлаша иде.



*70 нче елларның өлкән әдипләре. Сулдан уңга: язучы Афзал Шамов, шагыйрь Әхмәт Исхак, тәнкыйтьче Гази Кашшаф.*



*Җырчы Миңгол Галиев (сулда), нәфис сүз остасы Әзәл Яһүдин, композитор Зиннур Гыйбадуллин. 1981 ел.*




*Татар музыка сәнгатенә хезмәт иткән шәхесләр: Зәйнәп Хәйруллина һәм Җәүдәт Айдаров. 1981 ел.*



*Кави Нәҗминең төрмәдә төшерелгән рәсеме. 1937 ел.*



*Сынчы-рәссам Әхсән Фәтхетдинов. Түбән Кама. 2001 ел.*



*Язучылар җыелышыннан бер күренеш. Сулдан уңга— Солтан Шәмси, Рөстәм Мингалим, Ләбиб Лерон, Газинур Морат. 1992 ел.*

## Наилә Вәлитова

Жор, үткен телле, сүзгә кесәгә керми торган кешеләргә гомер буе кызыгып, сокланып яшәдем мин... Ә бу юлы сүзем республикабызның иң абруйлы китап нәшриятында 30 елдан артык бергә эшләгән, шушы елның 15 мартында 60 яшен тутыручы хезмәттәшем, каләмдәш дустым Наилә Минһаж кызы Вәлитова турында. Ишле гаиләдә үскән, тормышның әчесен-төчесен шактый татыган Наилә туры сүзле, гаять уңган, ярдәмчел, кешелекле булуы белән дә аерылып тора.



1954 елда әтиләрен, утызменче буларак, Кукмара районыннан Әгерже төбәгенә—Иж-Бубый авылына—колхоз рәисе итеп билгеләгәннән соң Наилә шунда урта мәктәп, аннары Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлап Иж-Бубыйга укытырга кайта. Соңрак, язмыш җилләре Казанга илтеп ташлагач, Наилә Татарстан китап нәшриятына эшкә керә, лаеклы ялга чыкканчы шунда мөхәррир булып эшли.

Бергә эшләү дәверендә Наилә төпле белеме, телне әйбәт тоемлавы, рус телен дә "су кебек эчүе", таләпчән мөхәррир булуы белән танылды. Укучыларга, китап сөючеләргә йөзләгән китап редакцияләп, төзеп, халкыбызның олы әдипләре Мөхәммәт Мәһдиев, Нурихан Фәттах, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Фоат Садриев һ. б. бик күпләрнең әсәрләрен дөньяга чыгарышкан кеше ул Наилә.

Халкыбызга матур-матур тәрҗемә китаплары да бүләк итте ул. Күренекле рус язучы В. Распутинның "Онытма гомергә" ("Живи и помни"), Н. Думбадзеның "Мәңгелек канун" ("Закон вечности"), Э. Устинскийның "Крокодил Гена", А. Милнның атаклы "Винни Пух маҗаралары" һ. б. Наилә Вәлитова тәрҗемәсендә дөнья күрде. Аны 1989 елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул иттеләр.

Хәзерге көндә Наилә Татарстан Фәннәр академиясенең "Фән" нәшриятында мөхәррир булып эшли.

Матбугат өлкәсендәге хезмәтләре өчен Наилә Вәлитова 1994 елда Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Каләмдәш дустыбызны олы юбилее белән котлыйбыз!

**Фирая ЗЫЯТДИНОВА**

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ 100 ЕЛЛЫГЫ

***

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында шагыйрь, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган “Үлмәс җыр” исемле тантаналы кичә булды.

Юбилей кичәсенә Татарстан Хөкүмәте әгъзалары һәм Дәүләт Советы депутатлары, иҗат берлекләре һәм җәмәгать оешмалары җитәкчеләре, күренекле әдәбият-сәнгать һәм фән эшлеклеләре, якын һәм ерак чит илләрдән килгән кунаклар җыелган иде. Бәйрәмдә шулай ук Җәлилнең кызы Чулпан һәм оныклары катнашты.

Тантаналы кичә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең чыгышы белән ачылды.

Аннары Кыргызстанның халык язучысы, республиканың Бельгиядәге илчесе Чыңгыз Айтматовка сүз бирелде. “Йөз елдан ил җаны, ир җаны янара, диләр. Сезнең халыкка да янарыш заманы килде дип уйлыйм,—диде ул чыгышында. —Бу янарыш шагыйрь исеме белән, милли казанышка әверелгән кеше исеме белән дә бәйле. Татар халкының үзге исән, йөрәге дәртле булуны искәртә бу. Дөнья Муса Җәлилнеке кебек батырлык гәүдәләнешен бүтән белми. Шуңа күрә аның язмышын һәм иҗатын гомумдөнья яссылыгында карарга кирәк”.

Мәшһүр әдип үзенең чыгышы ахырында каһарман шагыйрь Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында заманча нәфис фильм төшерергә, дөньядагы төрки телле язучылар өчен Муса Җәлил исемендәге әдәби премия булдырырга тәкъдим итте.

Кичәдә шулай ук Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Россия Язучылар берлеге рәисенең беренче урынбасары Геннадий Иванов, Гессен университеты (Германия) профессоры Марк Кирхкнер чыгыш ясады. Соңгысы Җәлил турындагы сүзен немецча түгел, татар телендә әйтте.

Юбилей кичәсенең икенче өлешендә Татарстан сәнгать осталары концерты булды. Анда республикабызның танылган актерлары, җырчылары, шулай ук музыкаль һәм хореография коллективлары чыгыш ясады.

Тантаналы кичәдә Татарстан Премьер-министры Рөстәм Миннеханов һәм Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм башка рәсми кешеләр катнашты.

***

15 февраль, Муса Җәлилнең тууына нәкъ 100 ел тулган көнне Татарстан Республикасының Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе Оренбургта булды. Делегация составында Татарстанның халык шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, язучы-публицист Рафаэль Мостафин, Бөтендөнья татар конгрессы рәисе Ренат Закиров, Россия Җәмәгать палатасы әгъзасы Роза Туфитуллова һ. б. бар иде. Татарстан делегациясе Оренбург өлкәсе губернаторы А. Чернышев белән очрашты. З. Вәлиева билгеләп үткәнчә, бу очрашу ике төбәк арасындагы дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгытуда тагын бер мөһим этәргеч булып тора.

Иң төп чара—Муса Җәлилгә багышланган кичә—Оренбург филармониясенең концертлар залында узды. Анда Оренбург өлкәсе губернаторы һәм Татарстан делегациясе вәкилләре чыгыш ясады. Аннан соң Оренбург һәм Казан сәнгать осталары катнашында зур концерт булды. Театральләштерелгән бу зур концертның режиссеры Рифкать Исрафилов иде.

Татарстан делегациясе шулай ук Оренбург татар театры коллективы белән очрашты, шәһәр музее белән танышты.

***

Каһарман шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган кичә Әлмәт районының мәдәният йортында узды.

*Ничек әсир булсын илен сөйгән*
*һәм җыр ташып торган ир җаны?*
*Камерада яткан көе Муса*
*әсир итте үзе дөньяны.*

Әлмәттә яшәүче шагыйрь Нур Әхмадиевнең бу юллары әлеге тантаналы кичәнең рухына бик тә туры килде. Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, күренекле шагыйрә Клара Булатова, Әлмәт язучылар оешмасы җитәкчесе Зөфәр Дәүләтов катнашты һәм чыгыш ясады. Шулай ук бу кичәдә чыгыш ясаган шәһәр башлыгы урынбасары Василий Самойлов болай

диде: "Татар халкының батыр халык икәнлеген тарих битләренә язган Муса Җәлил һәр сәнгать, әдәбият әһеленә рухи кыйбла, аның тормышы һәм иҗаты яшьләрне тәрбияләүдә гүзәл үрнәк булып тора".

***

Юбилей тантаналары шагыйрь исемен йөрткән поселокта, ягъни Җәлил бистәсендә дә гөрләп узды. Шагыйрьне зурлау тантанасында Казаннан килгән зур делегация катнашты. Татарстан Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева җәлилчеләргә шагыйрьнең биш томлык әсәрләрен тәкъдир итте, аларның бу бистәдә быел туган һәр нәнинең әти-әнисенә тапшырылачагы турында әйтте. Алмаз Хәмзин төзегән сценарий буенча барган бу җыен киң колачлы, тирән эчтәлекле иде. Анда язучылардан—Берлек рәисе Илфак Ибраһимов, Рафаэль Мостафин, Мәдинә Маликова, Клара Булатова, Нур Әхмәдиев, Дамир Гарифуллин, Данил Салиховлар; артистлардан—Ренат Тажетдинов, Зилә Сөнгатуллина, Рафаэль Сәхабиев, Зөһрә Сәхабиева, Хәлим Җәләлов, Руслан Дәминовләр чыгыш ясады. Кичәдә, шулай ук, бу тантананың төп хуҗалары—Сарман районы муниципаль берәмлеге һәм "Җәлилнефть" идарәсе җитәкчеләре дә катнаштылар, халыкка үзләренең фикерләрен ирештерделәр.

## "ЛИТЕРАТУРНАЯ ГАЗЕТА"—ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА

"Литературная газета"ның февраль аенда чыккан санындагы "Литературный Татарстан" кушымтасы Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган "Батырлык шагыйре" дигән мәкаләсе белән ачыла.

"Җәлил татар әдәбияты тарихына батырлык шагыйре буларак кереп калды. Аның исеме югары исеменә әверелеп, чыдамлык, каһарманлык һәм Туган илгә тугрылык билгесе булды",—дип яза Республика башлыгы.

"Литературная газета"да дүрт битле мондый кушымта әле беренче тапкыр чыга. Биредә каһарман шагыйрьнең "Моабит дәфтәре" циклындагы кайбер шигырьләр урнаштырылган; совет әдәбиятының күренекле вәкилләре—Константин Симонов, Сөләйман Рөстәм, Сергей Смирнов, Борис Полевой, Олесь Гончар һәм башкаларның Муса Җәлил турында фикерләре урын алган. Шулай ук бу кушымтада Рафаэль Мостафин, Тәлгат Галиуллин, Лирон Хәмидуллин, Әмир Мәхмүдов мәкаләләре; Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Роберт Миннуллин, Ренат Харис, Гәрәй Рәхим, Мөхәммәт Мирза, Лилия Газизова шигырьләре; Туфан Миннуллин, Әхәт Гаффар, Фәкил Сафиннарның әсәрләреннән өзекләр белән дә танышырга мөмкин.

Җәмәгатьчелектә абруйлы саналган бу газетада киләчәктә дә бүгенге татар әдәбиятына багышланган мондый кушымталарны даими чыгару күздә тотыла.

## КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ ҖЫЕН ҖЫЙДЫ

10 февральдә Татарстан журналистлары өчен зур вакыйга булды: "Казан" милли мәдәният үзәгендә Журналистлар берлегенең XVII съезды булып узды. Анда катнашкан 102 делегат оешма алдында торган әһәмиятле мәсьәләләрне тикшерүдә катнашты.

Съезд эшендә Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин катнашты. Ул каләм осталарына Президент М. Шәймиевнең котлавын җиткерде. "Журналистлар берлеге һәрвакыт чын мәгънәсендә гражданлык һәм иҗат мәктәбе үрнәге булды. Хәзер, сүз иреге шартларында, безнең республиканың үсешен гаммәви мәгълүмат чараларыннан башка күз алдына да китереп булмый",—диелә анда.

Парламент җитәкчесе Ф. Мөхәммәтшин үз чыгышында илдәге сәяси курсның үзгәрүе шартларында журналистларга эшләве шактый кыен булуын искәртте. Әмма безнең каләм осталары бу авыр хәлдән лаеклы рәвештә чыга алды, диде ул. Спикер Җиңүнең 60 еллыгына әзерлек барган көннәрдә сугыш ветераннарының каһарманлыгына югары бәя бирүләре, дошманга каршы көрәшнең һәр этабын белеп яктыртулары өчен журналистларга рәхмәт әйтте. Казанның 1000 еллыгына әзерлекне югары дәрәҗәдә башкарып чыгуда да журналистларның өлеше зур булуын билгеләп үтте.

Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин республикабызның кайбер журналистларына "Казанның 1000 еллыгы истәлегенә" медален һәм "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исемнең дипломнарын тапшырды.

Съездда Журналистлар берлеге эшчәнлеге турында Журналистлар берлеге идарәсе рәисе, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова сөйләде. Өч ел ярым вакыт эчендә оешмада әгъза булып торучылар саны 890га җиткән, ягъни 270 кешегә арткан һәм иҗат берлеге яшь ягыннан да шактый "яшәргән" икән. Идарә җитәкчесе, иҗат оешмасы хезмәткәрләре буларак, журналистлар өчен социаль ташламалар булырга тиешлеген дә әйтте. 2006 елның Татарстан Президенты Указы нигезендә Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителүен ассызыклап, Р. Ратникова журналистларны әлеге уңайдан оештырыла торган барлык чараларда актив катнашырга чакырды.

Журналистлар съездында РФ Дәүләт Думасы депутаты Ә. Кармеев, РФ Җәмәгать палатасы әгъзасы Р. Туфитуллова, "Бөгелмә гәзите" мөхәррире В. Изергин, Россия Журналистлар берлеге идарәсе сәркәтибе

Н. Ажгихина, "Татмедиа" агентлыгы генераль директоры М. Моратов чыгыш ясады.

Делегатлар Татарстан Журналистлар берлегенен яңа Уставын кабул итте. Идарә рәисе итеп кабат Римма Ратникова сайланды.

## ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ ЯҢА ПРЕЗИДЕНТЛЫ БУЛДЫ

Татарстан Фәннәр академиясенең еллык гомуми җыелышы һәрчак зур вакыйга булып санала, чөнки анда республикабыз үсешенең мөһим мәсьәләләре карала. Ә быелгысы—чираттан тыш узганы—тагын бер ягы белән яңалык алып килде: анда президент алмашынды.

Фәннәр академиясенә оешкан вакытыннан бирле җитәкчелек иткән күренекле галим, академик Мансур Хәсәнов, сәламәтлегә какшау сәбәпле, вазыйфасыннан азат итүне сорап гариза язган. Чираттан тыш гомуми җыелыш аның үтенечен канәгатьләндерде. Фәннәр академиясе җыелышында катнашкан Президент Минтимер Шәймиев, Мансур Хәсәновның республикабызда фәнне үстерүгә керткән зур өлеше өчен рәхмәт әйтеп, аңа зур чәчәк бәйләме тапшырды.

Фәннәр академиясенең яңа президенты итеп бертавыштан академик Әхмәт Мәҗһаров сайланды. Ул—белгечлеге буенча химик, Балтач районының Сосна авылында туып-үскән, 1985 елдан бирле Идел буе углеводород чимала фәнни-тикшеренү институтының директоры булып эшли. Академик Ә. Мәҗһаров технологиясе нигезендә Россиядә газ, бензин һәм ташландык суларны чистарту буенча 35 махсус комплекс төзелде. Шундыйларның берсе Болгариядә дә эшли. Аның технологияләрен АКШ һәм Иран нефть компанияләре дә сатып алды.

Академик Әхмәт Мәҗһаров үз чыгышында республикабыз үсешенә ярдәм итәрдәй фәнни эзләнүләргә булышлык күрсәтәчәген әйтте.

Фәннәр академиясенең гомуми җыелышында Президент аппараты җитәкчесе Юрий Камалтынов, Премьер-министрның беренче урынбасары Равил Моратов, Федерация Советының халыкара мәсьәләләр комитеты рәисе урынбасары Василий Лихачев, экология һәм табигать ресурслары министры Ирина Ларочкина, мәгариф һәм фән министры Рәис Шәйхелисламов, Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев һ. б. катнашты.

## КОЛЛЕГИЯ УТЫРЫШЫ

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Казан дәүләт яшь тамашачылар театры бинасында булып узган киңәйтелгән коллегия утырышында 2005 елга йомгак ясауга һәм 2006 елга бурычларны билгеләүгә багышланган төп доклад белән Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева чыгыш ясады.

"Үткән елда республикабыздагы иҗат әһелләренең, иҗат оешмаларының бөтен көчләре Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә юнәлдерелгән иде. Бу бәйрәм республикабыз җитәкчелегенең милли һәм мәдәни мәсьәләләрдә дөрес сәясәт алып баруын күрсәтте һәм дөнья күләмендә зур вакыйгага әйләнде,—диде ул. —Бүгенге вәзгыять безнең алга яңа бурычлар куйды. Президентыбызның "2006 елны Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итү турында"гы Указын тормышка ашыру, олуг шагыйрьләребез Габдулла Тукай, Муса Җәлил, дирижер Натан Рахлин, композитор Александр Ключарев, җырчы һәм композитор Сара Садыйкованың зур юбилейларын, композитор Рөстәм Яхинның 85 еллыгын, татар театрының 100 еллыгын лаеклы рәвештә билгеләп үтү өчен безгә бөтен хыял байлыгыбызны һәм тырышлыгыбызны эшкә җигеп хезмәт итәргә кирәк..."—диде ул.

Фикер алышуларда Казан хореография училищесы директоры Т. Шахнина, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры директоры Р. Мөхәммәтҗанов, Татарстан Кинематографчылар берлеге рәисе Ю. Гвоздь һәм башкалар чыгыш ясады. Коллегия утырышында йомгаклау сүзе белән Татарстан Республикасы Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов чыкты. Ул үзенең чыгышында әдәбият-сәнгать вәкилләре алдында торган актуаль мәсьәләләргә тукталды.

Соныннан Рөстәм Миңнеханов җырчы Вил Усмановка "Татарстанның атказанган артисты" дигән мактаулы исем бирелү турындагы дипломны, С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залы ачылуга 10 ел тулу уңаеннан аның директоры Мансур Шиһаповка "Газель" һәм "УАЗ" автомобильләре ачкычлары, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Фарит Бикчәнтәев һәм "La Prmavera" камера оркестрының сәнгать җитәкчесе Рөстәм Абязовка әр-яңа фатир ачкычлары тапшырды. Бер төркем сәнгать әһелләре "Казанның 1000 еллыгы истәлегенә" медальләре һәм ведомство грамоталары белән бүләкләнде. 2005 ел нәтиҗәләре буенча авыл җирендә мәдәният хезмәтен иң яхшы җәелдерүче, әйдәүче район буларак, Почет билгесе һәм күчмә әләм Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлегенә тапшырылды.

## ИСКЕ ЯҢА МӨФТИ

Февральнең 20 сендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең III корылтае булып узды. Ул бик әһәмиятле мәсьәләне—алдагы елларда республикабызда кемнең мөфти булып калачагын ачыклады.

Диния нәзарәте рәисе урынына дәгъвалык кылучыларның берсе "Печән базары" мәчете имам-хатыйбы Габдулла хәзрәт Галиулла иде. Әмма тавыш бирү вакытында аны бары тик

19 делегат кына яклады. 511 делегат Госман хәзрәт Исхакыйны яклап тавыш бирде.

Бүгенге болгавыр заманда халкыбыз Диния нәзарәтенә, гомумән, дингә зур өмет белән карый. Бигрәк тә яшьләребезне азгынлык һәм һәртөрле бозыклыктан коткарып калуда, аларда дөрес әхлак тәрбияләүдә таяныч итеп саный. Бу яктан һәр татар авылында диярлек төзелгән мәчетләр чын мәгънәсендә рухи таянычка әверелсен иде, диләр бүгенге хәлгә борчылган кешеләр. Диния нәзарәте моны киләчәктә исәпкә алыр, дип ышанабыз, диләр алар.

Корылтайда мөфти хәзрәтнең беренче урынбасары итеп Вәлиулла хәзрәт Ягъкуб, Диния нәзарәтенең баш казые итеп Балтач районы имам-мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев сайланды.

Корылтай эшендә ТР Хөкүмәтенең беренче вице-премьеры Равил Моратов катнашып, мөселманнарыбызга Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең котлавын җиткерде.

## КОЛ ШӘРИФ МӘЧЕТЕНДӘ

Казан Кремлендәге Кол Шәриф мәчетендә Исламият музаханәсен ачу тантанасы булды. Тантана мәчет фойесендә җәмәгатьчелеккә “Алмаз-холдинг” җәмгыяте бүләк иткән Кол Шәриф мәчете макетын күрсәтүдән башланды. Ул көмештән һәм зөбәрҗәттән эшләнгән икән.

Мәчетнең беренче катындагы Исламият музаханәсе Мөхәммәд пәйгамбәрнең “Аллаһ күркәм һәм күркәмлекне ярата”, дигән хәдисе белән ачыла. Монда башкалабызда 1816 елда нәшер ителгән Коръән нөсхәләре, “Бакырган” кебек кульязма китаплар, XIX—XX гасырларда яшәп иҗат иткән дин әһелләребезгә кагылышлы фотосурәтләр, кулъязмалар, дәреслекләр урын алган.

“Музей киләчәктә тагын да үсәр, киңәер, баер. Аны баетуга күпләребез үзләреннән өлеш кертер”,—диде Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин.

Дөнья диннәре, пәйгамбәрләр тарихы, дини бәйрәмнәребез, бүгенге дини мәгарифнең, көндәлек матбугатның торышы турында да музаханәдә шактый мәгълүмат алырга мөмкин.

## РӘССАМНЫҢ ЮБИЛЕЙ КҮРГӘЗМӘСЕ

Казан Кремлендәге “Хәзинә” Милли сәнгать галереясендә күптән түгел үзенең 60 еллыгын билгеләп үткән Татарстанның халык рәссамы Виктор Аршиновның юбилей күргәзмәсе ачылды.

Рәссамның бөтен иҗади биографиясе Казан белән бәйле. Унике ел рәттән ул Татарстан Рәссамнар берлегенең җаваплы сәркәтибе булып эшләгән. Китап графикасы, плакат, сынлы сәнгать, скульптура, театр-декорация сәнгате белән шөгыльләнгән.

Соңгы вакытта рәссам монументаль графика серияләре өстендә эшли. Күргәзмәдә 100 биттән торган “Марина Цветаева истәлегенә” һәм Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган 110 битле “Соңгы җыр” серияләре куелган. Шунысын да әйтергә кирәк, үз вакытында Виктор Аршиновның М. Җәлил шигырьләре буенча язылган “Моабит дәфтәрләре” графика сериясе зур танылу алган иде инде.

Күргәзмәдә юбилярны Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева ихлас күңелдән котлады.

## ЯЗУЧЫ ХАҖИ БУЛДЫ

Быел Татарстаннан 700дән артык мөселман хаҗда булды. Алар арасында күренекле әдип, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим дә бар иде. Әдип хаҗга автобус белән Россия, Әзәрбайҗан, Иран, Төркия, Сүрия, Иордания, Согуд Гарәбстаны аша барды. Ул Мәккә һәм Мәдинә калаларының Әл-Харам мәчетләрендә, Мина, Гарәфәт, Мөздәлифә тауларында булып, хаҗ гамәлләре кылды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, Балык Бистәсе районындагы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге директоры **Гарифуллина Рәсимә Әхмәтзакир кызына** “Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исем бирелде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, хәзерге заман әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән өчен язучы **Паушкин Геннадий Александрович** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* **Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең «Казан утлары» журналы баш мөхәррире Равил Фәйзуллин белән очрашуы.** *11 февраль 2006 ел.*






КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)